ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Л.Х. Мөхәммәтҗанова**

# ДӨНЬЯ ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕНДӘ ТАТАР ДАСТАННАРЫ

Казан
2018

**УДК 398**
**ББК 82.3(2)**
**М 98**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре докторы, проф. **Ф.И. Урманчеев**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы **А.Х. Садекова,**
филология фәннәре докторы, доцент **И.Г. Закирова**

**Мөхәммәтҗанова Л.Х.**
**М98** **Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары** / Л.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 280 б.
ISBN 978-5-93091-264-7

Татарлар – халык иҗатының гүзәл әсәрләренә – дастаннарга бай халык. Билгеле бер чордан татар дастаннары кулъязмалар булып таралганнар, милләттәшләребез тарафыннан кат-кат күчерелгәннәр, ә китап басу чорында күп тиражлы басмалар булып дөнья күргәннәр, кулдан-кулга йөреп укылганнар. Үз телләрендә эпик иҗатның мондый төренә караган ядкарьләре булу белән дөньяда сирәк халыклар гына горурлана ала. Монографиядә милли эпос-дастаннар татар цивилизациясенең зур бер өлеше буларак күзаллана, авторның фәнни сүзе – татар дастаннарының дөньядагы эпос мирасында тоткан урыны хакында.

Монография төрки халыклар эпосы, фольклоры, әдәбияты, тарихы белән кызыксынучыларга адреслана.

**УДК 398**
**ББК 82.3(2)**

**ISBN 978-5-93091-264-7**

© Мөхәммәтҗанова Л.Х., 2018
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

# КЕРЕШ

Эпос – үз эченә киң тарихны, бик тирәндә калган борынгылыкны, чордан-чорга күчеп сыналган иң яхшы шигъри традицияләрне сыйдырган гаҗәеп катлам. Озын-озак яшәү дәверендә халык барлыкка китергән эпик әсәрләр рухи тормышта зур урын били. Халыкта эпос бар икән, аңа карап, халыкның үзен дә күзалларга мөмкин. Эпосның хәле-халәтен аның эчтәлегендә яктыртылган вакыйгалар гына характерламый, жанрның үзе кебек үк, бу мәсьәлә дә гаять катлаулы. Мондый ядкарьләрнең сакланышы, кайчан, кайда, кемнән язып алынганлыгы, таралыш формасы, әсәргә халыкның мөнәсәбәте, аның популярлыгы, башка эпослардан аермасы, милли үзенчәлеге, шул ук вакытта генетик, ареаль, типологик охшашлыклар, жанрның галимнәр тарафыннан өйрәнелү дәрәҗәсе – эпосы булган халыклар өчен болар – һәрвакыт көн кадагындагы бик мөһим сораулар, аларга ачыклык кертү актуальлеген беркайчан югалта алмый.

Дөнья фольклорында эпос – акциональ, вербаль һәм текстуаль кырлары булган иҗат төре, ягъни, гади генә итеп әйткәндә, бу – махсус хәрәкәтләр, интонация, стиль кулланып, билгеле бер тәртиптә башкарыла торган эпик жанр; тел-авыз белән әйтелә-сөйләнә торган сүз сәнгате һәм бербөтен текст буларак кабул ителә торган күләмле әсәр. Төрле халыкларның эпосы гаять төрле. Дөньядагы эпосларны хронологик тирәнлек һәм географик киңлек бизмәне аша карасак, аларда шушы өч кырның үсеш кимәле төрлечә булганлыгы күренә. Билгеле бер чорда кайбер халыкларның эпосында акциональлек өстенлек иткән, кайбер мәдәниятләрдә ул вербаль якның нык үскән

булуы белән алдыра, кайберләрендә исә текстуальлек алгы планга чыга. Хәлбуки, халыкта әдәби-мәдәни традицияләрнең тарихи формалашу характерына бәйле рәвештә, эпослы халыкларда шушы өч кырның кайсы да булса берсе нык үсеш алган була. Акциональ кыр өстенлек алган очракта эпос жанры архаиклыкны бөтен тулылыгы белән саклый, мондый иҗат хәрәкәт-йола элементларын да саклаган күләмле сөйләмә эпос барлыкка килүгә китергән. Язма культура һ.б. факторлар йогынтысын кичергән эпос исә акциональ һәм беренчел вербальлектән ераклашкан.

Нәкъ менә язма культура йогынтысында трансформация кичереп формалашкан эпоска мисал дөнья фольклорында бихисап, халык иҗатында мондый төрнең формалашуы Урта гасырларга ук туры килә. Борынгы Һиндстанның классик эпопеяларыннан алып Урта гасырларның соңгырак чоры һәм хәтта Яңа заманга караган текстларны галимнәр шушы категориядә карый. Хронологиясе гаять тирән булган кебек үк, китап культурасы һәм кулъязмачылык белән тирән керешкән эпосның географиясе дә шактый киң – Көньяк-Көнчыгыш Азиядән алып Төньяк Африка һәм Скандинавиягәчә дип билгеләнә. Эпосның акциональлектән һәм сөйләмә харктердан бераз читләшкән, язма фольклор төшенчәсен барлыкка китерүдә зур роль уйнаган әлеге специфик төрендә фольклор һәм әдәби традицияләр үзара тыгыз бәйләнгән, хәтта чуалып беткән була.[1]

Татарлар – шулай ук дастанлы халык. Татар эпос-дастаннары дигәндә иң беренче чиратта китаби дастаннар алгы планга чыга. Идел буе татарлары халык иҗатының чын мәгънәсендә таҗы булган әлеге гүзәл әсәрләр төрле вариантта үз заманы өчен бик тә популяр булган. Бөек Тукай сүзләре белән әйткәндә, боларны «кечкенә чагында укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер»[2]. Гомумтөрки һәм дөнья эпосы яссылыгында татар халык дастаннары мәсьәләсе – халыкның рухи мирасын өйрәнү кысаларында гына кала алмый, ул – дөньякүләм эпос өйрәнү фәнни проблемасы да.

«Түләк», «Бүз егет», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Гыйсә улы Амәт», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Каһарман Катил», «Кисекбаш кыйссасы», «Чура батыр хикәяте», «Күр углы

---

[1] *Рифтин Б.Л.* Историческая эпопея и фольклорная традиция в Китае (Устные и книжные версии «Троецарствия»). 1970. 482 с.

[2] *Тукай Г.* Әсәрләр 4 томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 279.

Солтан» кулъязмалары яисә басмалары, ике гашыйкның мәхәббәт тарихын бәян итүдән гыйбарәт романтик рухлы «Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн» нөсхәләре, «Идегәй» («Идегә»)нең Нигъмәт Хәким һәм Нәкый Исәнбәт исемнәре белән мәгълүм җыйнама-тәнкыйди текстлары һ.б. – болар татар китап культурасын үстерүгә зур йогынты ясаган, язма әдәби-мәдәни процессны тагын да югарырак баскычка күтәрүдә әһәмияте бәяләп бетергесез гүзәл дастани мирасыбыз үрнәкләре. Бу әсәрләрнең татар телле иң камил, иң төзек вариантлары язмага теркәлеп, кулъязма нөсхәләр яисә китапка әверелеп таралган. Авторлы әдәби дастаннардан һәм импровизатор иҗаты булган традицион сөйләмә дастаннардан аермалы буларак, мондый төр эпоска карата фәндә «китаби дастан» төшенчәсе кулланыла. Бездә язма-китаби дастаннар барлыкка килү тенденциясе, эпик иҗатның мондый төренә омтылыш борынгыдан ук килә. Сюжет, тематикасы буенча кулъязма һәм хәтта китап булып басылган дастаннарның формалашу тарихын һәм таралуын Урта гасырлар ахыры һәм аннан соңгы чор дип билгеләү гадел булыр. Казан татарларында китаби дастаннарның һәркайсының халык тормышында урын алуының үз юлы, иҗтимагый-тарихи сәбәпләре бар.

Китапларга мөнәсәбәттәге фәнни теориядә «кулъязма китап»[1] дип аталган үзенчәлекле шартлы термин бар. «Кулъязма китап» сүзтезмәсе төрле өлкәгә караган төрле жанрдагы чагыштырмача күләмле язмаларга карата кулланыла. Кулъязма китап дип аталуның иң алгы планда тора торган шарты – текстның билгеле бер эзлеклелектә кулдан язылган һәм, китап рәвешенә китереп, төпләнгән булуы. Казан татарлары – Идел буе Болгары чорында һәм аннан да алдарак формалашып, соңрак Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында ныгыган язма культура варислары. Мең еллык язма мәдәнияткә ия халыкның китап культурасы югары булу – табигый хәл. Китаплы булу халыкның барлык өлкәсенә бик зур тәэсир ясаган, шул исәптән халыкның тел-авыз иҗаты саналган традицион сүз сәнгате дә язмачылыктан читтә кала алмаган. Бу күренеш фольклористикада

---

[1] *Каримуллин А.Г.* У истоков татарской книги. Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. С. 32 33; *Госманов М.* Гасырдан – гасырга. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. С. 76, 78–79; *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.

язма формада барлыкка килгән һәм кулъязмалар булып таралган эпос-дастаннарга мөнәсәбәттә кулланыла торган «татар китаби дастаны» терминының килеп чыгышын һәм мәгънәсен аңлауны җиңеләйтә. Кулъязма китаплы мәдәният шартларында барлыкка килгән мондый төр дастаннар безнең көнннәргә борынгы кулъязмалар, соңрак басма китаплар булып килеп ирешкән.

Язма әдәби-мәдәни процессларның татар халык иҗатына, аерым алганда дастан жанры формалашуга йогынтысы бик зур булганлыгы бәхәс уятмый. Татар басма китабының тарихы академик Ә. Кәримуллин хезмәтләрендә бәян ителсә[1], кулъязма китапка мөнәсәбәттә галимнәребез М. Госманов[2], М. Әхмәтҗанов[3] һ.б. саллы хезмәтләрен багышладылар. Татарның бик борынгыдан килә торган кулъязма китабы да, XIX гасырның башыннан дөнья күрә башлаган тулы канлы милли басма китабы да – мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнү өчен үтә кыйммәтле чыганак. Татарларның кулъязма һәм басма китабы бик бай һәм зур тарихка ия. Китап тарихын, бигрәк тә меңәрләгән кулъязма китапларны өйрәнү иң элек кулъязма материалны туплаудан башлана. Казанда Татарстан Фәннәр академиясе, Милли китапханә, Казан федераль университеты, Милли архив һ.б. фәнни үзәкләрдә татар кулъязма мирасын җыю-туплау һәм аның сакланышын тәэмин итү юнәлешендә максатчан эш алып барыла.

Татар халкының язма-китаби дастаннары дигәндә игътибар үзәгенә казан татарлары эпик иҗаты чыга. Мәгълүм булганча, казан татарлары – безнең халыкны тәшкил итә торган зур этник төркемнәрнең берсе. Әлбәттә, халык иҗаты әсәрләренә карата мондый аерымлау шактый шартлы, чөнки эпик һәм лиро-эпик әсәрләр арасында бер милләтнең төрле төркемнәре өчен генә түгел, берничә халык өчен бердәй уртак сюжетлылары билгеле. Билгеле сюжетка

---

[1] *Каримуллин А.Г.* У истоков татарской книги. Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. 223 с.; *Каримуллин А.Г.* Татарская книга начала XX века. Казань, 1974; *Каримуллин А.Г.* Татарская книга пореформенной России. Казань, 1983; *Каримуллин А.Г.* Из истории печатного слова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1984; *Каримуллин А.Г.* Книга и люди. Казань, 1985 һ.б.

[2] *Госманов М.* Гасырдан – гасырга. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 488 с.; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000, 270 с.

[3] *Әхмәтҗанов М.И.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

кардәш халыкларда традицион дастан сөйләнеп, бездә шул ук сюжетка язма-китаби дастан формалашкан булырга мөмкин.

Кулъязма һәм басма китапларга теркәлгән эпик иҗат – нигездә Идел буенда яшәүче казан татарларына хас милли үзенчәлекләрне үз эченә алган, шуларның икътисади һәм мәдәни үсешенә ярашып формалашкан, татар халкы дастани байлыгының иң зур өлешен биләп торган әсәрләр. Хакыйкатьтә халык иҗатындагы язма характерлы дастаннар татарларның урта диалектта сөйләшә торган ареалын гомумән били. XVII гасырдан башлап Идел буе татарларының Көнбатыш Себергә күпләп күчеп утыруларын исәпкә алганда[1], казан татарларының себер татарлары культурасына, шул исәптән фольклорына да ныклы тәэсирен күзаллау кыен түгел. Шуңа күрә язуга теркәлгән дастаннар традициясенең географиясе дә безнең чорга якынлашкан саен киңәя төшә. В.М. Жирмунский билгеләп үткәнчә[2], соңгырак чор төрки эпосына авыз иҗатыннан язмага күчә бару тенденциясе гомумән хас.

Хәзерге татарлар составындагы төп этник төркемнәрнең һәркайсының борынгы бабаларын Алтын Урда дәүләте хакимлеге берләштергән. Шулай булса да, бу әле бер үк дәүләт составына кергән, бүген бер милләт булып яшәүче татарларның һәрбер этник төркемендә тормыш-яшәү рәвеше, икътисади һәм мәдәни үсеш шартлары бердәй булган дигән сүз түгел. Идел буе, ягъни казан татарлары яшәешендә һәм гореф-гадәтендә зур рольне соңрак Алтын Урданың бер өлешенә әверелгән, әмма күпмедер дәрәҗәдә үзенең мөстәкыйльлеген, төгәлрәк әйткәндә, үз йөзен, үзенә генә хас колоритын саклап кала алган Болгар дәүләте үтәгән.

Ә Идел буе Болгары борын-борыннан үзенең утрак тормыш алып баруы белән мәгълүм. Биредә утрак тормыш Урта гасырга хас калалары, һөнәрчелек һәм халыкның җир эшкәртеп яшәве, тышкы һәм эчке сәүдәсе белән данлыклы. Идел буе Болгар дәүләтендә безнең бабаларның үз язу системасы җайга салынган, язма әдәбият югары дәрәҗәгә җиткән, гуманитар гыйлемнәр тармагы шактый зур үсеш алган булган. XIII гасыр башында биредә атаклы шагыйрь Кол Галинең мәгълүм сюжетка иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы

[1] История Сибири. Т. 2: Сибирь в составе феодальной России. Л.: Наука, 1968. С. 56.

[2] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 117.

үзе генә дә – биредәге җирле халыкта язма әдәби телнең, әдәбиятның ни дәрәҗәдә югары торганлыгына кире каккысыз дәлил. Мондый зур әдәби талант фәкать үзенә кадәр һәм үз чорында булган бай язма традицияләр җирлегендә генә туа ала.

Чыннан да, Идел буе Болгары, соңрак Казан ханлыгы ул – чал гасырлардан ук элгәрләренең язма иҗат традицияләрен үз чоры тормышына китереп җиткерә алган, алга таба үз мәдәниятенең төрле тармакларын язмачылыкка нигезләп үстергән һәм шуларның бәрәкәтле нәтиҗәсенә ирешә алган, язма иҗатка, фәнгә һәм гомумән китапка ихтыяҗы һәм ихтирамы феномен дәрәҗәсенә җиткән төркиләр – татарлар төбәге. Казан ханлыгы оешканга кадәр Алтын Урда составында яшәгәндә дә бу төбәк дәүләтнең үзәге саналган һәм шәһәр тормышы зур үсеш алган Алтын Урданың әлеге уңайлы территорияләре аеруча алга киткән булган. Дәүләтнең икътисади үсеше закончалыклы төстә рухи үсешкә – китап культурасына этәргеч биргән. Урта Идел татарлары иҗатында дастаннарның китаби төре формалашу һәм ныгып урнашу язма әдәби-мәдәни процессларның логик дәвамы булып күзаллана.

Язулы һәм дәүләтле халыклар эпосының язмышына карата Х.К. Короглы түбәндәгечә яза: «Язулы борынгы халыкларның (фарсы, һинд һ.б.) күбесендә эпос, язуга күчерелү белән үк, сөйләмә формада яшәүдән туктаган, чөнки дастан әйтүчене (сказитель) кыйссахан (чтец) алыштырган һәм ул авыл һәм шәһәрнең озын кичләрендә шул ук эпосны үзе «канунлаштырган» формада халыкка укып бирә торган булган. Шәһәр һәм авыл культурасы югары утрак тормышлы иранлылар, һинд, греклар,тарихи үсешләренең билгеле бер чорында, телдән башкарыла торган эпоска караганда язма эпосны кулайрак күреп, тулысынча язма эпоска күчкәннәр»[1].

Күп гасырлык язма мираска ия татарларда да эпик иҗатның язмышы әлеге закончалыкка шактый тәңгәл. Дөрес, гәрчә халыкта бик киң таралыш алган кайбер дастаннарыбызның кыскача эчтәлеген я булмаса бер өзеген көйләп-сөйләп бирү фактларына юлыккаласак та, хәтта кыйссачылар да Идел буе татарларында әллә ни популяр булган дип әйтә алмыйбыз, аларны кыйссачы яисә кыйссахан дип атау да гадәткә кермәгән. Моның сәбәпләре күләмле эпик әсәрнең язма культура белән кисешүеннән килгәнлеге ачык аңлашыла.

[1] *Короглы Х.Г.* Огузский героический эпос. М.: Наука, 1976. С. 114.

Шулай ук Болгар дәүләтендә әле X гасырга кадәр үк кереп ныгыган ислам дине дә, телдән башкарыла торган иҗатка карата халыкның игътибарын шактый киметеп, язма сүзгә һәм китапка ихтирамны бермә-бер арттыруга этәргеч ясаган. Бу исә үз чиратында дастаннарыбызның халыкның үзе тарафыннан ук язуга күчерелүенә, ягъни китабилашуына, алай гына да түгел, гарәп-мөселман язма чыганаклары йогынтысында Идел-Чулман буе татарлары иҗатында әдәби чыгышлы дастаннарның өр-яңа язма милли версияләре таралуга китергән. Монда беренчел чыганакның язма булуы да, Идел буе татарларында эпик фольклорда әсәрне телдән башкаруга караганда язмага әверелдереп тарату калыбы камилләшкән булу да үз ролен уйнаган.

Халыкның язмача иҗат ителгән эпосы татарларда дастаннар белән генә дә чикләнми. Әйтик, бәетләр, нигездә шәкертләр һәм укымышлы муллалар тарафыннан язылып, халыкта язмача һәм телдән тарала торган булганнар. Бу үзенчәлеккә XIX йөз ахырында К. Насыйри һәм шул турыда язып чыккан Н.Ф. Катанов әһәмият биргән. Бу хакта галим болай ди: «К.Насыйров сүзләренә караганда, бәетләр чыгару белән мәдрәсәдә, мөселман урта мәктәпләрендә укучы яисә укыган гадәти яшь егетләр, ә кайвакыт мөселман гыйлеме белән таныш булган карт-коры мавыга»[1].

Халыкның уку-язу белән турыдан-туры шөгыльләнүче катламы даирәсендә туган иҗатның язуга теркәлүе гаҗәп түгел. Чыннан да, халыкта шактый актив яши торган бәетләрнең яшәү формасы әле бүгенге көндә дә текстны кәгазьгә язып кую традициясеннән аерылгысыз. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдбият һәм сәнгать институты тарафыннан татарлар яши торган төрле төбәкләргә (әйтик, Татарстан районнары, Самара, Чиләбе, Оренбург, Әстерхан өлкәләре, Пермь крае һ.б. төбәкләрдәге татар авылларында) оештырылган фольклор экспедицияләрендә тупланган тәҗрибәдән чыгып фикер йөрткәндә, информант, бәет текстын хәтердән яхшы белсә дә, кагыйдә буларак, аны һәрвакыт дәфтәр битенә – язуга төшергән була, текстны тыңлаучыга язудан көйләп укып җиткерә.

---

[1] *Катанов Н.Ф.* Исторические песни казанских татар. Казань: Тип. Имп. ун-та, 1899. С. 3.

Бәет жанрының килеп чыгышы, формалашуы һәм үсеше мәсьәләләренә киң тукталып, Ф.И. Урманчеев түбәндәгечә яза: «Ничек кенә булмасын, әле XX гасыр башында һәм утызынчы елларда ук бәетләрнең язмача һәм телдән барлыкка килүе һәм таралуы ачык билгеләнгән иде. Бәетләрнең иҗат ителүендә һәм таралуында мәдрәсә шәкертләренең роле зур булу белән бергә биредә Урта Идел татарларында мәгърифәт һәм грамоталылыкның бик киң таралган булуын да күздә тотарга кирәк. Мондый шартларда әсәрнең нинди формада иҗат ителүе асылда принципиаль әһәмияткә ия түгел»[1]. Чыннан да, Идел буе татарларында мәгърифәт һәм грамоталылыкның фольклорның кайбер жанрларына тирән йогынтысы, милли-мәдәни менталитетка тәэсир итеп, халык иҗаты процессына әһәмиятле үзгәрешләр керткән булуы бәхәссез.

Фольклорның эпик жанрларында беренчел текст ул – әсәрнең чичән авызыннан турыдан-туры язып алынганы, вербаль чыгышның аутентик рәвештә кәгазьгә төшерелгәне. Безнең көннәргә якынайган саен мондый текст белән очрашу мөмкинлеге кыенлашканнан кыенлаша бара, чөнки гасырлар буена барган китап культурасы халыкның тел-авыз иҗатына сыйфат үзгәрешләрен шактый тирән һәм масштаблы кертә килгән. Төрки телле халыкларның саф фольклор әсәрләрен, ягъни «тере» эпик текстларны системалы рәвештә туплаган чыганак дип, әйтик, В.В. Радлов тарафыннан төзелгән «Образцы народной литературы тюркских племен» җыентыгын[2] атый алабыз. XIX йөзнең 60 нчы елларыннан алып XX йөз башынача дөнья күргән бу фундаменталь җыентыкта үзбәк, каракалпак, төрекмән халыкларыннан кала барлык төркиләрнең дә фольклор әсәрләре турыдан-туры, икенче төрле әйткәндә, ничек сөйләнгән, шул рәвешчә чагылыш та тапкан. Әлеге томнарның фольклористикада төрки эпосны һәм фольклорны фәнни нигезгә куйган беренче хезмәт буларак танылуы һәммәбезгә дә мәгълүм. В.В. Радлов бастырган томнардагы текстлар – беренчел чыганакка турыдан-туры нисбәтле, кириллицада диактрик билгеләр белән фонетик транскрипциядә бирелгән оригинал язмалар.

---

[1] *Урманче Ф.* Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: Основные проблемы изучения баитов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. С. 14.

[2] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен. Ч. I–X. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1866–1907.

Казакъ халык поэзиясен тирәннән белүче һәм аны җыючы мәшһүр Ч.Ч. Вәлихановның XIX йөз урталарына караган эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак туган җыентыклар[1] да реаль фольклорның беренчел текстларыннан гыйбәрәт бик әһәмиятле чыганак дип бәяләнергә хаклы. «Идегәй» эпосының ул язып алган казакъ һәм нугай версияләре, кыргыз «Манас»ыннан шактый зур фрагмент үзе генә дә –вербаль фольклор белән туры контакт ядкарьләре.

Н.Ф. Катанов җыйган һәм бастырып чыгарган[2] хакас фольклоры үрнәкләрен, Ә.Ә. Диваев[3] туплаган казакъ һәм каракалпак эпосын, себер татарлары фольклорындагы Г.Н. Потанин игътибар иткән «Ак Күбәк», «Йир Төшлек» һәм «Түләк» эпосының сөйләмә башкорт версиясен, 1942 елда казакъларның Морын-жырау Сенгирбаев исемле акыннарыннан язып алынган атаклы «Кырык батыр» циклын, кыргыз эпопеясының Сагымбай Орозбәков, Саякбай Каралаев һ.б. вариантларын, һәм шулай ук эпик иҗат буларак Идел-Урал территориясендә А. Киреев, Х. Ярми әһәмият биргән халык әкиятләрен шикләнмичә халык эпосының тулы канлы беренчел текстлары дип санарга җирлек бар. Хәтта халык эпосын шәһәр культурасы һәм классик поэзия кысрыклаган дип саналып килгән үзбәк халкында да фольклорчылар XX йөзнең 20 нче елларыннан 50 импровизатор-әйтүчедән 60 лап сюжетка 150 дастан тексты язып алганнар, әйтүче-информанты һәм язып алучысы турында мәгълүмат биреп, бастырып та чыгардылар[4].

Югарыда телгә алынган В.В. Радлов томнарының берсе Себердә яшәгән татарлардан, ягъни себер татарларыннан җыелган[5]. Бу томда урын алган йөздән артык фольклор текстының ике дистәгә якыны –

---

[1] *Валиханов Ч.Ч.* Избр. произв. М.: Наука, 1986. 414 с.; *Валиханов Ч.Ч.* Собр. соч. в пяти томах. Алма-Ата: Изд-во Акад. наук Каз ССР, 1961–1972 һ.б.

[2] *Доможаков Н.Г.* Николай Федорович Катанов. Материалы и сообщения. Абакан: Хакасское книж. изд-во, 1958.

[3] *Диваев А.А.* Батырлар. Т. 1–6. Ташкент, 1922.

[4] Мәсәлән: Узбек халк достонлари. Гулнор пари. Тошкент: Узбекистон ССР «Фан» нашриети, 1965. 309 б.; яисә: *Эраш Жуманбулбул угли.* Узбек халк ижоди. Таржимаи хол. Равшан. Кундуз билан Юлдуз. Икки жилдлик. Биринчи жилд. Тошкент: Гафур Гулом номидаги адабиет ва санъат нашриети, 1971. 448 б. (Үзбәк телендә) һ.б.

[5] Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, собраны В.В. Радловым. Ч. IV. СПб.: тип. Имп. Акад. наук, 1872. 414 с.

себер татарлары эпосы үрнәкләре. Бу – безнең өчен искиткеч зур кыйммәтле хәзинә. Шулай ук «Идегәй»нең Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль фольклор үзәге фондына тупланган башка күпләгән (гомуми саны дүрт дистәгә җитә) себер татар вариантлары[1] да әлеге категориягә керә.

Казан татарлары эпик ядкарьләрен алда карап үткән беренчел вербаль текстлар белән чагыштырганда шунысы игътибарны җәлеп итә: «XIX йөзнең икенче яртысында, бигрәк тә аның ахырында оешып өлгергән»[2] татар фольклор фәне, себер татарларының билгеле бер чорга караган һәм үз вакытында язуга күчереп сакланып калган эпосын исәпләмәгәндә, мондый беренчел язмалар белән эш итми. Һәрхәлдә казан татарлары иҗатында дастанның әлеге төренә юлыгу шактый кыен. Төрки героик эпосын тирәнтен өйрәнгән академик В.М. Жирмунскийның да Идел буе татарлары эпик иҗатының фәкать халык әкиятләре формасында гына саклануын искәртүендә[3] хаклык шул: эпос дигәндә галим нигездә беренчел вербаль текстларны (тере сөйләмнән язып алынган) күздә тота, үзенең уникаль хезмәтендә халык иҗатының шундый үрнәкләренә таяна.

Татар фольклорында эпик ядкарьләрне, я аларның фрагментларын язып алу, теркәү халкыбызның нәкъ менә язма тарихы башланган дәвергә карый, ягъни бездә эпик фольклорны туплау тарихы үзе үк тере информант авызыннан беренчел текстны язып алу белән түгел, ә икенчел текстка мөрәҗәгать белән тыгыз бәйле. Татар эпосы тарихында иң әһәмиятле рольне язма чыганаклар үтәгән.

Идел буе татарлары тарихына мөнәсәбәтле беренче иң эре һәм ышанычлы язма чыганак – X гасырның беренче яртысында гарәп хәлифе Әл-Муктадир сәркатибенең Идел буе Болгарына сәяхәте хакындагы китабы[4]. Бу китапта X гасыр башында Идел буе

---

[1] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге: ф. 4, 2 тасвир., 52 сак. бер.; шулай ук тасвирланмаган фонд материаллары.

[2] *Урманче Ф.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 20.

[3] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 20, 620 и др.

[4] Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу. Пер. и комм. под ред. акад. И.Ю. Крачковского. М.-Л.: Изд-во Акад. наук СССР, 1939. 212 б.; *Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествиях на Волгу в 921–922 гг. Харьков, 1956.

Болгар дәүләтендә икътисади һәм социаль-сәяси мөнәсәбәтләр генә түгел, ә Идел буе татарларының элгәрләренә хас ышанулар, йола-гадәтләрне тасвирлау да киң урын алган. Әлеге чыганакта иң әһәмиятлесе һәм соңрак башка галимнәрнең һәм сәяхәтчеләрнең хезмәтләрендә дә чагылыш тапканы – алып-баһадирлар турындагы мөстәкыйль эпик хикәят-риваятьләрнең теркәлеп калуы. Димәк, татар халкының эпик иҗатын язмача теркәп калдыру X гасырдан ук килә. Дөрес, Ибн-Фадланнан соң бу төр хикәят-риваятьләргә игътибар итүчеләр барлык мәгълүматны фәкать шушы язма чыганактан гына алганнар дип әйтеп булмый, аның халык теленнән турыдан-туры язып алынган формаларын кабат теркәү дә булган, әмма бу хакта иң әүвәл нарратив чыганакның булуы үз әһәмиятен югалтмый.

Моннан тыш татар халык эпосын теркәү өлкәсендә янә бер җитди чыганак – дин галиме Әбү Хәмид Әл-Гарнатиның XII гасыр башына карый торган сәяхәтнамәсе. 1135–1136 елларда Идел буе Болгарында яшәгән мөселман сәяхәтчесенең әлеге хезмәтендә Болгар алыплары турындагы риваятьләр шулай ук халык эпосына бик якын мөнәсәбәттә тора.

Безнең турыдан-туры бабаларыбызның фольклорына кагылышлы материаллар беренче карашка иң беренче чиратта чит ил, нигездә гарәп-мөселман галимнәре-сәяхәтчеләре тарафыннан теркәлгәннәр кебек. Әмма шул ук Әл-Гарнати хезмәтендә Болгар тарихчысы Йакуб ибн Ногман һәм аның «Тәварихы Болгария» исемле язмасы телгә алына, Әл-Гарнати Болгар алыплары һ.б. турындагы мәгълүматны да нәкъ менә шушы хезмәттән алуын хәбәр итә[1]. Димәк, XI гасырның икенче яртысында яшәгән Йакуб ибн Ногман хезмәтендә Болгар чорында халыкта таралган риваятьләр һәм легендалар язмача теркәлгән булган.

Шулай ук урта гасырлар язма истәлеге – Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет төрк» хезмәтендә дә тематикасы шактый чуар төрки эпос үрнәкләре китерелгән. Әлеге шигъри текстларга мөнәсәбәттә тикшеренүче галимнәр арасында ике төрле караш яшәп килә: берәүләр аларны тулысынча фольклорга нисбәт итсә (К. Брокельман, М. Хартман, А.Х. Хайитмитов, Х.Т. Зарифов, Х. Госман һ.б.), икенчеләре

[1] Путешествие Абу Хамида аль-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). М.: Наука, 1971. С. 31, 61, 83.

(мәсәлән, академик В.В. Бартольд) бу строфалар арасында индивидуаль иҗатка караганнары да, халык иҗаты да бар дип табалар. Х. Мәхмүтов «Диване лөгатет төрк»тә китерелгән бу шигъри юлларга карата түбәндәге фикерне җиткерә: «Борынгы дәвердәге язма поэзия һәм халык поэзиясе арасында эчтәлек ягыннан да, шигырь төзелеше буенча да зур якынлык булганга, күпчелек текстларны «бу әсәр шагыйрьнеке, монысы халыкныкы» дип өзеп әйтүе кыен, әлбәттә. Алай да аерым әсәрләргә карата шундый фараз кылулар очрый»[1]. М. Кашгари сүзлегендә фактик материал буларак урын алган дүртьюллык һәм ике юллык шигъри текстларның И.В. Стеблева аерым әсәрләргә берләштергән һәм шартлы исемнәр биргән кайбер өзекләрен төрки эпосның язмача яңгырашына мисал дип фаразларга да мөмкин. Мәсәлән, «Тангутлар белән сугыш»[2], Алып Ир Тоңаның үлеменә элегия»[3] кебек исемнәргә берләштерелгән строфалар китаби эпик традицияләрнең борынгы башлангычы була ала. М. Кашгари сүзлеге – шул традицияләрне безгә язмача китереп җиткерүче әһәмияте зур чыганак.

Идел буе татарлары халык эпосын туплауның X–XII йөзләрдән соңгы тарихы да нәкъ менә шушы метод белән, ягъни язма чыганаклар аша башкарылган. XIII–XV йөзләрдән татар халык эпосының бай материалы фарсы-иран язма чыганаклары «ярдәмендә» кайта башлый. Әйтик, XIII гасырда яшәве мәгълүм Җүвәйни исемле авторның (Җәләлетдин Ата-Мәлик Җүвәйни, 1226–1283) өч томнан гыйбарәт «Тарихе Джаганхушай» («История завоевателя мира») исемле хезмәтендә Бачман хан монгол явы белән каты көрәштә тасвирланган[4]. Җүвәйни язмалары соңрак Иран тарихчысы һәм дәүләт эшлеклесе Рәшид-эд-дин (1247–1318) хезмәтенә дә кертелгән[5].

Безнең халыкның себер татарларында популяр «Ак Күбек» дастаны сюжеты да, халык сөйләме белән параллель рәвештә, язма

---

[1] *Мәхмүтов Х.* Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкарьләрендә афоризмнар). Казан: Фикер, 2002. Б.85.

[2] *Стеблева И.В.* Поэтика древнетюркской литературы и ее трансформация в ранне-классический период. М.: Наука, 1976. С. 204–406.

[3] Шунда ук. Б. 210–211.

[4] Золотая Орда в источниках. Т.I. Арабские и персидские сочинения. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды , в переводах В.Г Тизенгаузена. Ч. II. М.: б.и., 2003. С. 259.

[5] *Рашид-эд-дин*. Сборник летописей. Т.II, М.-Л.: Изд-во Акад. наук СССР, 1960. С. 37–38.

чыганакларда урын алган. Ән-Нувәйри (1279–1333) һәм Ибн-Халдун (1332–1406) исемле авторларның хезмәтләрендә теркәлеп калган[1] әлеге мәгълүматлар татар фольклорын язма чыганаклар аша һәм китап культурасының зур бер өлеше буларак тану җәһәтеннән әһәмиятле факт булып тора.

Җирле авторлар да фольклорның язуга күчерелүенә күп өлеш керткәннәр. XIII гасыр башы бөек шагыйре Кол Гали фольклор белән генетик бәйлелектә торган, соңгырак чорларда халыкка шушы ук сюжетка яңадан-яңа вариантлар иҗат итүгә көчле этәргеч биргән мәшһүр әсәрен – «Кыйссаи Йосыф»ын язган. Моңа кадәр Идел буе татарлары халык эпосын туплауга мөнәсәбәттә телгә алынган язма документлар янәшәсендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы ул – Идел буе татарларында фольклор элементларының борынгы классик әдәбиятка үтеп керүен факт буларак искәртә торган иң беренче эре әсәр, шуңа күрә ул казан татарлары эпик иҗатының китап культурасына мөнәсәбәтле тарихын күзәткәндә кыйммәтле чыганак буларак та игътибарга лаек.

XVI йөз урталарыннан казан татарлары эпик ядкарьләрен өйрәнү-туплау төбәкнең сәяси-икътисади үзгәрешләргә дучар ителүенә бик нык бәйле. Бу чорда халыкның рухи җәүһәрләре булган дастаннарга мөрәҗәгать бермә-бер активлаша. Әлеге факт дәүләтен югалткан халыкның үз-үзен саклау инстинкты белән бәйле булса кирәк. Нәкъ менә шушы чордан Идел буе татарлары иҗатында каһарманлык рухы белән сугарылган эпик әсәрләр халык тормышында киң урын ала. Тагын шунысы безнең өчен әһәмиятле: XVII–XVIII йөз истәлекләре булган әлеге ядкарьләр рәтендә, «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан», «Аксак Тимер», «Нарык һәм Чураның хикәяте» «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Кахарман Катил» һ.б. дастан версияләрен күрсәтә алабыз. Татар халык эпосын туплау тарихының XVIII гасыр ахырларынача дәвам итә торган бу чоры мондый чыганакларга шактый бай. Әлеге тарихи дәвернең тагын бер үзенчәлеге булып XVI йөз урталарыннан татар халкы рухи мәдәниятенең рус

[1] Из истории ан Нувайри/Золотая Орда в источниках... . Ч. I. С. 72–88; Из истории Ибн-Халдуна/ Золотая Орда в источниках... .Ч. I. С. 169–181. Бу турыда шулай ук кара: *Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казан: Татар. кн. изд-во, 1984. Б. 29. (*Тизенгаузен В.Г.* Сборник материалов... . Т. I. М.-Л., 1941. С. 129, 541, 542.)

авторларын кызыксындыра башлавы тора. Мәсәлән, 1564–1565 елларда төзелгән «Казан тарихы»ның билгесез авторы үзенең хезмәтен язганда казан татарлары риваять һәм легендаларына мөрәҗәгать итүе турында хәбәр итә[1]. Соңрак аның бу мәгълүматларын башка галимнәр дә үз хезмәтләренә керткәннәр[2].

Ә инде XVIII йөздән, бигрәк тә 1725 елда Санкт-Петербургта Россия Фәннәр академиясе ачылгач, казан татарлары эпик мирасын барлау максатчан һәм җитди юнәлеш ала, бу исә китап культурасына да уңай йогынты ясамый калмый. Кайбер рус галимнәре белән бергә бу чорда үзебезнең укымышлыларыбыз дастани мираска игътибарларын арттыралар. Халыкның рухи ихтыяҗына туры килеп формалашкан һәм үскән язма-китаби төрдәге халык эпосының, фольклор әсәре булудан тыш, кыйммәтле язма чыганак буларак та әһәмияте зур.

Монда шуны искәртеп үтү зарур: мондый төр дастанның текстлары бүгенге көндә фольклорда фәкать авыз иҗаты буларак сөйләмнән язып алынган «беренчел» текстларга карата гына «икенчел», термин шартлы, әмма ул Идел буе татарларына хас дастан текстларын халык җырчысы авызыннан турыдан-туры язып алынган «тере» текстлардан аерып карау мөмкинлеген бирә. Язмачылыкка, укымышлылыкка омтылу тарихи-мәдәни үсешләренең бер баскычында татарларны, бер яктан, борынгы Шәрекъ этник мәдәниятеннән читләштергән, шуңа да бирелдә традицион төрки эпос характерындагы сөйләмә эпик иҗат ныклап үсеп китә алмаган, икенче яктан, Европага ияру, Европача булырга омтылу фольклорда да язмачылыкка өстенлек биргән. Беренче карашка дастанның тышкы билгесе һәм таралу формасы булып тоелган язмада теркәлү сыйфаты Казан татарлары эпик ядкарьләренең җитди үзенчәлеге, шуңа күрә татар китаби дастаннары халкыбызның кулъязма мирас тарихын баета торган матди булмаган кыйммәтләреннән санала да.

Гомер-гомергә китаплы халык булып саналган татарларда басма китап турында XVIII йөз башыннан гына сүз алып барып булса,

---

[1] Казанская история / подгот. текста, всупит. ст. и прим. Г.Н. Моисеевой; под ред. чл.-корр. АН СССР В.П. Андрияновой-Перетц. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1954. Б. 75; *Садеков М.Р.* Звучат лишь письмена... (Татарский фольклор периода Казанского ханства в русских исторических источниках). Казань: Дом печати. 2005. 128 с.

[2] Опыт Казанской истории с древнейших и средних времен, сочинен Петром Рычковым. СПб., 1767.

кулъязма китапның исә бездә тамырлары шактый тирән. Татар кулъязма китабын өйрәнүчеләр аның бик борынгы, бай һәм зур тарихка ия булуын ассызыклыйлар[1]. Әле бүгенге көндә дә әдәбиятчылар һәм тарихчылар тарафыннан табылып тора торган татар кулъязмалары бихисап. Араларында дастан категориясенә керә торган әсәрләр яисә шундый әсәрнең сакланып калган бер өлеш-фрагменты шактый. Китап турындагы фәнни теориядә кулланыла торган «кулъязма китап» терминының бай эчтәлегендә татарлар язып тараткан, соңрак бастырып чыгарган эпик иҗат әсәрләренең зур урын алып торуы, чыннан да, бәхәссез. Казанда Татарстан Фәннәр академиясе, Милли китапханә, Казан федераль университеты археографлары татар кулъязма мирасын фәнни үзәкләргә туплау, аларны өйрәнү белән шөгыльләнәләр. Бу җәһәттән кулъязма дастаннарыбызның һәркайсын аерым барлап, актив фәнни әйләнешкә кертү мөһим мәсьәлә булып тора.

Тарихчы һәм әдәбиятчы галимнәрнең тикшерү-өйрәнү объекты булган кулъязма дастаннарыбызның күпчелеге авыз-тел иҗаты белән кызыксынучы фольклорчылар игътибарыннан читтәрәк кала килгән. Дастани мирасыбызга карата бу гамәлне хаклы дип әйтеп булмый, чөнки татарлар яшәгән төбәктә әледән-әле табылып тора торган дини, әдәби, юридик, медицина, тарих һ.б. өлкәләргә караган кулъязмалар арасында (әйтик, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә генә дә 8000 берәмлектән артык шундый документ саклана[2]) иң зур күпчелекне дастаннар тәшкил итә.

Казандагы фәнни үзәкләргә тупланган кулъязмалар даими төстә гыйльми хезмәткәрләр тарафыннан каралып, тасвирлана баралар, каталоглар төзелә. Мәсәлән, А. Фәтхи[3], М.И. Идиатуллин[4],

---

[1] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 3–4.

[2] Шунда ук. Б. 5.

[3] *Фәтхи А.* Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә язмаларының тасвирламасы. Беренче бүлек. Казан, 1960; шул ук. Икенче бүлек. Казан, 1962; шул ук. Өченче бүлек. Казан, 1968; шул ук. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. КДУ фәнни китапханәсенә 1959–1969 елларда кергән кулъязмаларның тасвирламасы. Казан, 1986.

[4] *Идиатуллин М.И.* Арабские рукописи по астрономии,и математике в фондах научной библиотеи им. Н.И. Лобачевского. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1987.

С.М. Гыйләҗетдинов[1], М.И. Әхмәтҗанов[2] һ.б. хезмәтләре аша мирасханәләрдәге кулъязмаларны текстологик эшкәртүнең, тасвирлауның торышы турында бай мәгълүмат тупларга мөмкин.

Халык иҗатының моңа кадәр басылып чыккан җыентыкларында Казан фәнни үзәкләрендә саклана торган коллекция материаллары киң файдаланылган, бу эш бүгенге көндә дә дәвам итә. Фәнни әйләнешкә кертеп, халыкка кире кайтарылырга тиешле эпик текстлар яисә мәгълүм әсәрнең фрагментар вариантлары потенциалы да шактый. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, мәсәлән, 1940 елда ук фондка кергән дастан текстлары саклана. Араларында «Алпамыш», «Сәйфелмөлек», «Түләк», «Кузы Күрпәч белән Баянсылу», «Идегәй», «Каһарман Катил», «Кыйссаи Сәкам», «Кыйссаи Авык», «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн» кебек сюжетларга дастан вариантлары текстлары бар. Аларның күбесе – гарәп язуындагы татар телле күләмле әсәрләр.

Татарларда эпос-дастан билгеләрен үзенә тулысынча туплаган әсәрләр бар гына түгел, бик күп, әмма алар нигездә язмага теркәлгән дастаннар. Идел буе татарлары халык иҗатының чын мәгънәсендә таҗы дип аталырлык әлеге гүзәл жанр әсәрләре һәм аларның төрле вариантлары үз заманы өчен бик тә популяр булган. Китап теле белән язылган булуына карамастан, алар халыкның игътибарын нык җәлеп иткәннәр, бөек Тукай сүзләре белән әйткәндә, боларны «кечкенә чагында укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер»[3]. Чичән-импровизатор тарафыннан башкарылып та, язып алынмый калган беренчел вербаль эпик текстлар белән чагыштырганда китаби дастаннарыбызның язмышы куанычлырак та, чөнки алар, иске кулъязмалар һәм борынгы китаплар булып әле хәзер дә яшиләр, ягъни аларның шактые безнең көннәргә барлык тулылыгы белән килеп ирешкән, кайберләре хәтта безнең күз алдында диярлек китаби булып оешкан һәм аларны һәрьяклап фәнни

[1] *Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. Казань, 2002. 254 с.; *Гилязутдинов С.М.* Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в.). Казань, 2011. 212 с.

[2] *Әхмәтҗанов М.И.* Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2005. 224 б.

[3] *Тукай Г.* Әсәрләр 4 томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 279.

өйрәнү мөмкинлеге дә зур. Эпик фольклорга китап культурасы ясаган тәэсирләр ахыр килеп текстның камиллек дәрәҗәсенә дә йогынты ясамый калмаган. Бу сөйләм теле белән язма тел арасында бик күп фактик аермалар булу белән дә нык бәйле. Сөйләм тексты импровизациягә корыла, махсус сүз-иҗек калыбына яраклаштырылган була, ә язма текстны кайта-кайта камилләштерү мөмкинлеге зур. Сүз дастанны күчерүче-иҗатчының текстка эпоска хас булмаган кануннарны кертүе, сюжетны оригиналь коллизияләр белән баетып үзгәртүе хакында бармый, әмма кабат фольклорлашу процессында соңрак барлыкка килгән сөйләмә вариантлары белән чагыштырганда дастаннарның язмага теркәлгән вариантларының иң камил, иң яхшы сакланышлы текстлар булуын инкарь итә алмыйбыз.

Татар эпосын, бигрәк тә Урта Идел буе татарлары эпосын гомумтөрки масштабта карау безнең халыкка хас эпик иҗатның башка төркиләр эпосы белән чагыштырганда шактый зур специфик үзенчәлекләргә ия булуын күрсәтә. Бу үзенчәлекләр борынгы тамырларыбыздан килә торган дәвамчанлыкта да, иҗтимагый-тарихи үсеш-үзгәрешләр нәтиҗәсендә туган аермалы якларда да чагылыш тапкан. Халыкның эпик тел-стиль традицияләре, тере сөйләмнән язып алынган эпоска хас халык идеологиясе һ.б.ның безнең дастаннарда чагылыш кимәле бөтенләй башкача. Идел буе татарларында дастан жанры – ярым язма, ярым фольклор, ярым индивидуаль, ярым традицион бөтен. Китап культурасына бәйлелектә үсеш алган язма дастаннарыбыз бүгенге көндә галимнәр тарафыннан халыкның эпик мирасы буларак өйрәнелә башлады. Бу юнәлештә алып барылган эшләрдән шушы темага махсус монографиянең дөнья күргән булуын[1] һәм докторлык хезмәтенең[2] рәсми раслануын күрсәтеп үтү мөһим. XVIII–XIX йөзгә карый торган чыганакларда татар дастаннары еш кына төрле атама белән (кыйсса, хикәят, хикәя һ.б.) теркәлгәннәр. Ничек кенә аталган булсалар да, боларның барысының да дастан жанры билгеләренә туры килүе әлеге хезмәтләрдә тәфсилле дәлилләнә. Татарның язмага теркәлеп таралган дастаннары – халыкның язма

---

[1] *Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань, 2014. 380 с.

[2] *Мухаметзянова Л.Х.* Татарские книжные дастаны: история становления жанра и поэтика: дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2015. 377 с.; *Мухаметзянова Л.Х.* Татарские книжные дастаны: история становления жанра и поэтика: автореф. дис. ... д-ра филол. н. Казань, 2015. 45 с.

мәдәнияте репертуарында күп гасырлар буена яшәгән, тел-авыз-сүз сәнгате булган традицион фольклор белән дә тыгыз бәйләнештә тора торган үзенчәлекле эпик иҗат ул. Бездә эпос-дастаннарны халык үзе «дастан» дип тә, еш кына «кыйсса», «хикәя», «хикәят», «намә», «рисалә», «китап» дип тә атаган, бу атамалар дастан тексты теркәлгән кулъязмаларда яисә басмаларда еш очрый .

Билгеле бер чор татар әдәбиятының һәм фольклорының шигъри жанрларында яшәп килгән атамалар төрлелегендә аларның мәгънәләре ягыннан принципиаль аермалар юк, аларның нәкъ менә үзләренә генә хас булган үзгәрмәс һәм ныклы билгеләрен дә күрсәтеп булмый. Алар барысы да эпос-дастаннар жанрына карый. Бу сүзләр татар теленә иран, төрки-иран, гарәп-фарсы әдәбияты-мәдәнияте, шул исәптән фольклоры аша кереп урнашканнар, чыганак телдә белдергән мәгънәләренә нигездә тугры калганнар, әмма аларның казан татарлары иҗатындагы дастаннарга карата кулланылышында катгый таләпләр дә булмаган. Бу әлеге төшенчәләр белдергән мәгънәнең гасырлар дәвамында чыганагыннан ераклашып, татар җирлегенә генә хас традицияләргә хезмәт итә башлавыннан килә булса кирәк. Шуңа күрә аларның һәркайсының үзләренә генә хас характерлы билгеләре шактый дәрәҗәдә юыла төшкән һәм конкрет бер кагыйдәләргә әлләни буйсынмый. Шуңа да татар телле кулъязма һәм басмаларда дастан текстының жанры «кыйсса» дип тә, «хикәят» яисә «хикәя», «китап» дип, хәтта «роман» дип, я булмаса әсәрнең исеме белән генә дә бирелгән булырга мөмкин. Бер үк текстның һичбер үзгәртүсез кат-кат басылып, басылганы берендә әле кыйсса, әле хикәят, хикәя, дастан яисә китап дип бирелүе дә шушы фикерне куәтли. Мәсәлән, «Каһарман Катил» дастаны «Каһарман хикәяте», «Кыйссаи Каһарман», «Каһарман китабы» дигән исемнәр белән мәгълүм булган, халыкта аны «Каһарман дастаны» дип тә йөрткәннәр. Шул ук текст әсәр исеме белән генә дә, ягъни «Каһарман Катил» дип кенә дә басылган. Әсәрнең үзендә исә герой исеменең күбесенчә «Катил» сүзеннән башка гына, ягъни Каһарман дип кенә телгә алынган булуы да игътибарга лаек. Хәлбуки сүз барысында да шул бер үк Каһарман турында бара, чыганак – бер үк, текст белән текст арасында жанр аермалары юк.

Кулъязмада һәм басма чыганакларда урын алган популяр дастаннар теге я бу дәрәҗәдә «авторлар» тәэсиренә юлыккан. Бу исә татар дастаннары текстында фольклор башлангыч белән бергә ин-

дивидуаль иҗат башлангычлары да әһәмиятле роль уйный дигән сүз. Татар дастаннары, халык иҗаты әсәрләренә хас билгеләрне үзенчәлекле саклап, аерым шәхесләр, күчерүче-дастанчылар тарафыннан күпмедер дәрәҗәдә әдәби үзгәртү-эшкәртелүләргә дучар булганнар, эпосның телдән башкарыла торган «тере» төреннән аермалы буларак, тулы рәвешендә чичән-импровизатор тарафыннан халык алдында көйләп-сөйләп башкарылмаганнар. Татар дастаннарының чичән-импровизатор башкаруындагы авыз-тел иҗаты булудан читләшеп, язмага күчүе, әсәрдәге традицонлык билгеләренә индивидуальлек чалымнары өстәлгән булу һәм башка аермалар – жанрның язма культурага бәйлелеге. Бу, беренчедән, татарларда китап культурасының югарылыгын күрсәтсә, икенче яктан, язма мәдәниятне тагын да югарырак баскычка күтәрүдә үзенчәлекле бер катламны тәшкил итә торган күренеш тә.

Дастан жанрының татар халкында иң беренче чиратта китаби булып формалашуына китергән сәбәпләр шактый. Әлбәттә, татарларда уку-язуга омтылышның, китапка, язылган-басылган сүзгә хөрмәтнең зурлыгы хәлиткеч роль уйнаган, утрак тормыш шартлары эпосны язып иҗат итүне, күчереп-язудан укып тарату мөмкинлеген тәэмин иткән, мәҗүсилекне катгый тыйган ислам кануннары да күләмле сүз белән бәйле иҗатның телдән башкарылудан гыйбарәт өлешен бетерүгә үз йогынтысын ясаган. Борынгыдан үз язуы булу халыкта билгеле сюжетларны күчереп язып кую, ул сюжетларның популярлыгы боларны бастырып чыгару ихтыяҗын тудырган. Дастан жанрының күләмле, тыңлаучы яки укучы өчен мавыктыргыч эчтәлеккә ия үзенчәлеге дә китабилашуга этәргән. Дастан – беркадәр элитар жанр. Югары зәвыклы, шигъри эшләнешле, зур күләмле, теге я бу идеягә ия дастанның фәкать үзе дә шушы кимәлгә лаек укымышлы затларның гына нечкә күңелен яулый алуы бәхәссез. Бу факт та жанрның китабилашуына тәэсир итми калмаган. Әлеге алшартлар барысы да «тере» башкаруда традицион эпоска караганда язма-китаби эпик иҗатка өстенлек биргәннәр, татар эпосының тышкы фольклор билгеләре кими барып, тарихи процессның билгеле бер этабында ул нигездә китаби эпик иҗат булып формалашып җиткән.

Татар халык дастаннарының китабилашу дәрәҗәсе төрлесенеке төрлечә. Дастан текстларының кайберләрендә фольклор катламы өстенлек итсә, кайберләрендә әдәби сыйфатлар күбрәк үзләштерелгән. Бер ишләре фәкать кулъязмада гына саклanган булса, күбесе

инде аерым китап булып басылу дәрәҗәсенә җиткән, күчерүче-иҗатчы хәтта индивидуаль автор роленә керә башлаган. Әйтик, «Таһир белән Зөһрә» – шуңа мисал. Бу әсәрнең Сайадидән башлап, В. Радлов тарафыннан язып алынган, Ә. Кормаши күчергән һәм башка «авторлы» һәм «авторсыз» вариантлары бихисап. Әмма вариантлылыкның булуы һәм әсәрнең теле-стиле, сюжет-мотивлары – әсәрне һичшиксез халыкныкы итеп танытучы кире каккысыз дәлил. Текстта чагылыш тапкан мондый билгеләр дастанның фольклор нигезен ачыкларга ярдәм итә. Татарларның үзләрендә берничә вариантта таралган яисә башка төрки халык версияләре дә булган эпик ядкарьләребезнең барысының да фольклорга мөнәсәбәте бинииһая. Мондый әсәрләрнең һәркайсына индивидуаль якын килеп, текстларны эпик фольклор закончалыклары кысаларында тикшерү генә объектив була ала.

Кулъязма һәм басма китап рәвешендә таралыш алган татар дастаннары арасында тыгыз фольклор-әдәбият бәйләнешләре нәтиҗәсендә индивидуаль авторныкы булып әверелгән әдәби әсәрләр дә бар, әмма мондый әсәрләр фольклордан башлангыч алган булулары белән җиңел танылалар. Күренекле галим Х.Миңнегулов Урта гасыр татар әдәбиятының фольклор белән охшашлыклары һәм уртак якларын ачыклап язган мәкаләсендә болай ди: «Сүз сәнгатенең ике тармагын тәшкил итә торган фольклор һәм язма әдәбият Борынгы һәм Урта гасырларда аеруча тыгыз мөнәсәбәтләрдә торган. Хәтта аларны кайвакыт бер-берсеннән шартлы рәвештә генә аерырга мөмкин»[1]. Күләмле эпик жанр төре булган китаби дастаннар менә шушы шартлылыкның кыл уртасында тора торган таҗга тиң. Татар китаби дастаннарын язма-әдәби һәм фольклор башлангычларның кушылмасы, синтезы дип атарга мөмкин. Халык авыз иҗаты системасында караганда аларның язма әдәби-эстетик казанышларны да нык үзләштергән эпик текстлар булуы күренсә, индивидуаль авторның оригиналь әсәре итеп тикшерә башласак, боларның фольклорның бик борынгыдан килә торган эпик кануннарын үзенә бик нык сеңдергән булулары ачыклана.

[1] *Миңнегулов Х.Й.* Урта гасыр татар әдәбиятының фолклор белән охшашлыклары һәм уртак яклары // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 284.

Билгән урыны, күләмле булуы, эпиклыгы, язмача камиллеге, әһәмияте ягыннан саллы һәм затлы дастан жанры – халыкның китап культурасында үзенә аеруча нык игътибар сорый торган өлкә. Халык дастаннары – борынгы чорлардан алып бүгенге буын шагыйрьләре һәм әдипләре иҗатына төрле яклап тирән тәэсир ясаган, классик әдәби кануннар һәм традицияләр формалашуга шактый зур этәргеч биргән мәртәбәле жанр. Бу жанр шулай ук фәлсәфи һәм дини категорияләр, социаль һәм хокукый доктриналар эволюциясе белән дә тыгыз бәйләнештә.

Дастан дип билгеләнгән әсәрнең эчтәлеге үзенең тамырлары белән кайчандыр тарихта булган, инде риваять-легендага әверелгән вакыйгага барып тоташа, я булмаса әкияти-мифологик, тарихи-героик һәм дини-мистик яисә халык өчен әһәмиятле саналган тетрәндергеч-эмоциональ мәхәббәт интригасына корылган була, кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләрне эпик бәян итә. Эпиклык дастаннарның барысына да хас, алар күләмле эпик жанрга карыйлар, шуңа күрә фольклор һәм әдәбият белемендә «дастан»ны «эпос» сүзе белән синонимик мәгънәдә дә кулланалар.

«Эпос» үзе – грек сүзе, сүз, бәян итү, сөйләп бирү дигәнне аңлата[1], термин буларак шактый күп мәгънәгә ия. Энциклопедияләрдә аның киң һәм тар мәгънәләре күрсәтелгән[2]. Киң мәгънәсендә бу сүз вакыйга яисә вакыйгаларны хикәяләп сөйләүгә нигезләнгән әдәби төргә карата кулланыла, үз эченә әлеге сыйфатларга ия барлык әдәби һәм фольклор жанрларын гомумән ала. Тар мәгънәсендә «эпос» ул – фольклорда халык тормышын киң эпик планда сурәтләп бирә торган героик яки романик эчтәлекле әсәр. Татар энциклопедия сүзлегендә исә «эпос» сүзенә аеруча төгәл аңлатма «дастан» төшенчәсе аша бирелгән һәм эпосның беренче чиратта фольклор термины булуы ассызыкланган: эпос (грек epos – сүз, хикәя), чәчмә, шигъри, катнаш формадагы әсәрләр, халыкның борынгы тарихы, тарихи-героик һәм гыйшык-мәхәббәт вакыйгаларын чагылдырган күләмле дастан-

---

[1] Литературный энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия, 1987. С. 514.

[2] Краткая литературная энциклопедия. М.: Советская энциклопедия, 1975. С. 928.; Литературный энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия, 1987. С. 514–515.

нар җыелмасы. Киң мәгънәдә фольклорның башка кайбер жанрларын (әкият, легенда, риваять) үз эченә ала...»[1].

Дөнья фольклорында һәм әдәбиятында китаби эпос дигән термин бар һәм ул шактый еш кулланылышта. Китаби эпос, шиксез, – гомумэпосның зур әһәмияткә ия бер төре.

Дөнья эпосының стилендә, семантикасында, башкарылу, таралу үзенчәлекләрендә теге я бу дәрәҗәдә халык иҗаты традицияләрен саклаган һәм бүгенге көннәргә билгеле я билгесез автор яисә күчерүче тарафыннанмы, башка юллар беләнме китаби формада берничә вариантта килеп ирешкән, сөйләмә формасы сакланмаган яисә булмаган, әмма шул ук вакытта фольклор белән бәйләнешен бөтенләй үк югалтып бетермәгән төрледән-төрле язма эпик истәлекләрне П.А. Гринцер, В.М. Жирмунский, С.Ю. Неклюдов, Е.М. Мелетинский, А.Б. Куделин, С.Д. Серебряный, Б.Н. Путилов, Ю.К. Щеглов, Б.Л. Рифтин һ.б. атаклы галимнәр китаби эпос термины белән атыйлар һәм жанрның шушы төре яссылыгында фольклорга мөнәсәбәттә тикшерәләр.

Соңгы чор фольклор һәм әдәбият фәнендә китаби эпос мәсьәләсе шулай ук актуаль мәсьәләләрдән булып, әлеге темага милли яссылыкта индивидуаль якын килү киң күзәтелә башлады. Мәсәлән, 2001 елда Уфада «Изустная литература в системе башкирской словестности» дигән темага докторлык[2], 2006 елда Саранскта «Культурно-историческая основа эпоса о Тюште: фольклорно-литературные версии» исемле[3], 2007 елда Мәскәүдә «Устные и книжные элементы в тюркской традиционной словестности: турецкая городская повесть» дигән темага кандидатлык[4] һ.б. диссертацияләр якланды, фольклорчы башкорт галимнәре «Башкорт халык ижады»

---

[1] Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедия институты, 2002. Б. 787.

[2] *Идельбаев М.Х.* Изустная литература в системе башкирской словесности: автореф. дис… докт. филол. наук: 10.01.02. Уфа, 2001. 82 с.

[3] *Гурьянов И.А.* Культурно-историческая основа эпоса о Тюште: фольклорно-литературные версии. URL: http://www.dissert.com/content/. kulturno-istorieheskaya-osnova-eposa-o tyushte-folklorno-literaturnye-versiu/...(дата обращения: 08.05.2011.)

[4] *Аникеева Т.А.* Устные и книжные элементы в тюркской традиционной словестности: турецкая городская повесть: дис…канд.филол.наук: 10.01.09. М., 2007.139 с. URL: http://www.dissercat.kom/content/ustnye-i-knizhnye-elementy-v-tyrkskoi-traditsionn...(дата обращения: 04.02.2011.)

күптомлыгының бер томын «Язма кисса һәм дастандар» дип атадылар һәм шактый саллы әлеге җыентыкка халык иҗатының нәкъ менә китаби дастаннар буларак каралырга хаклы ядкарьләрен туплап бастырып чыгардылар[1]. Бу һәм шуңа охшаш башка хезмәтләрдә китаби эпос яисә китаби дастан термины кулланылу яисә кулланылмауга карамастан, хәлбуки сүз нәкъ менә аерым халыкларның югарыда каралган категориягә керә торган эпик иҗатына кагылышлы мәсьәләләр хакында бара.

Безнең көннәрдә күрше фин-угыр халыкларыннан мордва галимнәре атаклы «Масторава»ларын китаби героик эпос буларак җәмәгатьчелек хөкеменә тапшырдылар[2]. Әлеге китапка кереш сүздә «Масторава»ның халык эпосын җыйнама-әдәби басма итеп чыгаруда беренче тәҗрибә булуы әйтелгән[3]. Хезмәткә бәя биргән мәкаләсендә Е.А. Шаронова китаби эпос дигәндә нигезендә фольклор материалы яткан, әмма автор эшкәртүенә тулаем дучар ителгән, фәнни системалаштырылган аутентик текстны күздә тота[4]. Бу – китаби эпоска автор йогынтысы, аерым шәхес иҗаты нәтиҗәсендә шул ук фольклордан оешкан, яңадан туган фольклор әсәре дип билгеләмә бирүне алга сөрә торган караш. Барлык нечкәлеге белән үк туры килмәсә дә, күпмедер дәрәҗәдә татар халык китаби дастаннарыннан «Идегәй» (Н. Исәнбәт), «Идегә» (Н. Хәким) шундый юл белән барлыкка килгән. Әмма шунысы да бар: «автор йогынтысы» дип аталган элементның дәрәҗәсе һәм сыйфаты төрле китаби эпоста бик тә төрлечә булып, кайбер очракта мондый әсәрләрнең барысын бер калыпта карау мөмкинлеге булмавы да бар. Шуңа күрә китаби эпос яки китаби дастан категориясенә керә торган әсәрләрнең теләсә кайсы типтагысы индивидуаль якын килүне һәм үз тукымасына хас үзенчәлекләрне һәр милли очракта төгәл ачыклауны таләп итә.

---

[1] Башкорт халык ижады. 7-се том. Язма кисса һәм дастандар. Өфө: Китап, 624 б.

[2] Масторава. На основе эрзянских и мокшанских мифов, эпических песен и сказаний написал А.М. Шаронов. Саранск, 2003. 488 с.

[3] *Дорожкин М.В.* «Масторова» // Масторава. На основе эрзянских и мокшанских мифов, эпических песен и сказаний написал А.М. Шаронов. Саранск, 2003. С. 5–6. (488 с.)

[4] Эрзянь ки. Культурно-образовательный портал.URL: http. //www.erzan.ru. (дата обращения: 10.11.2010).

Яисә соңгы чорда үзбәк халык эпосында «китаби дастаннар» дип аталган аерым төркемгә игътибар итә башладылар. Үзбәк китаби дастаны дигәндә билгеле сюжетка индивидуаль автор әсәрләренең, дастан әйтүче-импровизатор тарафыннан фольклорга яраклаштырылып, кабат тел-авыз иҗатына әверелгән булуы күздә тотыла, мондый төр дастаннарның язма әдәбият белән бәйлелеге аларны «китаби дастаннар» дигән билгеләмә белән атарга мәҗбүр итә, дигән караш алга сөрелә[1]. Бу очракта китаби дастан ул – мордва галимнәре карашының капма-каршысы, ягъни фольклордан оешкан аутентик индивидуаль иҗат түгел, киресенчә, индивидуаль язма иҗаттан кабат эпик җырчылар репертуарына әйләнеп кайткан текст буларак карала.

Бүгенге көндә фольклористикада фольклор һәм постфольклор, шулай ук язма фольклор термины кулланылышта булып, таралышы гына түгел, гомумән яшәү формасы язмачылык белән бәйле китаби эпос күренеше шушы төшенчә эчендә дә карала башлады[2]. Язмачылык белән бәйле фольклор ядкарьләре барысы да бүген дөнья һәм рус фольклористикасында зур кызыксыну уята, сөйләмә һәм китаби традицияләрнең типологиясе һәм үзара бәйләнешләре җәһәтеннән актив өйрәнеләләр. Мондый категориягә милли фольклористикаларда төрле термин белән ныгыган истәлекләр карый. Әйтик, мифографиядән алып елъязмачылык, сәяхәтнамәләр, шәһәр демократик әдәбияты, телдән телгә күчә торган әдәбият (изустная литература), халык китабы, «парафольклор» язмачылык, төш юрау китаплары, төрле дидактик һ.б. характердагы кулъязма җыентыклар, наив әдәбият, әдәби сюжетларның сөйләмгә күчерелгән вариантлары (устные переложения), әдәби әкиятләр, автор поэзиясеннән үзгәртелеп, халык теленә күчкән әсәрләр, җыр дәфтәрләре, китаби эпос һәм «ясалма», ягъни махсус барлыкка китерелгән китаби эпоска кадәр булган әсәрләр шундыйлардан. Язма культура һәм фольклор төшенчәләрен гомумән колачлый торган әлеге өлкә бик киң, үтә бай һәм һәр халык өчен гаять индивидуаль. Индивидуальлек бу төр әсәрләрнең бер халыкта булып, икенчеләрдә бөтенләй булмау

[1] Узбекский нардный эпос: дастаны. URL: www.literature.uz/dastan/ (дата обращения – 27.11.2011)

[2] Фольклор и постфольклор: структура, типология, семиотика. URL: 0http// www.ruthenia.ru/folklore/program_aspir_gyalif.htm. (дата обращения: 08.06.2011).

мөмкинлегендә, бер үк яисә охшаш күренешләрнең төрлечә аталышында, бу ядкарьләрнең фольклор белән бәйләнешендәге үзенчәлекләрдә, тарихи нигезләрендә, структурасында, стилендә, типологиясендә, семиотикасында һ.б. чагыла. Безнең халыкның китаби дастаннары да – әлеге зур өлкәнең әһәмиятле бер буыны.

Дөнья, шул исәптән рус һәм башка милләт галимнәренең фәнни-теоретик концепцияләрендә эпик стиль һәм эпик семантика һәрвакыт конкрет тарихи җирлек белән бәйләп каралырга тиеш дигән фикер уздырылган. Эпик стильне һәм эпик семантикага хас сыйфатларның төп җирлеген географик, милли, социаль, хронологик пландагы тарихи нигез барлыкка китерә, китаби эпосның төп асылын билгеләүдә дә әлеге нигез турыдан-туры роль уйный. Шуннан чыгып, әгәр халыкның китаби эпосы яисә китаби дастаны бар икән, аның үз йөзе, үз характеры һәм типлары һәр очракта индивидуаль билгеләнә. Эпос үзенчәлекле милли традицияләрдә изоляцияләнгән хәлдә үсми, әлбәттә, һәр халыкның эпик иҗаты тирәюньдәге башка халыкларның шундый ук һәм шуңа охшаш иҗаты белән һәм гомумән әдәби-фольклор процесслары белән гаять тыгыз бәйләнеш тота. Шулай булуга карамастан, әйтик, монгол халыклары эпосын фәнни яктырткан кысалар татар халкына хас дастани эпос үзенчәлекләренә дә туры килә дип әйтеп булмый. Эпос жанрының төрләре, сәнгатьчә эчтәлеге, продуктивлыгы, сюжет-тематикасының күптөрлелеге һәр очракта барлык принципларны бер ноктага җыеп бетерүне тәэмин итә алмаска да мөмкин. Китаби дастаннар формалашу, барлыкка килү һәм үсеш алу мәсьәләсенә мөнәсәбәттә дә бу шулай.

Китап культурасының бер өлешенә әверелү – халыкның тормыш-яшәү рәвеше йогынтысында татар дастаннарында ныгып урнашкан милли характерга ия күренеш. Якут, тува, хакасларда, алтай төркиләрендә, бурят-монголларда, Кавказ халыкларында, шул исәптән карачай-балкарларда һ.б. халыкларда соңгы көннәргәчә эпосны музыка коралында уйнап (кубыз, саз, чатхан, татхан, дутар, думбра, топшур, комус, кифара һ.б.), ярым көйләп яки музыкаль речетатив белән башкару үрнәге сакланып килә. Мондый төр иҗат әлеге һ.б. халыкларда электә билгеле бер йола контекстында башкарылган һәм аудитория эпосны шушы эш белән махсус шөгыльләнүче талант иясе – чичән авызыннан ишеткән. Әйтик, кыргызлар һәм казакълар атаклы «Манас», «Кобланды»ны яу алдыннан билгеле

максатларда сугышчылары каршында башкарулары, тува, хакасларның шулай ук эпос әйтүне ыруг-кабилә сунарчылары алдында тайгада оештырулары жанрның йола үтәү белән тыгыз керешкәнлеге хакында сөйли.

Ә менә безнең чичәннәр иҗатына килсәк, биредә эпос жанрында йоладан аерылганлык шактый иртә чорлардан ук күзәтелә. Күләмле әсәрне халык алдында билгеле бер йолага бәйле рәвештә көйләп әйтү казан татарларында популяр булмаган. Тарихка мөрәҗәгать итсәк, Казанны яудан сакларга әзерләнгәндә, мәсәлән, татарларның чичән-башкаручыдан эпос-дастан көйләтүләре документаль дәрәҗәдә беркайда да теркәлмәгән, мондый вакыйгалар уңаеннан ул чорда биредә, әйтик, П. Рычков мәгълүматларына нигезләнеп, музыка уйнату гадәте генә гамәлдә булуын беләбез[1]. Бу факт XVI йөз башында ук инде казан татарларының эпосның сөйләмә төреннән ерагаюы хакында искәртә. Ә чичәнлек исә казан татарларында иң беренче чиратта дастан жанрында түгел, башка функциядә ачылган. Татар халкында гомумтөрки чичән образлары сакланган. Мәсәлән, Җирән чичән, Сыпра (Субра) җырау, Җамукай чичән. Аларның булуы хакында мәгълүматны безгә китереп җиткерүче – Н. Исәнбәт[2]. Идел-Урал төбәге шагыйрь-импровизаторлары саналган Әсән Кайгы (XV гасыр), Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау (XV гасыр ахыры – XVI гасыр башы), Чалгиз (Шалкиз) җырау (XV гасыр ахыры – 1560 нчы еллар)ның безнең көннәргә бик аз санда гына һәм нигездә өзекләр булып килеп җиткән әсәрләрен[3] яисә соңгы чорның исемнәре ачыкланган, әмма популярлашмаган тарихи чичәннәреннән Сабирҗан акын (Мәңгәр авылыннан), Байчыгави (Лаеш ягыннан), Кәшшәфетдин Шаһимәрдән Минзәләви (Минзәлә өязе Сөлек авылыннан) һәм тагын берничә шәхесне[4] күрсәтергә мөмкин. Аларның репертуары халык җырлары, афоризмнар, әкиятләргә га-

---

[1] Опыт Казанской истории с древнейших и средних времен, соч. Петром Рычковым. СПб., 1767. С.125.

[2] Татар халык мәкальләре / җыючысы һәм төзүчесе Н.Исәнбәт. 3 томда. Т. 1. Казан: Татар китап. нәшр., 1959. Б .67, 70.

[3] *Шарипов А.М.* Зарождение системы стихотворных жанров. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 2001. С. 259.

[4] Татар халык мәкальләре / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. 3 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Б. 70; *Бакиров М.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2011. Б.141.

ять бай, еш кына дастан текстының шигъри өлешен я каһарманның җырын көйләп-сөйләп бирәләр. Ә айлар буе эпос әйтү традициясе һәм репертуарында күләмле дастаннар булган чичәннәр иҗаты Идел буе татарларында үсеш алмаган. «Татар халык иҗаты. Дастаннар» җыентыгына кушымта рәвешендә бирелгән көй үрнәкләренең[1] «Алыпмәмшән», «Кузы Көрпәч», «Сәйфелмөлек», «Йосыф китабы», «Таһир җыры», «Бүз егет»тән эпик җыр һ.б. дастаннарның өзекләреннән генә гыйбарәт булуы мәгълүм. Бездә мондый иҗатчылар турында «җыр өлешләрен көйләп әйтә» яисә «дастанның шигъри өлешеннән берничә куплетны телдән әйтеп бирә» кебек байлыктан артыграк уңышыбыз бар дип әйтү кыен. Моның сәбәпләре – казан татарлары дастан жанрының буыннан-буынга язмача тапшырылуга корылган булуында һәм китаби дастан категориясенә керә торган әсәрләрдә башкаручы-импровизатор вазыйфаларына ихтыяҗның инде тулысынча югалып бетүендә. Шуңа күрә башка кардәш халыкларда импровизатор иҗаты буларак таралган дастаннарның казан татарлары версияләре безнең җирлектә күбесенчә китаби формага күчеп, янә бер төрле яшәү рәвеше алганнар. Китаби дастанга өстенлек биргән күчерүче-иҗатчылар исә мәгълүм сюжетлы дастанның әллә ничә яңа милли вариантын барлыкка китергәннәр.

Бу уңайдан галим Ф. Урманчеевның түбәндәге фикере шактый әһәмиятле: «Билгеле булганча, татар халкы, бигрәк тә Урта Идел татарлары, элек-электән язма мәдәнияткә ия китаби халык булган. Бу якта күләмле шигъри дастаннар, күрәсең, булмаган яки булып та онытылган. Шуның нәтиҗәсендә Идел буе татарларында, беренчедән, төрки дастаннарга тартым, зур күләмле тылсымлы һәм батырлык әкиятләре зур бер иҗади егәр белән үсеп китсәләр, икенчедән, китаби дастаннар киң урын ала»[2].

Татар китаби дастанының да беренчел чыганагы бар, фактта ул – халыктан. Дастанны буыннан-буынга җиткерүче ролен үтәүче информант та, әлбәттә, булган. Әмма казан татарлары дастан жанры информанты гадәттәге ашуг, бахшы, сәсән, манасчы белән чагыштырганда шактый үзгә функция үти. Ул күбрәк – текстны язып таратучы иҗатчы-дастанчы. Кульязма дастан күчермәләрендәге

---

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан, 1984. Б. 376–383.

[2] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Өч томда. 2 т. (Д–С) Казан: Мәгариф, 2009. Б. 7.

вариантлылык – күп очракта нәкъ менә шушы күчерүченең иҗади мөмкинлекләре нәтиҗәсе.

Казан татарларында бу вазыйфаны гадәттәгечә ашуг, манасчы, олонхосут кебек талантлы, халык шигыренә нигезләнеп зур текст әйтә белүче оста, грамотасыз халык вәкиле түгел, ә укымышлы кеше – мулла, мәдрәсә шәкерте һ.б. үти торган булган. Кайсы катлам аудиториясен күздә тотып иҗат ителгән булуына карамастан, дастан тексты язма мәдәният белән таныш һәм шуның белән турыдан-туры шөгыльләнүче кулыннан, әлбәттә, кайбер китаби үзгәрешләр кичереп таралган. Бу – татар язма-китаби дастаннарына хас иң характерлы билгеләрнең берсе. Ә инде казан татарларында дастанны халыкка җиткерүчеләрнең нинди исем белән аталуына килгәндә, бу мәгънәне белдерә торган сүзнең кулланылышы бирадә үтә пассив, махсус термин юк дәрәҗәсендә.

Иң борынгы эпик жанр яралгылары һәм иң архаик эпос йола-миф синкретизмы җирлегендә барлыкка килгән булса, алга таба акрынлап йола белән бәйләнмәгән иҗат башлангычы тернәкләнгән, җыр-шигырь-сөйләмнән гыйбарәт эпик үрнәкләр аерым очрак-хәлләр уңае белән чыгарыла башлаган. Ә тарихи үсешнең билгеле бер баскычында шул ук процесс символик церемония, ә тора-бара әдәби-эстетик функция үтәүгә күчкән.

Бу процессны поэтик сүз сәнгате оешу күренешенең борынгы ташгасыр вакыйгалары белән үк бәйләп, М. Бакиров мондый аңлатма бирә: «Күмәкләшеп синкретик йола-бәйрәмнәр уздыручы ыруг-кабилә коллективыннан башта оештыручы-башлап йөрүче шәхес – шаман (шам, бакши, узан, жаячы) аерылып чыккан. Һәм ул кабиләсендә ... иң беренче шагыйрь-җырчы функциясен дә үз өстенә алган. Шушы юнәлештә эш итеп, ул конкрет иясе булмаган «мифик автор» иҗатын индивидуаль «эпик һәм лирик автор» иҗатына әверелдергән һәм миф-йола синкретизмы җирлегендә туган архаик жанрларны тагын да үстергән, камилләштергән. Шаманның шигърияткә бәйләнешле функцияләре һәм традицияләре нигезендә үсеп чыккан җырау-чичәннәр (колчир, чәләби, кубызчы, акын, ашыглар) исә поэтик сүз сәнгатен тагын да үстереп, яңа баскычка күтәргәннәр. Нәкъ менә алар язма поэзия өчен бай традицияле җирлек әзерләгәннәр»[1].

[1] *Бакиров М.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 141–142.

Төрки бабаларыбыз тарихының казан татарлары чорына якынлашкан саен утрак тормышлы мәдәни процесслар, язма культура, әдәби-мәдәни багланышлар һ.б. йогынтысында миф-йола синкретизмыннан гыйбарәт дастани-эпик иҗат символик церемония үтәүдән бөтенләй үк аерылып җитмәгән, әмма баштагы функциясен башкаруга инде хаҗәте калмаган сюжетлы текст булып үзгәргән. Эпосның сүз белән бәйле булмаган эмоциональ элементлары гасырлар дәвамында юыла килеп, текст үзе халык дастанының иң төп билгеләрен эченә сыйдырган бердәнбер жанр атрибутына әверелеп калган. Шулай булса да, әйтик, күчмә төркиләр эпосы өчен характерлы речитатив Идел буе татарлары китаби дастаннарында да элекке функцияләрен үтәгән очраклар да юк түгел[1]. Кайбер дастаннарыбызның «шигъри өлешен дутар, думбра белән көйләп әйтү»[2] традициясе саклану да – шуңа дәлил. Кайбер сирәк чыганакларда зур әсәрнең кыска өзекләрен – сарын, тулгау, төп каһарманның җыры һ.б.ны телдән әйтү гадәтенә дә юлыккалыйбыз[3]. Әмма алга таба, төгәлрәк әйткәндә, Идел буе татары булып формалашуга таба барганда, бездә башкаручы-чичән һәм кабул итүче аудитория катнашыннан гыйбарәт жанрда китабилык, язма иҗатка омтылыш интенсив төстә үстенлек алган. Казан татарларына хас дастаннарда иң зур әһәмият җырчы-бәян итүченең текстны башкаруына түгел, ә текстның барлыгына, шигъри сүзгә бирелгән һәм әсәр язмача теркәлгән. Бу исә казан татарларының дастани иҗатында язма текстның гасырлар аша ныклы позицияләр алып урнашуы дигән сүз.

Кешелек цивилизациясе тарихында мондый форма үзгәртүләр һәрвакыт булып тора һәм функция алыштыру белән бәйле әлеге күренешләр дистәләгән гасырларны колачларга мөмкин. Эпос ул – халыклар һәм дәүләтләр формалашу процессы белән бергә үзгәрә һәм шулай ук формалаша торган гаять катлаулы күренеш. Язма-китаби дастаннар очрагында да без әлеге дәвамчанлык белән очрашабыз, китаби дастаннарның тамырлары шактый борынгы заманнарга ук барып тоташканлыкны күрәбез. Структур трансформация

---

[1] *Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари: Историко-этнографическое исследование. Казань: Магариф, 2008. С. 248.

[2] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. II. Казан: Мәгариф, 2009. Б. 6.

[3] Татар халык мәкальләре / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Б. 63 –71.

аша бүгенге көнгә килеп ирешкән дастаннарның барысын да, – героик характерлы гомумтөрки ташъязма текстмы ул, романтик характердагы борынгы Шәрекъ дастанымы, – язуга күчеп яши башлаган фольклор эчтәлеккә тугрылык берләштерә һәм бу эчтәлек һәрвакыт ритуал-мифологик контекстка ия булуы белән әһәмиятле.

Татар дастанына китап идеологиясе бик нык үтеп кергән. Индивидуаль иҗат белән халыкның күләмле эпик жанры үзара тыгыз керешкән өлкә буларак, алар арасына катгый киртәләрне куеп булмый. Әмма фольклорны һәм шул ук чор язма поэзияне генә алсак та, боларның һәр икесендә принципиаль аермаларны искәрми дә мөмкин түгел. Халык әсәре халык шигыренә, традицион ысулларга таянып үссә, индивидуаль иҗатта китаби идеология өстенлек алган. Китаби идеология образ-персонажлар бирелешендә дә, тема-мотивлар күләмендә дә, стиль үзенчәлекләрендә дә һ.б.да да чагылыш тапкан. Әйтик, китаби дастаннарга сөйләмне яки әсәр телен авазлар ягыннан оештыру, халыкның саф традицион дастанына хас булган аллитерацияле фонетик чаралар куллану кебек ысуллардан читләшү, ә язма әдәбият чараларына мөрәҗәгатьнең исә артуы хас. Казан татарлары укыган, язып тараткан дастаннарда архаик саф дастан формасы белән китаби традицияләр ярашу кичергәннәр. Халык дастанына гына хас булып, кайбер очракта индивидуаль иҗатка да килеп кергән стиль үзенчәлекләре, образлар, тема-мотивлар китаби дастанда үзенә бер төрле үсеш алган. Шул ук вакытта китаби дастанга индивидуаль иҗатта гына очрый торган китаби элементлар да күпләп үтеп кергән, жанрның халык идеологиясеннән, чичән фикереннән ераклашу белән характерлана торган яңа бер төре барлыкка килгән. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: казан татарларында ислам һәм тәүге адымнарыннан ук үзе дә иң элек халык иҗатына таянган язма культура белән тыгыз бердәмлектә үскән китаби дастаннарны нәкъ менә сөйләмә формалы гомумтөрки архаик дастаннар яссылыгында караганда беренчеләренең дә фольклор асылы ачыклана. Формалашу һәм таралу җирлеге Идел буе регионы булган татар милли дастаннары – язмага әйләндерелгән эпик фольклор.

Китап культурасы тәэсирендә үзенчәлекле юнәлеш алып үскән татар дастаны үзенең темасы, сюжет, мотивлары, идеясе, сәнгатьчә эшләнеше, типологиясе, яшәү-таралу рәвеше белән халык традициясенә нигезләнгән гомумтөрки эпосына да, шул ук вакытта Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятына һәм фольклорына да бердәй

таяна. Мондый төр эпос бездә язма мәдәният һәм ислам йогынтысында гасырлар буена формалашкан. Биредә, әйтик, силлабиканы классик шигырь системасы – гаруз шигырь төзелеше алыштырган. Ә төрки гарузның, гарәп-фарсы квантатив шигырь төзелеше кагыйдәсенә ияреп, борынгы язма поэзиядә кулланылган метрик система булуы мәгълүм[1]. Шулай ук архаиклыкның иң беренче билгесе булган тоташ тезмәдән гыйбарәт дастаннарыбыз гомумән сирәк, булсалар да, стиль җәһәтеннән индивидуаль үзгәреш кичергәннәр. Китаби дастанда еш кына әдәби, ягъни классик әсәрләргә хас фәлсәфи рух, идея-эстетик нечкәлекләргә дә урын табылган. Шул ук вакытта мондый төр эпоста традицион төрки дастаннар рухы да бик нык сизелә.

[1] *Курбатов Х.* Ритмика татарского стихосложения. Казань, б.и., 2005. С. 8, 20–85.

## I бүлек

# ТАТАР ХАЛКЫНДА ГЕРОИК ДАСТАННАР

Героик китаби дастаннар төрки эпос үрнәгендә каһарман образын алга чыгаралар. Төрки халыкларда һәм гомумән дөнья фольклорында эпос дигәндә иң әүвәл героик характердагы халык әсәре күз алдына килә, чөнки эпосның күпчелеге героик характерда. Героик эпос дигәндә фәндә тезмә яки катнаш бәян итүгә корылган, каһарманның героик җиңүен, яу чабуын, көрәшен, маҗараларын, гадәттән тыш вакыйгаларда катнашуын сурәтли торган әсәрләр күздә тотыла[1]. Үзәктә пәһлеван торган мондый әсәрләрдә еш кына төп герой туганда ук батыр булып туа, гадәттән тыш батыр булып үсә, үсеп җиткәч, илен-җирен, кавемен саклап, дошманнарга каршы көрәшә. Мондый дастаннарда батырның каршы көчләр белән героик көрәше картинасына зур урын бирелә, каһарманның аты, сугыш коралы аңа һәрвакыт ярдәмгә килә.

Төп тасвирлау объекты героика булган мондый төр дастаннар үзләренең эчтәлеге, хронологик билгеләре буенча архаик яисә тарихи-героик типта булырга мөмкиннәр. Архаик-героик дастаннар чыгышы белән ыруглык дәверенә үк барып тоташалар, героика монда табигать белән кеше, мифик образлар белән баһадир арасында барган көрәшкә корыла. Әйтик, «Түләк китабы»нда тасвирланган вакыйгалар билгеле бер катламы белән борынгы дәверләргә барып тоташалар. Биредә конфликт Түләкнең – җир кешесенең – аның өчен бөтенләй ят булган икенче бер чит дөнья вәкилләре белән бәрелешенә нигезләнә. Каһарман бу ят дөньяда Су кызының мәхәббәтен казана, әмма үз дөньясына – җиренә-суына булган җирсүе дә көчле. «Аһ, дәрига! – ди ул. – Сәнең зифа сурәтеңә алданып, адәмнәрдән

---

[1] Героический эпос народов СССР / предисл. Б.Н. Путилова. Л.: Лениздат, 1997. С. 3.

аерылып, нәсәпсез булдым! Үләр булдым! Атам-анам кайда? Ыруым бәнем – адәм!»[1] Героик дастаннарның аерылгысыз мотивы – туган илгә мәхәббәт, бу сүзләрдә үз җиреңә тугрылык чагыла.

Иҗтимагый үсешнең соңгырак чорында, халыклар формалашып, борынгы дәүләтләр барлыкка килгән дәверләрдә һәм тагын да соңгырак чорларга карый торган тарихи-героик китаби дастаннарыбыз да шактый. Алар архаик китаби дастаннар белән чагыштырганда күпчелекне тәшкил итәләр. Мондый төр дастаннарда тарихи вакыйгалар чагылыш тапкан, реаль тарихи шәхесләр пьедесталга күтәрелгән. Татар китаби дастаннарындагы мондый геройлар фольклорлашу процессында тарихилыкларын җуя төшкәннәр, реаль вакыйгалар да, әлбәттә, төрле үзгәрешләр кичереп тасвирланган. Мондый дастаннар архаиклыктан да бөтенләй азат дип әйтеп булмый. Тарихи китаби дастаннарда төрки һәм төрки булмаган эпоска хас яисә борынгы Иран, борынгы грек, Көнчыгыш язма истәлекләре белән уртак мотивлар очравы гаҗәп кызыклы. Мәсәлән, «Чура батыр» дастанында астрологлар Чураның әҗәле дошман (бу очракта урыс) кызыннан туган улыннан булуын күрәзәлиләр. Бу сюжет Борынгы Греция язма истәлекләрендә чагылыш тапкан. Грек мифларының берсендә Акрисий үз кызы Данаядан туган бала тарафыннан үтереләчәген белгәч, кызы балага узмасын дип, аны биек манарада бер бинага яшереп куя. Әмма Акрисий барыбер оттыра: Данаяга яшен алласы Зевс үзе гашыйк була һәм кызга алтын яңгыр булып керә[2].

Эпос тарихи әсәр түгел, ул – фольклор әсәре. Фольклорлашу процессы еш кына тарихи шәхесләрне эпик образларга әверелдерә, тарихның хронологиясен бозып тасвирлый яисә реальлектән бөтенләй читтә, тарихта булмаган образларны тарихи фактлар белән бәйли.

Татар халкының «Чыңгыз хан», «Аксак Тимер», «Гыйса улы Әмәт» дастаннарында реаль тарихи шәхесләр чагылыш тапкан. Бу дастаннарда сәнгатьлелектән бигрәк тарих бәян итү принцибы алга чыгарылган. Әмма бу әсәрләрне тарихи дастаннар рәтенә куя торган билгеләр шактый. Бу билгеләр вакыйгаларга карата халык карашларын гәүдәләндерүдә чагылыш таба. Тарихи шәхес образын тасвирлаганда эпик традицияләр чагылу, ягъни каһарманны ил батыры итеп сурәтләргә омтылыш та мондый әсәрләрне халык дастаны итә.

---

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан, 1984. Б. 3.

[2] Мифы в искусстве старом и новом: историко-художественная монография (по Рене Менуару). СПб., 1900. С. 119.

«Чура батыр» хикәятенә килсәк, бу әсәрне тарих белән якынайта торган фактлар аеруча күзгә бәрелеп тора. Мәгълүм булганча, дастан Казан алыну вакыйгаларын бәян итә. Дастанның Идел буе татарларыннан кала кырым татарлары, нугай, казакъ версияләре бар. Татар «Чура батыры» – башка төрки версияләр арасында иң беренче басылып чыккан китаби версия буларак аерылып тора. Бу әсәр 1862 елда И. Березин җыентыгында дөнья күрә[1].

Яу чабу, сугыш, ил-көнне яклап көрәшкә чыгу, дошман белән бергә-бер алышу күренешләрен бәян итү җәһәтеннән «Кыйссаи Сәкам», «Каһарман Катил», «Җик Мәргән», «Күр углы» кебек дастаннар игътибарга лаек. Мондый әсәрләрдә тарихилык шактый җуела төшкән, әмма аларның күбесендә сюжет бөтенлеге, идея үткенлеге, композиция төгәллеге сакланган.

Китаби героик дастаннар төркемендә героик-дини характердагы әсәрләрнең дә аерым урын алып торуына алдарак тукталып үткән идек. Аларның татар халкы рухи тормышында билгән аерым урыны һәм үз функциясе бар. Халыкның милләт буларак сакланып калу-калмавында күп очракта илдәге сәяси вазгыять зур фактор ролен үти. Билгеле бер чорда халыкта героик-дини темага мөрәҗәгатьнең артуы әнә шул фактор белән тыгыз бәйләнгән. Бу тема, әлбәттә, иң беренче чиратта дастан жанрында чагылыш тапкан. Дастанда героиканың дини-героикага күчүе – халыкның инстинкт дәрәҗәсендә үз мәдәниятен, үз традицияләрен, телен саклап калырга омтылу чарасы ул. Элгәрләре табынган ислам динендә, Аллаһ кодрәтенә ышануда халык милли һәм дини кысрыклаудан котылу һәм тынычлану тапкан. Бу исә дини эчтәлекле, күптән мәгълүм дастани сюжетларның яңаруна, героик өлгеле, ягъни каһарманлык фәлсәфәсе белән сугарылган, әмма дини характерлы дастаннарны күчереп таратуның җанлануына йогынты ясаган. Дәүләтчелек, рухи бәйсезлек проблемалары хакында турыдан-туры сөйләп булмаган элеге чор өчен мондый дастаннарның әһәмияте бик зур булган. Нәтиҗәдә, Мәскәү хаимлегендәге яңа социаль-сәяси шартлар казан татарларында героик-дини китаби дастаннарның ныклы үсеш алуына сәбәп булган. «Каһарман Катил», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Кисекбаш», «Дастаны Җөмҗөмә» кебек дастаннарның халык вариантлары – татарларда әнә шундый истәлекләрдән. Күпмедер дәрәҗәдә дөньяви карашларны чагылдыру

[1] *Березин И.* Турецкая хрестоматия. Казань, 1862. С. 41–56.

белән бер үк вакытта дини-героик китаби дастаннарда Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятыннан килә торган суфилык идеясе дә сизелә.

Әдәбиятчы һәм фольклорчы галимнәр тарафыннан шактый зур фәнни игътибарга лаек булган «Идегәй» дә, әлбәттә, – героик китаби дастаннарыбыз төркемен тулыландыра торган иң гүзәл әсәр. Татар халкының китаби «Идегәй»е себер татарларында телдән башкарылган дастан вариантларыннан кабат үсеп чыккан. Н. Хәким һәм Н. Исәнбәт версиясеннән тыш «Идегәй»нең себер татарларыннан язып алынган, чичәннәр башкаруында теркәлгән вариантларының берничә дистәдә мәгълүм булуы әлеге дастаныбызның татарларда әүвәл сөйләмә формада яшәгәнлеген раслый. Алда әйтеп үтелгәнчә, Себер җирлеге, себер татарлары биргән дастаннар китаби булып формалашкан дастаннардан бөтенләй аерылып тора. Бу аерма аларның башкарылу рәвешендә, поэтикасында, синкретик иҗат булуында һ.б. да чагыла. Халкыбызның себер татарлары этник төркемендә кайчандыр телдән башкарылган тарихи-героик эпик ядкарь XX йөздә кабат китапка күчкән.

Нигъмәт Хәким (Хәкимов Нигъмәтулла Гыйниятулла угылы, 1899–1938) – заманында Казан дәүләт педагогика институты галиме, доцент. «Идегәй» вариантын 1919 елда Себердә, элекке Тобол губернасы, Тара өязе Еланлы авылында Ситдыйк Мәһди углы Зәйнетдиновтан (1854–1927) язып ала, аны эшкәртеп төзәтә, зурайта, тәртипкә китерә, икенче төрле әйткәндә, җыйнама текст төзи. «Идегәй»нең Н. Хәким варианты – күләмле, тезмә катыш чәчмә әсәр.

Конкрет чичән авызыннан язып алынган текстны күпмедер дәрәҗәдә үзгәрткәннән соң, Н. Хәким дастанның бер нөсхәсен Ленинград университеты профессоры академик А.Н. Самойловичка җибәрә, текстны китап итеп чыгару ниятен әйтеп, шул китапка галимнән кереш сүз язуын үтенә. Бу эш шактый озакка сузыла, шул һәм башка сәбәпләр аркасында Н. Хәким әзерләгән «Идегәй» үз вакытында дөнья күрми кала.

Текст А.Н. Самойлович аша соңрак П.А. Фалев кулына эләгә. П.А. Фалев – А.Н. Самойлович шәкерте, дөресрәге, аның лекцияләрен иркәле тыңлаучы. П.М. Мелиоранский васыяте буенча А.Н. Самойлович Идегәй белән Туктамышка багышланган барлык версияләрне дә туплау һәм өйрәнү эшен җанландыра. 1911 елда әлеге өлкәдә иң уңышлы эшләүчегә махсус алтын медаль билгеләп,

Петербург университеты студентлары арасында конкурс игълан ителә. 1922 елда бу медальгә нәкъ менә П.А. Фалев лаек була. Әмма мәшһүр эпосның төрле версияләрен җыйнауда пионер дип табылган П.А. Фалев Ташкентта басылган хезмәтендә «Идегә»не «ногайские сказания» дип атый, бередә ни сәбәпледер дастанның В. Радлов варианты да, Н. Хәким варианты да бөтенләй телгә алынмый[1].

Соңлап булса да, академик А.Н. Самойлович Н. Хәким текстына карата кереш сүз язып, Казанга җибәрә. Әлеге фәнни язма Казан педагогика институты профессоры Л. Җәләй кулына килеп кереп, аның архивыннан бераз соңрак Х. Ярмигә күчә. В.М. Жирмунский соравы буенча, Х. Ярми аны 1969 елда Ленинградка юллый. Бу хакта мәгълүмат һәм А.Н. Самойлович мәкаләсе тексты үзе Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең тасвирланмаган фондында саклана. Анары бу мәкалә С.Г. Кляшторныйга тапшырылып, 1972 елда «Тюркологический сборник»та дөнья күрә[2].

«Идегәй»нең Н. Хәким варианты А.Н. Самойлович тарафыннан югары бәяләнгән: «Запись сказания о Едигее и Тохтамыше, произведенная Н. Хакимовым со слов Сыддык-карта ... является обширной и наиболее в литературном отношении ценной». Дастанның үзенә билгеле нөсхәләре арсында Н. Хәким вариантын галим В. Радлов вариантларыннан соң дүртенче урынга куя. «В мои намерения не входит всестороннее исследование нового, чрезвычайно ценного в историко-литературном отношении варианта о Едигее, найденного Н. Хакимовым в Западной Сибири. Такое исследование, надеемся, появится в свет за подписью национальных ученых Татарии, Казахстана, Дагестана, Крыма или Узбекистана после опубликования настоящей записи варианта Сыддык-бабая»[3], – дип язган галимнең ышанычы бик озак тормышка ашмый тора. Н. Хикмәт тексты 2003 елгача беркайда да басылмый. Дастанны бәян иткән Ситдыйк бабайга да, әлбәттә,

---

[1] Лекции, читанные проф. П.А.Фалевым в 1921 году в Туркестанском Восточном Институте. На правах рукописи. Ташкент, 1922.

[2] *Самойлович А.Н.* Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше, записанный Н. Хакимовым // Тюркологический сборник. 1972. М.: Наука. Главная ред. восточной лит-ры. С. 186–211.

[3] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең тасвирланмаган фонды материалларыннан.

яңадан мөрәҗәгать итүче булмый, аның башкаруында «Идегә»нең ни рәвешле яңгыраган булуын бүгенге көндә белү мөмкин түгел.

Бу кешенең (Ситдыйк Зәйнетдиновның) нәсел-бабалары Көнбатыш Себергә Урта Азиядән – Бохарадан килеп урнашкан булганнар. Бабасы кебек үк, Ситдыйк карт та олаучылык белән шөгыльләнгән. Сәүдә йөге белән Иркутск, Томск, Казан, Түбән Новгород, казакъ далаларына, Урта Азия шәһәрләренә йөргән, мәдрәсә белемле, гарәп телен белгән, халыкның эпик иҗатына мөкиббән шәхес булган. Улы Әҗем сөйләве буенча, 90 нчы еллардан бирле «Идегә»не ул җирле халыкка аңлаешлы туган телендә – тара татарлары телендә сөйләгән[1].

Ә инде Н. Хәким төзегән җыйнама вариант әле бүгенге көнгә кадәр чагыштырма планда җентекле өйрәнелмәгән. Әсәр беренче кат фольклорчы галимә Ф. Әхмәтова тарафыннан әзерләнеп басылып чыкты[2]. Соңрак дастан варианты «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгына кертелде[3]. Дастанның берничә күчермәсе Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондында саклана[4].

Н. Хәким варианты – татар халкының героик китаби дастаннар рәтен баета торган гаять күркәм әсәр. Китаби дастан термины белән атамаса да, дастанның чичән-импровизаторныкыннан аерылып торган ягына үз чорында академик А.Н. Самойлович та әһәмият биргән. Тексттагы берничә шигъри юлның тел-стиль ягыннан сизелерлек аерылып торуына игътибар итеп, ул бу юлларның борынгы дастаннанмы, әллә соңгырак чор иҗатымы икән дигән сорау куя[5]. Чичән-импровизатор тарафыннан чарланган дастан белән китаби дастан арасында принципиаль аермалар булу, әлбәттә, табигый. Тел-стиль

---

[1] *Валеев Ф.Т. С.М. Зайнитдинов.* Приложение к статье А.Н. Самойловича // Тюркологический сборник. 1972. М.: Наука. Гл. редакция восточной лит-ры, 1973. С. 212–213.

[2] *Әхмәтова-Урманче Ф.* Документларның да үз язмышлары. Идегәй. Татар халык дастаны // Казан утлары. 2003. № 9. Б. 102–135.

[3] Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләрне язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. Б. 286–331.

[4] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, ф. 52, оп. 1, сак. бер. 166, 167, 176, 177, 178 һ.б.

[5] *Самойлович А.Н.* Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше, записанный Н. Хакимовым // Тюркологический сборник. 1972. М.: Наука. Гл. редакция восточной лит-ры, 1973. С. 205.

ягыннан да, композицион билгеләре белән дә үзгәрешләр кичергәнгә күрә һәм галим-белгеч тарафыннан махсус эшкәртелеп оешканлыгына нисбәтән текст хезмәтебездә татар китаби дастанының аерым тибы үрнәге итеп карала. Бу исә китаби «Идегәй»не башка версия-вариантлары белән чагыштырма характерда тикшерүнең татар халык иҗатында әле һаман да актуаль булуы хакында сөйли.

Мәшһүр «Идегәй»нең Н. Хәким варианты һәм Н. Исәнбәт исеме белән йөри торган классик текст китаби дастаннар барлыкка килүнең иҗтимагый-тарихи сәбәпләрен барлаганда үзенә бер шартларда туган эксклюзив китаби истәлек буларак кыйммәт.

Татар китаби дастаннарыннан зур бер төркемне героик китаби дастаннар дип аеру һич тә очраклы түгел. Бу төркемгә керә торган эпик әсәрләребез шактый. Әлеге төркемдәге дастаннарыбыз борынгы мифологияне, тарихи үткәнне, дини тәгълиматны һәм әдәби үсеш сфераларын берьюлы колачлый, мәдәниятнең әлеге мөһим өлкәләренең һәркайсын үз эчтәлегенә җиңел сыйдыра. Алга таба хезмәтебездә татар халкы тарихындагы кайбер героик дастаннар махсус җентекле тикшерүгә алына.

### § 1. «Каһарман Катил» дастанында тарихи-мәдәни катламнар гармониясе

Идел-Урал буе татарларының «Каһарман Катил» дастаны – язма формалы халык эпосы, героик китаби дастан. Төрле фәнни үзәкләрдә «Каһарман Катил»нең XVIII йөздә казан татарлары тарафыннан күчерелгән кулъязмалары саклана, ә XX йөз башыннан ул мәркәзебез типографияләрендә берничә кат басылып та чыккан.

Аның исеме татар фольклоры тарихында күптәннән билгеле. XX гасырның егерменче елларында татар әдәбиятының күренекле галиме Г. Ибраһимов үз хезмәтендә «Каһарман Катил»не, халкыбызның «Йосыф – Зөләйха», «Таһир – Зөһрә» сюжетлы ядкарьләре, «Бүз егет», «Кыйссаи Сәед Баттал» һ.б. истәлекләре белән бер рәттән телгә алып узган. Бу мәкаләсендә әдип, татар әдәбиятында дәверләр мәсьәләсенә кагылып, «Каһарман Катил»нең дә «кадимге Шәрекъ (борынгы Көнчыгыш. – *Л.М.*) – Русия мөселманлыгы» дәвере әсәрләреннән булуын искәрткән, мондый әсәрләрнең җирлеген «үзенең дине, фикере, иҗтимагыйәте, бөтен тормышы белән бөтен Шәрекъкә гам булган (уртак булган. – *Л.М.*), шулар кыйбласына карап барган» ядкарьләрдән дип билгеләгән. Димәк, әдәбият белемендә

Г. Ибраһимов чорында ук бу һәм башка күп кенә әсәрләргә «бу дәвернең халыкка җан азыгы булган кыйммәтле әдәби җәүһәрләре» дигән теоретик караш булган, теге я бу дәрәҗәдә аларга бәя бирелгән[1]. Шулай да «Каһарман Катил»нең әдәбиятыбыз тарихында булу фактын искә алудан гыйбарәт хезмәтләрдән башка әдәбият белемендә һәм фольклористикада XX йөзнең ахырларынача аңа багышланган махсус фәнни хезмәтне атый алмыйбыз. Бүгенге көнгә кадәр ул хаксыз рәвештә фәнни яктан тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән эпик ядкарьләр рәтендә кала килде.

Бу әсәр татар китаби дастаннарының фәкать язмача көн күргән беренче тибына карый. Хәлбуки «Каһарман Катил»нең сөйләмә формада таралган вариантлары яисә фрагментлары казан татарларында гомумән юк. «Каһарман Катил» версиясе татарларда ике төрле формада көн күргән: әүвәл кулъязма нөсхәләр булып таралган, соңрак китаплар рәвешендә нәшер ителгән[2].

Кулъязма һәм басма рәвештә XX йөзнең 20 нче елларынача актив таралган татар версиясе «Каһарман дастаны», «Каһарман хикәяте», «Каһарман», «Каһарман китабы», «Каһарман Катил», «Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил», «Кыйссаи Каһарман» исемнәре белән мәгълүм. XIX йөз ахыры – XX йөз башынача татар халык иҗатында китаби дастаннарның халыктагы исеме «дастан», «хикәят», «кыйсса», «китап» төшенчәләре белән дә йөргән булуына һәм аларның барысының да асылда бер үк жанрны аңлатуына алдагы бүлектә тукталган идек. Чыганакта нинди атама белән бирелүен искәртеп тормастан, алга таба «дастан» термины «Каһарман Катил»нең барлык кулъязма һәм басма нөсхәләренә карата гомумән кулланыла.

Кулъязма нөсхәләрендә күчерүче-информантларның казан татарлары булуы, әсәр теленең Идел буе татарлары сөйләшенә, дөресрәге, үз чоры әдәби теленә тәңгәллеге, ахыр килеп, язма

[1] *Ибраһимов Г.* Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы// *Ибраһимов Г.* Әсәрләр. Сигез томда. Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 339.

[2] Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Казан: Бр. Кәримовлар нәшере, 1912. 116 б.; Кыйссаи Каһарман. Казан: Ун-т тип., Ш. Хөсәенов варислары нәшере, 1913. 14 б.; Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы. Казан: Матбагаи «Кәримия», 1914. 116 б.; Каһарман Катил. Казан: Милләт, 1915. 16 б.; Кыйссаи пәһлеван. Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә алып укырга бик кызыклы. Казан: Матбагаи «Кәримия», 1918. 87 б. һ.б.

вариантларының иң әүвәл нәкъ менә татар мәркәзе Казанда басылып таралганлык фактлары үзләре үк әлеге әсәрне Идел буе татарлары версиясе буларак карарга ныклы нигез булып тора.

Фольклор текстлары өчен кагыйдә буларак, дастанның кульязма нөсхәләре берничә. Күчермәләрнең барысы да татар кешеләре тарафыннан башкарылган. Кайбер очракларда күчерүченең исеме нәмәгълүм. Әмма язу рәвешенең төрлелеге аркасында кульязмаларның һәркайсы аерым шәхес тарафыннан башкарылган булуны расларда кыенлык тумый. Дөрес, әсәрнең эчтәлеге, вакыйгалар эзлеклелеге, образлар системасын гомумән алганда кульязмаларда әллә ни җитди аермалар бар дип әйтеп булмый, алай да кыйммәтле борынгы күчермәләрнең һәркайсы, күчерүче-информантның каләменә бәйле тулылык-кимлек, синтаксик аермалар җәһәтеннән, күчерелү вакытына, кем кулы тарафыннан һәм кайда күчерелгән булуына нисбәтле рәвештә, аерым вариантлар буларак каралырга хокуклы.

Беренче кульязма вариант – дастанның Казан шәһәрендә яшәүче Сания Кәримова һәм Рабига Замановаларда сакланып, 1984 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивына тапшырылган тулы күчермәсе. XVIII гасыр кульязмасы 270 кәгазьдә, яхшы сакланган. «Каһарман Катил» дип исемләнгән[1]. Күбрәк өлеше чәчмә юллардан торган, берничә урыннарда тезмә белән аралашкан күләмле текст. Лексик һәм грамматик җәһәттән теле шактый үзенчәлекле, ягъни бүгенге көн укучысы өчен авыр аңлаешлы. Әлеге кульязмадан зур гына бер өзек, хәзерге язуга транскрипцияләнеп, «XVIII йөз татар әдәбияты» җыентыгында дөнья күрде[2].

Икенче кульязма вариант – 1861 елда Казанда Мөхәммәтсадыйк бине Мөхәммәтҗан бине Мөхәммәтәмин бине Гобәйдулла бине Йосыф бине Кадир бине Бикмәмәт исемле кеше тарафыннан күчерелгән янә бер шактый тулы күчермәсе. Титул битендә исеме «Каһарман Катил кыйссасы» дип күрсәтелгән[3].

---

[1] Татарстан ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, колл. 39, сак. бер. 3497. Алга таба хезмәтебездә бу нөсхәне [К.К.I] дигән шартлы билге белән күрсәтербез.

[2] XVIII йөз татар әдәбияты: Проза. Казан, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. 2012. Б. 55–106.

[3] Татарстан ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, колл. 39, сак. бер. 6121. Алга таба хезмәтебездәге шартлы билгесе – [К.К.II].

Өченче кулъязма вариант – Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана торган берничә нөсхәсе[1]. Биредә барлыгы 7 кулъязма теркәлгән. Күчермәләр шактый таушалган, тулылык ягыннан да алдагыларыннан шактый калышалар. Барысы да хәзерге Татарстан территориясендә табылган. Күчерүчеләре – татар кешеләре.

Дүртенче кулъязма вариант – XVIII йөзгә караган күчермәсе, ул Татарстан Республикасы дәүләте Милли музееның әдәбият фондында саклана[2].

Бишенче кулъязма вариант – XVIII йөзгә караган тагын бер кулъязма. Ул Ереванда Матенадаран институтында 596 нчы санлы документ булып саклана[3].

Алтынчы кулъязма вариант – дастанның кечкенә хикәят рәвешендә йөргән кулъязмасы[4]. Аны 1973 елда археографик экспедиция вакытында Татарстанның Әтнә районы Олы Мәңгәр авылыннан М. Әхмәтҗанов табып алып кайткан. Күчермә 14 битлек фрагментар характердагы тексттан гыйбарәт. «Каһарман хикәйәте» дигән исем куелган. Биредә Каһарманның Икъвалзәррә (К.К.I һәм К.К.II һәм басма вариантларында – Әквал дию) исемле дию белән көрәше сурәтләнгән. Бу вариант татарларда зур дастаннан бер өлешне аерып алып, күчереп тарату гадәте яшәгәнлекне раслый торган факт буларак кыйммәт. Дастанны күчерүче-информант әсәрнең әһәмиятле саналган өлешеннән мөстәкыйль укылып йөри торган әсәр оештырган, алга таба әлеге өлешне аерым хикәят итеп бирү традицион төс алган. Кулъязманың факсимилесы белән бергә, Каһарман пәһлеванның дию белән каты көрәшен тасвирлаган бу кыска хикәятнең текстологик эшкәртелгән варианты безнең көннәрдә матбугатта кабат дөнья күрде[5].

---

[1] Казан (Идел буе) федераль университетының Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар фонды. Т 141, Т 518, Т. 519, Т 646, Т 741, Т 762, Т 2262. Алга таба хезмәтебездәге шартлы билгесе – К.К.III].

[2] Татарстан Республикасы Дәүләт Милли музееның әдәбият фонды. Шифр Л 3027. Алга таба хезмәтебездәге шартлы билгесе – [К.К.IV].

[3] Хезмәттәге шартлы билгесе – [К.К.V].

[4] Татарстан ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инстутының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, колл. 39, сак. бер. 6026. Алга таба хезмәтебездәге шартлы билгесе – [К.К.VI].

[5] *Әхмәтҗанов М.И.* Каһарман хикәяте// Татар дәүләт гуманитар институты. Гыйльми язмалар. Ученые записки. 8 нче чыгарылыш. Казан, 2000. Б. 129–134.

«Каһарман Катил»нең басма формадагысына килсәк, дастанның кулъязмалары белән чагыштырганда басма формада да әллә ни җитди аермалар юк. Халык әсәренең таралу спецификасына хас булганча, чыганак бер генә басмада да күрсәтелмәсә дә, басма формадагы «Каһарман Катил»нең нәкъ менә милли татар кулъязмалары тәэсирендә һәм фәкать шулар нигезендә дөнья күргән булуы шиксез. Бу – татар китаби дастанының әлеге тибы өчен характерлы яшәү-таралу үзенчәлекләрен чагылдыра торган әһәмиятле күренеш. Чорга бәрабәр лексик-грамматик аермаларны исәпкә алмаганда, кулъязмалар аша соңрак басылып чыгып, халыкта басмача таралган «Каһарман Катил» дастанының сюжетында, образ-персонажлар бирелешендә кулъязма нөсхәләрдән аерылып тора торган артык зур үзенчәлекләрне күрсәтеп булмый. Басма «Каһарман Катил»нең теле, әлбәттә, бүгенге көн әдәби татар теленә якынрак тора.

Биредә татар китаби дастаннарының фәкать язмада гына көн күргән беренче тибына хас закончалык хөкем сөрә: күчерүче-информант (соңрак басучы мөхәррир) мондый төр дастаннарның сюжетына артык зур үзгәрешләр кертүне хупламый, мәгълүм нөсхәдәгечә бирүне дөрес дип табып, шул хакыйкатькә омтыла. Мондый кагыйдә татар китаби дастаннарыннан «Түләк китабы» нөсхәләрендә, Гыйсә улы Амәт, Чыңгыз хан, Аксак Тимергә багышланган язмаларда һ.б. әсәрләргә дә турыдан-туры кагыла. «Түләк» нөсхәләренә мөнәсәбәттә Р. Мәрданов[1], «Чыңгызнамә» циклына керә торган «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан турындагы дастан», «Аксак Тимер турындагы дастан» кулъязмаларына мөнәсәбәттә М. Госманов[2] һ.б. галимнәр әлеге дастаннарның мәгълүм нөсхәләрендә аермаларның нигездә тулылык-кимлек, синтаксик-орфографик үзенчәлекләр, кулъязмаларның саклану сыйфаты һ.б. нечкәлекләргә кайтып калуын билгелиләр. Әлбәттә, мондый тип ядкарьләрдә һәрбер дастанның аерым нөсхәсе үзенә генә хас текстологик үзенчәлекләргә ия, вариантлар шуның белән бер-берсеннән аерылалар да. «Каһарман Катил» – зур әсәр, биредә сюжет корылышы әсәрдән күпләгән мөстәкыйль хикәятләр аеру мөмкинлеген тәэмин итә ала. Әмма бу һәм башка күләмле дастанны күчерүче-информант мондый иҗат мөмкинлекләреннән файдалана

[1] Түләк китабы: дастан / төз.-авт. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 76 б. («Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап).

[2] *Усманов М.Г.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. С. 97–134.

алмый, чөнки жанр таралышында мондый традиция булмаган. Шуңа бәйле рәвештә дастанның фәкать традицион төстә аерымланып килә торган өлеше генә («Каһарман Катил» очрагында ул – мифик дөньяда Каһарманның Әквал дию белән көрәшен тасвирлаган эпизод) игътибар үзәгенә алынган. Китаби дастанның әлеге тибында жанр моделе тексттагы бер генә блокның да төшеп калмавын таләп иткән. Дастанның телдән башкарылмыйча, язма формада реальләшүе дә мондый төгәллекне саклау өчен стимул булган. Шуңа күрә, язылмаган кагыйдә буларак, мондый дастаннар белән эш иткәндә күчереп язучы яисә бастырып чыгаручы тарафыннан текстка артык зур үзгәрешләр кертелүгә юл куелмаган.

Текстның күләменә нисбәтән басма формалы «Каһарман Катил» ике төргә бүленә.

Беренчесе – кыска хикәят рәвешендә басыла килгән төр, 14–16 битлек китапчыклар рәвешендә көн күргән[1]. Кыска төрдә зур дастаннан бер эпизодны яисә әһәмияткә ия вакыйганы тасвирлаган өзек китерелгән. Зур күләмле дастаннан кечерәк хикәятләр аерымлану күренешенә алдарак тукталган идек. Бу очрак – нәкъ менә шул традициянең бер чагылышы, татарларда зур әсәрнең бер өлешен генә күчереп язу һәм хәтта соңрак шул рәвештә бастырып чыгару үрнәге.

Әсәрнең басма формага кертелгәннәренең икенчеләре исә – дастанның тулы, зур күләмле басмалары. Болары 87 һәм 116 битлек шактый саллы китаплардан гыйбарәт[2]. Боларда вакыйгалар катлаулы сюжет нигезендә бәян ителгән.

Димәк, «Каһарман Катил» дастанының безнең халыкта ике төре дә – кыска хикәят рәвешендәгесе дә, катлаулы сюжетка корылган күләмлесе дә популяр булган. XVIII гасырга нисбәтле кулъязмаларында очраган үзенчәлекләр аның XX йөз башындагы басмаларында да нигездә үзгәрешсез кабатланган. «Каһарман Катил»нең ике төрле – кыска һәм озын варантларда халыкта яшәве XVIII гасыр – XX йөз башы аралыгында ныклы традициягә әверелгән.

---

[1] Кыйссаи Каһарман. Казан: Ун-т тип., Ш. Хөсәенов варислары нәшере, 1913. 14 б.; Каһарман Катил. Казан: Милләт, 1915. 16 б. h.б.

[2] Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Казан: Бр. Кәримовлар нәшере, 1912. 116 б.; Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы. Казан: Матбагаи «Кәримия», 1914. 116 б.; Кыйссаи пәһлеван. Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә алып укырга бик кызыклы. Казан: Матбагаи «Кәримия», 1918. 87 б. h.б.

Гомумән алганда төрле нәшриятларда басылган текстларның сюжетында, образлар системасында әллә ни принципиаль аермалар юк, «Каһарман Катил» дип бирелгән әсәрнең кыскасында да (кыска дигәндә биредә зур әсәрнең кыскача эчтәлегеннннән гыйбарәт текст күздә тотылмый, сүз шушы әсәрдән шул ук исем белән аерымланган хикәят турында бара), озынында да сүз бер үк каһарман турында бара, сюжет бер үк вакыйгалар нигезендә үстерелә. Әмма әсәрнең исеме әле «Каһарман Катил», әле «Кыйссаи Каһарман Катил» яисә «Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил» формасында төрләнеш кичерә. Әлбәттә, һәрбер аерым басмада әсәр исеменең үзенчәлекле яңгырашка ия булуы – XX йөз башы татар әдәбиятына хас формаль мәсьәлә. «Каһарман Катил»гә карата халык иҗатында «дастан» мәгънәсендә кулланыла килгән һәр атаманың (кыйсса, хикәят, китап һ.б.) актив булуы мәгълүм. Күләмле фольклор әсәрләренең үзатамасына мөнәсәбәттә мондый төрлелекне алдарак бу чорда терминнар янәшәлегенең популярлыгы һәм әлеге мәсьәләдә принципиаль кагыйдәләрнең юклыгы белән аңлаткан идек. Монда халык терминологиясе белән фәнни терминологиянең һәрвакыт туры килеп бетмәвен дә итсә тотарга кирәк. Каһарман Катил исеме белән бәйле дастаннар да халыкта төрле үзатама белән йөргән. Әлбәттә, татар матбугатының чәчәк аткан һәм нәшриятларның күплеге белән дан тоткан бу дәвердә (XIX йөзнең беренче яртысыннан нәшриятлар саны һәм басылган продукциянең тиражы буенча татар китабы Россиядә рус китапларыннан кала икенче урында торган[1]) китаби дастан исемнәрен махсус рәвештә мөмкин кадәр төрләндереп бирергә омтылышның булуы да әһәмиятле роль уйнаган. Шуннан чыгып, дастанның күпмедер дәрәҗәдә яңача яңгыраштa басылып чыгуын инде моңа кадәр катькат басылган әсәргә кабат тукталган нашир-нәшриятларның бертөрлелектән качарга, азмы-күпме яңалык кертергә омтылышы дип тә бәяләргә мөмкин. Әмма бу – чынлыкта мәсьәләнең тышкы ягы гына.

Татарларда «Каһарман Катил» дастаны феномына тирәннәнрәк караганда исә шунысы ачык: күчерелүе XVIII йөзгә караган кульязмаларыннан башлап, XX гасырның 20 нче елларына кадәр гарәп язулы китаплар булып шактый зур тираж белән басыла килгән икән (әйтик, 1912 елда «Кәримия» нәшриятында китапның 6000 гә якын,

---

[1] *Каримуллин А.Г.* У истоков татарской книги. От начала возникновения до 60-х годов XIX века (Издание 2-е, испр. и пер.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. С. 196.

ә 1913 елда «Ш. Хөсәеновлар нәшере»ндә төгәл 6000 данә белән басылуы мәгълүм[1]), димәк, «Каһарман Катил»гә халыкта, шиксез, ихтыяҗ булган, әсәр кабул ителгән, яратып укылган, таралган һәм – иң әһәмиятлесе – хәтта «Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы»[2] дигән тәкъдимнәр белән өндәп, рекламалау рәвешендә халыкка аңлы һәм максатчан рәвештә таратылган.

Шул рәвешчә, әсәр әдәби мирасыбызда шактый ныклы урын алган. Татар героик китаби дастаны халык тормышында эмоциональ-экспрессив дәрәҗәдәге рухи азык, тәэсирле язма укып, күңел юату, вакыт уздыру чарасы гына булмыйча, тарихның халык өчен хәлиткеч әһәмияткә ия бер этабында үзенә күрә бертөрле идеологик функция дә үтәп килгән. Мөселман илендәге ислам гаскәренең героик маҗараларын бәян иткән «Каһарман Катил» дастанының да татарларда шушындый популярлыгы төрки героик дастаннарга хас әлеге функция белән турыдан-туры бәйләнештә булу ихтималы зур. Әсәр ислам гаскәренең Һинд иленә яу белән килүенә мөнәсәбәтле бәяннан гыйбарәт. Башка дини конфессиядәге рус дәүләте составында гомер кичергән мөселман-татарлар, рус илендәге тәртипләр белән ачыктан-ачык көрәшмәсәләр дә, «Каһарман Катил», «Кыйссаи Сәкам», «Кисекбаш» кебек дини-героик дастаннары аша хөкүмәтнең эчке һәм тышкы сәясәте белән килешмәүне белдергәннәр. Дастанда көрәшнең бөтен дөньяда ислам җиңүенә юнәлтелгән булуы да бик зур эчке мәгънәгә ия. Шул һәм башка сәбәпләр бу әсәрне татар халкына якынайткан һәм шактый күп нөсхәләр булып таралуына йогынты ясаган. Иң беренче чиратта нәкъ менә фәлсәфи рухлы һәм шактый бай идея-эстетик кыйммәткә ия булуы «Каһарман Катил»не халыкның китаби дастаны дип карау ихтыяҗын китереп чыгара.

Гарәп язулы, татар телле «Каһарман Катил»не текстологик эшкәртеп, фәнни әйләнешкә кертүче – әдәбиятчы-текстолог галим, филология фәннәре докторы М. Әхмәтҗанов. Галим дастанның борынгы кулъязмаларын барлаган, шуларга таянып, әсәрнең өр-яңа кулъязмаларын тапкан, әлеге ядкарь текстларын укып-өйрәнеп, текстның телен бүгенге сөйләмгә якынайтып, әтрафлы кереш сүз белән әсәрне аерым китап рәвешендә халыкка кире кайтаруга

[1] *Гилазев З.З.* Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2005. С. 149, 148.

[2] Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы. Казан: Матбагаи «Кәримия», 1914. Б. 1.

ирешкән[1]. «Каһарман Катил»нең һәрбер кульязмасы белән яхшы таныш галим дастанны безнең көннәргә кайтару өчен нигез итеп аның 1918 елгы басмасын алган. Текст бүгенге көндәге дөрес язу кагыйдәләренә яраштырып, укучыга авыр аңлаешлы сүзләргә аңлатмалар белән һәм типография тарафыннан җибәрелгән хаталарга корректура ясап тәкъдим ителгән. М. Әхмәтҗанов китабында 1918 елгы басмадагы җитешсезрәк урыннарны әсәрнең кульязмаларында сакланган текст белән ялгап куйган урыннар да күзгә чалына. Бу хакта автор-төзүче һәр очракта үзе дә искәртеп уза.

Монан тыш «Каһарман Катил» кульязмаларына әһәмият бирүче галимнәребездән шулай ук текстолог-галим, гарәп теле белгече Рәшит Кадыйров хезмәтен күрсәтү мөһим. Р. Кадыйров тарафыннан дастанның иң беренче табылган һәм иң тулы, камил саналган күләмле (270 кәгазьдән гыйбарәт) нөсхәлләреннән [К.К.I] варианты текстологик эшкәртелеп, кириллицага күчерелгән. (Бу текст әлегә дөнья күрмәде, ул авторның үзендә кульязма рәвешендә саклана). Шул ук кульязмадан ([К.К.I]) транскрипцияләнгән бер өзек Төркиядә төрекчә дөнья күргән «Төркиядән читтәге төрки әдәбиятлар антологиясе»нең «Татар әдәбияты» дигән томына кертелгән[2]. Бу җыентыкта дастанның бер өлеше латин хәрефләре белән татар һәм төрек телләрендә басылган. Биредә искәртелгәнчә, тәкъдим ителгән өзек М. Әхмәтҗанов тарафыннан эшләнгән.

Хезмәтебездә «Каһарман Катил» турында сүз алып барганда төп объект буларак бүгенге көндә иң тулы рәвешендә халыкка кире кайтарылган вариантны – М. Әхмәтҗанов тарафыннан 1918 елгы басмасы нигезендә эшләнгән дастанны алырбыз, дастан текстыннан мисалларга мөрәҗәгать иткәндә шушы вариантка нигезләнербез.

Чарланган-камилләшкән вербаль фольклор текстына әверелү өчен әсәр әллә ничә гасырны үтеп формалашырга мөмкин. Тарихлар кичкән мондый әсәр гадәттә үз тукымасына чорына хас үсешүзгәрешләрне һәм җирле үзенчәлекләрне дә сеңдерә бара, ягъни үз юлында төрле катламнар тәэсирен кичереп, фольклор әсәре булып оешып җитә. Шуңа күрә, әгәр текстта хронологик фактлар сакланмаган яисә бөтенләй дә юк икән, фольклор әсәренең нәкъ менә кайсы

[1] Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар.кит. нәшр., 1998. 221 б.

[2] Каһарман китабы. (XVIII Yuzyil)// Baslangicindan Gunumuze Kadar Turkiye disindaki Turk Edebiyatlari antolojisi. T. 18. Tatar Edebiyati. II. Ankara: Kultur Bakanligi, 2001. С. 183–197.

чорда барлыкка килүен тәкърарлау – шактый катлаулы һәм бәхәсле мәсьәлә. Бу мәсьәләдә фольклорда күп очракта идеаль төгәллekkә ирешеп булмаска да мөмкин. Ә менә эпик сюжетның кайсы чыганакка барып тоташуын нигездә ачыклап була. Дастанның тамырларын барлау аша күп кенә принципиаль сорауларга да җавап табарга, хәтта әсәрнең барлыкка килү вакытын чамаларга да мөмкинлек туа.

Бу җәһәттән, ягъни үзенең генетик тамырлары белән «Каһарман Катил» дастаны борынгы дәверләрдән мәгълүм фарсы телле чыганак – «Каһарманнамә»гә барып тоташа. Борынгы фарсы истәлеге «Каһарманнамә»нең исә XI–XIII йөзләргә караганлыгы, аның бик борынгы фарсы эпосы йогынтысында барлыкка килгән аноним әсәр булуы мәгълүм[1]. Фарсы әдәбиятындагы мондый әсәрләр язма характерда булып, «төрле җәмәгать урыннарында профессиональ чичәннәр тарафыннан телдән башкарыла торган булганнар» («но обычно устно исполнялись грамотными профессиональными сказителями на разного рода собраниях»)[2]. «Каһарманнамә» чоры Иран һәм Урта Азия әдәбиятларына характеристика биргән галимнәр фикеренчә, бу – халык традицияләре дә, заманының алдынгы, аристократларча, клерикаль тенденцияләре дә әсәрнең үз эчендә берьюлы үзенчәлекле чагылыш тапкан каршылыклы, катлаулы ядкарь (один из замысловатых анонимных произведений периода «классической поэзии на фарси, внутри которого с народными традициями своеобразно переплетены передовые, аристократические, клерикальные тенденции литературы одновременно»)[3]. Аңа халык китабы тибындагы аноним әсәр дигән билгеләмә тәңгәл. Фарсы телле «Каһарманнамә» турында гомумән мәгълүматлар бик аз, булганнары аны Иран һәм Урта Азия әдәбиятларына күзәтү ясаганда борынгы Иран эпосы реминисценцияле язма истәлек дип телгә алудан узмый. Төрки-татар «Каһарман Катил»е сюжет-мотивларында, персонаж исемнәрендә һ.б.да фарсы-иран эпик традицияләренең шулай ук бик нык күзгә чалынуына нигезләнеп, бу әсәрнең тамырларын нәкъ менә шушы ядкарьдән эзләргә мәҗбүр булабыз. Фарсы «Каһарманнамә»се – беренчел чыганагының да, үзенең дә авторы гомумән билгесез язма истәлек.

[1] *Брагинский И.С.* Литература Ирана и Средней Азии // История всемирной литературы: в девяти томах. Т. 2. М.: Наука, 1984. С. 266.

[2] История всемирной литературы: в девяти томах. Т. 2. М.: Наука, 1984. С. 265.

[3] Шунда ук. Б. 277.

Беренчел чыганагына нисбәтән, татар «Каһарман Катил»енең дә авторы нәмәгълүм.

Төрле чыганаклар тәэсирендә Иран террриториясендә туган әдәби-мифологик сюжет-мотивларның Борынгы чорлардан алып Урта гасырлар буена тирә-юнь халыкларга гаҗәеп зур йогынты ясап килгәнлеге мәгълүм. Бу йогынты шактый зур ареалны били, үз чорында Иран белән күршеләр мөнәсәбәтендә яшәгән халыклар әдәбиятына һәм фольклорына гомумән карый. Әлбәттә, мондый йогынтының бер генә яклы булмыйча, тарихи үсеш процессында күрше-тирә төрки һәм төрки булмаган кабиләләрнең үзләренең дә Иран әдәбияты-мәдәниятенә үзгәрешләрне шактый керткәнлеге аңлашыла. Шуңа күрә фарсы язма чыганаклары күп очракта үзләре дә чын мәгънәсендә төрле культура ассимиляциясе катламнарыннан гыйбарәт.

«Каһарман Катил»гә мөнәсәбәттә шунысына игътибар итәргә кирәк: татар версиясенең беренчел чыганагы, ягъни фарсы язма истәлеге «Каһарманнамә» дастанының ватаны – Урта Азия, Иран һәм Азәрбайҗан регионы ул – соңгырак этапта төрки кабиләләр күпләп үтеп кергән төбәк тә. Биредә X–XI йөзләрдә иран һәм төрки элементлар катнашкан өр-яңа мәдәният формалашкан, вакыт узу белән соңгыларының роле үсә генә барган. Әлеге факт иран эпосының да, төрки элементларга нык кына баеп, билгеле бер этапта төрки-иран эпик традицияләре синтезыннан гыйбарәт иҗат булып әверелүе турында сөйли[1]. Иран язма истәлеге булган «Каһарманнамә»нең барлыкка килүе әлеге синтез инде күптән формалашкан чорга туры килә. Төркиләр күпләп үтеп кергән әлеге төбәктә табылган язма чыганакның биредә нәкъ менә төркиләр тәэсирендә популярлашкан булу ихтималы да юк түгел. Көнчыгыш фарсы җирләрендә X гасыр башыннан төрки династияләр – Караханилар, Газнәвиләр, Сәлҗүкләр династияләре хакимлек иткән[2]. Әлеге территорияләрдәге алга киткән төрки мәмләкәтләрнең берсе – Караханилар дәүләте (942–1212[3]), мәсәлән, Урта гасырларда барлыкка килгән Көнчыгыш

[1] *Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983.

[2] Восточные персидские земли и Центральная Азия до прихода турок и сельджуков // URL: http://runivers.ru/doc/isl/index.php?SECTION_ID=278&IBLOCK_ID=50 (дата обращения –3.03.2012 г.)

[3] История Восточного Туркестана. Википедия // URL: http://ru.wikipedia.org/wiki (дата обращения – 3.03.2012 г.)

Ренессансының мөһим төрки үзәге санала[1]. Күчмә һәм утрак уйгыр кабиләләре кушылуыннан барлыкка килгән, зур шәһәрләре белән дан алган бу куәтле дәүләтнең һәм аның әдәбиятының-мәдәниятенең «Каһарман Катил»дастанына турыдан-туры мөнәсәбәте булырга мөмкин. Караханилар дәүләтендә үз чорында төрки телле мөселман әдәбияты чәчәк аткан. Мәхмүд Кашгари, Йосыф Баласагуни, Фирдәүсиләр калдырган язма мираска игътибар итсәк, идея-рух, сюжет типологиясе җәһәтеннән боларда «Каһарман Катил» белән уртаклыкларны шактый табарга мөмкин. Әсәр кулъязмаларының телендә угыз элементларының булуы да әһәмиятле. Барлык төркиләрне генетик бәйләнештә караганда һәм төрле чорда төрле дәүләт берләшмәләренә кергән төркиләрнең төрки телдәге әдәби иҗатын барысын да бер үк өзлексез әдәби процесс итеп күзаллаганда[2], дастанның соңрак кабат төркиләрдә – аларның утрак тормышлы дәвамчыларында, әйтик, үзбәкләрдә, төрекләрдә, казан татарларында таралуы бик тә табигый. Бу яктан фарсы «Каһарманнамә»сен угыз төркиләре иҗаты тәшкил итә дип тә карарга мөмкин. Әмма дастанның казан татарлары китаби версиясендә доминанта ролен төрки эпос традицияләре белән бергә борынгы иран эпосы традицияләре дә үти, моннан чыгып, чыганак әсәр «Каһарманнамә»не синкретик характердагы төрки-иран эпосы дип карау хакыйкатькә якын булыр.

Фарсы телле «Каһарманнамә»нең башка халыклар иҗатына тәэсире әллә ни зур булган һәм масса төсен алган дип әйтеп булмый, алай да ул бөтенләй әһәмиятсез дә калмаган. Бу әсәр башка халыклар эпосына ачыктан-ачык «Каһарман Катил» яисә «Каһарман» исеме белән кереп түгел, ә күбрәк гомуми мотивлары, идея-эчтәлеге, композицион охшашлыклары ягыннан тәэсир иткән булырга тиеш. М. Әхмәтҗанов үзенең фәнни мәкаләсендә[3] грузиннарның «Караманиани»ларын (XVIII йөз) һәм үзбәкләрнең 1910 елда басылган, Урта Азиягә хас үзенчәлекләр белән сугарылган «Каһармон» әсәрен[4] шушы борынгы язма чыганакка нисбәт итә.

---

[1] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. С. 45–48, 137.

[2] *Стеблева И.В.* Поэтика древнетюркской литературы и ее трансформация в раннеклассический период. М.: Наука, 1976. С. 166.

[3] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы... Б. 198–205.

[4] Каһармон. Зумрад вә Киммәт. Узбек халк ижоди: күп томлык. Тошкент, 1988. Б. 25–33.

Чыннан да, грузиннарда сюжеты читтән килеп кергән «Барам и Гуландам», «Хосров и Ширин», «Сейлан-наме», «Сокровище владык», «Бахтияр-наме», «Книга Синдбада» һ.б. әсәрләр белән бергә «Карамaниани» әсәре дә бар һәм бу истәлекләрнең барысын да грузиннарда XVIII йөздә фарсыдан кергән сюжетларга нигезләнгән, үз чорында гаять популярлык казанган ядкарьләр яки тәрҗемә әсәрләре булулары берләштерә[1]. «Карамaниани» грузин телендәге, маҗаралы-героик характердагы күләмле текст буларак мәгълүм. Ул – грузиннарның яратып укылган әдәби истәлекләреннән берсе. Катлаулы сюжетка ия булуы һәм зур күләменә нигезләнеп, грузин әдәбияты белгечләре аны еш кына «роман» дип тә атыйлар. Грузин «Карамaниани»сы фарсы телле ике әсәрдән оешкан – «Каһарманнамә» һәм «Сәйләннамә»не берләштерә.

Үзбәкләрнең «Каһармон» әсәре – шулай ук катлаулы сюжетлы, мавыктыргыч эчтәлекле, зур күләмле әсәр, «Карамaниани» кебек үк, «Каһарман Катил» сюжеты белән зур уртаклыкка ия. Шушы ук сюжетка язма әсәрнең төрекләрдә булуы турында да мәгълүматлар бар[2].

«Каһарман Катил»нең татарларда таралыш алу сәбәпләрен эзләгәндә төп игътибар, әлбәттә, әлеге сюжетка язма истәлекләре булган Көнчыгыш тибындагы культурага ия халыкларга юнәлә. Бу җәһәттән безнең халыктагы «Каһарман Катил» версиясенең иң әүвәл нәкъ менә төрек-татар әдәби-мәдәни бәйләнешләре нәтиҗәсе булуы мөмкин кебек. Чыннан да, төрек язма мәдәниятенең татар әдәбиятына тәэсире булган, әлбәттә. Биредә XVIII йөздә фольклор нигезле оригиналь, төрек халык һәм читтән кергән сюжетларга билгеле бер автор хикәяләвендә кулъязма дастаннарның киң таралыш алган булуы мәгълүм. Мондый төр әсәрләрдә борынгы төрек, фарсы, гарәп хикәятләре автор йогынтысында бик нык трансформацияләнеп бирелә торган булган. Моңа мисал рәвешендә Гали Газиз исемле авторның (1798 елда вафат) кысалы кыйссалар рәвешендә төзелгән китабын күрсәтергә мөмкин («Фантазии» дип атала, тулы исеме – «Чудеса божественного откровения»)[3]. Ул үз эченә шул чор Стамбул тормышын тасвирлаган һәм «Мең дә бер кичә» циклы мотивлары буенча

[1] Хронология средневековой грузинской литературы. URL: http://dic.academic.ru/dic.hsf/ruwiki/698693 (дата обращения – 29.02.20012); История Всемирной литературы: в девяти томах. Т. 5. М.: Наука, 1988. С.511.

[2] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы... Б. 199.

[3] История всемирной литературы: в девяти томах. Т. 2. С. 458.

төзелгән хикәятләрне алган. Төрек әдәбиятындагы бу һәм шундый башка истәлекләр хезмәтебездә татар китаби дастаны категориясендә карала торган әсәрләргә якын тора. Әмма мондый процесс, ягъни фольклор текстларының автор эшкәртүендә яңа сулыш алуы төрек һәм татар әдәбиятларының һәркайсында үз нечкәлекләре белән параллель рәвештә барган. Татар кулъязма вариантларының төрек телле «Каһарман Катил» тәэсирендә барлыкка килгән булу ихтималын бөтенләй үк инкарь итеп булмаса да, татар версиясенең бер генә чыганагында да төрек «Каһарман Катил»енә нинди дә булса ишарә юк. Моннан тыш, төрек-татар әдәби-мәдәни бәйләнешләренең нык активлашкан чоры XIX йөз ахыры – XX йөз башы булуы билгеле, ә «Каһарман Катил» кулъязмалары татарларда XVIII йөзгә, кайбер фикерләр буенча хәтта Алтын Урда чорына ук карый. Шуңа күрә татар «Каһарман Катил» версиясенең турыдан-туры төрек язма әдәбияты аша кергән булу фактын ныклы дәлилләр белән раслап булмый. Татар «Каһарман Катил»енең фарсы «Каһарманнамә»се һәм гомумән борынгы фарсы эпосы белән сюжет-мотив уртаклыгы күп очракта сүзне нәкъ менә фарсы-татар бәйләнешләре файдасына алып бару өчен ныклы нигез ролен үти.

Төрки-татарларга фарсы тамырлы «Каһарман Катил»нең ни рәвешле һәм ни сәбәпле килеп кергән булуы аерым аңлату таләп итә. М. Әхмәтҗановның хаклы фикеренчә, бу әсәрнең татарлар арасында таралуында төп рольне «Каһарман Катил»нең рухы белән төркиләр томышына һәм төрки героик эпосына якынлыгы уйнаган[1]. Дастанда, чыннан да, борынгы төркиләр җәелеп яшәгән урыннарга мөнәсәбәтле географик атамалар, яшәү рәвешләре, көнкүрешләренә бәйле лексика кулланылган. Борынгы төркиләргә хас булганча, дастан геройларының чатыр корып, күченеп йөрүләрен тасвирлавы, төрки эпостагы кебек, сугыш-орыш картинасының ике якның данлыклы батырлары көрәшеннән башлануы, сугыштан тынып торган арада чатыр каравыллаучыларның чатыр янында түгәрәк ясап утырып, думбра чиертүләре, каһарманның атаклы үз сугыш коралы – кылычы булу, агачка атын бәйләп куеп, шул агач төбенә үзе ятып йоклаган батыр янына дошманның килеп чыгуы кебек элементлар дастанны төрки мохиткә якынайта. Әлеге сыйфатлары белән дастан сюжетының төрки-татарларны җәлеп иткән булуы мөмкин, әлбәттә.

[1] Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 3–15.

Әмма бу сюжет казан татарларыннан тыш төрки халыклардан фәкать төрекләрдә һәм үзбәкләрдә генә чагылыш тапкан. Шуңа күрә «Каһарман Катил»нең төрки рухлы булуы турындагы әлеге фаразны да дастанның таралыш закончалыгы турындагы бердәнбер версия дип раслап булмый. Дастан сюжетындагы күчеп хәрәкәт итүләр иң беренче чиратта әллә кайчан утрак тормышны үз иткән казан татарларын түгел, ә күчмә халык булып безнең бабайларга караганда шактый озак гомер кичергән төркиләрне кызыксындырган булырга һәм иң беренче чиратта алар иҗатында чагылыш тапкан булырга тиеш иде кебек. Тагын шунысы да әһәмиятле: үзбәкләр, билгеле булганча, азәрбайҗаннар, төрекмәннәр, каракалпаклар кебек үк, иранлылар белән этногенетик бәйләнештәге халык. Ә менә казан татарларының этногенезында иран субстратының катнашы юк. Алай да нәкъ менә татар халык иҗатында фарсы чыгышлы дастанның милли версиясе бар һәм ул үз чорында шактый актив таралган булган.

Моның сәбәпләре тарихи-мәдәни шартлар белән бәйле берничә җитди факторны үз эченә ала.

Әсәрнең татар халкындагы популярлыгының төп хикмәте – төрки-татарлар белән фарсыларның борынгыдан килгән үтә тыгыз әдәби-мәдәни бәйләнешләрендә. Фарсы «Каһарманнамә»се белән татар телле «Каһарман Катил»нең идея-рух якынлыгының үзен дә нәкъ менә шушы факт билгели. Татар халкының, бигрәк тә казан татарларының язма мәдәният белән кызыксынуы үтә зур булып, алар, чыннан да, күп яклап төрки-татар традицияләренә туры килгән мондый мавыктыргыч әсәргә битараф кала алмаганнар. Гарәпләр йогынтысында VII гасырдан ук ислам кабул иткән фарсылар белән Идел буе татарлары язма эпик иҗатын, әлбәттә, дин берлеге дә бик нык якынайткан. «Каһарман Катил»нең мөселман идеологиясе белән сугарылган истәлек булуы аның Идел буе мөселманнары арасында җиңел таралуын тәэмин иткән. Дастанда ислам дине яссылыгында төрки-иран мифологиясе, фольклоры ачык тасвирланган, борынгы тамырлардан килә торган административ-хәрби тәртипләр чагылыш тапкан.

Идел буе татарлары Болгар дәүләтеннән үк, бераз соңрак Алтын Урда составында, аннары Казан ханлыгы чорында, ягъни электәэлектән Һиндстан, Урта һәм Кече Азия, Якын Көнчыгыш һәм, әлбәттә, Иран белән сәяси, дипломатик һәм мәдәни багланышлар тотып яшәгәннәр. Иран фольклоры белән төрки-татарлар фольклоры генетик бәйләнештә тормаса да, борынгы фарсы язма чыганакларының

безнең халык иҗатына һәм әдәбиятына тәэсире аеруча зур булганлыгы – исбатланган факт. Әдәбият галимнәре Х. Миңнегуловның[1], Р. Ганиеваның[2] махсус хезмәтендә бу мәсьәләләр җентекле яктыртылган. IX гасырдан фарсы теле фарсылар өчен генә түгел, күп кенә башка халыклар өчен дә язма тел, ягъни әдәби тел функциясен үтәп килгән. Иран территориясендә күп кенә халыкларның бер дәүләт кысаларына сәяси, икътисади, мәдәни берләшү факты фарсы теленең иран халыкларының гына түгел, анда яшәгән төрки халыкларның да әдби теленә әверелүенә китергән. Традицион төстә бу үзенчәлекнең, кайбер башка төркиләрдәге кебек, Идел буе регионында формалашкан татар мәдәниятенә һәм әдәбиятына да бердәй хас булуын беләбез. Безнең халык фарсы язма истәлекләрен татар теленә күчереп кенә түгел, ә оригинал телдә укыган, чөнки бу чорда фарсы теле татарлар өчен чын мәгънәсендә әдәби-гыйльми аралашу теле булган. Бездә төрле өлкәгә караган фарсы телле язма мирасның күплеге нәкъ менә шуның белән аңлатыла да[3]. Фарсы теленең аерым алганда Идел буе регионында формалашкан татар мәдәниятенә, бигрәк тә әдәбиятына йогынтысы Идел буе Болгары чорыннан алып, күп гасырлар буена барган. Төбәк Алтын Урда составына кергән чорда бу бәйләнешләр шулай ук ныгыган гына, чөнки төрки-татар теле дәүләт теле булып саналган Алтын Урда укымышлылары арасында гарәп һәм фарсы телләрен белү дәрәҗә саналган[4]. Рус дәүләтенең XVI йөз урталарыннан алып барылган тышкы сәясәте нәтиҗәсендә, ягъни тагын да соңрак, XVIII–XIX гасырларга исә татарларның Урта Азия белән бәйләнешләре янә ныгып, татарлар өчен Урта Азия аша Иран әдәбиятына юл яңа этапта ачылган.

Фарсы язма истәлекләре аша үтеп кергән дастани сюжетлар, мотивлар халык иҗатына да күпкырлы тәэсир ясаган. Чыганагы язма булу бу дастаннарның татарларда турыдан-туры язмача эпик иҗат булып таралуын да тәэмин итми калмаган. Мондый сюжетларның

---

[1] *Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и восточная классика (Вопросы взаимосвязи и поэтики) Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. С. 24–80.

[2] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессас и поэт Кул Гали... С. 138.

[3] *Гилязутдинов С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства. Казан: Фикер, 2002. 254 с.;. Гилязутдинов С.М. Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в.). Казань, 2011. С. 7–9.

[4] *Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. китап. нәшр., 1999. Б. 32.

күбесенә казан татарлары җирле телдә өр-яңа яңгырашлы үз версияләрен барлыкка китергәннәр. Гаҗәеп мавыктыргыч сюжетлы «Каһарман Катил» дастанының Идел буе татарларында популярлашкан булуы да – нәкъ менә шушы тарихи-мәдәни багланышларның һәм татарларда «Каһарман Катил» тибындагы эпик истәлекләргә үз чорында булган көчле ихтыяҗның логик нәтиҗәсе.

Борынгы фарсы чыганаклы сюжетның Идел буе татарларында шактый актив очравының сәбәпләренә күзәтү ясау түбәндәге нәтиҗәгә китерә: безнең халыкта язма эпик мирас белән кызыксынуның зурлыгы, мондый төр иҗатның халыкның билгеле бер катламы өчен үз чорында чын мәгънәсендә рухи азык булуы халыкның традицион дини карашларына туры килә торган һәм төрки-татар эпосы белән бик күп типологик охшашлыклардан гыйбарәт «Каһарман Катил»нең Идел буе татарларында китаби дастан булып таралуын тәэмин иткән.

С. Гыйләҗетдиновның «Х гасырлардан фарсы телле язма истәлекләр белән тыгыз бәйләнештә торган татар халкы фарсы телле әсәрләрне оригинал телдә дә, тәрҗемә итеп тә күпләп укыган»[1] дигән хаклы фикергә ачыклык кертеп, бу очракта «Каһарман Катил»не фарсы әсәренең туры тәрҗемәсе дип кенә карау үзен акламавын күрсәтеп үтик. Моны әлеге әсәр кулъязмалары тукымасында төркитатарларга хас җирле үзенчәлекләрнең булуы раслый. Галим М. Әхмәтҗанов кулъязмаларның берсендә Һушән шаһның Дәште Кыпчак падишаһы буларак тасвирлануын, шәһре Болгарның телгә алынып, аның солтаны Давыт Болгари турында сүз алып барылуны күрсәтеп, әсәрнең татарларга Алтын Урда чорында ук мәгълүм булуын ассызыклый[2]. Әсәрнең кулъязмалары белән яхшы таныш галим С. Гыйләҗетдинов та үз хезмәтендә «Каһарман Катил»нең XVIII йөздә күчерелгән бер нөсхәсендә Дәште Кыпчак далалары падишаһы Хушаншаһның гаскәр башлыкларыннан берсе Давыт Болгари исемле булуга игътибарны юнәлтә[3]. Димәк, фактик чыганаклар белән раслап булмаса да, әсәрнең җирле үзенчәлекләреннән чыгып, «Каһарман Катил»нең бездә XVIII йөздән генә түгел, аннан да иртәрәк –

[1] *Гилязутдинов С.М.* Персидско-татарские литературные связи (Х – начало ХХ в.). Казань, 2011. 212 с.

[2] Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар.кит. нәшр., 1998. Б. 11.

[3] *Гилязутдинов С.М.* Персидско-татарские литературные связи (Х – начало ХХ в.). Казань, 2011. С. 168.

XIV йөзләрдә үк мәгълүм булу ихтималы юк түгел. Фарсы кулъязма китабы белән татар әдәбияты арасындагы чал гасырлардан ук килә торган бәйләнешнең ныклыгы бу фикерне шактый ныгыта.

«Каһарман Катил» дастаны каһарманнарның һәм бигрәк тә төп каһарманның маҗаралы героик язмышын тасвирлый, үзенең ярым реаль, ярым мифологик мавыктыргыч сюжеты белән укучыны җәлеп итә. «Каһарман» сүзе төрки героик эпоста тасвирланган «тиңе юк батыр», пәһлеван мәгънәләренә тәңгәл, шуңа күрә ул типик мәгънәсендә кабул ителә дә. Бу образның дастанда бирелеше дә шушы типиклыкныраслый. Төрки эпоста гадәттә геройның туганчыга кадәрге чордан алып үлгәнчегә кадәрге каһарманлык тормышы сурәтләнә, ә биредә Каһарман турындагы тасвир аның сабый чагында юлыккан маҗарасын тәфсилләп сурәтләүдән башлана, батырны саф төрки эпостагыча пьедесталга күтәрү дастан сюжетын төрле маҗаралы чит элементлар белән баету белән бергә бара. «Каһарман Катил»дә героик эпос рухындагы каһарманнар берәү генә түгел, берничә, әмма дастанга исем биргәне – әсәрдә иң зур урын бирелгән гаять күренекле батыр. Биредә «катил» сүзенә аңлатма бирсәк, гарәп теленнән бу сүзнең «үтерүче, һәлак итүче» дип тәрҗемә ителүен беләбез[1]. Бүгенге эстетик карашлардан чыгып карасак, Каһарман Катилгә мондый кушамат һич туры килми кебек. Әмма әсәр сюжетының борынгы фольклор белән бәйләнешеннән чыгып караганда үтерүче, һәлак итүче Каһарманны ничек бар, шулай кабул итүргә кирәклеге аңлашыла. Әсәр эчтәлегеннән чыгып анализлаганда, ул – чыннан да үтерүче. Каһарман һәр очракта шулкадәр гайрәт белән сугыша, «ач арыслан төсле гаскәрне кыра», «аждаһа кебек ыжгырып сугыша», «сугышта үлгәннәрнең каныннан Җәйхун елгасы кебек кан агарлык була» һ.б. Дастанда сурәтләнгән сугыш-орыш картиналарында Каһарман кызгануны белмәс җәллад булып күз алдына баса. Эпик геройга хас булганча, ул үзен һәрвакыт хаклы саный һәм хаклы түгелләрне, ягъни дошманнарын кыра. Димәк, Каһарманның катиллеге хак эш өчен көрәшү фонында аклана. Шуңа да дастан эчтәлегендә беренче чиратта Каһарманның катил булуы түгел, ә гаҗәеп көчле, тиңсез батыр булу факты алга чыгарыла. Каһарман үз пәһлеванлыгын изге эш өчен – ислам гаскәренең җиңүе өчен сарыф итеп, үз падишаһының

[1] Гарәпә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). 1 т. Казан: Иман, 1993. Б. 206.

идеяләренә тугры хезмәте белән дан казана. «Каһарман Катил» дип аталса да, дастанда бу образ Каһарман Катилгә караганда Каһарман дип кенә ешрак телгә алына. Дастан нөсхәләре арасында әсәрнең исемен үк «Каһарман», «Каһарман хикәясе», «Каһарман китабы» дип кенә бирү дә бар.

Дастанда борынгы төркиләр яшәгән урыннарның географик атамалары һәм яшәү рәвешләре, көнкүрешләренә бәйле лексика кулланылган булу «Каһарман Катил»не татар халкының үз җирлегендә формалашып өлгергән шактый борынгы истәлек дип карарга мөмкинлек бирә. Әсәр шактый катлаулы, ул үз эчтәлегендә зәрдөштлек диненең изге китабы Авестадан ук килә торган архаик Иран катламыннан алып, фарсы мөселманлыгы чоры пластын да, мөселман-гарәпләр аша Коръән мотивларын да, Идел буе мөселманнары – татарлар тәэсирен, шул исәптән исламның биредә ныгып урнашкан этник формасы йогынтысын да кичергән. «Каһарман Катил» – кабатланмас, үзенчәлекле төсмерләргә үз җирлегебездә баеп, үзебездә формалашып җиткән һәм, халыкның укымышлы катламының эчке ихтыяҗлар таләбен канәгатьләндереп, әллә ничә нөсхәдә таралган дастан.

Билгеле булганча, китаби дастаннарның героик төренең дә, романик төренең дә нигезендә әле исламгача ук формалашкан гомумтөрки эпик мотивлар, я булмаса шулай ук исламга кадәрге гарәп-фарсы сюжетлары ята. Мондый борынгы дастаннар рәтендә татарларда фәкать кулъязма формада гына көн күргән «Түләк китабы»н, халкыбызга кулъязмалар, басма китап һәм шулай ук сөйләмә вариантлары аша да мәгълүм «Бүз егет»дастанын һ.б. атый алабыз. «Таһир-Зөһрә», «Ләйлә-Мәҗнүн», «Сәйфелмөлек» сюжетлы дастан версияләребезнең дә нигезендә шушындый бик борынгы сюжетлар ятуы мәгълүм. Әлбәттә, бик борынгы гомумтөрки эпик яисә архаик гарәп-фарсы традицияләре кимәле аларның һәркайсында төрлечә сакланган. Табигый ки, чагыштырмача соңрак, ислам тәэсирендә сюжет-мотивлардагы бу борынгылык шактый нык үзгәрешләр дә кичергән, шуңа да һәр конкрет дастанда исламгача ук булган мотивларның үзенчәлекле кыйпылчыкларын гына да табарга мөмкин. Әмма борынгы сюжетлы мондый дастаннарыбыз, ислам йогынтысын да һичшиксез кичереп, үсеш-үзгәрешләр аша үзебезнең традицияләргә нигезләнеп формалашканнар.

Китаби дастаннарыбыз арасында янә бер төркемне идея-тематикасы белән дә, сюжет-вакыйгаларының үзенчәлекле

яктыртылуы белән дә аерылып тора торган дастаннар тәшкил итә. Болар – турыдан-туры гарәп-мөселман язма чыганаклары тәэсирендә һәм ислам йогынтысында барлыкка килгән, вакыйгаларны дини позициядән торып яктырта торган милли версияләребез. Әйтик, «Кыйссаи-Сәкам», «Кисекбаш» кебек ядкарьләребез алдарак телгә алган төр әсәрләр белән чагыштырганда бөтенләй үзгә. Мондый дастаннарның идея-сюжет кысалары ислам идеяләре белән сугарылган һәм аларга героик дастаннар арасында үзенә бер төрне тәшкил итә торган дини-героик дастаннар дигән билгеләмә тәңгәл килә. Мондый дастаннарда эпик сюжетларга, эпик образларга хас чикләнгәнлек дини элементлар белән баетылган була. Әйтик, каһарман үз дошманнары белән көрәштә Аллаһ ярдәменә таяна башлый, борынгы төрки героик эпоста фәкать үз көченә генә ышанса һәм аяусыз көрәштә һичшиксез үз көче белән генә җиңү яуласа, биредә ул дошманнарын (бик еш кына кяферләрне) Аллаһы ярдәмендә җиңә, дошманнары да дини дошманнар сыйфатын ала һ.б. Шул рәвешчә, гомумиләштереп алганда, мондый дастанда эпик кануннар ислам кануннары белән яраклаштырыла.

Борынгы төрки катлам традицияләре Идел буе татарлары китаби эпосында шушы һәм башка рәвештә яңарыш кичергән. Әмма үз чорында ул халыкта нәкъ менә шушы сыйфатлары белән гадәти күренеш буларак кабул ителгән, халык дастаны буларак укылган-таралган. Бу – шулай ук китаби дастаннарга хас әһәмиятле билгеләрдән. Шунысын да искәртеп үтик: төрле тарихи чорда төрле этаплар үтсә дә, гомумән алганда ислам кануннары һәм татар халкының яшәү-хуҗалык итү үзенчәлекләре бер-берсе белән тирән каршылыкта тормый. Идел буенда исламның артык катгый булмаган формасы – Хәнәфи мәзһәбе ныгып урнашкан, бу исә күпмедер дәрәҗәдә исламның бездә җирле халык традицияләрен бөтенләй үк кире кагып бетермәгән халык дине формасында үсеш алуына юл ачкан. Шуңа күрә дини-героик китаби дастаннарыбызның да халыкның рухи тормышына җиңел ярашып китүе күзәтелә.

Әмма мондый дастаннар ислам белән бергә барлыкка килгән тәртипләрне һәм фәкать Коръән образлары-персонажларын гына пропагандалый дип фикер йөртү дә дөреслеккә туры килми. Дини-героик дастаннарда ислами тәгълиматны, дөньяга дини карашны, дини идеологияне ачыктан-ачык алга сөрү белән бергә ихтыярсыз рәвештә исламгача булган эпик традицияләр дә үз көчендә кала. Бу,

күрәсең, дастан сюжетының борынгылыгы белән, ә дини тәгълимат йогынтысының соңгырак этапта килеп кереп, әсәрне нык үзгәрешләргә дучар итүе белән аңлатыла. Шуңа күрә дастани ядкарьләребезнең исламгача ук таралганнарында да, турыдан-туры мөселманлык карашлары белән сугарылганнарында да гасырлар буена формалашкан эпик традицияләр чагылыш тапкан, формалашып җиткән китаби дастаннарда төрле катлам – борынгы иран, төрки-иран, гомумтөрки, мөселман-гарәп традицияләре төрле дастанда төрле дәрәҗәдә бер-берсенә тирән керешеп киткән.

Дастани сюжетлар генезисына бәйле мондый бүленештә караганда, «Каһарман Катил» дастанын дини-героик дастаннар төркемендә карар өчен җирлек бар. Текстның һәрбер кулъязмасы һәм басмасының Аллаһы исеме белән башлануы ук – дастанны әлеге төркемгә нисбәт итүнең әһәмиятле тышкы билгесе.

Мәсьәләгә тирәнрәк якын килсәк, бу әсәрнең чишмә башы Коръән тәфсирләренә мөнәсәбәтле фарсы язма чыганагыннан килә дигән фикер дә бар. Татар дастаннарында, бәетләрендә, ышануларында ислам нигезләрен барлаганда филология фәннәре кандидаты А. Ахунов бу әсәрнең тамыры булган «Каһарманнамә»нең эчтәлегенә Коръәннең гарәп тәфсирләре яисә аларның кабат эшкәртелгән фарсы телле тәрҗемәләре йогынты ясаган дип саный[1].

Татар «Каһарман Катил»ендә зур гына ике сюжет сызыгы аерылып чыга: аның берсе – дини-героик, ә икенчесе – әкиятимифологик өлеш. Дастанның бербөтен сюжетка берләшкән вакыйгалары аша алар бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнештә торалар. Әлеге ике сюжет сызыгы үзләре дә бербөтен буларак кабул ителерлек аерым-аерым виграк хикәятләрдән оешкан, дөресрәге, дастан вакыйгалары мөстәкыйль сюжетлы вак хикәятләргә җиңел аерымлана ала. Шуңа күрә безнең халыкта «Каһарман Катил»нең тулы варианты да, әсәрдән аерым хикәят булып аерымланган варианты да күчерелеп-укылып йөргән. Төрки-татар «Каһарман Катил»енә Коръәнгә һәм аның тәфсирләренә барып тоташа торган мотивларның булуы белән бергә вакыйгаларны гомумән ислам традицияләре күзлегеннән яктырту хас. «Каһарман Катил» дастанын исламга якынайта торган элементлар аның героик сюжет сызыгын да, мифологик өлешен дә

[1] Татарская электронная библиотека: *Азат Ахунов.* Исламизация Волжско-Камского региона (VII–X вв.). URL: http://kitap.net.ru/ahunov4.php?lang=tat (дата обращения – 26.01.2012).

тулаем били, дастанда ике зур сюжетны берләштерә торган идеологик күпер ролен башкара.

Әсәрдәге иң төп фикер – ислам диненең куәтен арттыру. Аллаһыга буйсыну, һәр эшне аңа тапшырып үтәү, Аллаһ кодрәтенә баш ию һәрвакыт әсәр вакыйгаларының төп таяну ноктасы булып кала. Дастанда вакыт исәбе дә ислам нигезендә яткан намаз вакытларына карап билгеләнә, текстта яуның, батырның узган юлы, сугыш-орыш арасындагы паузалар һ.б. бик еш кына «ахшамга кадәр», «ахшам узгач», «икендедән соң» рәвешендә билгеләнгән. Әсәр сюжетында тормыш-көнкүреш вакыйгаларыннан баһадир белән аның мәгъшукасы мөнәсәбәтләрен никах аша ныгыту күренеше дастанда берничә кат тасвирланган. Вакыйгалар бәянында һәр эш Аллаһка тапшырып һәм аның пәйгамбәрләре исеме белән үтәлә, пәһлеванның батырлыгы «Аллаһ ярдәме белән», «Ходай куәт бирсә» кебек шартларга нигезләнә. Кискен хәлдә Аллаһны искә алу, Аллаһыга тәвәккәл итеп, юлга чыгу дастанда бик тә табигый нәрсә буларак кабул ителә. Хәтта исламда хупланмаган гамәлләрне тасвирлаганда да нәтиҗәдә моның Аллаһ ризалыгы белән башкарылуына ышану сизелә. Әйтик, фал ачып яисә астролог чакыртып, киләчәкне каратканның соңында «Ходайның һичбер эшенә каршы килү мөмкин түгел», – дигән нәтиҗә ясалу – шуңа ишарә.

Әсәр сюжетында мифологик өлеш дип аерырга мөмкин булган вакыйгалар да шушы ук фикергә буйсына. Әйтик, Шаһбал шаһ, хатыны Кәмәррухны коткару өчен, Фарсы падишаһы пәһлеваны Каһарманнан ярдәм сорагач, Каһарман диюләр белән алыш-бирешкә юлга чыгып китә. Аллага тапшырып кое төбенә төшеп җиткәч, Каһарманның диюләр янындагы маҗаралы батырлыклары бәян ителә. Каһарманның киләсен сизгән диюләр: «Я, Раббым, бу бит – Каһарман пәһлеван», диләр. Ә Шәгъбан диюне Каһарман махсус кылычы белән урталай яргач, дию, телгә килеп, болай ди: «Әй, пәһлеван! Динең хөрмәте өчен тагын бер кат кылычың белән чап әле!» Яисә Каһарманның Әкъвал диюне кылычы белән урталай чабып өзүе «Әкъвал диюне җәһәннәмнең җиде кат төбенә җибәрү» буларак бәяләнә. Ягъни, мисаллардан аңлашылганча, дастанның күпмедер дәрәҗәдә мөстәкыйль күренгән мифологик сюжет сызыгы да дини тәгъбирләрдән һәм дини сугыш алып бару идеологиясеннән азат түгел.

Дастанда фарсы мәмләкәтенең падишаһы Һушән шаһ гаскәре һәр очракта ислам гаскәре дигән тәгъбир белән янәшә килә, Һушән шаһ

сугышчылары исә, кагыйдә буларак, – ислам сугышчылары, мөселманнар. Һушән шаһ үзе – фарсы җиренә Синҗак дигән мәмләкәттән падишаһ итеп чакыртылган бик «гакыллы һәм баһадир», үтә дә тәҗрибәле, Һиндстаннан кала барлык падишаһларны үзенә буйсындырган көчле җитәкче. Фарсы тәхетенә ул килеп утыру белән мәмләкәтнең бөтен игътибары Һиндстанга юнәлә, дастан сюжетындагы батырларның максаты табигый рәвештә падишаһныкына туры килә.

Әсәр сюжетында әһәмиятле элемент – хат язып, илчеләр аша аны иясенә җиткерү. Шундый хатларның берсендә Һушән шаһ һинд патшасына үз мәмләкәтенең нинди изге миссия үтәп, яу белән Һиндстанга якынлашуын ачык аңлата. «Җир вә күкләрне тәрбия итүче Аллаһы исеме белән һәм дә олугъ пәйгамбәре исеме белән» башланган, шактый озын тексттан торган бу хатта мондый юллар бар: «Аллаһы Тәгаләнең һидаяте (дөрес юлы. – *Л.М.*) белән без куәтле һәм кырмыскадан күп гаскәремез белән җир йөзен мөшрикләрдән (мәҗүсиләрдән. – *Л.М.*) пакьләп, бөтен җиһанга дин-мөбин исламны таратып, бөтен җир йөзен нурландырабыз». Һинстан патшасы, иң әүвәл дипломатик юл белән, алай барып чыкмаса, гаскәри көч кулланып, «тугры вә хак юлга» басарга чакырыла. Дастан сюжетының бөтен барлыгын биләгән эпик көрәш-алыш картиналарын, героик эпоска хас батырлык сыйфатларын сурәтләү текстта ислам байрагы астында алып барыла. Батырлар каһарманлык намын да шушы максатларга җитү юлында алалар. Орыш-сугыш картиналарын җентекле тасвирлау бер яктан борынгы эпик кануннарга нигезләнсә, икенче яктан бу гаҗәеп матур сурәтләнгән көрәш сюжетны һәрвакыт ислам гаскәре җиңүенә алып бара.

Тарихтан мәгълүм булганча, VII гасырдан башлап дини миссионерлык байрагы астында алып барылган яулап алу сугышлары аша Һиндстанны буйсындыручы ил – фарсылар түгел, ә Гарәп хәлифәтлеге. Фарсылар үзләре дә нәкъ шушы йогынтыны тирән кичереп, ислам кабул иканнәр. VII–IX гасырларда – социаль-икътисади тормышта Иран һәм Урта Азия Гарәп хәлифәтлеге составына кергән. «Каһарман Катил» дастаны вакыйгаларында, фольклор әсәренә бик еш хас булганча, тарихны бозып күрсәтү, рольләрне алышу күзәтелә. Әсәрдә Һиндстанга ислам динен тарату белән килүчеләрнең фарсылар буларак тасвирлануы фольклорда тарихи вакыйгаларның контаминация кичерүе нәтиҗәсе булса кирәк. Татар «Каһарман Катил»ендә бу – фарсы язма чыганагы аша турыдан-туры килеп кергән тарихи

фальсификация чагылышы булырга мөмкин. Ихтимал, фарсы «Каһарманнамә»се әсәр вакыйгаларындагы җиңүче ролен фарсыларга биргән яисә фарсы язма чыганагы, бирелә ислам тәртипләре ныгып урнашкач, чыннан да, Коръән тәфсире нигезендә барлыкка килгән[1]. Әле IX гасырларга кадәр фарсы әдәбиятының гарәпләр аша мөселман идеологиясе тәэсирендә булып, бу регионда гарәп теле өстенлек иткәнлеге мәгълүм. Гарәпләр йогынтысы аша фарсы теле һәм әдәбияты үз чорында дөнья мәдәнияте белән турыдан-туры бәйләнешкә кереп, иң югары дәрәҗәдәге чәчәк ату чоры кичергән («Соприкоснувшись с другой культурой, арабоязычная персидская литература в VII–IX вв. настолько обогатилась, что не только подняла на новую ступень саму арабскую литературу, но, по существу, создала предпосылки для последующего возникновения классической персидской литературы уже на родном языке. Этому способствовало и то, что арабский язык в то время играл роль мирового языка и персидская литература таким образом непосредственно связалась с мировой культурой той эпохи»)[2].

Мәсьәләгә бу яктан караганда, борынгы фарсы текстының безгә гарәпләр тәэсирен һәм үзгәртүләрен кичереп, гарәп әдәбияты-мәдәнияте аркылы килеп ирешкән булырга да мөмкин. Фарсы-татар әдәби бәйләнешләрен тикшергәндә текстолог-галим С. Гыйләҗетдинов та «Каһарман Катил» кулъязмаларын татарларга гарәп әдәбияты арадашлыгында кергән ядкарьләргә нисбәт иткән[3]. Татар «Каһарман Катил»е үз эчтәлегенә борынгы Иран пластын да, фарсы мәдәниятенең мөселманлык дәверенә нисбәт итәрлек традицияләрне дә иркен сыйдырганга күрә, тарих тузаны арасыннан җеп очын җиңел генә табып алып, әсәрнең кайбер элементларына мөнәсәбәттә өзеп кенә бер фикерне куәтләп булмаска да мөмкин. Мәсьәләне мондый нечкәлектә хәл иткәндә бер факт бәхәссез һәм тиешенчә расланган: фарсы «Каһарманнамә»се аноним әсәр булып гарәп яулап алуларыннан соң күпкә соңрак оешкан. Шуңа күрә югарыда телгә алынган фаразларның һәркайсы бертигез хокукта

[1] Татарская электронная библиотека: Азат Ахунов. Исламизация Волжско-Камского региона (VII–X в.).

[2] *Брагинский И.С.* Из истории персидской и таджикской литератур. Избранные работы. М.: Наука, 1972. С.486.

[3] *Гилязутдинов С.М.* Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в.). Казань, 2011. С. 167–168.

була ала. Фарсы «Каһарманнамә»се дә, бездәге «Каһарман Катил» дә, чорына хас барлык үсеш-үзгәрешләрне үзенә сеңдерә барганга ошый, шул ук вакытта болар – әсәр нигезендәге иң борынгы катлам – Борынгы Иран эпосы традицияләрен дә саклый килгән күркәм истәлек. Дастанда сурәтләнгән кайбер моментларга нисбәтән биредә мөселман Ираны культурасыннан да күп иртә булган күренешләрнең чагылышына да юлыгырга мөмкин.

«Каһарман Катил»дә дошман патшасының һәм гаскәренең утка табынулары, утка сәҗдә кылулары турында берничә урында телгә алына. Сугыштан тынып торган вакытта һәр ике як мәетләрен урнаштыралар. Ислам гаскәренең вафат сугышчыларына, табигый, җирләү оештырылса, һиндләр үз мәетләрен утта яндыралар. Үлгән кешене мөселманча күмү-җирләү тәртипләре дастанда утка табынучы дошманның үз мәетләрен яндыру ритуалына каршы куела. Биредә ислам гаскәренең төп дошманы – утка табынучы һиндләр гаскәре.

Утка табынуның һәм мәетне утта яндыруның нигезләре бик борынгы чорлардан, хәтта утка табынучыларның шактый куәтле системаны тәшкил иткән китабы – Авестадан да күп иртә барлыкка килгән булуы мәгълүм. Үлгән кешене яндыру аның җаны югарыдагы зат – Аллага тизрәк күтәрелсен дигән максаттан башкарылган. Борынгы гарәпләр шулай ук утка табынганнар.

Фарсы «Каһарманнамә»се барлыкка килүнең географик ареалы Борынгы Иран булуны истә тотсак, дастандагы утка табынуга каршы көрәшнең нигезләре шул ук Иран территориясенә барып тоташуны ачыклау кыенлык тудырмый. Тарихка мөрәҗәгать итсәк, утка табынучылар диненең тамыры «Каһарманнамә»неке кебек үк, Борынгы Иранга барып тоташа. Биредә гарәп яулап алуларына кадәр, төгәлрәк әйткәндә VII–VIII гасырларгача, утка табынучылар дине – зәрдөштлек хөкем сөргән. Борынгы Иран диненең изге китаплар җыелмасы Авеста дигән исем белән мәгълүм, ә зәрдөштлек төшенчәсе шушы дингә нигез салган легендар пәйгамбәр Зароастр (Заратуштра) исеменнән килеп чыккан[1]. Диннең нигезендә Коръән белән бергә иңгән ислам дине тәгълиматына капма-каршы булган утка табыну ята. Шуның нәтиҗәсе буларак, мәңгелек ут храмнары зәрдөштлек йолаларында хәлиткеч роль уйный. Үз чорында Иран территориясе

[1] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. I (А–Г). Казан: Мәгариф, 2008. Б. 37–39.

тулысынча зәрдөштлек тәэсирендә булган. Авеста үзе төрле чор идеяләрен үз эченә алган биш китаптан гыйбарәт. Авестаның аерым идеяләре Азия һәм Урта диңгез халыкларының дини карашларына, сәнгатенә, әдәбиятына көчле йогынты ясаган. «Каһарман Катил» дастанында утка табынучыларның үз мәетләрен яндыру гадәте зәрдөштлек традициясе чагылышы булуы ихтимал. Әмма «зәрдөштлектә торучылар мәетне җирләмиләр дә, яндырмыйлар да, кыргый хайваннар һәм кошлар ашап бетерсен дип, ачык килеш ташлап калдыра торган булганнар»[1] дигән мәгълүматка нигезләнсәк, мәетне яндыру гадәтен Авеста дине белән генә бәйләүнең хакыйкатькә туры килеп бетмәве ачыла. Биредә бер нәрсә төгәл билгеле: мәетне борынгы зәрдөштлектәге кебек җир өстендә калдыру яисә яндыру бик борынгы гадәтләрдән булып, ислам тәртипләре моңа чик куйган. Мәетне яндыру гадәтенең тамырлары Авестадан да күп иртә яшәгән традицияләргә үк барып тоташуны таныйбыз, әмма «Каһарман Катил»дә моның исламда тыелган гамәл буларак кына игътибарга алынган булу ихтималы өстенлек ала. Димәк, дастанда дошман ягының ислам гаскәре тарафыннан үтерелгән сугышчыларын яндырулары турында сүз алып баруны исламның өстенлеген ассызыклау, ислам тәртипләренә каршы килә торган күренешне тәнкыйтьләү өчен кулланылган чара дип кабул итәргә мөмкин. Утка табынуның да, мәетне яндыруның да тарихи тамырлары б.э.к. ге чорларга ук барып тоташса да, дастанда бу традицияләрнең фәкать риваять характерында һәм фольклорча контаминация кичергән булуы ачык.

Утка табынучыларның кечкенәрәк төркемнәре Һинстанда әле дә бар, биредә мәетне яндырып, көлен су өстенә сибү гадәте әле дә яши. Безнең көннәрдә зәрдөштлек диненә табынучылар Бомбей шәһәре тирәсендә гомер итәләр. Биредә яшәүче мөселманнарның аларны кяферләр (аларча: гебрлар – бу сүз иран телләрендә «динсез» дигән мәгънәне аңлата) дип атаулары да мәгълүм[2]. Гебрлар – биредә азчылыкны тәшкил итүче, зәрдөштлек динен тотучылардан гыйбарәт бер төркем. Димәк, соңгырак чорда дастанда утка табынучылар белән көрәшне тасвирлаганда төп объектның Һиндстан итеп алынуы бөтенләй үк нигезсез түгел. Бу чорда фарсы җире үзе

---

[1] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. I (А–Г). Б. 39.

[2] Авеста в русских переводах (1861–1996) / сост., общ. ред., примеч., справ. разд. И.В. Рака // Журнал «Нева» РХГИ, СПб., 1997. С. 434.

мөселманлык кабул иткән, биредә инде ныгып урнашкан исламның төп дошманы – әле дә булса утка табынучылар яшәп яткан Һиндстан булуы фольклорда контаминация туу өчен менә дигән җирлек була ала. Дастанга һинд-иран дин тарихына бәйле реаль вакыйгалар йогынты ясаган булырга да мөмкин.

Гарәп-фарсы мөселманнары утка табынучыларны кяферләр дип атаганнар. «Кяфир (кяфер)» – гарәп сүзе, динсез, нәтиҗәсез, яхшылыкның кадерен белмәүче, ягъни Аллаһыдан адәм баласына тәкъдим ителгән хак юлны күрмәүче дигән мәгънәләрне белдерә. Коръәндә ул гадәттә нәкъ менә исламны танымаучы мәҗүсиләргә карата кулланыла да. Әмма «Каһарман Катил»дә «кяфер» сүзе бер тапкыр да очрамый. Моның сере гади. Татарлар өчен кяферләр ул – Идел буе мөселманнарының дин дошманнары – күрше христианнар. Казан татарларында «кяфер» сүзе гадәттә аларның мөселман булмаган ут күршеләренә адреслана торган булган. Тарихи яктан караганда да бу бик табигый һәм дөреслеккә туры килә. Татар дастани эпосында ук моңа мисаллар бар. Әйтик, татар халкының Чура батырга багышланган күләмле дастанында булсын, шул ук теманы ачкан бәеттә яисә риваятьтә булсын – Казан ханлыгын саклаучы Чура батырның дошманнары күрше христианнар булуы ачыктан-ачык язылган һәм бу эпик әсәрләрдә алар кяферләр дип аталганнар[1]. Менә, мәсәлән, Чура батырга багышланган татар дастанынньында мондый юллар бар:

Күк чобарым (батырның аты. – *Л.М*) арытмай,
Күк чыбыгым (батырның сугыш коралы. – *Л.М.*) кара канга
җебетмәй,
Бу кяфернең кереш күзле малаен (Чураның рус хатынныннан
туган баласы турында сүз бара. – *Л.М.*)
Иңрә иңен (буен. – буен) ана Иделгә колатмай,
Бу кяфер миңа серен чактырмай,
Ак мәсҗедләр салдырмай,
«Аллаһ»лап азан әйттермәй,
Морадыма җиткермәй
Кайтмам да, кайтмам да!

Хәлбуки «Каһарман Катил» дастанында мохит бөтенләй башка, шуңа күрә биредә «динсезләр»гә каршы махсус көрәш алып барылса

[1] *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 44, 158.

да, Идел буе татарларының дин дошманнарына карата куллана торган лексик гыйбарәсе урын алмаган. Бу исә чорына һәм сюжет-мотив үзенчәлекләренә мөнәсәбәттә татар китаби дастаннарында үзенә генә хас лексик-семантик чикләүләр традициясе барлыкка килгәнлеге хакында сөйли. Алдарак образ-персонажлар, аларның эшгамәлләре, сюжет-мотивларның эпик чикләнгән булуы хакында сүз булган иде. Биредә «Каһарман Катил» мисалында халыкның китаби дастаннарына да үзенә бер төрле тотрыклы чикләүләр системасы хас булуы ачыклана.

«Каһарман Катил»дәге утка табынучыларның Авеста диненә иярүчеләрдән шактый ерагайган булуын, шул сәбәпле күп кенә яклары белән зәрдөштлек традицияләрен ислам күзлегеннән яктыртып, бозып сурәтләвен дастандагы дини-мифик зат Иблис шулай ук ачык чагылдыра. Авестада Иблис юк. Иблис турында (яисә аның Шайтан, Сатана, Дьявол һ.б. исемнәре) Зәрдөштлек китабында гомумән мәгълүматлар бирелми. Авеста китапларында утка табыну төп урыннарның берсен алып торса да, биредә ут Иблис белән бәйләнештә каралмый. Иблис – тамыры күп төрле чыганакларга барып тоташа торган гаять борынгы чыгышлы үтә катлаулы образ. Кайбер дини тәгълиматларда ул күренекле урын алып тора, ә кайберләрендә, мәсәлән, яһүдләр динендә аның роле бик томанлы[1].

Иблис – «дьявол»ның исламдагы исеме. Ә «дьявол» сүзенә «Зур энциклопедик сүзлек»тә түбәндәге билгеләмә бирелгән: грек сүзеннән – diabolos – сатана, җен, Иблис, кайбер диннәрдә (христиан, ислам һ.б.) явыз рух яки явыз рухларның башлыгы, Алла белән каршылыклы мөнәсәбәттә тора, җәһәннәм хакиме («Дьявол – (греч. diabolos –сатана, черт, Иблис), в некоторых религиях (христианстве, исламе и др.) злой дух и глава зых духов, противостоящий богу; властелин ада»)[2]. Иблис образы татар халык иҗатына һәм язма әдәбиятка шактый тирән үтеп кергән. Әйтик, татар халыкының «Күрәзәче карчык» әкиятендә ул – шайтаннар патшасы буларак тасвирланган мөстәкыйль персонаж. Фольклор жанрларыннан мөнәҗәтләрдә дә Иблис образы еш очрый.

---

[1] Большая энциклопедия: в шестидесяти двух томах. Т. 16. М.: Терра, 2006. С. 265.

[2] Большой энциклопедический словарь: в 2-х т. Т. 1. М.: Советская энциклопедия, 1991. С. 419.

Коръәндә Иблис (шайтан, сатана) Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне, җеннәрне һәм беренче пәйгамбәр Адәм галәйһиссәламне бар иткән вакытта ук яралтылган зат буларак тасвир ителә. Аллаһы әмере буенча нурдан яралтылган фәрештәләр дә, уттан яралтылган җеннәр дә Адәм галәйһиссәламгә баш ияргә тиеш булалар. Әмма җеннәрдән берсе – Газазил исемлесе Аллаһ әмереннән баш тарта:

– Мин аннан өстенрәк, чөнки мине уттан яралттың, аны балчыктан гына, – ди. («Әгъраф» («Пәрдә») сүрәсе, 7: 12). «Иблис» сүзе гарәп телендәге «ул өметсез» дигән мәгънәне белдерә торган тамырга барып тоташа, ягъни Аллаһ рәхмәтеннән чыккан, төзәлергә өмете бөтенләй юк зат дигәнне аңлата. Димәк, Иблис зәрдөштлектән дә күп алда барлыкка килгән булып чыга. Иблискә Коръәндә шактый ачык характеристика бирелгән булуга карамастан, Иблисне Коръән персонажы дип тәкърарлау дөреслеккә туры килми, чөнки ул Коръәнгә кадәр Библиядә дә, аңа кадәр дә шактый телгә алына. Әмма алай да Коръәнгә кадәр үк күп иртә барлыкка килгән бу зат турында мәгълүматның татарларга нәкъ менә Коръән аша кергән булуы да бәхәссез, ә Коръәндә Иблис турында шактый тулы аңлатылган.(«Кәһаф» («Мәгарә») сүрәсе, 18: 48, 18:50; «Хиҗр» (Хиҗр иле» сүрәсе, 15: 27; «Рахман» («Рахман») сүрәсе, 55: 15). Безнең татарларда дини эчтәлекле маҗаралы хикәят жанры гаять популяр булып, оригиналь сюжетлы, әмма аноним характердагы мондый әсәрләрдә Иблиснең шулай ук бик еш тасвирлануы да әһәмиятле[1]. Кызыклы һәм гыйбрәтле мондый хикәятләрдә дә Иблис Коръәндә бирелгән характеристикасына тугрылыкны тулысынча саклаган.

«Каһарман Катил»дә дошман патшасы һәм гаскәре утка табына. Әмма каршы як, ягъни Һушән шаһның ислам гаскәре күзаллавы буенча, дошманнарның уты артында Иблис утыра, бу зат – аларның Аллалары да. Һиндләр, имеш, «олуглап утка сәҗдә итәләр», аларның падишаһлары Раи Һинд утка: «Әй, минем мәгъбүдем (аллам. – *Л.М.*), нур вә нур – ут!» дип мөрәҗәгать итә, уттан киңәш сорый. Бу эпизодта сурәт тудыра торган китаби тәгъбирләрнең күп булуы да игътибарны җәлеп итә. Алар әсәрне халык эпосы традицияләреннән читкә

---

[1] *Исмәгыйлев Н.* Татар хикәятләрендә Иблис образы // Әдәби мирас һәм текстология. Икенче чыгарылыш. Казан, 2011. 148 б. Б. 17–22; Гыйбрәтле хикәятләр / кулъязмаларны басмага әзерләүче, хәзерге әдәби телгә күчерүче һәм рәсам-бизәүче – Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 175 б.

алып китә, ә индивидуаль башлангычны исә көчәйтә. Һинд патшасы Раи Һинд уттан Иран падишаһы белән сугышыргамы, әллә килешергәме дип сорап торган бер вакытта «адәмнәрнең һәм диннең дошманы, Җәнабе Хактан сөрелгән Иблис ләгыйн, утның артыннан ачулы тавыш белән» җавап бирә һәм җавабында, әлбәттә, сугышырга өнди, ягъни адәм балаларын котырта. Иблис образында сурәтләнгән Уталлаларыннан җиңү вәгъдә ителгәч, һиндләр сугышка күтәреләләр һәм шактый тәфсилле сурәтләнгән сугыш-орышлардан соң, ниһать, ахырда җиңеләләр.

«Каһарман Катил»дә утка табынучылар тоткан кыйбланың, Коръәндә тасвирланганча, уттан яралтылган, Аллаһ кушканны үтәмәве аркасында «өметсез» мөһере сугылган Иблис образына ни өчен килеп бәйләнгәнлеге аңлашыла. Утка табынучы кавемгә бәйле вакыйгаларны Иблис арадашлыгында сурәтләү «Каһарман Катил»гә татарларның уттан яралтылган бу зат белән Коръән аша таныш булуларыннан килә. Шуңа күрә, архаик Иран пластына хас Авеста катламы дастанда соңгырак чор күзаллаулары белән керешеп киткән дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Бу – утка табынучыларны тәнкыйтьләгән дастанның нигезен Коръән тәфсирләре белән бәйли торган, дастанда мондый каршылыкның ислам җиңүен күрсәтү өчен генә китерелгән тарихи ялган булуын ачып сала торган игътибарга лаек янә бер элемент. Тамырлары Коръәннән дә алдарак торган чыганакларга барып тоташуына карамастан, бу эпизод «Каһарман Катил» дастанына Коръән сюжетлары аша кергән дигән нәтиҗәгә киләбез. Биредә Иблиснең дастандагы дини-мифологик өлештә түгел, ә дөньяви өлештә, ягъни әсәрнең дини-героика белән сугарылган өлешендә тасвирлануы да бу образның борынгы Иран яисә мәҗүси төрки мифологик эпосы белән бернииди уртаклыгы булмавын һәм аның әсәргә бөтенләй башка максатларда килеп кергәнлеген дәлилли.

Шулай итеп, татар дастанында һиндләргә барып ислам урнаштырып йөрүне тасвирлауның нигезендә Иранда инде ныгып җиткән мөселманлык дәверендә әсәр булып формалашкан сюжетны татар-мөселман карашларына туры килә торган юнәлешкә кертеп, китаби сурәтләп бирү ята. Төрле этапларда төрле үзгәрешләргә дучар булуына карамастан, татар версиясендә Һиндстанны мөселманлаштыру идеясенең төп тамырлары әнә шуннан килә.

Дастанның идея-эчтәлегендә исламның зур роль уйнавы бәхәссез булса да, әсәр сюжеты моны гадәти, һәркемгә ачык аңлаешлы

нәрсә кебек тәкъдим итә, төп игътибар эпиклыкка юнәлтелә, нәкъ менә шул сыйфаты әсәрне мавыктыргыч һәм җанлы ясый да.

Гасырлар дәвамында һәм фарсы чыганагыннан төрки-татар версиясе булып әверелү процессында әсәр төрле үзгәрешләр кичергән. Дастан безнең җирлектә туган яисә безгә кайдан да булса үтеп кергән икән, аның һичшиксез шушында яшәүче халык ихтыяҗларын үтәүгә хезмәт итә башлаган булуы бәхәссез. Дини-героик дастаннар да, ислам динен тарату яисә ныгыту максатына түгел, ә халык яшәеше кануннарына, җирле үзенчәлекләргә буйсынганнар. «Каһарман Катил»дә кайбер хәлиткеч моментларда вакыйгаларның саф төрки героик эпосы кануннарыннан тайпылып, ислам канунына буйсына башлавына игътибар иттек. Монда оригинал фарсы әсәренең йогынтысы шактый зур, әлбәттә. Әмма татар версиясенең күпмедер дәрәҗәдәге динилеге Коръән тәфсирләренә дә бәйле «Каһарманнамә» тәэсире булу белән бергә үзебезнең җирлектә дастанның дини-идеологик үзгәрешләргә дучар ителгәнлегеннән дә килә.

Татар дастаны үзенең сюжетында, образ-персонажларның исемнәрендә, әсәрнең типологик үзенчәлекләрендә фарсы-иран һәм төрки-иран эпик традицияләренә шактый зур тугрылык саклаган. Дастанның төп мотивларында исламга каршы килерлек яисә исламгача тормыш рәвешенә нисбәт итәрлек элементлар булмаса да, аны тулысынча дини-мистик карашлар белән өретелгән әсәр дип кенә дә бәяләп булмый.

«Каһарман Катил» ислам кагыйдәләрен тулысынча тормышка ашыра торган дастан түгел. Биредә исламның халыклашкан тибы, ягъни этник мөселманнар дине турында сүз бара. «Аллаһ» мәгънәсендә текстта күбрәк «Хода», «Ходай», хәтта «Тәңре» дигән сүзләр кулланылган булу ук шуңа ишарә итә. Сүзлекләрдә «Хода», «Ходай» сүзләренең фарсы теленнән кергәнлеге күрсәтелгән, ә «тәңре»нең борынгы төркиләрдә үк «Аллаһ» белән бер мәгънәдә кулланылган сүз булуы турында мәгълүмат бирелгән[1]. Галим М.Х. Бакиров һун һәм төркиләр баш алласы Тәңренең төрки-болгар-татар мифологиясендә күк алласы булып исәпләнүе һәм җирдәге халык, ил язмышы белән идарә итүче, ир-ат башлангычы белән бәйләп каралучы илаһ итеп күзаллануы турында

[1] Ислам. Белешмә-сүзлек. Казан: Татар. китап нәшр, 1993. Б. 151.

язган иде[1]. Аллаһы Тәгалә мәгънәсендә мондый сүзләр кулланып сөйләү һәм язу катгый ислам таләпләренә җавап бирмәсә дә, хәтта рәсми ислам моны тыйса да, татарларда «Ходай» сүзен дә, борынгы төркиләрдә үк бөтен дөнья белән идарә итүче мәгънәсендә йөргән «тәңре» сүзен дә куллану җирле традициядә бик күптәннән ныгып урнашкан булган. Шул ук традиция халык иҗатының бәет, мөнәҗәтләренә дә кергән һәм дини дастаннар лексикасы өчен дә нормага әверелгән. «Каһарман Катил» дастанында да бу үзенчәлек ачык чагыла. Бирендә, чыннан да, исламдагы рәсми Аллаһ мәгънәсендә иң актив очрый торган сүзләр – «Ходай», «Тәңре». Илаһи зат шулай ук еш кына «Аллаһ» дип тә телгә алына. «Җәнабе Хак» төшенчәсен дә үз эченә алып, ниһаять, дастанда әлеге мәгънәдәге эпик лексика чикләре ябыла. Бер үк мәгънәне белдерә торган сүзнең «Каһарман Катил» дастанында мондый чуарлыкта китерелүе Идел буе татарлары традициясе йогынтысы булып, ул исә «Каһарман Катил» дастанының җирле элеменларга шактый бай әсәр булуын ассызыклый.

Моннан тыш әсәрдә багучылык, фал ачу бик популяр сюжет сызыгын тәшкил итә. Мәгълүм булганча, ортодоксаль исламда багучылык ширек гамәл санала («ширек» – гарәп теленнән «иптәш» дип тәрҗемә ителә), Аллаһының иптәшкә һичбер мохтаҗлыгы юк, шуңа күрә исламда ширек иң зур гөнаһ санала һәм аның һәртөрле формасы тыела. Бу – идеаль исламдагы таләп. Әмма һәрбер халыкка борынгыдан хас булганча, төркиләрдә дә киләчәккә алдан күз салу мөмкинлеге белән кызыксыну яшәгән һәм бу кызыксыну, табигый, халыкта гаять көчле булган. Борынгы төркиләрнең IX гасыр ахырында – X гасыр башында ук рун язулы атаклы «Ырк битиг» дип аталган юрау китабы төзегәнлекләре мәгълүм. Китап зур практик әһәмияткә ия булган. Борынгы уйгыр истәлекләрендә шулай ук язмыш юрау китабы «Ан битиг» телгә алына[2]. Шушы һәм башка чыганаклар нигезендә соңрак халыкта төш юрау китапларының таралуын да багучылыкның үзенчәлекле бер тармагы буларак карарга мөмкин.

Хәлбуки, катгый ислам кануннарына туры килмәсә дә, халыкта багучылыкның хикмәтле гамәлләрдән саналып, аңа мөрәҗәгатьнең күплеген инкарь итеп булмый. Астрологларга мөрәҗәгать итеп яки

[1] *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 24–25.

[2] *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М.: Изд-во АН СССР, 1951. С. 155.

башка рәвештә багучылык белән шөгыльләнүгә һәм каһарман язмышын алдан багуның кызыклы нәтиҗәләренә күпләгән мисаллар татар дастаннарында теркәлеп калган. Мондый гамәл, ягъни киләчәк тормышта ниләр булачагыннан алдан ук хәбәрдар булу белән бәйле шөгыль безнең халыкта ислам ныгып урнашкач та дәвам иткән. «У поволжских татар это называлось «фал ачу» (гадание), «Коръән ачу», «китап ачу» (раскрывание Корана или книги), у сибирских татар это действо называлось «палтар ачу»[1]. Чыннан да, филология фәннәре докторы И. Закирова искәрткәнчә, тора-бара багучылыкны Изге китап Коръән белән бәйләү күренеше барлыкка килгән. Бу – ислам диненә нигезләнгән халык диненә, халык исламына хас күренеш, моны исламгача ук ныгып урнашкан борынгы традицияләрнең гаять дәрәҗәдә көчле булуы белән аңлатырга мөмкин. Исламда тыелган булуына карамастан, багучылык халык динендә шул ук ислам тәртипләре кысасына кертеп карала башлаган.

Шул рәвешчә, исламның иң башлангыч чорында тыелган кайбер тәртипләр аның тарихта яшәве дәверендә кеше психологиясе белән бәйле тирән традицияләр басымына буйсынган. Тикшеренүчеләр хәтта «мөселман магиясе» дигән күренешнең барлыкка килүен күрсәтеп, аны өч төргә бүлеп карыйлар: ономатомантия (Коръән хәрефләре, сүзләре һәм Коръәндәге исемнәргә карап юрау), рапсодомантия (юрауда текст мәгънәсен гомумән файдалану) һәм тамим (Коръән сүрәләрен талисман сыйфатында файдалану)[2]. Беренче ике очракта әлеге магик процедураның асылы фал ачуга кайтып кала. Димәк, исламда мабух, ягъни кылырга ярамый торган гамәлләрдән саналса да, кайбер гамәлләр барыбер башкарыла килгән, алай гына да түгел, алар халыкка шул ук ислам традициясе рәвешендә, ягъни Коръәнгә бәйле аңлатылып барып ирешкән. Ахырга таба тирә-юньгә, кешеләргә зыян итми генә киләчәккә күз ташлауга хәтта ортодоксаль ислам үзе дә күз йомган дияргә дә мөмкин.

Фал ачу, фалчыга, фал китабына мөрәҗәгать татар халкында да бик популяр булган. Гөнаһлы гамәл – Аллаһыны узып, киләчәккә күз ташлаудан аермалы буларак, теге я бу мәсьәләдә изге Коръәнгә, китап-

---

[1] *Закирова И.Г.* Мотив «написанной» судьбы в тюркском фольклоре // Вестник Адыгейского государственного ун-та. Серия «Филология и искусствоведение». Майкоп: Изд-во АГУ, 2010. Вып. 4. С. 19.

[2] *Емельянов В.* Народный ислам. URL: ethno.ru/cntnt/narodnij_i.html (дата обращения – 4.04.2012)

ка карап, Аллаһ сүзен алдан белү, фал ачу гадәте – борынгыдан килгән багучылыкны исламга нигезләп алып барырга тырышу нәтиҗәсе ул. Китапка изгеләштереп карарга күнеккән татар халкында шушы ук максатларда еш кына язма әдәби истәлекләргә дә мөрәҗәгать итү очрый. Бездә, мәсәлән, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабын фал ачу өчен куллану очраклары мәгълүм.

«Каһарман Катил» сюжетында да әлеге борынгы традиция, ягъни киләчәкне юрау максатыннан төрле магик ысулларга мөрәҗәгать итү (аның гарәпчә исеме – «гыйлем әл-гайб», ягъни «яшерен белем») шактый әһәмиятле урын алып тора.

Әсәрнең башында ук, кинәт пәйда булган кара болыт, яшен һәм караңгылык фонында өч яшьлек Каһарманның серле югалуына бик кайгырып, атасы – падишаһ Таһмасып багучыларны җыя. Югалган баласы хәсрәтеннән вафат булган Таһмасыпның хамилә калган хатыннарыннан берсе бала тапкач, Таһмасып урынына калган Һирасып баланың «бәхетен, киләчәген карар өчен» багучыларны җыйдырта. Беренче очракта багучылар китап белән эш йөртсәләр, икенче очрактагылары – мөнәҗимнәр, ягъни астрологлар – юрауны йолдызларга карап башкаралар. Хикмәт шунда: фалчы-багучылар сүзе, урыны-вакыты җиткәч, һичшиксез тормышка аша. Бу очракта да Каһаррманның һәм ул югалгач туган бөрадәре Каһтаранның язмышлары юраучылар әйткән финишка һич үзгәрүсез барып ялгана.

Мондый рәвештә каһарман язмышын алдан күрүгә мисалны, башка күпләгән әсәрләр белән бергә, татар һәм Алтын Урда составында яшәгән кайбер башка төркиләр иҗатында бик популяр «Чура батыр» дастанында очратабыз. Биредә Чураның үлеме нидән икәнен белер өчен төрки-татар дастаны сюжеты хәтта урыслардан астрологлар җыены җыйдырта. Кеше язмышын йолдызларга карап ачыклауны Ф.И. Урманчеев «борынгы, хәтта Урта гасырлар урыс мәдәнияте өчен дә хас нәрсә түгел» – дип искәртә[1]. Галим дастанга килеп кергән әлеге сюжетның Урта гасырлар Көнчыгыш, шул исәптән төрки әдәбиятларда һәм халык иҗатында киң таралган күренеш булуын әйтеп уза. Чыннан да, нәкъ шушындый сюжетның фарсы язма чыганагына барып тоташа торган «Каһарман дастаны»нда гаять дәрәҗәдә популярлыгы ук әлеге фикерне раслый. Халыкта киң таралган багу төрләреннән биредә киләчәкне күбрәк китапка мөрәҗәгать итеп белү

[1] *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. 1995. № 9. Б. 100.

өстенлек итә. Хәтта астролог-багучылар да киләчәкне «китапларына карап», «китап ачып» әйтәләр.

Дастанда багучылык белән ислам диненең халыкчан бергә үрелүе күзәтелә. Үзеннән соң ил белән Һушән шаһ исемле падишаһ идарә итәчәген, шаһзадәләр Каһарман белән Каһтаранның аңа тугрылыклы хезмәттә булып, зур батырлыклар кылачагын мөнәҗимнәр чакыртып алдан белгән Һирасып моның Аллаһ биргән язмыш булуы белән килешә, багу аша беленгән мәгълүматка Аллаһ сүзе итеп карый, «Ходайның һичбер эшенә каршы килергә мөмкин түгел» дип, багучылар әйткәнгә карусыз ышана. Алай гына да түгел, багучылар әйткәнне тормышка ашыру өчен үзе үк чаралар күрә – алар әйткәнгә туры китереп, Һушән шаһ чит мәмләкәттән тәхеткә чакыртып китерелә, улы Каһтаранга, «Баһадирлык падишаһлыктан артык», дип, падишаһка карусыз тугрылыклы хезмәт итәргә, бертуганы Таһмасыпның улы баһадир Каһарманга юлыккач, аңа кадер-хөрмәт күрсәтергә вәгазь-нәсыйхәтен әйтә. Әсәр вакыйгаларының нинди юнәлештә барачагына шушында ук нигез салына – алга таба багучылар юраган гел юш килеп тора, ә Каһтаран атасы әйткәннәрне төгәллек белән үти.

Бу – ширек гамәл аша Аллаһыны тану, аңа буйсыну – татарларда исламны халыклашкан рәвешендә аңлауга ачык мисал. Дастан вакыйгаларына көтелмәгәнлек, алдан күзаллап куелганнан читкә тайпылыш, башбаштаклыклар кылу гомумән хас түгел. Биредә төп кагыйдә – ислам гаскәре падишаһына хыянәтсез хезмәт итү, буйсынучанлык күрсәтү. Игътибар итсәк, болар – ислам динендә мөселманнарга куелган таләпләр белән тәңгәл, димәк, ислам динендәге халыкның тормыш-яшәү рәвешендәге төп кагыйдәләргә дә туры килә. «Каһарман Катил»нең дини-героик дастан булуының төп хасияте дә нәкъ менә шунда – биредә төрки эпик традицияләр кысасында дини тормыш рәвеше калыпларыннан читкә чыкмаган каһарман һәм вакыйгалар урын ала. Дастан идеологиясенең бу рәвешле корылуында Борынгы Иран эпик кагыйдәләренә туры килә торган шаһлар, патшалар династияләренә дан җырлау мотивлары да чагылып китә кебек. Бу мотивлар борынгы иран эпик кагыйдәләре белән җиңел яраша, алар рухына туры килә.

«Каһарман Катил» дастанындагы кайбер әһәмиятле моментлар ихтыярсыздан әсәрнең чишмә башы булган «Каһарманнамә»нең архаик тамырларына мөрәҗәгать итүне сорый. Бу җәһәттән Борынгы

Иран эпик традицияләренә Авеста диненең зур йогынтысы тикшерелә торган әсәрдә дә үз эзен калдырган булуы әһәмиятле. Авестаның эчтәлеген тәшкил иткән Караңгылык рухы (Анграа-Майнью) белән Яктылык рухы (Ахура-Мазда), аларның һәркайсына туры килгән мифологик, фәлсәфи, космогоник, физик, әхлакый һ.б. затлар, сыйфатлар, атрибутлар арасындагы көрәш билгеле бер этапта борынгы Иран эпосында киң чагылыш тапкан. Төрки эпосының олугъ белгечләреннән Х.Короглы Авестада телгә алынган күп кенә мәгълүматларның үзләрен үк эпик һәм фольклор материаллары буларак карарга кирәклеген искәрткән иде. Чөнки борынгы Авеста – «әсәрнең стиле буенча фикер йөрткән тикшеренүчеләр уенча, Аллаһыдан иңгән китап түгел, ә автор әсәре»[1]. Биредә персонажлар катгый рәвештә Яхшы һәм Явызлык башлангычларына бүленәләр (Ахура-Мазда һәм Анграа-Майнью капма-каршылыгы). Дөньяны мондый бүленештә күрүне Х.Короглы кешеләрнең борынгы фикерләү рәвешендә һәм шуның аша халык иҗатында да чагылыш тапкан дип бәяли, архаик Иран эпосында мифологик һәм легендар персонажларның шушындый ук классификациядә урын алган булуына игътибарны юнәлтә. Борынгы Иран эпосында Яхшылык башлангычы ролендәге шаһлар һәм аларның тугрылыклы батырлары Явызлык башлангычы вәкилләре булган гадәттән тыш көчкә ия мифик затлар, мәсәлән, Диюләр һ.б. белән көрәш алып баралар. Әмма басып алу яулары, миграцияләнү, ассимиляция һәм соңрак тарих аренасына төрки телле кабиләләрнең чыгуы һәм борынгы иранлылырның алар белән турыдан-туры мөнәсәбәте архаик Иран эпосының, Авеста йогынтысыннан чыгып, башка юнәлеш алуына китергән[2].

Әмма Иран эпосында әлеге бик иртә чор сюжетын чагылдырган кайбер моментлар сакланып калган үрнәкләр дә бар. «Каһарман Катил»дә шактый зур урын алып тора торган акыллы һәм гадел Һушән шаһ падишаһ образы, мәсәлән, шул ук Авестада сурәтләнгән Хушанга (Хаошйангха) исемле персонаж белән гаять дәрәҗәдә охшаш. Бу охшашлык дастандагы Һушән шаһ исеме белән Авестада тасвирланган падишаһларның берсе Хушанганың исем аваздашлыгына гына кайтып калмый. Авеста Хушангасы, Ахура-Мазда кушуы буенча, җиде ил белән

[1] *Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. С. 54.

[2] Шунда ук. Б. 103.

тугрылыклы хакимлек иткән. «Җиде ил» төшенчәсе соңрак иран һәм көнбатыш төркиләр иҗатында «бөтен дөнья» буларак аңлашыла һәм фольклор белән әдәбиятка шул мәгънәдә керә. Монголларның Гесер турындагы атаклы китаби эпосында да шуңа охшаш момент бар – Гесер ун ил белән, ягъни дөнья белән идарә итә, әсәрдә ул даими рәвештә «Десяти стран света владыка» буларак телгә алына[1]. Хушанга кешеләрнең генә түгел, дию, җаду (җасус, сихерче. – *Л.М.*) кебек гадәттән тыш көч ияләренең дә патшасы, Ахура-Маздага тугрылыклы хезмәт итә, скиф мифик шәхесе Паралат (Геродотта – Паралатас) белән бер тамырдан булган гаҗәп күп мәгънәле сүз – Парадхата титулына ия була. Авестада бу титул фәкать Хушанга падишаһка карата гына кулланылган[2]. Авестада тасвирланганча, кырык ел буе гаделлек белән хакимлек итү дәверендә Хушанга Хакыйкатькә каршы тора торган тискәре көчләрне – Друджга (борынгы фарсы сүзе – «драуга», «ялган») хезмәт итүчеләрне һәм мазан диюләрен (Каспийның көньягындагы Мазендаран территориясенең һәм биредә яшәгән диюләргә табынучы кабиләләрнең Авестадагы чагылышы) күпләп юк итә. Күп кенә текстларда Хушанганың кешеләр өстеннән падишаһ хакимлеген канунлаштыруы, ягъни идарә системасын урнаштыруы турында сөйләнә[3]. Хушанга Пишдадид исемле персонажның «Шаһнамә» әсәрендә дә булуы мәгълүм. Биредә дә ул, Авеста Хушангасы кебек үк, кырык ел хакимлек итә, ул падишаһлык иткән чор әлеге китаби героик эпоста «кешелекнең алтын гасыры» дип сурәтләнә. Фирдәүсигә нисбәт ителә торган «Шаһнамә»нең дә Авеста һәм борынгы иран эпосы җирлегендә иҗат ителгән әсәр булуы мәгълүм[4].

«Каһарман Катил»дәге Һушән шаһка килсәк, чыгышы белән ул – Синҗак дигән мәмләкәттән, шул мәмләкәтнең данлыклы падишаһы. Гаделлеге, акыллылыгы һәм дә бик баһадир булуы белән күп шөһрәт казанган. Һиндстаннан кала җир йөзенең барлык падишаһлары моңа буйсынган. «Хәтта моның мөһаятеннән (хәзерлекле булуыннан. – *Л.М.*)

---

[1] *Неклюдов С.Ю., Тумурцерен Ж.* Монгольское сказание о Гесере. Новые записи. М.: Наука, Гл. ред. восточной лит-ры, 1982. С. 129, 138, 141 и др.

[2] *Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана... С. 54–56.

[3] Авеста в русских переводах (1861–1996) / сост., общ. ред., примеч., справ. разд. И.В. Рака. СПб.: Журнал «Нева» РХГИ, 1997. С. 466.

[4] *Бакиров М.* Шигърият бишеге: Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 227.

куркып, күп падишаһлар җирләрен ташлап, әллә кайларга, дөньяның бер почмагына качканнар». Фарсыларның үзләренең махсус чакыруы буенча, үз урынына улы Һайланны калдырып, Һушән шаһ Фарсы тәхетенә килә. Дастанда Синҗак җире Фарсы җиреннән берничә көнлек юл буларак сурәтләнгән. Фарсы тәхетендә Һушән шаһның күп яхшы гамәлләр кылып идарә итүе турында сөйләнә. Әмма төп максат – һиндләрне җиңеп, биредә ислам урнаштыру. Һушән шаһ, «Аллаһының һидаяте (дөрес юлы. – *Л.М.*) ярдәмендә, Фарсы иленең искиткеч батырлары һәм «куәтле, кырмыскадан күп» гаскәре белән, бу көрәштә дә җиңү яулый, озак еллар гаделлек белән хакимлек итеп, дөнья куя.

Димәк, Хушанга да, Һушән шаһ та – бөтен дөнья белән идарә итүчеләр. Авеста герое моны Ахура-Мазда кушуы белән башкарса, Һушән шаһ идарәсе исә – Аллаһының багучылар аркылы беленгән язганын үтәүче. Ахура-Мазда тарафдары буларак, Хушангага барлык уңай сыйфатлар хас. Моңа бәрабәр Һушән шаһ та – идеаль патша. Борынгы Шәрекътән килә торган идея буларак, борынгы төрки-татар әдәбиятында да тугрылыклы идеаль идарәче образының гаять популяр булуы мәгълүм. «Каһарман Катил» дастанында Һушән шаһка хас барлык билгеләрнең Авеста герое билгеләренә барып тоташуын һәм хәтта исемнәренең дә бер төрле яңгыраштa булуын һич тә очраклылык буларак кына бәяләп үтү мөмкин түгел.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар китаби дастаны һәм зәрдөштлек дине китабы – Авестадагы бу параллельләр борынгы Иран эпосыннан үсеп чыккан фарсы «Каһарманнамә»сендә сакланып калган архаик персонажлардан ук килә. Бу исә әсәрнең нигезендә берничә мең еллар элек булган эпик сюжетларга, ягъни Авестага ук барып тоташа торган катламның да булуын дәлилли. Хәлбуки татар версиясендә инде бу сыйфатлар чыганак текстка тугрылык рәвешендә генә китерелгәннәр. Әсәрдә Һушән шаһның төп чыгышы нәрсәгә һәм кемгә барып тоташуга әһәмият бирмәстән, бу персонаж бөтенләй башка кыйммәтләр күзлегеннән тасвирланган. Шуңа күрә «Каһарман Катил» дастанында очрый торган төрле пластларның фольклор контаминациясен бик нык кичергән, кайбер очракларда хәтта символик дәрәҗәдә генә сакланып калган булуын истә тоту зарур.

Дастанда сурәтләнгән Һушән шаһ мәсьәләсендә тарихта янә бер гаҗәеп охшашлык үзенә җәлеп итә. Аңа галим М. Әхмәтҗанов игътибар иткән. Галим атаклы төрек сәяхәтчесе һәм язучысы Әүлия Чәләбинең (XVII йөз урталары) Һушән шаһ мәсьәләсенә бик якын

мөнәсәбәте булган хәбәрләр язып калдыруына әһәмият биргән. Рус теленә тәрҗемә ителгән китаптан алынган әлеге мөһим хәбәрләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «По поводу древних гробниц города Сарая. Отметим, во-первых, что почитаемые гробницы членов общины Мухаммеда и прочих пророков находятся вне города, в стороне кыблы. Среди них прежде всего назовем древнюю гробницу Хушенг-шаха, находящуюся к югу от города, в земляном холмике, в отдалении от реки Волги. Ее почитают, говоря, что Хушенг-шах был пророком мусульманского населения этой страны и наряду с этим – других мусульман. Со всех четырех сторон она обнесена высокой стеной, точно крепость. Длина самой могилы – 70 шагов. В том конце, где голова, поставлен вертикально столб, который едва обхватят три человека. В том конце, где ноги – колонна из белого мрамора. На этой колонне имеется своеобразная надпись, словно печать, и древним письмом изложены все обстоятельства жизни покойного: «Я был падишахом, который правил 40 лет, благоденствовал 500 лет и первым водрузил корону себе на голову»[1].

Бу каберлекне күргән һәм аның хакында тарихи риваять характерындагы хәбәрләр язып калдырган Әүлия Чәләбинең Дәште кыпчак далаларына сәяхәте 1641–1642 һәм 1666–1667 елларда булганлыгы мәгълүм[2]. Риваятьләрдә хәбәр ителгән мәгълүматлар «Каһарман Катил» дастаны рухына һәм андагы вакыйгаларны үз тирәсенә туплаган Һушән шаһ образына гаять дәрәҗәдә туры килә. Бу борынгы хәбәрләр үз эченә төрки кабиләләрнең борынгы чорда бик киң географик таралышы мәсьәләләренә үк барып тоташа торган үтә кызыклы һәм бәхәсле тарихи проблемаларны кузгата.

Хәзер әлеге ике фикерне бер ноктага туплыйк: Авеста Хушангасының да, Дәште кыпчак далалары Хушан шаһының да бер үк шәхес булулары әлегә тарихчылар тарафыннан исбатланган факт булмаса да, моны игътибарсыз калдырып яисә инкарь итеп тә булмый. Дастанның әкияти-мифологик өлешендә Һиһатия далалары турында телгә алына. Шул ук Әүлия Чәләби исә Һиһатиянең Дәште Кыпчакның синонимы булуын күрсәтеп уза: «А во времена Чисгисхана во всех концах Дешти Кыпчака – т.е. Хейхат имелось 170 крупных

---

[1] Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар.кит. нәшр., 1998. Б. 10.

[2] *Челеби Эвлия.* Книга путешествия. (Извлечения из сочинения турецкого путешественника XVII вв.). Вып. 2. М., 1979.

городов. Ныне среди их руин разбивают свои стоянки и кочуют калмыцкие шахи – Тайша шах и Мончак шах с двумястами тысячами кочевых стойбищ. Все упомянутые города разрушил могучий Тимур-хан»[1]. Үз заманында Дәште Кыпчак гаять киң территорияне биләгән. Дәште Кыпчак – Иртеш елгасыннан Дунай елгасына чаклы, Балхаш күленнән Сыр-Дәрьяның түбән агымына, аннан Кырымга хәтле сузылган, Идел буе Болгары белән рус кенәзлекләре чигенә кадәр булган кыпчаклар яшәгән җир-далаларның XI–XV йөзләрдә гарәп-фарсы тарихи язмаларында кулланылган атамасы, 1240 еллардан Алтын Урда биләмәсе[2]. IX–X һәм хәтта аңа кадәрге үк Иран – Урта Азия территорияләре картасында да Сыр-Дәрья тирәсеннән башланган шактый зур күрше биләмәләрнең Хихат сүзе белән күрсәтелгән булуы игътибарга лаек. «Каһарман Катил»нең иң төп персонажы Һушән шаһның әүвәл Авестада сурәтләнеп, соңрак, легендалар нигезендә Дәште Кыпчак падишаһына әверелдерелгән шәхеснең прототибы булуы бик ихтимал. Дастанның географик ареалы һәм хронологик тирәнлеге үз эчтәлегенә мондый бәйләнешне иркен сыйдыра. Һушән шаһның Фарсы җиренә читтән китерелгән шөһрәтле падишаһ булу факты исә моны янә бер кат раслый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Каһарман Катил» Һушән шаһының Авеста персонажы Хушанга падишаһ белән дә, кабере Кыпчак далаларында табылуы турында мәгълүматлар сакланган падишаһ Хушан-шаһ белән дә зур уртаклыкка ия булуы дастанның тарихи һәм географик масштабын тагын да ачыграк күзалларга мөмкинлек тудыра. Әмма биредә дан-шөһрәтле, җиңүче Һушән шаһның исламны берләштерү идеясен тормышка ашыру өчен кулланылган дастани персонаж булуын да истән чыгарырга ярамый. Борынгы язма чыганакларга яисә реаль тарих вакыйгаларына никадәр генә якынайган булуына карамастан, дастандагы Һушән шаһ ул – гаять дәрәҗәдә бай һәм тирән тамырлы шартлы образ.

Дастанның әкияти-мифологик сюжеты исламгача Борынгы Иран мифологиясен шактый актив тасвирлавы белән татар халкының тылсымлы әкиятләр дип классификацияләнә торган төркеменә караган жанр персонажлары белән дә зур уртаклыкка ия. Татар ха-

[1] Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 11.

[2] Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002. Б. 197.

лык әкиятләрендә һәм кайбер дастаннарында гаять популяр диюләр, пәриләр, хәтта дию пәриләре, Сәмруг кош, сихерче-җадулар һәм алар белән янәшә, алар белән тыгыз мөнәсәбәттә тасвирланган көрәшче-батыр образы катнашындагы сюжет бик еш кына Борынгы Иран мифологиясенә барып тоташа. Биредә дә, ягъни Борынгы Иранда да явыз рухлар белән көрәшеп, аларны җиңүче батыр үзәк урыннарның берсен алып торган. Мәсәлән, Иран героик эпосында атаклы Рөстәм батырның диюләр белән көрәше тасвирлана. Яхшылык белән Явызлык конфликтын чагылдырган бу көрәш Иран архаик эпосында китаби-пәһләви әдәбияты буларак мәгълүм. Пәһләви әдәбияты – исламгача булган пәһләви һәм фарсы телле әсәрләр берлеге. Иран әдәбияты белгечләре Зәрдөштлек китабы Авестаның (ул үзе биш китаптан тора) үзен дә шушы чор истәлеге итеп карыйлар[1]. Иранның мөселманлык чорына кадәрге язма истәлекләреннән гыйбарәт бу ядкарьләр, әлбәттә, барлык тулылыгы белән сакланып кала алмаганнар. Әмма Яхшы белән Яман көрәше темасы, шуңа бәйле рәвештә һәм шуннан килеп чыга торган гадел патша, патшаны саклаучы баһадир, баһадирның явыз мифик затлар белән сугышып җиңүе һ.б. күп кенә идеяләр халык иҗатында һәм аерым алганда аның эпосында килеп җиткәннәр. «Каһарман Катил» дастанындагы Әквал дию образы, әйтик, фарсы халык дастаннарындагы («Мәлик Җәмшид», «Шаһнамә» һ.б) Акван-див исемле дию образы белән исемнәр яңгырашы ягыннан да, индивидуаль персонаж буларак холык-фигыленең тасвирланышы белән дә бер-берсен кабатлыйлар. Әквалнең дә, Акван-дивның да таштан салынган гаҗәеп затлы сарайлары, гөл-чәчәк бакчалары бар. Алар үзләре әллә ничә тел беләләр (диюләрнең бу сыйфаты дастанда тасвирланган башка дию образларына да хас), яманлык яклы образ буларак гәүдәләнгәннәр. «Каһарман Катил»дә Әквал дию һәм аның белән бәйле вакыйгалар дастанның Борынгы Иран мифологиясе белән тыгыз бәйләнеше хакында сөйли.

Сюжет традицияләре архаик Ираннан ук килә торган моментлар «Каһарман Катил» дастанында, чыннан да, шактый зур урын алып тора. Образ-персонажлары, аларның үзара мөнәсәбәте җәһәтеннән әсәрнең зур бер сюжет сызыгын тәшкил иткән әкиятимифологик өлеше дә борынгы Иранның язмача теркәлеп калган иң

[1] *Брагинский И.С.* Литература Ирана и Средней Азии // История Всемирной литературы: в девяти томах. Т. 2. М.: Наука, 1984. С. 248.

зур истәлеге – Авеста белән зур уртаклыкка ия. Биредә Авестаның үзенең дә архаик Иран эпосы белән тыгыз бәйләнештә булуы әһәмиятле. Төрки-татар дастан-әкиятләренең архаик Иран эпосы белән охшашлыгының тамырлары һич кенә дә Авеста яисә борынгы һәм урта фарсы телле чыганаклардан турыдан-туры калька түгел. Монда генетик бәйләнеш юк, шуңа күрә генетик якынлык һәм аның аша әдәби истәлекләрдәге охшашлык турында да сүз була алмый. Шул ук вакытта мифик образлардагы, идея-мотивлардагы уртаклыкның һәркайсын халыкара типологик бертөрлелек дип кенә дә бәяләп бетереп булмый. Гаять дәрәҗәдә зур охшашлыкның төп нигезе бик борынгы заманнардан – Иран территориясенең Дәште Кыпчак территорияләре белән тарихи һәм географик якынлык чорыннан ук килә. Шул ук вакытта Иранга үтеп кергән төрки кабиләләрнең дә үз әдәби-мәдәни кыйммәтләре аша биредәге мәдәнияткә көчле тәэсир ясаган булуын истән чыгарырга ярамый.

Архаик Иран эпик образлары белән татар дастаннары һәм әкиятләре арасындагы уртаклыкның тамырлары төрки-иран якынлыгыннан килә булса кирәк. Бу якынлыкның иҗтимагый-тарихи сәбәпләре халыкның рухи таләпләре һәм территориаль бергәлек принципларына барып тоташа, аның тәэсире милли үткәнебезнең берничә гасырны берьюлы колачлаган әһәмиятле этабын тулаем иңли. Дию, әллә ничә башлы аждаһа, пәриләр, Сәмруг кош, акыллы патшаның гадел хакимлеге, патшага тугрылык, диюләрне җиңүче батыр, хәтта хәйлә-мәкер интригалары, ахырда явыз көчләрнең уңай каһарманнар, гадәттә гадәттән тыш батыр кеше тарафыннан харап ителүе – болар бар да безгә татар халык әкиятләреннән үк таныш образ-мотивлар. Нәкъ шушындый бергәлектә алар Борынгы Иран эпосында да урын алганнар. Мондый гаҗәеп охшашлыкны, тематик һәм фикер якынлыгын асылда бик борынгы чорлардан алып шушы ареалга мөнәсәбәтле халыкларның рухи берлеге белән генә аңлатырга мөмкин.

Алда санап үтелгән образ-персонажлар, мотивлар «Каһарман Катил» дастанында үтә катлаулы эзлеклелектә гаҗәеп бай гәүдәләнеш тапканнар.

Каһарман Катилне өч яшьлек вакытында ук диюләр урлап китә. Дастанда мифик затлар дөньясы белән кешеләр яши торган дөнья арасында бәйләнеш бик зур булуга карамастан, дастанда алар икесе ике дөнья буларак бирелгән. Мифик затлар дөньясы турындагы тасвир әсәрнең маҗаралылыгын бик нык арттырса да, бу ике дөнья

затлары арасында кайвакыт хәтта никах җепләре сузылып, пәри заты һәм адәм заты кушылудан туган кешеләр тасвирланса да, кешеләр, пәриләр һәм диюләр дөньясы иҗтимагый мәсьәләләрдә берничек тә бер-берсенә керешеп китми. Мәсәлән, ислам гаскәре үз максатларына кешеләр җәмгыятенә хас рәвештә генә – ике як сугышчылары арасындагы каты сугышларда җиңү яулап кына ирешә. Ә пәриләр һәм диюләр мәсьәләсе дастанда аерым-аерым күләмле хикәятләр рәвешендә хәл ителә бара. Биредә дә шул ук батырлар, аларның, аерым алганда Каһарманның, искиткеч зур батырлыклары турында сүз бара, әмма мифик затлар дөньясының үзләренә генә хас үзенчәлекләре дә шактый (сихерче-җадулар аша эш йөртү, бик еш кына хәйлә-мәкер юлына басып, максатка җитү һ.б.). Боларның дөньясы икенче бер чит дөнья характерында булып, кешеләр дөньясына хас проблемаларны хәл итүдә алар катнашмый.

Дастанда реаль дөнья белән мифик дөнья аерып куелса да, алар арасында каршылык юк, ә менә гадәти адәм көче белән үтеп булмаслык чик һәм әлеге ике дөнья затлары арасындагы мәңгелек көрәш бар. Бу ике дөнья үзләренә генә хас булган образ-персонажлар системасы белән бер-берсеннән аерыла да, шул ук вакытта бик тыгыз бергәлектә дә тора. Биредә дөньяны исламча аңлау ике төрле дөньяга да үтеп кергән булып аңлашыла, чөнки биредә мифик дөнья персонажлары да Аллаһ исемен телгә алып сөйли, пәриләр исламның җиңүе белән кызыксыналар һ.б. Әсәрдәге вакыйгалар әнә шулай китаби традициягә хас бәйләнештә бирелгәннәр. Дөньяны ике төрле күзаллауның бер әсәргә берләшкән булуы – үзе дә фәкать китаби традицияләр нәтиҗәсендә туган сурәт ул. Моңа мисал «Түләк китабы»нда (Түләкнең су асты дөньясына килеп эләгүе), «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы дастаннарда (Таһирны сандыкка салып суга агызу эпизоды), «Йосыф кыйссасы»нда (кое образын һәм аның сыйфатларын тасвирлау) һ.б., һ.б. китаби дастаннарда очрый.

«Каһарман Катил»дә борынгы төрки һәм төрки-иран фольклоры һәм язма поэзиясе образларыннан Сәмруг кош, кое образы, кайчандыр атаклы җадудан сабак алган, хәйлә-мәкергә оста, пәриләр телен белүче Кердан Кешан, тылсым көче һ.б. дастанда шушы ике дөньяны үзара тоташтыра торган буын ролен үтиләр. Мифик дөнья персонажы Шаһбал шаһ, авыр хәлдә калгач, кешеләр дөньясына пәриләрен җибәреп, алар аша хатын тапшырта. Эчтәлеге Каһарманнан ярдәм сораудан гыйбарәт бу хатны Кердан Кешан укып, тәрҗемәләп

биргәч, Каһарман Шаһбалның хатыны Камәррухны коткарырга, Әквал дию белән көрәшеп, аны җиңәргә дип, Гамгам кылычын алып, юлга кузгала.

Иң әүвәл ул, пәриләргә атланып, Мохит тавы аша Һиһатия далаларына килә. Бик матур бер бакчадагы гаҗәеп гөмбәздәге язуны укый. Бу язуда Каһарманның биредә күптән көтелгән кеше булып, аңа күрсәтмәләр бәйнә-бәйнә язылган була. Алга таба Каһарман максатына җиткәндә һәрвакыт шул күрсәтмәләрне исендә тотып гамәл кыла. Пәриләр атавы булган бу урыннар – беренче кат мифик дөнья булса, алга таба Каһарман икенче бер мифик дөньяга килеп чыга. Монысы кое аша башкарыла. Бу дөньяда ул катлаулыдан-катлаулы һәм гаять дәрәҗәдә маҗаралы вакыйгаларда катнаша, гаҗәеп тылсымнар ярдәмендә, әмма шул ук вакытта Аллаһка тапшырып һәм Каһарманның шәхси батырлыклар кылуы аркасында (ул үзе белән һәрвакыт Гамгам исемле кылычын йөртә) явызлык иясе Шәгъбан диюне үтерә, Карун шаһның дәверләр йозагына бикләнеп, Каһарман исемле пәһлеванның килүен көтеп яткан сихер-тылсымнарын ача. Монда ирексездән дастан белән татар халкының «Ак бүре» әкияте арасында параллельләр үткәрү ихтыяҗы барлыкка килә, чөнки сюжет һәм образ охшашлыклары бик күп. Күргәнебезчә, «Каһарман Катил»дәге мифик дөнья үзе дә гаять катлаулы һәм тармаклы. Каһарман биредә әллә ничә кое аша үтә. Кое гадәти генә түгел. Ул бик тар, тирән – Каһарман аңа таш атып карый, ташның төшеп җиткән тавышы ишетелми. Шуннан биленә бау бәйләп, бауны кое читендәге кадакка эләктереп, төшеп китә, алай да төпкә җитә алмый, кадак Каһарман авырлыгына түзмичә ычкынып китә һәм батыр, бик озак очканның соңында, ниһаять, төпкә килеп төшә һәм сәгатьләр буена исенә килә алмый ята. Каһарман Катил бирегә килеп эләккәнче үк язуда күрсәтелгән эшләрнең барысын да җиренә җиткереп, әкият баһадирларына хас батырлыклар кылып, маҗараларны уңай чишеп, Бәллүр тавына китеп, Камәррухны коткара. Мифик дөньяда Каһарман Катил бердәнбер уңай персонаж түгел, биредә диюләрнең яхшылык тарафдарлары да бар, аңа пәриләр дә ярдәмгә килә, шулай ук адәми затлардан да кайберәүләр бу маҗараларда актив катнаша. Шуларның берсе – Каһарманның никахлы хатыны, һиндләр ягыннан Ислам гаскәре ягына чыккан акыллы сылу – Сәрви Хораман. Төрки эпосына хас булганча, баһадирның хатын-кыз юдашы аңа күп төрле ярдәмнәр күрсәтә.

Кабат «үз» дөньяларына адәмнәрнең бер төркеме пәриләр ярдәмендә әйләнеп кайта. Ә Каһарман, эшләп бетерәсе эшләре булганга, Һиһатия сәхрәсе ягындагы Каф тавы итәгендә урнашкан Кечкенә Бәллүр тауга килә, биредә Сәмруг кошның балаларын үлемнән коткара. Сәмруг кош балаларына янаган куркыныч – аларның Кечкенә Бәллүр тауда үскән агач башындагы ояларына үрмәләп менеп килә торган аждаһа. Билгеле булганча, аждаһа – кешегә зыянлы мифологик зат һәм әлеге образ үзенең тамырлары белән Иран мифологиясенә барып тоташа[1]. Биредә аждаһаның күп башлы булмыйча, бер генә башлы булуын әйтеп үтик. Бу яктан һәм дастанда аңа чагыштырмача аз функция йөкләтелгән булуы белән ул Иран традициясендәге күп башлы аждаһадан күпмедер аерылып тора һәм төрки халыклар арасында киң таралган, Кытай мифологиясе белән уртаклыгы зур булган бер башлы канатлы еланга якынаеп китә кебек. Татар халык әкиятләрендәгечә үк, Каһарман аждаһаны үтерә.

Рәхмәт йөзеннән Сәмруг кош батырга кире «үз» ягына кайтара торган юлның бер өлешен үтәргә булыша. Каһарман, Сәмруг кошка утырып, җиде көн оча – җиде айлык юл үтәләр, чөнки «Сәмруг гаять каты оча иде». Шул рәвешле Каһарман Әквал дию яши торган Бәллүр тавына җитә, биредәге исәп-хисаптан соң, Сөһман дию ярдәмендә Каһарман кабат «үз» дөньясына кайтып җитә, биредә аны данлап каршы алалар, Һушән шаһ үзе аны каршыларга дип юлга чыга. Соңыннан барысы бергә Һинд иленнән кире фарсы мәмләкәтенә кайтып, бәхетле гомер кичерәләр.

Игътибар итсәк, дастанның мифик дөнья белән бәйле өлешендә генә дә исламгача булган төрки-иран пластын да, мөселман традицияләре йогынтысы катламын да табарга мөмкин. Дию, пәриләр, аждаһа – болар бар да бер тирәдә, ягъни бер дөньяда яшиләр. Аларның биләмәсенә барып җитү адәми зат кулыннан килә торган гамәл түгел. Әмма бу бөтенләй үк мөмкин булмаган эш тә түгел. Дастанда бу дөнья һәм теге дөнья гәүдәләнешен күрәбез. Адәми зат ул дөньяда кала алмый, маҗаралар аша, үлем белән көрәшә-көрәшә, кире бу дөньяга әйләнеп кайта. Ике төрле дөнья арасы елларга торырлык ерак, әмма шул ук вакытта теге дөнья образ-персонажлары бу дөньяда да һәрвакыт янәшәдә генә. Болар – борынгы фикерләү

[1] *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 28.

рәвешенең татар эпосындагы чагылышы, яшәү-үлем фәлсәфәсенең татар китаби дастанына хас типик чишелеше.

Монда реаль дөньяның сурәтләнешен исламча дөньяга караш дип билгеләсәк, диюләр, пәриләр, җадулар белән тулы, әлеге мифик затлар тормышын сурәтләгән икенче бер дөнья исә бик борынгы, исламгача ук булган дөньяга карашның традицион картинасын өлешчә торгызу булып аңлашыла. Дастан персонажлары бу дөньядан тегесенә һәм киресенчә бик актив хәрәкәт итәләр, кире үз урыннарына әйләнеп кайталар. Бу – дөньяны, борынгы мифологиягә хас булганча, «тереләр» һәм «үлеләр», «үземнеке» һәм «чит» дип бүлү мотивына якын тора. «Каһарман Катил»дә тудырылган реаль дөнья картинасы дөньяның мифик тасвирланышы белән янәшә бирелү дә дастандагы берничә катлам традицияләренең бер әсәргә тупланган булуыннан килә. Әсәрдәге «үземнеке» дип билгеләп була торган исламча дөньяга караш борынгы төрки һәм иран субстратыннан гыйбарәт дөньяга караш белән гаять дәрәҗәдә ярашкан.

Мифик дөньяда йөргәндә Каһарман мәрмәр таштан эшләнгән мәһабәт гөмбәзләр янына килеп чыга. Гөмбәз дигәндә биредә ишеген ачып кереп була торган зур бина – сарай күздә тотыла. Сарай каршындагы юан таш баганага Каһарманга атап язулар язылган. Каһарман, анда язылганнарга буйсынып, сарайның эченә үтә бара. Биредә сарайны һәм аның эчендәгеләрне тасвирлауда архитектура, скульптура, рәсем сәнгатенә мөнәсәбәт гаять кызыклы. Ислам гаскәренең җиңүе идеясен алга сөрә торган дастанда төрле җанвар – арыслан, фил, крокодил сурәтләре, стенадагы сурәтләрнең авыз ачып бик каты кычкырулары, кычкырган саен сурәтләрнең авызларыннан коелып торган еланнар, чаяннар, таш сыннар һ.б. турында сөйләнә. Моннан тыш та әле дастан сюжетында Бәһрам Җәбали исемле пәһлеван белән аның мәгъшукасы Диләрәмне Әквал диюнең Азрык җаду сихере ярдәмендә таш сынга әйләндергән булуы хакында сүз бара. Сын ясау, сурәт тудыру, бигрәк тә кешенең йөзен ясау – мөселман традициясенә капма-каршы гамәл. Әлеге мәсьәләләр белән махсус шөгыльләнгән Л. Масиньон кеше йөзен ясауның һәм гомумән сәнгатьнең Коръәндә ачыктан-ачык тыелмаса да, хәдисләрдә каты тәнкыйтьләнүе хакында яза һәм мисалга бер хәдисне китерә: «В день страшного суда бог накажет художников, творцов образов, потребовав от них невозможного: оживить свои творения»[1].

---

[1] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали... С. 111–112.

«Каһарман Катил»гә килеп кергән мондый зооморфик элементлар әсәрдә берничә катлам традицияләренең тәртипсез буталуыннан килеп чыккан күренеш. Болар – борынгы төрки фольклор традицияләре катламы. Биредә дөньяга карашның борынгы мифологик атрибутлары урын алган.

Сынчылык, таш сурәтләр – эпитафик истәлекләр буларак борынгы төркиләрнең реаль тарихында да булган фактлар. Кыпчак далаларында Җаектан алып хәзерге Молдавия җирләренә кадәрге территориядә XI–XII гасырларда ук угыз һәм кыпчак кабиләләре тарафыннан куелган ир һәм хатын-кыз таш сыннары саклана. Боларның куелу тарихы шактый бәхәсле булып, рус тарихында алар «болван» термины белән аталалар. М. Әхмәтҗанов әлеге терминның төрки-татарлар героик эпосында «батыр» мәгънәсендә кулланыла торган «пәһлеван» сүзенә аваздашлыгына игътибар итә[1]. «Каһарман Катил»дә дә батырларга карата пәһлеван сүзе кулланылган. Уйгыр, үзбәк һ.б. төркиләрдә «пәһлеван» сүзе «палван» рәвешендә үзгәреш кичергән. Димәк, чынбарлыкта бүгенгәчә сакланып калган болваннарның төрки палван – пәһлеван булу ихтималы юк түгел. «Каһарман Катил» дастанында үз урынын тапкан таш сыннар, сынга әверелдерү кебек элементлар да мифик дөнья сурәтендә борынгы төркиләр чалымына ишарә итә кебек. Таш сыннар, таштагы җанлы сурәтләр – төркиләрнең каһарманлык дастаны образлары.

Дастанда каһарманның батырлык сыйфатларын тасвирлау, сугыш-орыш картиналарының гаять җентекле бирелеше, әһәмиятле иҗтимагый-сәяси вакыйгалар уңаеннан сөенче алу, төп каһарманга гашыйк булып, аңа ярдәмгә килүче дошман ягы гүзәл заты, төрки эпос өчен типик саннарның популярлыгы, реаль дөньяда да, мифик дөньяда да пәһлеванның махсус сугыш киеме, үзенә генә аталган сугыш коралы булу, төрки этикет кагыйдәләре, аларның үтәлү-үтәлмәвенә бәя бирелү һ.б. – болар бар да әсәр сюжетында төрки-татар эпик пластын тәшкил итә торган мөһим элементлар.

«Каһарман Катил»дә һиндләргә каршы сугышып йөргән вакытта һиндиләр патшасы кызының ислам гаскәренә ярдәмгә килүе тасвирлана. Бу кыз Каһарманга гыйшык тота башлый, шул сәбәпле төрле юллар белән үз атасының түгел, ә мәгъшукының җиңүе өчен тырыша. Бу – тарихи эпос өчен типик хәл. В.М. Жирмунский

[1] Каһарман Катил. Дастан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 6.

мондый мотивка мисалны казакъ дастаннарыннан китергән иде. Анда калмык ханы Кобактының кызы Карлыга, каракыпчак баһадиры Кобландыга гашыйк булып, каһарманга үз атасын җиңәргә булыша, дошманының йомшак ягын Карлыга аша белеп алган Кобланды Кобактыны уктан атып һәлак итә[1]. «Каһарман Катил»дә шушы ук мотив үзе бер сюжет сызыгы дәрәҗәсенә үстерелгән. Монда кызның гыйшык утыннан яну-көюләре, үз мәхәббәтен аңлату һәм Каһарманның да үзенә карата мөнәсәбәтен ачыклау өчен төрле гамәлләр кылуы, аларның хат язып аралашулары, атасының серен ислам гаскәренә чишүе, үзенең дә җиңгән гаскәр ягына чыгып, соңыннан никах укытып кавышулары, катлаулы ситуацияләрдә хатынының Каһарманга һәрвакыт ярдәмгә атлыгып торуы һ.б.ның барысы турында да гаять мавыктыргыч итеп сөйләнә.

«Каһарман Катил» дастанында төрки героик эпосына хас мондый сюжет-мотивлар, детальләр бик зур урын алып тора. Традицион төрки эпосында гадәттә мондый элементлар нейтраль сурәтләнгән була. Болар – халык тормышының табигый атрибутлары. Эпоста аларга карата гомумхалык фикере чичән теле белән читтән торып бирелү формасын алган була, ягъни традицион дастанда нейтраль сурәтләнеш – чичән тарафыннан әйтелгән гомумиләштерелгән фикер бирелеше ул. Ә менә китаби дастанда югарыда саналган төрки катлам элементлары гаять җентекле тасвирланып кына калмаганнар, саф эпостан аермалы буларак, аларга һәр очракта диярлек детальле китаби бәя дә бирелә барган. «Каһарман Катил»дә китаби дастанның бу үзенчәлеге әсәрдәге эреле-ваклы һәр картинаны мөселман идеологиясенә төреп, китаби-эмоциональ чагыштырулар, әдәби-сәнгатьчә тәгъбирләр белән баетып бирергә омтылышта чагыла. Менә, мәсәлән, ислам гаскәре белән һиндләрнең каты көрәшен тасвирлаган юллардан бер мисал: «Әлхасыйль, сугыш шундый куәтле булды ки, ата угылны, ана кызны, туган кардәшен танымаслык кыямәт көн кебек булды. Менә бер вакыт Каһтаран һинд гаскәренең уңындагы башлыгы Сәһрапка очрады вә икесе кара-каршы сугыша башладылар. Ахшамгача сугышсалар да, һичберсе җиңә алмады. ... Ике як та үлекләрне санагач, ислам гаскәреннән 612 кеше шәһид булган, һиндиләрдән 20500 гә якын кешенең кырылганы беленде.

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 245; Казахский эпос / под ред. И. Сельвинского. Алма-Ата, 1958. С. 41; 124–127; 259.

Һушән шаһ, шәһид булган гаскәриләр өчен бик кайгырып, сугышны туктатып торып, үлекләрне күмәргә әмер кылды...». Сугыш-орыш картинасы тасвирындагы мондый үзешчәнлек саф архаик төрки дастаннарыбыз өчен бөтенләй чит. Хәлбуки биредә индивидуаль иҗат тәэсире сизелә. Әлбәттә, әсәрнең әлеге башлангычы аноним, әмма әсәрне аңлап кабул итү барышында бу башлангычның роле аермачык күренә. Әсәр стилендә китаби тәгъбирләрнең күп булуы, текстта сирәк кенә очраган тезмә юлларның да китаби стильгә күчкәнлеге (силлабика юк, тезмә урыннар бар да – гаруз, мәсәлән:

Баштан ашып бәхре бәла (бәла диңгезе. – *Л.М.*) чыгалады,
Аташ һәм җан вә чәкәрем дагалады.
Күз яшем түктем, тәмам булдым сукыр,
Күргәнем минем җафамны кем укыр),

булачак һәр вакыйгада Аллаһка таянырга өндәү, фәлсәфи рух – болар һәммәсе «Каһарман Катил»нең фольклордан гыйбарәт эреле-ваклы кисәкләрен индивидуаль иҗатның сутлы җепләре белән тоташтыручыплэү булып күзалланалар.

Шулай итеп, «Каһарман Катил» – төрки-татарларның синкретик характерга ия героик китаби эпосы. Биредә борынгы төрки һәм борынгы иран компонентлары да, соңгырак чор мөселманлык компонентлары да, төрки эпик традицияләре катламы да, исламны Идел буе татарларында күпмедер дәрәҗәдә халыклаштырып аңлау формасы да чагылыш тапкан. Дастан төрки фольклор традицияләренең архаик иран һәм төрки-иран мөселманлык дәверләре традицияләре белән эмоциональ-фикри бергәлеген тәшкил итә. Бу бергәлек дастандагы аноним-индивидуальлек ярдәмендә хасил булган. Югарыда күзәтелгән ике башлангычка корылган булуы «Каһарман Катил»нең күләмле эпик бөтен булып формалашуын тәэмин иткән. Сюжеты фарсы язма истәлегеннән килә торган бу әсәр, чыннан да, төркиләр тормышына һәм төрки героик эпосына күп яклап бик якын, мавыктыргыч вакыйгалар укучыны тиз җәлеп итә, шулай ук дөньяны мифик күзаллау кебек һәм идеологик моментлар да үз ролен уйный. Ул – борынгы төрки-иран этносара бәйләнешләрен һәм әлеге халыклар фольклорында һәм әдәбиятында үзара йогынтыны күзәтеп ачыклауда бәһасез бай чыганак, халкыбызның героикага нигезләнгән күренекле һәм кыйммәтле китаби дастаннарыннан берсе.

## § 2. Чура батырга багышланган эпик иҗат

Заманында Алтын Урда составына кергән төркиләрдән казан, кырым татарлары, нугай, казакъ һәм башкорт халыкларының эпик иҗатында Чура образы бик популяр. Чура батырга багышланган дастан, риваять, бәет, кобайырларның һәркайсы тарихта билгеле вакыйганы – Казан алынуны бәян итә. Ә Казанның рус дәүләте тарафыннан 1552 елда яуланган булуы билгеле, шуңа күрә бу әсәрләрнең барлыкка килү вакыты XVI йөз уртасыннан да иртәрәк була алмаган. Дөрес, эпик сюжетларның кайсы чорга караганлыгын төгәл ачыклап бетерү мөмкин түгел, тик бу очракта конкрет тарихи факт үзе ярдәмгә килә. XVI йөз уртасыннан соң формалашкан һәм төрле версия-вариантларда таралган әлеге эпик иҗатны, академик В.М. Жирмунский фикеренә таянып[1], төрки эпосның тарихи-сәяси темасы ачыкланган соңгырак катламына нисбәт итәбез.

Башка төрки версияләре белән чагыштырып анализлау күрсәткәнчә[2], бу образның татар халык иҗатындагы чагылышы үзенең күбрәк китаби иҗатка нисбәтле булуы белән аерылып тора. Традицион фольклор әсәрләрендә, ягъни телдән сөйләнеп килгән жанрларда да гәүдәләнгән булуга карамастан (аның исеме белән бәйле риваять күздә тотыла), бу образ татар халык иҗатында иң әүвәл язма мәдәният – дастанның китаби төре аша танылу алган. Дөрес, Чура батырга багышланган дастаннарның башка халыктагы версияләрен дә тел-авыз иҗатының иң саф үрнәге дип әйтеп булмый. Соңгырак чор төрки эпосына сөйләмә формадан язуга күчә бару тенденциясе гомумән хас. Табигый ки, бу процесста традицион дастан авыз-тел иҗаты билгеләрен югалта төшкән. Шулай да нугай, кырым татарлары һәм бигрәк тә казакъ дастаннарында телдән башкарылу техникасы яхшырак сакланган, текст стилендә халык шигыренә нигезләнү өстенлек итә. Шулай ук башкортларда әлеге сюжет кобайыр шигыре белән ярым чәчмә, ярым тезмә рәвештә хикәят итеп сөйләнгән. Башкорт халык иҗатында Чура (Сура) батыр хакында телдән сөйләнә торган риваять рәвешендәге төрле вак сюжетларны әле хәзер дә очратырга мөмкин[3].

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 90.

[2] *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. 192 б.

[3] *Хөсәенов Г., Сөләйманов Ә.* Нугай сыгышлы эпостың башкортлашканы // Башкорт халык ижады. 7-се том. Язма кисса һәм дастандар. Өфө: Китап, 2004. Б. 508.

Безнең фольклорда Чура образы берничә эпик жанрда гәүдәләнгән. Башка төрки халыклар эпосы белән аваздаш күләмле дастан һәм аның вариантлары[1], тарихи бәет[2] һәм риваятьләр[3] – һәммәсе бу образны халык каһарманы буларак тасвирлау белән характерланалар. Иң беренче чиратта башка төрки халыклар эпосы белән аваздаш күләмле дастан игътибарны җәлеп итә.

Татарча дастан тексты беренче мәртәбә 1862 елда ук Н.И. Березинның «Турецкая хрестоматия»сендә «Нарәң һәм Чура батыр турында хикәят» исеме белән басылган[4]. 1984 елда исә «Татар халык иҗаты. Дастаннар» китабына фольклорчы галимә Ф. Әхмәтова тарафыннан шушы хрестоматиядән алып кертелгән[5]. Фольклор галиме Ф.И. Урманчеев дастанның Н.И. Березин хрестоматиясендә төрекмән диалекты үрнәге итеп бирелүен түбәндәгечә шәрехли: «Лингвистикада «төрекмән диалекты» дигән тел яисә диалект мәгълүм түгел. Бәлки биредә сүз Иделнең түбән агымындагы ярым-татар, ярым-нугай, ярым-төрекмән диалектында сөйләшүче трухменнар турында барадыр? Әсәрнең телендә, чыннан да, казакъ һәм нугай телләре йогынтысы сизелә»[6].

Әмма дастан татар телендә язылган. Әсәр үзенең идея-сюжеты ягыннан казан татарларының XVI йөзнең икенче яртысыннан соңгы мохитын үтә якыннан тасвирлавы белән аерылып тора. Шул ук вакытта теленең татар теленең урта диалектына хас билгеләре дә бу әсәрне казан татарларына нисбәт итә. Моннан тыш татар халкында сакланып калган бәет, риваятьләр Чура батырга багышланган башка төрки версияләренә караганда нәкъ менә шушы дастан рухына тәңгәл килә, шул ук әсәр вакыйгаларының урыны-вакыты белән чагыша, шулай ук казан татарыннан язып алынган сөйләмә вариантта да,

---

[1] *Баязит Р.* Яңа кала. Чура батыр // Ак юл. 1915. № 16. Б. 282–286; *Юлдаш К.* Чура батыр // Аң. 1916. 5 нче сан. Б. 85–86; Кыйссаи Чура батыр. Казан: Вечеслав тип., 1884. 16 б.

[2] Казан тарихы // Насыйри К. Календарь 1881 елга. Казан, 1880; Казанская история // Катанов Ф. Исторические песни Казанских татар. Казань, 1899. Б. 5–22.

[3] Карауҗа // Татар халык иҗаты. Риваять һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. С. 51–53 һ.б.

[4] *Березин И.* Турецкая хрестоматия. Казань, 1962. С. 41–56.

[5] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 108–119.

[6] *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас, 1995. № 9. Б. 100.

шигъри формалы «автор»лы китаби вариантында да (Кыям Юлдаш варианты) шушы версиянең тәэсире зур. Татарларда телдән яки язма рәвештә яшәгән-таралган әлеге әсәрләрнең иң тулысы, иң зур күләмдәгесе – И. Березин хрестоматиясендә басылып чыккан дастан тексты, шуңа күрә ул башка ваграк текстлар өчен беренчел чыганак ролен башкара. Әлеге сюжетка нәкъ менә кайсы текстның иң беренче барлыкка килгәнлеге үтә фәлсәфи һәм бәхәсле булып тоелса да, текстларда күзәтелгән эчтәлек-фикер җәһәтеннән чыгып караганда, югарыдагы фикер раслана. Текстларның тарихта теркәлү хронологиясе дә шушы ук фикерне куәтли. Димәк, И. Березин варианты әлеге батыр хакында татар халкында мәгълүм барлык текстларны үз тирәсенә җыйнау функциясен үти. Икенче төрле әйткәндә, бу әсәр – татарларда таралыш алган «Чура батыр» сюжетының язма формада ныгыган берләштерүче үзәге. И. Березин җыентыгындагы оригинальлектә дастан башка бер генә версиядә дә кабатланмый. Болар бар да башка төрки халыкларның Чура батырга багышланган дастаннары янәшәсендә Н.И. Березин хрестоматиясендә басылган «Чура батыр хикәяте»нең нәкъ менә татар җирлегендә иҗат ителгәнлеге файдасына сөйли һәм әсәрнең казан татарларына мөнәсәбәте шикле булмауны дәлилли. «Чура батыр хикәяте» – татар халкының классик дәрәҗәдәге героик китаби дастаны. Татар китаби дастаннарының югарыда каралган типларына нисбәтән «Чура батыр» дастаны беренче типка, ягъни дастан буларак безнең халыкта нигездә язмада гына көн күргән дастаннарга карый.

Чура батырга багышланган дастаннарның иң әүвәл басмада дөнья күргәне нәкъ менә татар халык версиясе булу факты да шактый кызыклы һәм һич кенә дә очраклы түгел. Бездә «Чура батыр»ның иң беренче чиратта язма вариантта сакланып калуы Урта Идел буенда яшәүче татарларда дастан жанрының китабилык традициясенә буйсынган булуы белән турыдан-туры бәйләнгән. XX йөз башында «Чура батыр» темасына татар вакытлы матбугатында өр-яңа текстлар[1] басылып чыгу да шушы традициянең дәвамы булып аңлашыла. Әлеге әсәрләрнең «автор»лары билгеле, алар фәкать язмача гына дөнья күргәннәр, әмма тулысынча фольклор материалларына нигезләнгәннәр. Бу – «Чура батыр» дастанының татар халкында яшәеш

[1] *Баязит Р.* Яңа кала. Чура батыр // Ак юл. 1915. № 16. Б. 282–286; *Юлдаш К.* Чура батыр // Аң. 1916. 5 нче сан. Б. 85–86.

һәм таралыш формасы китаби төрдә булуны янә бер кат раслый торган факт.

Чура батыр турында татар халык дастанын тикшерүнең әһәмияten берничә аспектта күрсәтергә мөмкин. Беренчедән, дастани Чура образы Казан ханлыгында яшәгән сәясәтче, дипломат Чура би шәхесе белән шактый охшаш. Дастандагы башка образлар һәм вакыйгалар да күп яклап XVI йөздәге реаль шәхесләргә һәм хәлләргә якынаялар. Охшашлыклар очраклы гына булган дип карау бу очракта үзен аклый алмый. Бу хакта тарихчы галим Д. Исхаков, Х. Паксой, филолог галим Ф. Урманчеев, Л. Ибраһимова үз фикерләрен белдерделәр һәм дастандагы персонажларның һәм вакыйгаларның реаль тарихка мөнәсәбәтен ачыкладылар[1]. Әлбәттә, чорга кагылышлы архив документларының яндырылган булуы XVI йөзнең беренче яртысында Казан ханлыгында Чура Нарык углы шәхесенең яшәп, сәяси һәм дипломатик эшчәнлек алып барганлыгын рәсми дәлилләүдә кыенлык тудыра. Әмма әлеге затның эшчәнлеге турында Казан ханлыгы тарихын яктырткан хезмәтләрдә шактый гына мәгълүмат бар[2]. Моннан тыш борынгы татар шәҗәрәләрен барлаучы М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган шәҗәрә[3] үзе генә дә Чура батыр прототибын татардан эзләүнең хаклылыгын дәлилли. Галим «Чура батыр шәҗәрәсе» дип атаган бу документта Чура – Күкәс һәм Нарык буыннарыннан соң килүче зат. Шәҗәрәдә Чураның Нарык углы дип күрсәтелүе аның тарихи шәхескә тәгаенләнүе өчен җитәрлек нигез булса, дастандагы

Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел, карамын,
Асылымны сорасаң –
Күкес углы Тамамән.

дигән юллар һәм әсәрдә Чураның атасы Нарык турында җентекле тасвир исә дастан вакыйгалары белән татар шәҗәрәсенең тамырларын уртак итә. Хәлбуки дастани Чура батырны Казан ханлыгында яшәгән

---

[1] Бу турыда кара: *Паксой Х.Б.* Чура батыр кисәтүе // Идел. 1994. № 9. Б. 9; *Исхаков Д.* Чура батыр кем ул? // Идел, 1994. № 9. Б. 17–19; *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. № 7–8; *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 7–27.

[2] *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 7–27.

[3] *Әхмәтҗанов М.И.* Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 323–324.

тарихи шәхес Чура Нарыковка бәйләүне бөтенләй үк хаксыз гамәл дип танып булмый, моны инкарь итә торган дәлилләр юк.

Димәк, нигезендә үзебезнең халыкның тарихи вакыйгалары яткан татар эпосына күзәтү ясау халык батырына игътибарны үстерә, тарихи һәм дастани Чура язмышын чагыштыру планында карау мөмкинлеген бирә.

Икенчедән, Чура батыр турында әлеге дастан – татар халкының җитди эпик әсәре, шул ук вакытта татар халкының китаби дастаннары традициясенең гаҗәеп үрнәге. Билгеле булганча, Казан ханлыгы, оешкан чорыннан алып бөтен яшәү дәвере буена Мәскәү Бөек князьлеге белән көч сынаша һәм, ниһаять, XVI йөз уртасында үзеннән көчлерәк дәүләт тарафыннан рәсми төстә яулана. Тарихта никадәр генә прогрессив күренеш буларак бәяләргә омтылыш булса да, мондый зур вакыйгаларга халыкның һәрвакыт үз фикере бар һәм еллар буена чарланган әлеге фикерләр фольклорда да чагылыш тапмый калмаган. Казан татарларына турыдан-туры кагылышлы бу вакыйгага реакция халык иҗатының эпик жанрларында, иң беренче чиратта, әлбәттә, дастаннарда яңгыраган. Героик китаби дастаннардан «Чура батыр» – халыкта милли фаҗига итеп кабул ителгән вакыйгаларның кайтавазы буларак кыйммәт. Безнең халыкның милли азатлык көрәше белән авазлаш әлеге дастан тарихи-традицион яктан да, әдәби формасы ягыннан да, стиле-таралышы белән дә гаять кызыклы. Бер үк халык фольклорында бер үк сюжетның, теманың һәм образның төрле жанр әсәрләрендә һәм төрле формаларда очравы фольклорда әллә ни еш күзәтелми. Чура батыр образы һәм аның белән бәйле вакыйгалар чагылыш тапкан эпик сюжетларның татар халкының үзендә генә дә берничә булуы шулай ук игътибарны җәлеп итә. Әлеге текстларның иң тулысы, зур күләмлесе – И. Березин хрестоматиясендәге дастан. «Чура батыр» дастанындагы эпик мотивларның, идея-сюжет һәм стиль үзенчәлекләренең гомумтөрки эпос масштабында үз урыны бар һәм моны ачыклау мөһим.

Әсәрнең «Татар халык иҗаты. Дастаннар» китабына «Чура батыр хикәяте» дип кертелүенә һәм И. Березинда да «хикәят» дип аталуына игътибар итеп, бу сүзгә аңлатма биреп үтик. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул түбәндәгечә шәрехләнә: «хикәят, хикәя – нинди дә булса вакыйга турында телдән сөйләнгән инша»[1]. Яисә «Әдәбият

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Т. III. Казан, 1981. Б. 367.

белеме сүзлеге»нә күз салсак, хикәят жанры өчен «эпиклык, хикәяләү хас, – диелә анда. –... Хикәят генетик яктан фольклордагы эпик жанрлар белән тыгыз бәйләнешле»[1].

Хикәят, кыйсса, китап һ.б. аталган текстларның асылда «дастан» жанры белән тәңгәллеген хезмәтебезнең теоретик өлешендә тулырак дәлилләгән идек. Шуңа өстәп, кайбер дастаннарның, шул исәптән, «Чура батыр»ның да «хикәят» дип бирелгән булуын искәртергә генә кала. Бу очракта да хикәятнең жанр үзенчәлекләре аны дастан жанры буларак тикшерүне тәэмин итә.

Татар халык китаби «Чура батыр»ының төп каһарманы традицион төрки эпосы Чура батырыннан берни белән дә аерылмый, якыннарын, үз халкын һәм дәүләтен дошман эзәрлекләвеннән саклаучы һәм яклаучы гадәттән тыш көчле баһадир буларак тасвирлана.

Курку белмәс Нарык, үзенең сөекле хатыны Миңлесылу белән Дагыстан йортындагы мавыктыргыч хәлләрдән соң, күченеп Кырымга китеп барган вакытта, юлда аларның уллары Чура дөньяга килә. Чура тугач та, аның аягы тигән сусыз җирдән су тибеп чыга. Бу – дастанның Чура батырга багышланган өлешендә баланың гадәттән тыш батыр булачагын хәбәр итә торган беренче билге буларак сурәтләнә һәм ул, чыннан да, төрки героик эпосы кануннарына тулысынча яраша торган героик тормыш юлы үтә. Чура батырның гадәтидән күпкә аерылып торган балачагы, дошманнары белән орыш-көрәштә һәрвакыт җиңү яулавы, яшьтән үк дан-дәрәҗәгә ирешүе, гаскәр туплавы, махсус сугыш коралына һәм бик шәп атка ия булуы, ата-анасына, кыз карендәшенә, хатынына мөнәсәбәте, дошманнарына карата аяусызлыгы, сыналган дустына тугрылыгы, илен, халкын яклап, соң чиккәчә көрәшүе – әлеге мотивлар «Чура батыр»ның төп сюжет сызыгын тәшкил итәләр. Барлык героик дастаннарга хас булганча, биредә дә хикәяләү төп каһарманның хис-кичерешләрен түгел, ә аның эш-гамәлен тасвирлау характерында тормышка ашырыла. Манас, Алпамыш, Идегәй һ.б. төрки эпос персонажлары кебек үк, Чура да физик яктан баһадир көченә ия курку белмәс батыр, горур һәм гадел, әмма үз-үзенә артык ышанучан, ярсу холыклы һәм тәкәббер.Төрки версияләрнең һәркайсына хас бу закончалык күзәтелә торган әсәрдә дә үз урынын алган. Холкындагы тискәре сыйфатлар, башка обьектив һәм субьектив сәбәпләр белән

[1] Әдәбият белеме сүзлеге. Казан, 1980. Б. 204.

берлектә, еш кына героик эпос каһарманын һәлакәткә илтә. Чура батыр да, Казанны саклап, атына атланган көе дошманнары белән бик озак сугыша, ахырда атының аягы кызып, ат Иделгә егылып төшә, Чура суга батып үлә. Дастанның кыскача эчтәлеге менә шулардан гыйбарәт.

Эпос Дагстан йортында яшәгән олуг мирза Казый би турында сөйләүдән башланып китә. Игътибар итсәк, «Чура батыр»ның һәр вариантында Нарык (Нарик) каяндыр читтән Кырымга күчеп килә. Мәсәлән, казакъ дастаннарында Нарык Казаннан китерелә. Татар версиясендә Нарәң язмышын Дагстан белән бәйләү каһарманны читтән китерү традициясеннән булырга мөмкин. Бу – Чура батырга багышланган дастаннарның барысына да хас күренеш.

Сюжет үстерелеше татар һ.б. төрки дастаннарда еш телгә алынган ауга чыгу эпизодын тасвирлау аша дәвам итә. Мондый мотивны татар халык дастаннары «Кузы Көрпәч белән Баян-сылу» да (Ак хан белән Кара хан, балалары туар алдыннан ауга чыгып китәләр), «Гыйса углы Амәт»тә (Җанибәк хан, көмәнле Тайдула ханымны калдырып, «кош чөймәгә ау аулый чыга»), «Түләк» дастанында 60 хезмәтче-нүкәре һәм Түләкне алып, Бачман хан ауга чыга) һ.б. очратабыз. Биредә, ягъни «Чура батыр»да да, традицион сюжет буларак, көннәрдән бер көнне Казый би ауга чыгып китә. Үзе белән гаскәрен дә ала. Ауга киткән җиреннән Казый би әле генә кем тарафыннандыр җәбер-золымга дучар ителгән бер авылга барып чыга. Авылларның талануы, көчлерәк кабиләләрнең көчсезләрен кыерсытуы яисә хан яки башка югары катлау вәкилләренең ауга чыгарга һәвәслеге – Урта гасырлар өчен табигый күренеш. Традицион төрки дастаннардан бераз аермалы буларак, татар халык «Чура батыр»ында бу һәм башка шундый вакыйгаларга китаби гомумиләштерү хас. Чичән тасвирлавындагы халыкчан стиль, вакыйганың һәр деталенә фольклорча җентекле якын килүне биредә читтән торып тасвирлау-бәяләү, иң мөһим мәсьәләләрне генә алга чыгару алыштырган.

Үз чоры өчен гадәти булган мондый вакыйгаларның дастанга килеп керүе шушы чорның кайтавазы һәм башка төрки дастаннар тәэсире булса кирәк. Авылда җан әсәре булмый. Яудан урманга качып котылган бер бала гына, Казый би гаскәрен күреп, болар янына чыга. Казый би аны үзе белән ала. Баланың чырае ялкын-ут төсле була, шуңа карап, аңа Наррәң дип исем бирәләр. (Нар – гарәпчә ут, ялкын.

Бу очракта – исем компоненты[1].) Исем кушу йоласына татар дастаны Чура батырга багышланган өлештә дә аерым игътибар бирә. Бу – төрки халыклар иҗатында киң таралган мотив, аның турында соңрак сөйләрбез.

«Наррәң» исеменең «Наррәңк», «Нарәк», «Нарик», «Нарык», «Нарыкбай» исемнәре белән аваздаш булуын искәртергә кирәк. Татарча текстның үзендә генә дә бу исем «Нарәң», «Наррәң» яки «Нарәк» формасында очрый. Мондый төрлелек гарәп язуыннан файдаланып татарча язганда [ң] һәм нечкә [к] авазларын бирү өчен файдаланылган хәрефләрнең охшашлыгыннан килеп чыккан бутап язу гына да булырга мөмкин.

Дастанны Нарыкның бала чагын сурәтләүдән башлау башка бер генә вариантта да, хәтта Нарыкка аерым дастан багышлаган казакъ версиясендә дә юк. Бу – Чура батыр турындагы татар халык дастаның үзенчәлеге. Биредә аның Казый би йортында тәрбияләнеп үсүе, батыр пәһлеванга әверелүе тасвирлана. Наррәң кылган батырлыкларга, дошманнарының кемнәр булуына аерым эпизодлар китерелмәгән, әмма теләсә кайсы героик эпоска хас булганча, игътибар аның яуга баруына, андагы җиңүләренә юнәлтелә.

Гадәттә гади халык вәкиле булган җыручы, акын яисә чичәннең билгеле бер эпик җыруны халык аудиториясендә бер төрле, феодаль катлау өчен үзгәрәк итеп башкаруы – Урта гасырлар фольклорына хас күренеш. Төрки халыклар иҗатыннан кыргызларның атаклы «Манас» эпосын алсак, мәсәлән, шундый мохит идеологиясе тәэсирендә бу әсәрнең өлешчә феодаллашуын күрсәтергә мөмкин. Югары катлау вәкилләре бик теләп мәшһүр манасчыларны үзләренә хезмәткә ала торган булганнар. Феодаль дифференциальләшү процессының «Чура батыр» дастанына ни дәрәҗәдә тәэсире бар соң? Биредә шунысына игътибар итәргә кирәк: беренчедән, күләмле татар дастаны бары бер генә версиядә сакланып калган, шуңа күрә башка вариантлар белән чагыштырып карау мөмкинлеге була алмый, икенчедән, тикшерелә торган әсәрнең феодаллар өчен иҗат ителгән булуына текстта ишарәләр юк. Би-морзалар турында сөйләп башланган дастан алга таба Чура батырның түбән катлау вәкиленнән чыгуын искәртә:

---

[1] *Саттар-Мулилле Г.* Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). Казан, 1998. Б. 189.

Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел, карамын.

Нәррәң үзе исә дастанда урта хәлле тормыш алып барган кеше буларак сурәтләнә. Олуг морзалардан булган Казый бинең Наррәңгә хатынлыкка алып биргән кызы Миңсылуның аксөяк нәселеннән булуы әйтелсә дә, мәсьәләнең бу ягы әсәрдә аеруча мөһим итеп куелмаган. Биредә татар «Чура батыр»ының чичәнлек традициясеннән шактый ераклашып, китаби традициягә нигезләнүен һәм, XVI йөз урталарыннан соң иҗат ителеп, татар мохите шартларына яраклаштырылуын истән чыгарырга ярамый. Югары катлау вәкилләренә махсус яраклаштырылган чичән идеологиясенең дастанда әллә ни сизелмәве китаби традицияләр тәэсире дип бәяләнергә хаклы. Мондый сыйфатлары белән «Чура батыр»ның татар версиясе казакъларндагы вариантларыннан күпкә аерылып тора. Казакъ, каракалпак, үзбәк халыкларында дастан әйтүче акыннар буыннан-буынга җыру сәнгатен тапшыра килгән династияләр тәшкил иткән. Чичәнлек, җыраулык, импровизаторлык сәнгате белән бергә героик эпос та шактый үсеш алган. Казакъ «Чура батыр»ында (бу әсәрне Ә. Диваев 1922 елда Оренбургта дөнья күргән җыентыкка «Нарик батыр улы Шура» дигән исем керткән[1], шул ук әсәрнең эчтәлеге А.С. Орлов хезмәтендә тәфсилләп сөйләнгән[2]) тел-авыз иҗатының традицион дастан жанрына хас үзенчәлекле сюжетлар бик күп. Казакъ версиясенең әлеге вариантыннан хан-солтаннар һәм аларның яраннары мөнәсәбәтен җентекле тасвирлауга корылган, югары даирә мохитын сурәтләгән бер сюжетка мисал китереп узыйк.

Куян артыннан куганда Акча ханның яраткан эте югала. Казаннан Үргәнечкә килеп, хан хезмәтендә торучы Нарик, этне эзләп барганда, бер мәгарәгә, ә аның эченә кергәч, алтын өеменә тап була. Бу серне үзендә генә саклый алмыйча, Нарик алтыннар турында ханына сөйләп бирә. Хан табылдык алтыннарны ала. Рәхмәт йөзеннән, хезмәтчесе Нарикны би дәрәҗәсенә күтәрә. Ханның бу эше башка биләрдә көнчелек тууга сәбәп була, Нарик һәм биләр арасында дошманлык башлана. Нарик, дошманнарыннан котылу өчен, ханнан үз иленә – Казанга

---

[1] Труды общества изучения Киргизского края. Вып. III. Оренбург: Караван-Сарай, 1922. С. 117 – 126.

[2] *Орлов А.С.* Казахский героический эпос. М.: Изд-во АН СССР, 1945. С. 112–114.

кайтып китәргә рөхсәт сорый. Тегесенең исә тугры хезмәтчесен җибәрәсе килми, ул, мәҗлес җыеп, матур сөйләүчеләр бәйгесе үткәрә. Сүз осталары, үгетләп, Нарикны Үргәнечтә калдырырга тиеш булалар. Әлеге мәҗлестәге әйтелгән чичән сүзе тардицион дастан текстының иң тәэсирле һәм гүзәл урыннарының берсен тәшкил итә.

Имровизаторлык сәнгате нык үскән казакъ халкында җыр әйтешеп ярышу һәм аның дастан сюжетына килеп керүе табигый. Традицион дастан жанрына хас чичәнлек нәкъ менә шундый сүз көрәштерү мәҗлесләрендә ачылган. Казакъ фольклорында мондый әйтешләр (казакъча – айтыс) соңгы чорларгача сакланып калганнар, анда катнашучыларны акыннар дип йөртәләр[1]. Әйтеш текстлары безнең гасырда казакъ галимнәре тарафыннан казакъ телендә бастырып та чыгарылган[2]. Татар халкының дастан жанрында мондый һәм моңа охшаш бәйгеләр әллә ни популяр түгел. Безнең халык иҗатында сүз әйтешеп ярышу әкият жанрында күбрәк сакланган. Бу күренеш әле чичәнлек формалары югалмаган чорларга ук барып тоташадыр, әмма татар дастаннарының китаби традицияләргә нигезләнеп һәм индивидуаль иҗат белән тыгыз аралашып үсүе дастан жанрыннан чичән идеологиясен алга сөргән импровизацияле монологларны кысрыклый төшкән. Шуңа да казакъ версиясендә киң урын бирелгән әлеге момент безнең версиядә чагылыш тапмый калган.

Әсәрнең башында ук Казый бинең Канмирза исемле энесе барлыгы искәртелгән иде. Алга таба аның йогынтысында вакыйгалар үстерелеше кискенләшеп китә. Наррәңнең гүзәл хатынын күреп, Канмирза аңа гашыйк була һәм Наррәң юкта Миңсылу янына килә. Миңсылу Канмирзаны куып җибәрә. Хәлне ишеткән Наррәң Казый би энесен кылычтан үткәрә. Наррәңне үз улыдай якын күрсә дә, кан кардәшен үтергән өчен, Казый би аңа: «Син инде минем янымда торма, бер якка кит», – ди. Наррәңнең (Нарик яисә Нарыкның) чибәр хатынына ханның, хан улының гашыйк булу мотивы – Чура батыр турындагы дастаннарның аерылгысыз атрибуты. Казакъ, кырымтатар, нугай версияләрендә бу эпизод бер генә урында китерелсә, татар вариантының сюжет интригасы әлеге хәлнең берничә мәртәбә кабатлануы белән катлауландырылган. Биредә Миңсылуны, кая гына барса

[1] *Исмаилов Е.* Акыны. Алма-Ата: Худож. Лит., 1957. С.25 – 29.

[2] Aitьs [Айтыс] / под ред. Сабита Муканова и Есмагамбета Исмаилова. Т. I. Алма Ата, 1942; Айтыс. Т. I / под ред. Муканова Алма-Ата, 1964.

да, бер үк язмыш көтеп торган булып чыга. Казый би иленнән китеп, Акча солтанга барып сыенгач, солтан үзе Миңсылуның матурлыгын күреп, аңа гашыйк була. Акча солтан, мәкер корып, Наррәңне читкә җибәрә, кичен үзе Миңсылу янына килә, хатынга Наррәңнең гаскәрдә үлеп калачагын, Миңсылуның солтанныкы булудан башка чарасы юклыгын әйтә. В.М. Жирмунский бу эпизодны феодализм дәверенең реаль көнкүреш мөнәсәбәтләре тудырган мотив дип бәяли, аның баһадирлар турындагы әкиятләрдән башлап, күп кенә героик дастаннарда очравын искәртә[1]. Нәкъ шундый ук күренешне, мәсәлән, «Патша малае һәм аның фәкыйрь күршесе», «Алтынчәч», «Патша белән солдат» дип аталган татар халык әкиятләреннән, «Кугул тарихы» дигән казакъ әкиятеннән табарга мөмкин. Биредә, әйтик Кугулның хатынына казакъ ханы гашыйк була һәм үзенең якыннары киңәше белән Кугулны 10 еллык куркыныч сәфәргә чыгарып җибәрә, ә хатынын урлап китә. Төрки һәм башка халыклар эпосына хас булганча, каһарман-ирнең өйгә көтмәгәндә кайтып керү интригасы «Чура батыр» дастанында да сакланган. Тагын шунысын әйтеп үтәргә кирәк: традиция буларак, мондый очракларда катлаулы вазгыятьтән чыгу юлын геройның хатыны үзе күрсәтә. Шул ук «Кугул тарихы»нда, мәсәлән, ханның явыз ниятен акыллы хатын иренә җиткерә, куркыныч юлда тылсымлы атның Кугулга ярдәмгә киләчәген әйтеп, аны тынычландыра. Чура батыр турындагы дастаннарда исә Миңсылу (Миңлесылу, Акменде) ханга (хан улына) гыйбрәтле хикәят сөйли. Мәгънәсе бер үк булган әлеге гыйбрәт төрле вариантта төрлечә яңгырый. Татар халык дастанында Миңлесылу сөйләгәне исә – чагыштырмача иң җыйнагы. Наррәң хатынының Акча солтанга әйткән сүзе шушы хикәяттән чыгарылган нәтиҗәне генә хәтерләтә. Ул болай ди: «Арыслан бүренең ашын ашамас. Син гади кешеләр арасында арыслансың. Нарәң синең яныңда бүре баласы кебек кенә. Арысланга бүре баласы саркытын ашау ятышлы булыр микән?» Бу җаваптан соң татар вариантында солтан, ник килгәненә үкенеп, чыгып китә.

Монда тагын шуңа игътибар итәргә кирәк: Акча солтан образы һәм аңа бәйләнешле вакыйгалар татар һәм казакъ дастаннары (казакъ версиясенең алдарак телгә алынган варианты турында сүз бара) өчен уртак. Наррәң (яисә Нарык) Акча солтан янында «бик хөрмәт

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л., 1974. С. 321.

белән күп заман» тора, аннары солтан Миңсылуга (Миңле Сылуга) гашыйк була, хатынның җавабын ишетеп, кире борыла. Аерма шунда: казакъ варианты мәсьәләне конфликтсыз хәл итсә, Нарәң Акча солтанны үтерә. Татар версиясе сюжет вакыйгаларын кискенрәк вариантта тәкъдим итә. Бу – әсәрне укучыга үтемлерәк итеп җиткерү максатыннан башкарыла торган индивидуаль алым. Татар героик дастаннарында бу юнәлештә авантюрага, интрига тудыруга, маҗаралылыкка корылган сюжетларның күпләп һәм яратып кулланылуын искәртергә кирәк. Моңа мисалны татар җирлегенә хас героик китаби дастаннарның һәркайсында очрата алабыз. «Каһарман Катил»дә яисә «Күр углы»нда да моңа мисаллар җитәрлек.

Һәр вариантта да Наррәң (Нарык) Акча солтан белән хатыны арасындагы сөйләшүне очраклы гына тыңлап тору аркылы ишетә. Бу мотивны А.С. Орлов борынгы төрки эпос тәэсире дип күрсәтә[1]. Шушы вакыйгадан соң Нарәң хатыны белән качып китә.

Юлда барганда Калавыз дигән су буенда Нарәңнең улы Чура дөньяга килә. Булачак баһадирның гадәттән тыш шартларда тууы, аның дөньяга килүен шактый мәшәкатьле, озакка сузылган процесс итеп сурәтләү – шулай ук гомумтөрки эпос традициясе. Гадәттә, батыр бик көттереп кенә, ата-анасы Алладан яисә нинди дә булса илаһи заттан ялварып сорагач кына дөньяга килә. Моңа мисалны угыз эпосы «Китаби Коркот»тан, «Алпамыш»тан, казакъларның «Кобланды-батыр»ыннан һ.б.дан китерергә мөмкин. Галим В.Я. Пропп, эпик әсәрдә каһарманның могҗизалы юл белән дөньяга килүенә игътибар итеп, бу күренешнең геройны гомуми фоннан аерып күрсәтүче билге булуы турында язган иде. «Могҗизалы юл белән дөньяга килү – каһарманның бер билгесе, – ди ул. – Герой илен дошманнардан азат итү өчен туа»[2].

«Чура батыр» дастанында нәрсәгәдер табынып бала теләнү мотивы юк. Бу татар халкында башка кайбер төркиләр, әйтик, казакълар белән чагыштырганда, ислам тәэсиренең көчлерәк булуыннан һәм иртәрәк ныгып урнашуыннан килә булса кирәк. Аның каравы, татар дастаны Чураның тууын тасвирлауга шактый урын бирә. Миңсылуның тулгаклаган чакта ире Нарәңгә җайлап кына әйткән сүзләре – төрки эпос традициясендәге халыкчан шигъри монолог үрнәге:

[1] *Орлов А.С.* Казахский героический эпос. М., 1945. С. 98.
[2] *Пропп В.Я.* Фольклор и действительность. М., 1976. С. 237.

Иделнең башы – Арман тау,
Җаекның башы – кырык Чәүлан,
Туры ат башы – ак чатыр,
Җамның буе – җиде үзән,
Сары болак – арка сал,
Бу буйны сал тамагыма ташы,
Бер аның эчәем дисәм, суы ачы,
Туса – башым киленчәк,
Тумаса – башым кыйнамай,
Әй, батырым, батырым,
Үзең булышлы, аначы.

Монда алдагы берничә юлда дөньяга яңа кеше туугa ишарә ителә булса кирәк, ягъни Миңсылу үзенең хәлен иренә образлар аша аңлата. «Туса – башым киленчәк, тумаса – башым кыйнамай» – ягъни, ни булса да, хәерле булсын. Соңгы юлларда ул батырдан кендек әбисе ролен үтәвен сорый. Каушап, югалып калган Нарәңгә, кирәкле сүзләр табып, иренең тормышында булган вакыйгаларны мисалга китереп, җыру белән әйтеп бирү моменты башка вариантларда очрамый:

Әй, батырым, батырым,
Адамачы (*каушамачы*) батырым,
Каберенә Казый бинең энесен каерып,
Үз кулың белән сән чалдың,
Адамадың, батырым.
Хаҗитарханда Акча солтанны каерып,
Үз кулың белән сән чалдың,
Адамадың, батырым!
Корбанлыгың чалсана,
Куш чырагың яксана,
Чураны азат итсәнә,
Тизрәк җитеп килсәнә.

Нигезендә халыкның шигъри стиле яткан мондый монологлар татар ки таби дастанын традицион төрки эпос кагыйдәләренә яраштыра. Болар һәммәсе – дастанның индивидуаль иҗат һәм традицион башлангычлар белән тыгыз керешкән бөтенлек булуын тәэмин итүче элементлар.

Шуннан соң Нарәң, Миңсылу әйткәннәрне эшләп, баласын кабул итеп ала. Миңсылу угыл бала таба. Атын Чура дип кушалар. Төрки эпоста геройга исем кушу вакыйгасына гадәттә зур игътибар

бирелгән. Булачак баһадирга нинди исем кушу, бу «бәхетле исем»не кемнең уйлап табуы, кем тарафыннан балага куелуы – бу моментлар гаять мөһим саналып, эпик әсәрләрдә күренекле урын алганнар. Мәсәлән, угыз героик эпосы «Китаби Коркот»та бу йола аеруча ачык буяулар белән бирелгән[1]. Балага исем кушу зур мәҗлес итеп үткәрелә, анда бәкләр җыела. Кушылган исемнең балага бәхет китерүен теләп, догалар кылына. Яисә «Алпамыш»ның каракалпак версиясендә Байбүре белән Байсары изге каберне зиярәт итеп кайтканнан соң туган балаларына исем кушу өчен зур мәҗлес җыялар. Балаларга нинди исем кую турында шау-шулы бәхес куба. Шул вакытта Кәгъбә ягыннан 7 дәрвиш пәйда була. Алар дөнья буйлап адәмнәргә ярдәм кылып йөрүче Гаиб иран кырык җәһәлтән (челтән) дип аталган изгеләр икән. Болар – Байсары кызына – Гөлбарчин, Байбүре кызына – Карлыгач, ә улына Алпамыш (текстта: Алфамыш) дигән исемнәр кушып, күздән югалалар[2].

«Чура батыр» дастанында балага ни өчен нәкъ менә шул исемне кушу ассызыкланган: «Атын – азат кылган колы Чураның урынына – Чура атады». «Чура» – борынгы төрки-татар исеме, ир бала, батыр, батыр сугышчы, дружина члены һ.б. мәгънәләрне белдерә[3]. Ихтимал, дастан героеның исеме аның киләчәктә чын баһадир булачагына ишарәдер. Батырның дөньяга килү эпизодын башка дастаннар, әйтик, казакъ версиясенең бер варианты[4] түбәндәгечә тасвирлый: көтеп алган бала тугач, бу шатлыкны җиткерергә дип, ике хатын, берсен-берсе узып, Нарыкбайга ашыгалар. Нарыкбай аларны юмарт бүләкли. Чура тууны (текстта: Шора) 70 көн бәйрәм итәләр, алтын бишеккә салып, изге карттан исем куштыралар.

Татар вариантына килсәк, бала тугач, Нарәңнең гаиләсе белән Кырымга барып яши башлаганы әйтелә. Бу – Чурага багышланган дастаннарның барысына да диярлек хас традиция: күпчелек версия-вариантларда Чура батыр Кырымда тәрбияләнгән каһарман итеп күрсәтелгән.

[1] Книга отца нашего Коркута. Огузский героический эпос. Баку, 1987.

[2] *Диваев А.А.* Алпамыс-батыр. Ташкент, 1901. С. 4–5.

[3] *Саттаров Г.Ф.* Татар исемнәре сүзлеге. Казан, 1981. Б. 213.

[4] Казакъларның әлеге варианты турында кара: *Орлов А.С.* Казахский героический эпос. – М., 1945. С. 95–97; *Ибраһимова Л.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 118–128.

«Чура батыр»да әлегә кадәр төп сюжет сызыгы Нарәң батыр тормышын яктыртып килде. Әйтергә кирәк, татар вариантының Нарәң батырга багышланган өлеше шактый күләмле, бай эчтәлекле. Монда дастанның «Нарәң һәм Чура батыр турында хикәят» дип исемләнүен тагын бер кат искәртеп китү мөһим.

Төрле халыкларның эпик иҗатына мөрәҗәгать итсәк, күпсанлы генеалогик цикллаштыру мисалларына тап булабыз. Тулысынча шушы принципта төзелгән, әрмән баһадирлары – Давид Сасунлының бабалары һәм оныклары турындагы циклны искә төшерик[1]. Урта Азия халыклары эпосында генеалогик үсешнең ачык үрнәге дип Күр углы турындагы эпосны, «Алпамыш»ның үзбәк вариантын күрсәтергә мөмкин. Каһарманның улына, уллыкка алган баласына (мәсәлән, «Күр углы»ның азәрбайҗан яисә үзбәк халкындагы вариантлары), онычыгына багышлап, халык яңадан-яңа әсәрләр иҗат иткән. Шундый принципта язылган дастаннар генеалогик циклларны тәшкил иткән.

«Чура батыр» дастанында күзгә ташланып торган мөстәкыйль, шул ук вакытта бер-берсе белән генеалогик бәйләнештә торган ике өлеш бар: Нарәңгә багышланган һәм Чура батыр турындагы өлешләр. Бер дастан нигезендә яңа дастан барлыкка китерү – Урта Азия һәм Казакъстан чичәннәренең иҗат нәтиҗәсе булса, татар дастаны да шушы традициягә күпмедер дәрәҗәдә якын тора булса кирәк. «Чура батыр» дастанын шартлы рәвештә икегә бүлеп карау мөмкинлеге шундый фикергә китерә. Шушы ук әсәрдә Колынчак батырга аеруча зур игътибар бирелеп, әсәрдә бер өлешнең хәтта «Колынчак батыр хикәяте» дип аерымлануын да әйтеп үтәргә кирәк. Әмма китаби вариантта әлеге традиция үтә дә йомшак чагылыш тапкан. Аерымланган өлешләр күләмле әсәр дәрәҗәсенә җитеп мөстәкыйльләнүдән ерак торалар. Биредә мондый аерымлану – төрки эпоска хас традициянең китаби дастанда сакланып калган яисә югалып бетмәгән кыйпылчыгы гына.

Чура тугач, Нарәң белән Миңсылу арткы планга күчеп, мәйданга Чура батыр чыга. Гадәттәгечә, Кырымда тәрбияләнеп, биш-алты яшькә җиткәч, Чура бозау көтүе көтә башлый. Каһарманның кечкенәдән көтү көтүе – төрки халыклар эпосы өчен типик күренеш. Мәсәлән, мәшһүр «Идегәй»нең күп кенә версияләре каһарманның бала чагында көтүче булуы турында сөйли. Әлеге дастан герое кебек үк, Чура да

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л., 1974. С. 93.

гади генә бала булмавы белән башкалардан аерылып тора. Ул яшьтәшләренә баш булырга омтыла, Чураның сүзе һәрвакыт өстен чыга. Героик эпоска хас булганча, дастан батыры гомуми фоннан аерылып торучы, гадәттән тыш батыр йөрәкле пәһлеван итеп сурәтләнә. Бу, әлбәттә, «Чура батыр» дастанының гына үзенчәлеге түгел. Үзбәк халкының «Алпамыш» дастанында, мәсәлән, каһарман 7 яшендә үк беренче батырлыгын кыла. Аны атасы Байбүре, падишаһка хезмәткә әзерләү уе белән, хәрби һөнәргә өйрәтә. Шул чакта Хәким бабасы, Алпинбинең 14 батман бакырдан ясалган борынгы җәясен киереп, ук атып җибәрә. Малайның аткан угы тауның башын кыеп төшерә. Шушы батырлыгыннан соң аны Алпамыш дип йөртә башлыйлар[1]. «Чура батыр»ның янә шул ук «Идегәй» белән аваздашлыгын искәртеп, кечкенәдән көтү көткән Идегәйнең иптәш малайлары тарафыннан үзләренә башлык итеп сайлану фактын, 7 яшендә үк үзенең лидерлыгын, батырлыгын күрсәтү эпизодларын да мисал итеп күрсәтергә мөмкин.

«Чура батыр» дастанында да нәкъ шундый күренеш: кечкенә «батыр» яшьтәшләре белән бергә бозаулар бага. Шунда Чура: «Кем бер бозау суеп ашата, шул кешене башлык итеп билгелибез», – дигән тәкъдим кертә. Башка малайлар икеләнеп торган арада Чура үз бозавын суеп, башкаларны сыйлый. Үз бозавын суеп, башкаларны сыйлавы булачак батырга яшьтәшләре арасында шөһрәт китерә, ул башка балаларга әмерләр бирә башлый. Чураның абруе үсә.

Каһарманның үз көчен бик яшьли, әле кечкенә чагында ук күрсәтә башлавы барлык халыкларның эпик әсәрләре өчен характерлы. «Алпамыш»ның үзбәк версиясендә эпик каһарман җиде яшендә беренче батырлыгын кыла; «Кондыз илә Йолдыз»да Күр углының ун яшьлек Нурали исемле оныгы, атасы Аваз ханны коткарырга дип, чиксез күп дошман гаскәре белән уратылган тауларга китә, барысын җиңә, Күр углы үзенең сугышчы егетләре белән килеп җиткәнче, атасын коткара. «Урак белән Мамай» дастанының казакъ вариантында Уракның уллары – җиде яшьлек Карасай һәм Казый икәү – калмыкларга каршы чыгалар һәм җиңәләр. Чура батыр»ның сюжет үстерелешендә дә һәр вакыйга каһарманның кечкенәдән көчле шәхес булып формалашуына ишарә итә.

Җитәкчелекне үз кулына алган малай хәзер гаскәр башлыгы булу турында хыяллана. Үзенә буйсынган иптәшләренә ул болай ди:

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л., 1974. С. 120.

«Һәр көн бозауларыгызны әйдәп өйгә кайтканда бозауларыгызга менеп, яулыкларыгызны таякка бәйләп, байрак итеп: «Без Чура батыр гаскәре!» – дип, авылга чапкалап барыгыз». Бүгенге эстетик караштан чыгып бәяләгәндә, бу – малайның чираттагы шуклыгы кебек. Әмма дастанда эшләр җитдирәк төс ала: Чура батыр һәм аның гаскәре турында тирә-юньгә дан тарала. Хәбәр Иделгәчә килеп ирешә. Шул рәвешчә, әлеге эпизод каһарманның батыр балачагын ил-җирен яклап көрәшәчәк чын пәһлеван язмышына китереп бәйли.

Халыкның, Чура батыр гаскәреннән куркып, Идел кичүен үз күзләре белән күрергә дип, атасыннан баһадир өчен кирәкле әйберләр – ат, садак-савыт алып, герой Кырымнан чыгып китә. Чураның Идел буена сугышчан сәяхәте каһарман биографиясендә героик эпизод буларак әһәмиятле. Бу – батырны көрәштә, яуда сынау сюжетының бер чагылышы. Мисалга, кыргызларның мәшһүр поэмасында Манасның 10 тапкыр яуга чыгуы турында сөйләнә[1]. «Чура батыр» дастанында Идел буена килеп дошманнар белән көрәшү мотивы юк, әмма каһарманның яңа җиңүләргә омтылуы ачык сиземләнә. Бу җирләрдә Чура үзенең батырлыгын янә бер кат раслый: бер картның Идел кичкәндә батып баручы кызын коткара.

Чура исеме күптәннән мәшһүр булса да, биредә аны әлегә берәү дә танымый. Батырны танымау мотивы үз тамырлары белән бик борынгы заманнарга барып тоташа. Чура батыр турындагы дастаннарның һәрберсендә диярлек мондый эпизодлар бар. Бу мәсьәләгә кырымтатар версияләрен тикшерү барышында киңрәк тукталырбыз.

Чура турында төрки эпослар арасында татар варианты Колынчак батыр образына аеруча зур урын бирүе белән дә үзенчәлекле. Биредә төп геройның булачак көрәштәш дусты Колынчак белән танышуына Чура тарафыннан коткарылган кыз сәбәпче була. Ул, имеш, Колынчакның хатыны икән. Картның кызын яисә Колынчакның хәләл җефетен суга батудан коткарган Чура үз юлына киткәч кенә, Колынчак каяндыр пәйда була һәм, карттан батыр турында ишетеп, аны эзләп китә.

Ф.И. Урманчеев: «Колынчакның прототибы Казандагы Кырым чирүенең башында торган, даими рәвештә Мәскәүгә каршы көрәшкән шәхес Кошчак углан түгел микән» дигән фикер әйтә[2].

---

[1] Манас. Великий поход. М., 1946. С.17.

[2] *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. 1995. № 9. Б. 102.

Монда тарихи чынбарлык белән чагыштырганда каршылык туа: Чура Нарыков үзе Казан ханлыгындагы «көнбатыш» төркем тарафдары булган. Казанның мөстәкыйльлеге өчен көрәшкәндә «көнбатыш» төркеме Кырымга түгел, күбрәк Мәскәүгә йөз тоткан булуы белән мәгълүм. Тарихи шәхесләр Кошчак белән Чура Нарык углының үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлаган документаль чыганак табылмады. Дастанда исә алар көрәштәшләр, фикердәшләр буларак сурәтләнә. Биредә XVI йөз вакыйгаларына бүгенге караштан чыгып бәя бирүнең бик үк дөрес була алмавын ассызыкларга тиешбез. Казан ханлыгының үз чорында Кырым ханлыгына сыенуы, хәзерге милли күзлектән караганда, иң дөрес юл кебек күренә. Тел кардәшлеге, дин берлеге, тамырлар уртаклыгы һ.б. факторлар шушы фикерне алга сөрә. Әмма XVI йөздә Рус дәүләтенең дә, Кырым ханлыгының да тышкы сәясәте Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген ныгыту булмый, димәк, ханлыкның мөстәкыйльлеге мәсьәләсендә Мәскәү дә, Кырым да бер төрле үк куркыныч тудыра. Мондый вазгыятьтә Чура Нарык углының «көнбатыш» төркемдә торуы һәм Мәскәүдән яклау өмет итүе ханлыкның мөстәкыйльлеге өчен көрәштә Мәскәү белән компромисс табарга омтылу булып аңлашыла. XVI йөз – Алтын Урда ханнары төзегән тәртип тәмам какшап, Рус дәүләте исә, киресенчә, кисәк көчәеп киткән чор. 1486 елдан бирле Казанның Рус дәүләте протекторатында торуын да онытмаска кирәк. Мондый хәлдә тәхет азатлыгы өчен көрәштә Чураның да, башка шәхесләрнең дә сайлау мөмкинлеге әллә ни күп булган дип тә әйтеп булмый. Шуңа күрә Чура Нарыковны тарихи яктан тискәре, ә Кошчак угланны уңай шәхес, аларны реаль тормышта бер-берсеннән бик ерак кешеләр дип бәяләү үтә примитив булыр иде. Мәсьәләгә бу җәһәттән караганда, Кошчак угланның халык иҗатында Колынчак образында гәүдәләнгән булуы бик мөмкин һәм бу очракта Чура батыр белән Колынчакның фикердәшләр булуы да аклана. Реаль чынбарлыкта да, дастани образ буларак та алар – ил азатлыгын кайгыртып яшәгән кешеләр булып гәүдәләнәләр.

Алга таба Колынчак Чура батырга коткарылган кызны бирү шартын куя: йокларга яткач, кем уяу кала – кыз шуныкы, ди. Беренче булып Колынчак йоклап китә. Куелган шарт буенча, Чура батыр, аның хатынын алып, атын йөгәнләп, качып китә. Артларыннан Колынчак куып җиткәч, Чура әйтә:

– Синең хатының миңа кирәк түгел. Мин, сине кичә әйткән сүзендә тора микән дип, бу эшне эшләдем. Хатының үзеңә булсын! – ди.

Алай да Колынчак хатынын Чурага багышлаган икән инде, кызны атасы өенә алып кайтып, зур туй ясыйлар, Чурага бирәләр. Ә Чура батыр үз чиратында Колынчакка кыз кардәшен ярәшә. Шул рәвешчә, дастанда Чура батыр белән Колынчакның туганлашуына ишарә ясала.

Төрки халыклар эпосында бик борынгыдан килә торган героик ярәшү сюжеты мәгълүм. Гадәттә Себер һәм Урта Азия төркиләре кәләшне башка кабиләдән ала торган булганнар. Казакъларда, мәсәлән, җиденче буынга кадәр кан кардәшлеге булмаган очракта гына никахлашу рөхсәт ителгән[1]. Кәләшне читтән эзләү мотивының экзогамиягә бәйле булуы турында Себернең төрки-монгол халыклары иҗатына мөнәсәбәттә Е.М. Мелетинский җентекләп яза[2]. Алтай әкияте «Кан-Пудей»да[3] «алтын күкрәкле, көмеш аркалы» каһарман күк кызын, бикерактан, «җир белән күк тоташкан урыннан» алып кайталар. Төрки һәм монгол халыклары өчен уртак сюжетның «Чура батыр» дастанында чагылышы – әлеге теманың ерак кайтавазы. Игътибар итсәк, «Чура батыр» дастанында Казый би Нарәңгә хатынлыкка кызны башка авылдан – Кабак дигән җирдән алып бирә. Чура үзе кәләшне Кырымнан Идел буена килеп таба, Идел буенда очраткан дусты Колынчакка Кырымда калган кыз кардәшен ярәшә. Әлеге сюжетны борынгыдан килә торган традицион никахлашу-ярәшү мотивының соңгырак чордагы чагылышы дип кабул итә алабыз. Баһадирлар турындагы әкиятләрдән (В.М. Жирмунский билгеләмәсе), алыплар турындагы хикәятләрдән аермалы буларак, биредә кәләш эзләү моментына киң тукталу юк, сүз нигездә каһарманның ил азатлыгы өчен көрәше турында бара.

Дастанда «кем беренче булып йоклап китми – кыз шуңа» дип килешүгә яңадан кайтсак, шарт кую аша гадел чишелешкә килүнең мондый мисалын Чура батыр турында дастаннарның кайбер вариантларында, мәсәлән, кырымтатар версияләренең берсендә очратабыз[4]. Казан батырлары Караман, Сары, Колынчак Чораны еланлы

---

[1] *Ауэзов М., Соболев Л.* Эпос и фольклор казахского народа // Литературный критик, 1939. № 10–11. С. 215.

[2] *Мелетинский Е.М.* Происхождение героического эпоса. М., 1963. С. 259–260.

[3] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен. Ч. I. СПб., 1886. С. 68–86.

[4] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы северных и тюркских племен. Ч. VII. СПб., 1896. С. 167–183.

түшәктә йоклатып сыныйлар, Чора бер дә курыкмагач, аның чын батыр булуын таныйлар.

Идел буена сәяхәтеннән соң Чура батыр кабат Кырымга әйләнеп кайта. Алга таба дастан вакыйгалары янә башка төрки вариантлардагы традицион сюжет белән кисешә. Бу – Гали би (Али би) белән конфликт эпизоды. Батыр үзе читтә йөргәндә аның туган иле, өе, гаиләсе, ата-анасы, хатыны, апа-сеңелләренең кем тарафыннандыр кыерсытылу сюжетын Ф.И. Урманчеев казакъ, кыргыз, үзбәк, нугай халыклары, Алтай төркиләре дастаннарына хас сюжет дип күрсәтә[1]. Борынгы һәм Урта гасырларда көчсезрәк кабиләләрне дошман явы килеп буйсындыру, талап, кырып китү күренеше күп кенә тарихи риваятьләрдә сакланып калган. Мондый риваятьләр тамырлары белән иң беренче рәсми төрки дәүләте яшәгән ерак заманнарга ук барып тоташа. Күренекле урыс язучысы Д.М. Мамин-Сибиряк тарафыннан XIX гасырда Урта Азиядә язып алынган борынгы риваятьтә, шулай ук XI йөз фарсы тарихчысы Әл-Гардизинең «Хәбәрләр күрке» дигән китабында китерелгән риваятьтә, мәсәлән, әнә шундый хәлләр тасвирланган[2]. Заманы өчен актуаль булган әлеге сюжет төрки дастаннарда да киң таралган. Героик эпос буларак, «Чура батыр» дастанында да яу чабу сюжетының баштан ахырга кадәр кызыл җеп булып сузылуы табигый. Яудан исән калган бала – Нарәң турында сөйләп башланган дастан аның улы Чураның яудагы һәлакәте белән төгәлләнә. Сюжет үстерелешендә эреле-ваклы яу чабу вакыйгалары дастан героеның тормышын баеталар, шәхси батырлык өчен җирлек әзерлиләр, яңа батыр Чураны эпик югарылыкка күтәрәләр.

Чура батыр Кырымга әйләнеп кайткач, атасы Нарәкнең (текстта моңа кадәр Наррәң, Нарәң дип бирелгән исем хәзер яңа яңгыраш ала, яисә гарәп шрифтендә шул ук исем башка билгеләр белән бирелгән) җыр белән әйткән сүзләреннән түбәндәгеләрне беләбез: Акташ дигән җирдән килгән Гали бәк, Нарәк үзе дә суймаган иң җитез, шук куйны суеп, елкысын менеп, Нарәкне кыйнап, анасы Миңсылуга авыр сүзләр әйтеп, иң сөекле аты Карагирне алып киткән. Моны ишеткән Чура батыр болай ди:

Әй, җылкычым, әй агам!
Актан киярем минем ал(ып) килче!
Атым киер(т)еп менәем.

[1] *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас, 1995. № 9. Б. 102.
[2] *Фәхретдинов Р.Г.* Татар халкы һәм Татарстан тарихы. Казан, 1996. Б. 43.

Ак көбәмне (*көбә* – борынгы сугыш киеме) ал(ып) килче!
Битенә биктәр (*биктәр (биткәр*) – көбәнең битлеге) тышлап кияем.
Алдамияным (*алдамиян* – металлдан ясалган кул кабы) ал(ып) килче!
Эч-билемә бу ивием (*ивү* – чорнау)
Бу киткәннән китәем,
Алмачык суның буенда
Акташның Гали бигә җитәем.
Акташның Гали бигә җиткәннән соң,
Кабыргадан (*кабыргадан* – яннан мәгънәсендә) юл салып,
Сөйре (*очлы*) телем көрмәләп (*көрмәләп* – бәйләп),
Сөяк тешем кашкарып (*кашкарып* – яшереп),
Бәреңләй (*бәрең* – атның я сугышчының гаскәри киеме) бәнем кадалып,
Гали бидән атамның Карагирен
Тәгъзим (*тәгъзим* – хөрмәт итү, олылау) әйтеп теләем,
Теләп-теләп бирмәсә,
Ярдагы боландай кискәләшеп үләен.

Гаделсез рәнҗетелүне, бигрәк тә якыннарын кыерсытуны төрки эпик геройның кичерергә хакы юк. Шигъри формада ярсып әйтелгән әлеге юллар Чура батырның ачу кайтару планын чагылдыралар.

Гали би (Али би) турындагы эпизод кырымтатар, казакъ, нугай вариантларының барысы өчен дә уртак. Татар дастанында Гали би белән ике арада элек-электән килә торган дошманлык та юк, талау-рәнҗетүнең социаль мотивлары да күренми. Бу – фәкать индивидуальлектән ерак торган героик дастаннар өчен уртак сюжет кына. Татар вариантында Чураның батырлыгын ассызыклау өчен китерелгән эпизод нәкъ менә башка төрки версияләр сюжеты нигезендә тулылана. Гали би белән Чура батыр арасындагы дошманлыкның татар эпосында күрсәтелмәгән сәбәпләрен алар җентекләп аңлатып бирәләр.

Алга таба дастанда Чура батырның Гали бидән Карагир атын кире кайтаруы, дошманын исә кылыч белән чабып үтерүе турында сөйләнә. Шул китүдән Чура туры Казанга юл тота. Татар дастанының тарихи җирлеген тәшкил иткән Мәскәү-Казан конфликтлары шушы урында тулырак гәүдәләнә башлый. Әсәрдә түбәндәге юллар бар: «Казанга барып Колынчак батырны чакыртып алдырды. Андагы батырлар белән кушылып, Казан шәһәрен алмага килгән урыс гаскәре белән сугышып торды». Әйтергә кирәк, Чура турындагы дастаннарның татар версиясе – Казан ханлыгында булган трагик вакыйгаларга иң зур әһәмият бирелгәне. Аларның үзәк проблема итеп алынуы,

әсәрнең кайбер урыннарында эчтәлекнең чынбарлыкка якынаеп китүе дастанның татар җирлегендә иҗат ителүенә шик калдырмый.

Иҗади әсәр буларак, «Чура батыр»га тарихи билгеле фактларны халык күрергә теләгән формада, аның хыялы биеклегеннән торып, фикерләү үзенчәлегеннән чыгып тасвирлау хас. Илгә куркыныч янаган бер чорда бердәм булудан да көчлерәк чара юк. Шушы фикерне куәтләп, дастан Чура белән Колынчакны бер үк идеяләр өчен көрәшүче батырлар итеп күрсәтә. Алар бер-берсен тиз аңлыйлар, дошманга каршы бергәләп көрәшәләр. Шушы уңайдан әсәрдә Шагали ханның да (тарихи прототибы – Казан ханлыгы тарихына турыдан-туры мөнәсәбәтле шәхес – Шаһгали хан, 1521, 1546, 1551–1552 елларда тәхеттә утырган) нык кына идеаллаштырылуын искәртеп үтәргә кирәк.

Дастан сюжетына килсәк, монда кайчандыр Нарәң белән булган кайбер вакыйгалар Чура язмышында кабатлана төсле: Нарәң батырны Акча солтан хөрмәтләп каршы алган булса, Чура батырны да Казан ханы Шагали үзенә чакырта. Алай гына да түгел, хан-түрәнең батырны үзенә сыендыруы, аның дошманнарга каршы көрәштә иң гайрәтле пәһлеваны ярдәменә таянуы – Чура турында барлык төрки дастаннарга да хас уртак сюжет элементы.

Тарихи чынбарлык җәһәтеннән караганда, Шаһгали – Казан ханлыгы тәхетенә Мәскәү тарафыннан утыртылган хан, тулысынча урыс кенәзе йогынтысында булган, халык арасында аз гына да дәрәҗәсе юк. Әмма шуңа карамастан, башка төрки вариантлар тәэсирендәме, татар халык дастанында Шаһгали образы уңай герой буларак тасвирлана. Дастан Чура батырны гына түгел, Шаһгалине дә нык кына идеаллаштыру, аны да милләт мәнфәгатьләрен яклаучы һәм саклаучы хан итеп сурәтләп бирә.

Дастан, Шаһгали шәхесенең татар тарихы өчен тискәре тип булуын аңлапмы, аңламыйчамы, аны тәнкыйтьләүдән читкә китә, үзе күрергә теләгән сыйфатларны гына туплап, аны Шагали образында бирә. Ничек кенә булмасын, дастандагы әлеге моментлар ил язмышы хәл ителгәндә ызгыш-талашларга урын юк, хан да, батырлар да бердәм булырга тиеш, дигән самими идеяне чагылдыралар кебек. Чура үзе дә нәкъ менә Казанга килеп, хан гаскәренә башлык булып алганнан соң милли каһарман буларак ачыла. Татар халык героик дастанында ханның да, Чураның да, шулай ук каһарманнарның да тарихи прототиплары мәгълүм кешеләр булу – ул әле әсәр шушы шәхесләргә махсус багышланган иҗат икән дигән сүз түгел. Монда

мәгълүм сюжетның һәм төрки эпосына хас җыйнама образларның татар җирлегенә килеп эләккәннән соң охшаш тарихи шәхесләр, татарларга якын тема, билгеле вакыйгалар нәтиҗәсендә контаминация кичергән булуына да киң урын кала.

Дастан вакыйгалары эзлеклелегенә кире кайтып, Чураның, урыс гаскәренә каршы сугышып йөри торгач, урысларны тәмам гаҗиз итүен аңлыйбыз. Үлеме нидән икән, дип, алар астрологларны җыялар. Йолдызларга карап, кеше язмышын ачыклауны Ф.И. Урманчеев: «...борынгы, хәтта Урта гасырлар урыс мәдәнияте өчен дә хас нәрсә түгел», – дип искәртә[1]. Галим дастанга килеп кергән әлеге сюжетның Урта гасырлар Көнчыгыш, шул исәптән төрки әдәбиятларда һәм халык иҗатында киң таралган күренеш булуын әйтеп уза.

Астрологлар Чураның әҗәле дошман (бу очракта урыс) кызыннан туган улыннан булуын ачыклыйлар. Бу сюжетны Борынгы Грециядәгедән дә алда тапмадык. Грек мифларының берсендә Акрисий, үз кызы Данаядан туган бала тарафыннан үтереләчәген белгәч, кызы балага узмасын, дип, аны биек манарада бер бинага яшереп куя. Әмма Акрисий барыбер оттыра: Данаяга яшен алласы Зевс үзе гашыйк була һәм кызга алтын яңгыр булып керә[2].

Дастанда исә шундый күрәчәк язмыш махсус оештырыла: матур киендерелгән бер кызны, «дүрт яхшы ат җигеп», Чурага җибәрәләр, балага узгач, кире урысларга кайтырга кушалар. Кыз әмерне төгәл үти. Нәтиҗәдә урыслар ягында Чура батырның улы туа.

Алга таба татар халык эпосында вакыйгалар кабат Нарәң батырга әйләнеп кайта. Чура Шагали хан янында урысларга каршы сугышып йөргән арада Гали бинең якыннары, яңадан килеп, Нарәңнең йорт-курасын талап киткәннәр, Нарәң үзе ярлылыкка чыккан икән. Шул сәбәпле атасы, ярдәм сорап, Казанга, улы Чура батыр янына килә. Гарьчел Чура башта, атасының яман киемле булуыннан оялып, аны танымаганга салыша. Батырлар Нарәңнән җыру әйттерәләр. Ул әйткән сүзләр дастанда импровизацияле монолог рәвешендә китерелгән. Атасының сүзләре Чурага тәэсир итә, ул, оялып, Нарәңне кабул кыла, аңа күп итеп акча бирә. Ул гына да түгел, үзе башлык булган гаскәрне атасы килгән хөрмәткә тезеп, сугышчыларына картны күрсәтә. Казан ханы да Чура батырның атасы Нарәңне кунак итә,

[1] *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. 1995. № 9. Б. 103.

[2] Мифы в искусстве старом и новом (по Рене Менару). СПб., 1900. С. 119.

хөрмәтли. Дастанның казакъ вариантлары Нарәң батырны Казан бәге дип күрсәтсәләр, татар версиясе исә аның язмышын мәшһүр кала белән әнә шул рәвешле бәйләгән. Шунысы да бар: биредә Кырым белән Казан шәһәренең арасы бик якын кебек тасвирлана. Күпчелек вариантларга хас булганча, Нарәң (Нарик, Нарык) Кырымга килә, шунда төпләнеп яши, Чура да шул төбәктә туа. Татар халык иҗатында Кырым-Казан мөнәсәбәтләренең киң яктыртылышы, беренчедән, тарихи чынбарлык чагылышы булса, икенче яктан караганда, – Чура батыр турындагы төрки дастаннар өчен уртак традицион сюжет элементы.

Дастан вакыйгаларына килсәк, алга таба әсәргә Шагали кызы Сарыкани килеп керә. Реаль Шаһгали ханның Сарыкани исемле кызы булу факты мәгълүм түгел, әмма Казан ханының кызы образы кырымтатар ($К_1$ $К_3$), нугай ($Н_1$) вариантларында бик популяр. Гадәттәгечә, Сарыкани батырларга бүләк өләшә. Батырга бүләк бирү, бигрәк тә сугыш коралы, ат бүләк итү – тикшерелә торган дастаннарга гына түгел, гомумән, төрки эпоска хас күренеш. Мәсәлән, кыргызларның «Манас»ында каһарманга Ак кәлтә дигән корал бүләк итүләре мәгълүм[1]. «Йир Төшлек»тә аждаһа янына киткән геройга кәләше «унике җанлы Чалкойрык» ат белән алмас кылыч бүләк итә[2].

Биредә хан кызы Чура батырга алтын тартма бирә. Башка версияләрдәгечә үк, Чура, бүләкне мәгънәсез дип табып, баштарак сугышка чыкмый ята. Сарыкани батыр янына үзе килеп, бүләк тартманы ачып карарга киңәш итеп, аның эченнән Чурага аталган «Күк чыбык» дигән кылыч килеп чыккач кына, ул кабат яуга каршы китә һәм «дошманның күп кенә гаскәрен харап итә».

Батырга бүләк ителгән коралның махсус исемләнүе һәм, эпик геройның үзе кебек үк, коралының да гадәттән тыш булуы хакында кыргызларның «Манас» эпосына мөнәсәбәттә В.М. Жирмунский язып үткән иде[3]. Манас кылган батырлыклар аның Ач албарс дигән үткен кылычы һәм Ак кәлтә исемле утлы сугыш коралыннан аерылгысыз. Ә «Чура батыр»да каһарманның Күк чыбык дигән кылычы эпик элемент буларак әһәмиятле. Батырның махсус исеме булган атаклы сугыш коралына ия булуы – татар халык дастаннарында шактый популяр элемент. Алдарак каралган «Каһарман Катил»дә дә, мәсәлән,

[1] Манас. Эпизоды из киргизского народного эпоса. М., 1960. С. 45.
[2] Йир Төшлек // Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан, 1984. Б. 67.
[3] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л., 1974. С. 58–59.

төп герой үзенең дошманнарын һәрвакыт Гамгам исемле кылычы белән кыра. Болар – безнең дастаннарда төрки эпосына хас типик «уртак урыннар». Коралларының борынгылыгы сюжетның да шуңа муафыйк икәнлеген раслый. Утлы сугыш коралларының Урта Азиядә XIV йөзнең урталарында кулланыла башлавы мәгълүм. Ә Урта Азия эпосына мондый төр корал XV–XVII йөзләрдән дә иртә кермәгән[1]. «Каһарман Катил»дә дә, «Чура батыр»да да каһарман кылыч, хәнҗәр тотып сугыша. Кайсы да булса элементның эпик традициягә әверелеп китүе өчен шактый вакыт кирәк булганлыгын исәпләгәндә, биредә карала торган дастан версияләренең борынгы эпик традицияләргә тугрылыкта иҗат ителгәнлеге ачыклана.

Чура батырның дошман явына каршы көрәшүенә күңеле булган Шагали хан, халыктан күп мал, хәзинә җыеп, аның атасын Кырымга кайтара. Чура исә Казанда кала. Үз йортына кайтып җитү белән Нарәң зур мәҗлес җыя. Анда Чура батыр мактала, бигрәк тә анасы Миңсылу, үзе белгән бәк-морзалар исемен телгә алып, улын шулар белән тиңли, аның үз баласы булуы белән горурлана һәм бу турыда сүзләрен җыр белән әйтә.

И. Березин тапкан кулъязмага нигезләнеп басылган дастан шушы урында төгәлләнгән форма ала һәм алга таба вакыйгалар «Хикәят Колынчак батыр» исеме белән дәвам итә.

Кыргыз, казакъ, үзбәк һ.б. халыкларның эпик традициясендә үзәк фигура тирәсенә башка каһарманнарны да туплаган әсәрләр мәгълүм. Бер эпик әсәрдә берничә батыр аерып күрсәтелә, яисә алар турында дастаннар махсус циклларга берләштерелә. Мәсәлән, мөстәкыйль тарихи риваять геройлары буларак килеп кергән Күкче, Тештүк, Кошой, Җамгырчы һ.б. образларның һәрберсенә кыргызларның «Манас»ында аерым эпизод багышланган[2]. Яисә төрки-угызларның «Китаби Коркот»ында Баюндур хан үзәк урынны биләсә, аның тирәсенә берләшкән баһадирлар – мөстәкыйль эпик әсәр геройлары[3].

Нарәң һәм Чура батырга багышланган дастанда Колынчак образына да дастанның башка версияләре белән чагыштырганда зуррак урын бирелүне алдарак әйтеп узган идек. Биредә аңа аерым хикәят багышлану ул – күп кенә халыклар эпосына хас булган генеалогик

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л., 1974. С. 58–59.
[2] Киргизский героический эпос «Манас». М., 1961.
[3] Книга отца нашего Коркута. Огузский героический эпос. Баку, 1987.

циклларга бүлү традициянең бер чагылышы. Әйтик, әрмән, азәрбайҗан, Урта Азия эпосы мондый мисалларга гаять бай. Әмма Колынчак батыр турындагы вакыйгалар дастан сюжетында әллә ни аерымланмыйлар, текстта аерым хикәят итеп бирелүгә карамастан, татар дастаны нигездә шул ук сюжет буенча дәвам итә, Колынчак мөстәкыйль хикәятнең үзәк батыры дәрәҗәсенә күтәрелми. Бу – китабилашкан версиянең җыйнаклыкка, эчтәлек җәһәтеннән кыскалыкка омтылуы нәтиҗәсе.

Казанда урыс гаскәренә каршы сугышып йөрүче Чура, өенең иминлеген, кыз кардәшенең (Колынчакның хатыны) хәлен белсен дип, Колынчакны Кырымга җибәрә. Чура батырның кыз туганы текстта Айсылу исемле дип бирелгән. Кырымтатар вариантлары аны төрки эпосы өчен традицион исем белән Ханыкей дип атый. Ханыкей – «Чура батыр»ның казакъ версиясендә калмык ханы Караманның кызы, соңрак Чураның (Шора) хатыны. Идегәйгә багышланган дастаннарда исә Ханыкей белән Таныкей – Туктамыш ханның кызлары, аталарын җиңгән Идегәйгә әсирлеккә төшәләр. Ханыкей (Каныкей) образы – кыргызларның «Манас»ында – Манасның хатыны, Манаска Алмәмбәт белән хыянәттә хаксызга гаепләнә[1]. Чураның хатыны, Колынчак кайтып керер алдыннан, иренең карендәше Айсылуны ирләр киеменә киендереп, аның белән кочаклашып утыра. Моны күргән Колынчак, хәйләне аңламыйча, кире Казанга чаба, хәбәрне Чурага җиткерә. Кызу канлы батыр, «хатынны үтерәм!» – дип, бар эшен ташлап, Кырымга килә. Әмма бөреләнгән конфликт, «Манас»тагы кебек үк, уңай чишелеш ала: хатыны Чурага бу эшне ирен үз янына кайтару өчен махсус оештыруын әйтә.

Биредә без Чура батырга багышланган төрки дастаннарның бер-берсе белән һәм шул ук вакытта сюжетлары бөтенләй башка төрки эпос белән дә зур уртаклыгын күрәбез. Татар дастанында күп кенә үзгәрешләр-тайпылышлар бар, әлбәттә, шулай булуга карамастан, идея һәм типологик охшашлыклар искиткеч күп. Тулаем алганда, татар халкының «Чура батыр» дастаны үзе төрки героик эпосының үзенчәлекле генеалогик циклын тәшкил итә кебек. Игътибар итсәк, төрки эпоста Ханыкей белән Таныкей – батырга капма-кршы позициядә торучының, ягъни дошман ханының кызлары. Киң таралган гадәт буенча, җиңүче аларны хатынлыкка ала. В.Г. Тизенгаузен

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 63.

мәгълүматларына таянып[1], В.М. Жирмунский болай дип яза: «Фарсы тарихи чыганаклары Туктамыш кызларыннан берсенең, чыннан да, Идегәй тарафыннан әсир ителүен һәм ул кызның Идегәйдән улы тууын раслыйлар... Рәшидеддин язган «Монголлар тарихы»ның казакъча-татарча тәрҗемәсендә Туктамыш кызының исеме дә әйтелә: И. Березин нәширлегендә чыккан җыентыкта[2] ул Джаныкей (дөресе Ханыкей булырга тиеш) дип күрсәтелә»[3]. Шул рәвешчә, Ханыкейның төрки эпос персонажы булу белән бергә тарихи шәхес булу ихтималы да зур. Чура батыр сюжетлы дастаннарга һәм шул исәптән, бераз үзгәреп, татар версиясенә дә шушы образның килеп керүе – әлеге тарихи-традиционлык нәтиҗәсе. Дошман кызына өйләнү сюжеты исә татар версиясенә җирле үзгәрешләр кичереп килеп кергән булырга охшый. Биредә дә Чураның улы дошман ягыннан җибәрелгән хатыннан туа, дошманнар ролендә исә күрше руслар чыгыш ясый.

Әсәр эзлеклелегенә кабат әйләнеп кайтсак, Чура, хатыны янында бер кич кунып, кабат яуга чыгып китә. Яуга китеп барганда хатынының ирен озату күренеше дастанда җыр аша бирелгән:

Ала кит, батыр, ала кит,
Ат савырына (*савыр* – ат сыртының арткы өлеше) сала кит.
Екет башыңа, батырым,
Бездәй иткән сабаны (*саба* – ямьсез хатын)
Үз юлыңа корбанлыкка чала кит.

Гомумән алганда, хушлашу күренешенә, елау-сыктау эпизодларына татар варианты зур игътибар күрсәтмәгән. Андый күренешләргә кырымтатар, нугай дастаннары киң урын бирә. Әйтик, нугай халкындагы «Айсул улы Әхмәт», «Кобланды батыр», «Мамай», «Адел солтан», «Эр Күсеп», «Елкилдек батыр» һ.б. дастаннарның һәркайсында каһарман үлеме белән бәйле елау-сыктау монологы бар. Копланлы үлеменнән соң хатыны Карлыгаш, Адел солтан үлгәннән соң Данабикә, Мамай үлгәч, җыручы-автор, Күсеп үлгәч, хатыны Акмаңлай елап әйткән сүзләр аша чичән тыңлаучы халыкка эмоциональ тәэсир ясаган. Бу – авыз-тел иҗаты булган традицион героик эпоста

---

[1] *Тизенгаузен В.Г.* Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т. 2. М. Л.: Изд-во АН СССР, 1941. С. 194.

[2] Библиотека восточных историков, изд. И. Березиным. Т. II. Ч. I: Сборник летописей (татарский текст с русским предисловием).

[3] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 75.

импровизатор тарафыннан кулланыла торган отышлы алымнарның берсе. Нугай халкының Чура батырга багышланган дастаннарында Чура (Шора) һәлакәтеннән соң анасы Миңлесылуның елавы да – традицион төрки эпос өчен типик әлеге күренешнең ачык үрнәге:

Ай, ай, көнем, ай, көнем,
Җаным, бәгърем, Чура улым,
Суга баткан, бел, улым.
Кайгылар, сөенечләрең
Истән китмәс үк булдың,
Инде нәрсә итәем?
Баласы үлгән дөядәй,
Бызлый-бызлый китәем.

Татар версиясендә мондый елау-сыктау урыннары гомумән юк. Ә ирен яуга озатканда Сылубикнең елап әйткән сүзләре исә 5 юлдан артмый. Чура батыр, хатынының сүзләренә җавап та кайтарып тормыйча, китеп бара. Бу –традицион дастанның чичән чыгышыннан гыйбарәт, формулалылыкка нигезләнгән тәэсирле урыннары татар китаби версиясендә кыскаруга яисә бөтенләй төшеп калуга йөз тоткан дигән сүз.

«Чура батыр»ның һәрбер төрки версиясендә каһарманны героик көрәштә сынау мәйданы итеп Казан ханлыгы күрсәтелгән. Кырым татарлары, нугай, казакъ версияләре Казан алыну вакыйгасына чичән осталыгына бәйле әнә шундый эмоциональ төсмер бирсә, татар версиясе Чураның Казанга юнәлүен, аннары аның һәлакәтен һәм Казан алыну вакыйгасын фактик хәбәр итү белән тәмам була.

Чура Кырымнан килеп җиткәндә шәһәрне дошман явы камап алган була, халык куркуда икән. Бу урында эпик каһарманның әйткән сүзләре эпик-героик рухтагы җыру буларак кыйммәт. Монда батырның үз көченә нык ышануы, мин-минлеге чагылыш тапкан һәм дастан герое өчен бу халәт табигый дә:

Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел, карамын,
Асылымны сорасаң –
Күкес углы Тамамән,
Казанны яу алды, дип ирәмән,
Без барганчы алмаса,
Алып кулга салмаса,

Казан атлы шәһәрнең
Капкасының авызында,
Кальгасының төбендә
Таштан суккан чикмән булай.

Алга таба Чураның дошман гаскәрен Казаннан куып чыгаруы турында сөйләнә. Батыр янә данга күмелә. Дастан сюжеты буенча Чура батырның үлеме үз улыннан булырга тиеш иде. Әсәр ахырына таба юрау чынга аша башлый. Яңадан яу булып килгән урыс гаскәре эчендә Чураның марҗадан туган улы барлыгы әйтелә. Дошманга каршы киткән Чура батыр шул угланын үтермәкче булып озак йөри. Бер-ике селтәнү белән бөтен бер гаскәрне җиңә алган батыр (арттыру алымы) бу юлы ни өчендер уңышка ирешә алмый. Сугыш эпизодларын җентекләп тасвирлаган кайбер казакъ, кырымтатар вариантлары белән чагыштырганда, татар дастаны алар турында әйтеп узу белән чикләнә, әмма шул ук вакытта Чура батыр тарафыннан әйтелгән эпик җырларда игътибар көрәшнең ни дәрәҗәдә кызу булуына юнәлтелә.

Эпик дастаннарның барысына да хас булганча, «Чура батыр»да да каһарманның хис-кичерешләренә караганда эш-хәрәкәтләре турында күбрәк сөйләнә. Кыргызларның Манас батырын, үзбәк яисә башка төрки халыкларның Алпамышын, казакъ халык эпосындагы кырык нугай батыры циклын тәшкил иткән дастаннарның батырларын, Идегәй һ.б.ларны алсак, бу каһарманнарның холык-сыйфатларындагы уртаклыкны күрми мөмкин түгел. Алар үзләренең героик холыклары белән героик булмаган, ягъни гадәти характерлардан бердәй сыйфатлар аша аерылып торалар кебек. Каһарман холкының нигезен бала вакыттан ук гаҗәеп физик көчкә ия булу, җитезлек (беркем иярли алмаган атка менеп атлану эпизоды), кыюлык, курку белмәү, гаделлек кебек сыйфатлар тәшкил итә. Шул ук вакытта мондый тип характерга хас булган тискәре сыйфатларны да күрергә мөмкин. Батыр, гадәттә, үз көченә артык ышанып, эреләнеп китә, масаючанлыгы, тәкәбберлеге яисә тиз кабынып китүе аны һәлакәткә алып бара. Әмма, эпик кануннар нигезендә, каһарман үзенең җиңелүен танып, кемгә дә булса баш ия дә алмый. Эпик әсәр кысаларыннан чыкмыйча, каһарман үлгәндә дә горур булып кала.

Төрки халыклар эпосындагы әлеге закончалыклы күренеш «Чура батыр» дастаннарына һәм аның татар версиясенә дә килеп кергән. Баһадирның дошман белән сугышуын чарлактан күзәтеп утыручы Сарыкани Чурага, сусаганын басып, су эчеп китәргә киңәш

бирә. Батырның үз-үзен тотышында героик холык өстенлек ала: Чура Сарыканине тыңламый, үз көченә артык ышана, кызу канлылык күрсәтә. Ул, ярсып, теләген җыр белән әйтә:

Шагали ханның йорты (текстта: *җорты*) өчен,
Сарыканиның күңеле өчен
Күк чобарым арытмай,
«Күк чыбыгым» кара канга җитми,
Бу кяфернең кереш күзле малаен
Иңрә-иңен (*иңрә-иң* – буй) ана Иделгә колатмай,
Болар миңа серен чыктырмай,
Ак мәсҗедләр салдырмай,
«Аллаһу»лап азан әйттермәй,
Морадыма җиткермәй
Кайтмам да! Кайтмам да!

Чура гаскәрне кыра, ә марҗадан туган үз улын үтерә алмый күп йөри. Бу урында дастан бүгенге көндә дә актуаль булган катнаш никахлар, алардан туган балалар мәсьәләсенә дә кагылып үтә кебек. Галим Х.Б. Паксой болай дип язган иде: «Марҗа кызы белән бәйләнүе сәбәпле, ул үз үлемен таба, ә бит моны бер генә батыр да, хәтта берничә гаскәр дә эшли алмас иде»[1]. Чыннан да, дастан әлеге күренешкә фәлсәфи йомгак ясый дип әйтергә була.

Шул ук вакытта Чураны артык дуамаллыгы, башкалар фикеренә колак салмавы харап итә. Бу – эпик каһарман өчен типик холык. Ул – шундый бердәнбер батыр, дастанда аның башкача тасвирлануы эпик нормага сыешмас та иде. Дастанда яу кадәр яуга каршы чыгучы итеп бердәнбер Чура гына күрсәтелә. Янәшәсендә гаскәре дә, дусты Колынчак та юк. Тарихи чынбарлыкта ил язмышының бер генә батырга бәйләнмәве аңлашыла. Әмма бу – конкрет шәхесне эпик югарылыкка күтәрә торган халык әсәре, эпик чараларның һәркайсы Чура образын тиешле дәрәҗәдә калку итеп тасвирлауга юнәлтелгән.

Ахырда Чураның аты тәмам кыза, туктый алмыйча, Иделгә егыла, Чура батыр суга батып үлә. Моны кырымтатар[2], нугай[3] вариантларында телгә алынган «батырның үлеме судан булачак» дигән

---

[1] *Паксой Х.Б.* Чура батыр кисәтүе // Идел, 1994. № 9. Б. 12.

[2] Кырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгы / төзүчесе Джафар Бекиров. Ташкент: Укитувчи, 1991. Б. 57–72; *Радлов В.В.* Образцы народной литературы северных тюркских племен. Ч. VII. СПб., 1896. С. 21–22.

[3] Шора бьтир // Ногай давысы. 1992. № 46, 59–60, 93.

юрауның күпмедер дәрәҗәдә татар дастанында да үзен сиздерүе дип аңларга мөмкин. Хәер, биредә туганда ук Чураның Калавыз суы буенда дөньяга килүе ассызыкланган иде, үлеме дә суда – Иделдә була. Чура түбәндәге сүзләрне әйтеп үлә:

Казан алды катлау-катлау кара су,
Камышлап төшеп идем сай да дип.
Тирән дә юк, сай да юк,
Индегедән арбаган (*арбаган* – бәхет, уңыш),
Бездәй ирләргә Казан атлы сар (*шәһәр*) да юк.

Әсәр Нарәң һәм Чура батырга багышланган. Әмма Чураның үлеме белән генә дастан төгәлләнми әле. Аның батырлыгын бәян иткән эпос тарихи хроника төсен ала. Татар ханлыкларының бер-бер артлы кинәт көчәеп киткән Рус дәүләтенә буйсындырылу факты турында дастанда түбәндәгеләр җиткерелә: «Соңра урыс гаскәре җиңүче булып, Казан шәһрене алды, – диелә анда. – Бу Казан шәһрен алгандан соң бер ел соңра Хаҗитархан шәһрен янә алды». Шул рәвешчә, шәхси батырлыкка дан җырлаучы эпик әсәр вакыйгалары тарихи чынлыкка кайтып төшә: татар ханлыклары «урыс падишаһына табигъ булдылар (*буйсындылар*)». Нәкъ менә шушы вакыйганың ассызыклануы дастанны башыннан ахырынача тагын бер кат күздән кичерергә этәрә. Казан-Кырым, Казан-Россия мөнәсәбәтләре, XVI йөзнең урталарына таба Казан ханлыгы, татар ханлыкларының көчсезләнүе, үзара аңлашылмаучанлык һәм һәлакәт. Төрки батырлык эпосының классик үрнәге булган дастанда әлеге чынбарлыкның барысын да табарга мөмкин. «Чура батыр» эпосы – татар халкының әдәби һәм тарихи традицияләренең бер кыйпылчыгы. Бу урында Х.Б. Паксой сүзләре белән дә килешми мөмкин түгел: «Чура батыр» урысларның тарихны үзләре теләгәнчә боргалауларына каршы килерлек көчне тәшкил итә», – ди ул. «Тарихи әсәр буларак, – дип дәвам итә автор, – ул совет тарих белемендә телгә кергән «уртак милли тамырлар», «тарихи» дуслык», «урыс дәүләтенә ирекле кушылу» кебек күпме буынның миен агулаган сафсатаны төбеннән кире кага. Барлык дастаннар кебек үк, яңа совет кешесен тудыру омтылышында булган мифологиянең юлында җитди киртә»[1] Галим, чыннан да, хаклы. Тарихи яктан караганда әлеге дастан бик күп реаль вакыйгаларны үз эченә ала, чынбарлыкка эпик йомгак ясый. Моңа игътибар итми мөмкин түгел. Бигрәк тә татар

[1] *Паксой Х.Б.* Чура батыр кисәтүе // Идел. 1994. № 9. Б. 9.

версиясендә дастан вакыйгалары тәмам булганнан соң китерелгән елъязма өлеше әһәмияткә ия. Дастан жанры шул рәвешчә тарихи-хронологик детальләргә баеган. Чичән башкара торган традицион героик дастаннар өчен мондый стиль хас түгел. Бу – безнең версиянең жанр буларак трансформацияләнүгә йөз тотканлыгын раслый торган момент. Тарихи җәһәттән мөһим роль уйнавына карамастан, дастан стилендә бу урынның китаби өстәлмә булуы ачык күренә.

«Чура батыр»ның тел-стилендә шигъри юллар проза белән аралашып, чиратлашып килгәннәр. Кагыйдә буларак, автор сөйләме чәчмә юлларда, ә персонажлар сөйләме шигырь белән бәян ителгән. Төрки эпоста мондый катнаш форманы угыз эпик циклы «Китаби Коркот»та да очратырга мөмкин.

Дастан текстында чагыштыру, эпитетлар кулланылган. Мисалга Нарәңнең Карагир атын тасвирлаган юллардан бер өзек китерергә мөмкин. Чура батырга багышланган барлык төрки дастаннарда да атны мактау игътибарга лаек.

> Саурысы(*сауры – ат сыртының арткы өлеше*) кара табадай,
> Яны (*текстта*: *җаны*) кара күпчектәй (*мендәрдәй*).
> Алдыннан килеп карасам,
> Алгы теше көрәктәй,
> Арт азуы тояктай.
> Җаным башы, җай тамгалы
> Карагир куркуга төште инде.

Гали бидән үч алырга киткәндә Чура әйткән сүзләрдән:

> Сөйре телем көрмәләп,
> Бәреңләй бәнем кадалып...
> Гали бидән атамның Карагирен
> Тәгъзим әйтеп теләем.

Шәрехтә бу болай: очлы телемне озынайтмый гына, сөяк тешемне яшереп, Гали бидән Карагирне яхшылап сорап карыйм әле. Гомумән, дастанда шигъри юллар бүгенге көн укучысына аңлау өчен шактый кыен. Шигъри өлештә читләтеп әйтүләр дә еш очрый. Мәсәлән, Миңсылуның тулгаклаган вакытта иренә әйткән җыруы, улы Чура белән горурланып сөйләгән сүзләре шундый сурәтләү чараларына бай.

Чура батырга багышланган дастаннарның татар версиясенә хас булган тагын бер сыйфатны әйтеп үтәргә кирәк. Чәчмә өлештә кайбер

вакыйгаларга киң тукталып, тәфсилләп сөйләнсә, кайберләре турында кыскача әйтеп китү белән чикләнелгән. Мәсәлән, Чураның бозау багу эпизоды нечкәләп, озаклап бәян кылына. Ә аның үсеп җитеп гаскәр туплавы, Идел буена барып чыгуы турында информация 2–3 җөмләдә җиткерелә. Бу башка төрки вариантлар, бигрәк тә казакъ дастаннары белән чагыштырганда, татар «Чура батыр»ының күбрәк чичәнлек традицияләренә түгел, китаби традицияләргә нигезләнүеннән килә. Артык әһәмияте булмаган кебек күренгән кайбер урыннарның текстта тәфсилле сурәтләнеп, шактый зур әһәмияткә ия кайбер вакыйгаларның исә җыйнак формада урын алуы – дастан стилендәге кытыршылыклар түгел. Бу – китаби дастан традицияләренең традицион төрки героик эпосына керткән җитди үзгәрешләре. Әсәр вакыйгаларының күз ачып йомганчы бер урыннан икенче урынга күчүе, артык тәкәллефләнеп, ваклыкларга кереп сурәтләүдән качу, стильнең көтелмәгән борылышларга дучар ителүе – болар әнә шул үзгәрешләр нәтиҗәсе. Шул ук вакытта татар халык «Чура батыр»ы традицион төрки героик эпос элементлары белән дә тыгыз керешкән. Мондый керешү дастанның төрки шигырь системасына нигезләнгән өлешләрдән бөтенләй үк азат булмавында, урыны-урыны белән чичән теле белән сөйли башлавында, сюжет-мотивларның, каһарман холкының эпос кагыйдәләренә ярашуында һ.б.да чагыла.

Дастандагы вакыйгаларны дүрт зур өлешкә бүләргә мөмкин: 1 – Нарәң батырның тормыш көнкүреше; 2 – Чура туу һәм аның балачагы; 3 – Чура батырның Казан белән бәйле эш-гамәлләре. 4 – Әсәргә йомгак рәвешендә китерелгән Казанның, Хаҗитарханның урыслар тарафыннан яулануы турындагы хәбәр. Дастан сюжетында батыр һәм ил язмышы бергә үрелә, Чура тормышындагы трагик вакыйгалар Казан ханлыгы фаҗигасенә барып тоташа. Шуңа күрә бу эпик әсәрнең темасын Чура батыр турында дип тә, Казан ханлыгы җимерелү хакында дип тә билгеләргә мөмкин.

Татар халык иҗатында И. Березин җыентыгында басылып чыкан дастаннан тыш та Чура образын яктырта торган берничә эпик әсәр бар.

Шуларның берсе – 1884 елда шулай ук Казанда басылып чыккан, 16 битлек аерым китапчыктан гыйбарәт текст[1]. Кем тарафынан төзелгән яисә күчерелгән булуы хакында мәгълүмат юк. Төрки

---

[1] Кыйссаи Чура батыр. Казан: Вечеслав тип., 1884. 16 б.

халыклардагы версияләреннән нугай халык дастанына якын, әмма турыдан-туры тәрҗемә түгел. Текст өчен күп кенә кыскартулар, гомумиләштерүләр хас. Тезмә катыш проза белән язылган. Сюжеты ягыннан башка төрки версияләр белән аваздаш, әмма хикәяләү калыбы белән мөстәкыйльлеккә дәгъва итә торган китаби дастан. Бирeдә дә Чура образы башка төрки дастаннар рухына туры килә. Бу вариант – үзебезнең һәм кардәш халыкларда популярлашкан версияләр нигезендә аерым авторлар (күп очракта аларның исеме нәмәгълүм) тарафыннан җыйнама характердагы яңа дастан төзеп бастыру үрнәге. Әлеге вариант халык теленнән язып алынган булудан ерак тора. Бу текст, И. Березин җыентыгындагысы кебек үк, фәкать язмача дөнья күргән булуы белән әһәмиятле.

Шундый ук рухтагы тагын бер дастан XX йөз башында татар вакытлы матбугатында Рәхим Баязит исемле кеше тарафыннан бастырыла[1]. «Чура батыр» дип аталган әлеге текст тулысынча прозада. Күчерүче-иҗатчы үзе әсәрне «кыргыз риваятеннән» дип күрсәтә. Әле XX йөз башында да «казакъ» этнонимы «кыргыз» яки «каракыргыз» исеме белән параллель кулланылган, шуңа күрә узган гасыр башында басылган бу текстның астөшермәсендәге «кыргыз» сүзе «казакъ» мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла. Чынлыкта да шактый күләмле әлеге әсәр казакъ версиясендәге бер вариантка[2] якын, әмма бу, югарыда карап үткән аноним вариант кебек үк, ияреп язу да, тәрҗемә дә түгел, ә бәлки нәкъ менә татар халык иҗатына хас мөстәкыйль дастан. Мондый үрнәктә хасил ителгән әсәрләр XIX йөз ахыры – XX йөз башында Казан татарлары язма иҗатына гомумән хас һәм боларның телдән таралган вариантлары бөтенләй булмау аларны турыдан-туры халкыбызның китаби эпик мирасына нисбәт итә. Тугандаш халыклар иҗатына мөрәҗәгать итеп, уртак сюжетка татарча текстлар төзеп бастыру бу чор өчен үтә характерлы күренеш булган.

Кайбер китаби дастаннарыбызның һәм конкрет бу очракның автор исеме белән мәгълүм булуына килгәндә, дастанның тиешле югарылыкка күтәрелеп җитүе өчен күп вакыт талантлы шагыйрьнең әдәби осталыгы таләп ителгән булу сер түгел. Низаминың «Ләйлә белән Мәҗнүн», Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» поэмасы кебек мәшһүр

[1] *Баязит.* Яңа кала. Чура батыр // Ак юл. № 16. Б. 282 – 286.

[2] Этнографические материалы, собранные и переведенные А.А. Диваевым. Шура батыр: киргизская былина // Сборник материалов Сыр-Дарьинской области. Т. IV. Ташкент: Тип. Бр. Каменские, 1895. С. 1–88.

поэмалар да – шушындый иҗат методы нәтиҗәсендә туган әсәрләр, әмма болары инде фольклор башлангыч белән чагыштырганда индивидуаль башлангыч күпкә өстенлек алган әдәби әсәрләр булып формалашканнар. Ә китаби дастаннарда исә авторлык мифик дәрәҗәдә генә булып, «Чура батыр» варианты мисалындагы кебек, әсәрдә фольклор кануннары хакимлек итә. Шуңа күрә аларны оригиналь әсәр дип кабул итү дә, әдәби әсәр критерийларын кулланып тикшерү дә обьектив була алмый. Бу – уртак сюжетлы дастанның үзенчәлекле яшәү рәвеше алган тагын бер татар варианты.

Татар әкиятләренә яисә риваятьләре кебек, «күптән-күптән», инде моннан ничә йөз еллар элек» дип башланып киткән дастан беренче юлларында Ак кала исемле шәһәрдә Айрактан һәм Тәмән дигән кабиләләрнең яшәгән булуы турында хәбәр итә. Алга таба дастан күчмә феодаль тормыш рәвешен тасвирлый, ике кабилә арасында барган ызгыш-талашлар турында сөйли. Айрактаннар бик күп булып, үзләрен бу җирнең хуҗасы итеп санныйлар, ә Тәмән кабиләсе бу тирәгә күптән түгел генә күчеп килгән һәм өйләре кырыктан артмаган. Соңгылары беренчеләренә баш иеп, үзләренең малларын алар белән бүлешеп яшәгәннәр. Бу өлеш күчерүче-иҗатчы тарафыннан шактый гына кыскартылганга охшый, зур вакыйгалар автор үзгәртүендә эпик гомумиләштереп бирелгән.

Шундый керештән соң, дастанга Нарык образы килеп керә. Башка төрки версияләр һәм шул исәптән И. Березин җыентыгындагы татар варианты Нарыкның тормыш юлын көтү көтү, ханга хезмәт итүдән башласалар, Р. Баязитта ул – «иге-чиге булмаган дәүләте аркасында бөтен тир-юньдә мәшһүр бер бай».

Төрки героик эпосның гадәти атрибуты – баһадирның көчле аты – дастанда иң күп телгә алынган, тенденциоз макталган образларның берсе. Атны сурәтләгәндә биредә әдәби чараларга мөрәҗәгать арткан. Бу – татар китаби дастанында эпик традицияләрнең индивидуаль иҗатка хас оригиналь тасвир белән керешүе. Мәсәлән, Нарык байның бихисап маллары арасында «кышкы салкын кара төндә йөз меңнәрчә йолдызлар арсында берсе генә ялтыраган кебек» бик шәп кара тулпары булган. Мондый образлы тасвир традицион эпоска хас түгел, биредә автор тәэсире, аның әдәби фикерләве сизелә. Әмма алга таба дастан кабат төрки эпостагы уртак сюжетка – «Чура батыр»ның барлык версиясендә телгә алынган Гали би белән конфликт картинасына кайтып төшә. Алай да биредә дә оригиналь таси-

вир урын алган: Нарык байныкы кебек матур һәм гайрәтле ат башка берәүдә дә юк, булса да тик хәзрәт Галинең Дөлдөле генә икән. Гали би үзе Айрактан кабиләсенең башлыгы дип бирелә.

Нарык бай – киң күңелле, намуслы, нәзәкатьле кеше, юмарт. Аның тирә-юньдә шөһрәте дә зур икән. Образ турындагы мондый мәгълүматлар, геройның нинди булуы укучыга аның эш-гамәлләре аша түгел, ә автор бәясе аша җиткерелә. Бу – шулай ук китаби тасвир. Автор төзәтмәләре кайбер китаби дастанда ачыктан-ачык күренә. Р. Баязит тексты – моның ачык мисалы.

Дан-шөһрәтле Нарыкның баласы булмый. Кайбер халыклар эпосында мондый сюжет киң таралган. Мәсәлән, «Алпамыш» дастанының үзбәк версиясен искә төшерик. Анда агалы-энеле Байбүре һәм Байсарының баласы булмый, шушы җитешсезлекләрен телгә алып, мәҗлестә аларга мыскыллау сүзләре әйтәләр. Шуннан соң Байбүре белән Байсары, бала теләп, Шаһимәрдән каберлеген зиярәт кылалар. Әлеге мотив казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак кебек төрки халыклар эпосы өчен бик популяр. Изге кешеләр каберлегенә барып бала теләнү казакъларда, мәсәлән, культ дәрәҗәсендә булган. Әйтик, бик күпләр изге Хорхут (Коркот) кабере төрле авырулардан йолып кала дип ышанаганнар. Бу кабер кешеләрнең хәтта табыну урынына әверелгән. Бу турыда В.М. Жирмунский Ә.Ә. Диваевның түбәндәге сүзләрен китерә: «Анда бик еш изге Хорхутка табынырга дип кыргыз ирләре һәм хатыннары (ягъни казакъ ирләре һәм хатыннары) килә һәм төрле чирләрдән, бәлаләрдән котылу, бигрәк тә «әрвак» дип аталган шайтан чиреннән арыну өмете белән кабер янында төне буе күз яше коеп, дога кылалар»[1]. (Часто туда приезжают киргизы и киргизки (т. е. казахи) на поклонение святому и проводят ночи в слезах и молитвах ва надежде получить облегчеение от тех или других недугов, в особенности от болезней, известных под общим названием «арвак», происхождением которой они обязаны нечистой силе»[2].) Изгеләр кабере дигән төшенчә татарларда да булса да, ислам мондый табынуларны тыйган, мөселман-татарларда әлеге ширек гамәл артык нык таралган дип әйтеп булмый. Ә менә казакъларда әлеге гореф-гадәт нык таралган булган. Моның сәбәпләре казакъ халкында мәҗүсилек тамырларының шактый нык булуыннан килә.

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 546.
[2] Шунда ук. Б. 546.

Шуңа охшаш эпизод тикшерелә торган вариантта да бар. Бу – татар иҗатчысының текст төзегәндә казакъ версиясенә мөрәҗәгатен дәлилли торган сыйфат. Биредә Нарык, балалары булуын сорап, изгеләр каберенә бара, корбаннар чала. Чура батырга багышланган дастаннарның казакъ версиясенең бер вариантында[1], Нарык белән аның хатыны Бабай-Тукты-Чәч каберлеген зиярәт иткәннән соң, ир белән хатынның теләкләре кабул була. «Алпамыш»ның югарыда телгә алынган вариантында да, Шаһимәрдән каберлегеннән бер өн чыгып, Байбүре белән Байсарыга теләкләре кабул булачагын әйтә. Р. Баязитта исә культка табынуның файдасызлыгы ассызыклана. Бу – казакъ дастанын файдаланып, яңа әсәр төзегән татар авторының төзәтмәсе. Изгеләр каберенә барып ялварганы өчен түгел, ә «Алланың рәхмәте белән» көннәрдән бер көнне Нарыкның хатыны дөньяга ир бала китерә.

Гадәттә, Чура батырга багышланган төрки, бигрәк тә казакъ дастаннары Нарыкның тормышын тасвирлауга киң урын бирәләр, генеалогик цикллаштыру традициясендә Нарыкның үзенә аерым дастан да багышлыйлар. Тикшерелә торган вариантта исә Нарык турында сүз чагыштырмача кыска, төп бәян каһарман Чура белән бәйле вакыйгалар хакында.

Балага исемне Чура дип кушалар. Күбрәк казакъ версиясенә нигезләнсә дә, Р. Баязит исемне татарча яңгыраштa биргән, юкса казакъ дастаннарында Чура «Шора» дип бирелгән. Төрки халыкларның героик эпосы каһарманы туганда ук, хәтта туганчы ук кем булачагын белгертә, гадәттән тыш тиз үсә, көче-куәте, зирәклеге белән дә аерылып тора. Чура батыр турындагы төрки дастаннарның һәркайсында бу закончалык тиешенчә саклаган. Р. Баязит варианты да бу кагыйдәләрне төгәл үти. Чура тиз үсә, дөньяга килүенә кырык көн дигәндә көлә һәм ата-анасын ят кешеләрдән аера башлый; бер яшьтә ул үзенең матурлыгы белән халыкны таң калдыра. Дүрт яшендә укый башлап, ун яшендә «шул замандагы бөтен укуларны тәмам итә». Каһарманның гадәттән тышлыгын тасвирлаганда автор уртак мотивны нигез итеп алган, әмма традицион булмаган үз сурәте дә сизелми калмаган. Чураның мәктәптә укуы турында хәбәр кырым татарлары версиясенең бер вариантыннан[2] кала башка дастаннарда очрамый.

---

[1] *Орлов А.С.* Казахский героический эпос. М.: Изд-во АН СССР, 1945. С. 96–99.

[2] Кырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгы / төзүчесе Джафар Бекиров. Ташкент: Укитувчи, 1991. Б 57–72.

Геройның тышкы кыяфәтен сурәтләгәндә эпик әсәр игътибарны аның физик сыйфатларына юнәлтә. Казакъларның Кобланды батыры, мәсәлән, киң ишектәй күкрәккә, калкандай нык иңнәргә, чүкечтәй авыр йодрыкларга ия[1]. Мондый гротесклы тасвир Р. Баязит вариантына да хас. Чура да, «унике яшенә җиткәндә, әкиятләрдә генә сөйләнә торган зур бәдәнле, киң күкрәкле гайрәтле бер батыр» булып әверелә. Ниһаять, кырык өйле тәмәннәр кабиләсендә чын баһадир үсеп җитеп, аларга карата дошман булган айрактаннарны тар-мар итә башлый. Бу – батырның беренче җиңүе. Сугышчан аты чаптар ат Чурага һәрвакыт ярдәмгә килә. Ә мондый тугры дуска ия булу өчен төрки эпос герое гадәттә шактый көч куя. Чура батырга багышланган төрки дастаннарында Гали би (Али би яисә бәй) каһарманның ата-анасын рәнҗетеп, малларын суеп, иң шәп атын алып киткән була, атасы Нарыкның яхшы аты Тасмалы Кер (Тасмагер)не Чура Гали би белән каты орышта кире кайтаруга ирешә. Бу эпизод Р. Баязит вариантында бар һәм ул әдәби тасвир буяулары катнашында шактый үзенчәлекле яктыртылган. Биредә Чура батыр атасыннан «судагы балык кебек, һавада очкан кош кебек, җилдән дә тизрәк йөри торган» яхшы ат сорап ала. Бу атның җитезлеген сурәтләгәндә Р. Баязит эпик кагыйдәләрне уздырып та җибәрә. Аның теленә-стиленә җете чагыштырулар хас: «Тулпарның чабуы шул кадәр шәп була ки, хәтта күлдәге су аның җиленнән дулкынланып кала, шунда күл читендә утырган кошлар аның аяк астыннан очып чыгарга өлгерми таптальп калалар». Беркемгә баш бирмәс тулпарны иярләүгә ирешеп, Чура Гали би улы Занминнәт белән көрәшергә китә. «Батыр балачак» сюжеты Занминәтне җиңеп, Айрактан кабиләсеннән булган башка яшьтәшләре белән көрәш эпизодында дәвам итә. Аларның барчасын кырап бетергәч, Чура батыр коралланган Гали би гаскәренә каршы көрәшә. Биредә дә Гали би – Чураның ата-анасына һәм бөтен ыру-кабиләгә көн күрсәтмәүче чит кабилә җитәкчесе. Бу – күчмә халыклар өчен характерлы күренеш, җир мәсьәләсендә кабиләара көрәш халык иҗатында да чагылыш тапкан. Казакъларда казан татарларына караганда озаграк сакланган әлеге мотивка Р. Баязит вариантында киң урын бирелгән.

Героик сугыш дошманның җиңелүе, гаскәренең Чура тарафыннан кырылып бетүе белән төгәлләнә. Шушы вакыйгадан соң Чура

[1] Кобланды батыр: Казахский героический эпос / сост. тома, авторы исслед. и комм. Н.В. Кидайш-Покровская и О.А. Нурмагамбетова. М.: Наука, 1975. С. 223.

батыр чит кабиләләр арасында да шөһрәт казана, батырларның батырына әверелә.

Гадәттәгечә, биредә дә Чураның язмышы Казан каласы белән бәйләнә: алдагы җиңүләрне эзләп, Чура Ак Каладан Казанга, «Казан ханына хезмәт итәргә дип», юлга чыгып китә. Әсәр шушы урында тәмам була.

Р. Баязит вариантына ясалган күзәтү әлеге текстны XX йөз башы татар укучысына яраклаштырылган китаби вариант дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Әсәр Р. Баязит тарафыннан билгеле дәрәҗәдә әдәби үзгәрешләргә дучар ителгән, шул ук вакытта ул төрки халыкларның кайберләре иҗатында чагылыш тапкан «Чура батыр» дастаны рухына тулысынча яраша.

Татар халкында язмача яшәгән «Чура батыр» дастаны бездә Чура образының башка жанрларда да эзлекле яктыртылышын һәм популярлашуын тәэмин иткән. Биредә, әлбәттә, Чура турындагы традицион төрки дастаннар тәэсирен дә исәпкә алырга кирәк. Уртак төрки эпик образ – Чура батырның татар халкында тагын берничә эпик әсәрдә чагылган булуы гаять кызыклы.

Мәсәлән, халык иҗаты әсәрләреннән бәетләр бу образны киң эпик планда сурәтлиләр. «Казан тарихы»дип аталган бәет тексты К. Насыйриның 1880 елда дөнья күргән календаренда[1], шулай ук Н.Ф. Катановның «Исторические песни Казанских татар» исемле китабында теркәлгән[2]. Бәеттән өзекләр шушы китаптан алыначак. Кыскартылган формада бу әсәр «Бәетләр» җыентыгында да урын алган[3], Чура турындагы өлеше исә анда юк.

Бу бәеттә татар халкының Болгар чорыннан алып Казан алыну вакыйгаларынача тарихы кыскача яктыртылган. Иң элек анда Аксак Тимернең Габдулла хан кулыннан Болгар шәһәрен алуы турында сөйләнә. Шуннан сүз Казан ханлыгына күчә. Биредә бәет сюжетының халык риваятьләрендә сөйләнгән вакыйгалар белән аваздаш булуын әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, нәкъ шушы сюжетка нигезләнгән, Казан салынуга багышланган тарихи риваять мәгълүм[4].

Бәет эчтәлегенә кайтсак, 262 ел буе Казанның мөселманнар кулында булып, аннары урыслар тарафыннан яулануын хәбәр иткәннең

[1] *Насыйри К.* Календарь 1881 елга. Казан, 1880.

[2] *Катанов Н.Ф.* Исторические песни Казанских татар. Казань, 1899. Б. 5–22.

[3] Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 2.

[4] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987. Б. 51–53.

соңында әсәр Казан алынганчы андагы тормыш-көнкүрешне тасвирлый. Тасвир ханнар идарә иткән чорга мөнәсәбәттә хронологик төстә бара.

Газыйлары (*дошман белән сугышучылары*) күп иде, муллалары
күп иде,
Галимнәре күп иде заман Ядкарь (*Казанның соңгы ханы*) ирдия
Бу җиһан мөнәүвар(*якты, нурлы*) иде, җәбер вә җәфа юк иде,
Мөрид (*шәкерт*) – мөршид(*туры юл күрсәтүче*) күп иде,
заманы хуп ирдия.
Галимнәре дус иде, мөршидләре хасс (*биредә*: җәмгыятьнең
югары катлавы) иде
Барча дошман пәст (түбән, хурлыклы) иде, заманы Ядкарь ирдия.

Ядкарь хан бәеттә күккә чөеп мактала. Казан шәһәре урыслар тарафыннан яуланган чорда Касыйм хан углы Ядкарьнең хан булып утыруы мәгълүм. Ул Казанда озак патшалык итмәгән (1552 елның марты – 1552 елның октябре), тарихта җитди эз калдырмаган. Тарихи чыганаклар күрсәтүенчә, Иван IV Казанны алган вакытта Ядкарь хан урысларга әсир төшә, үлгән елы билгесез, әмма 1553 елда ул әле исән була. Бәеттә Ядкарь ханның «тугыз йөз илле җидедә» дөньядан китүе әйтелә. (Милади белән 1550 елга туры килә.) Бу – тарихи вакыйгаларның халык иҗатында буталып бирелүе. Алга таба әсәр Ядкарьнең бик булдыклы бер кызы калуын хәбәр итә. Имеш, атасы аны тәхет варисы итеп калдырган. Әмма атасы үлеп киткәч, ни сәбәпледер, кыз үзен-үзе үтерә. Бәет жанрына игътибарны аянычлы вакыйгаларга күбрәк бирү хас, әлеге мотив әсәргә шушы максатлардан кертелгән булырга тиеш. Әмма Казан ханының кызы турындагы сюжетка мөрәҗәгать итү ягыннан татар бәете һәм Чура батыр турындагы дастаннарның (һәм, беренче чиратта, татар версиясенең) күпмедер дәрәҗәдә аваздаш булуын искәртеп үтәргә кирәк. Документаль яктан расланмаса да, хан кызы халык иҗатында популярлык тапкан, бер жанрдан икенчесенә күчеп яшәүче уртак образга әверелгән.

Шаһгали хан образы бәеттә Шагали дип бирелә:

Нәселендә бер ир бар ирде, исеме аның Шагали
Шифаларга яр ирде, тоткын булмыш ирдия.

Аңа бәеттә тискәре мөнәсәбәт сизелә:

Дөнья дигән сарайга җәбер-җафа салдыя.

Бәеттә Казанның урыслар тарафыннан яулануында Шагали гаепләнә. Монда тарихи шәхес Шаһгали ханга гади халыкның мөнәсәбәте ачык чагыла. Бәет авторы ханнарның хронологик тәртибен үзгәртеп биргән. Шаһгалинең Казан тәхетендә соңгы тапкыр 1551–1552 елларда, ә Ядкарьнең аннан соң утыруы мәгълүм. Чорның гомуми атмосферасы исә бәеттә дөрес чагылыш тапкан. Монда Казан – Мәскәү арасында XVI йөз урталарына таба даими булып торган орыш-көрәш картинасын күрергә мөмкин.

Урыслар хәбәрдар ые, мөселманнар бихәбәр ие,
Шәһри Казан җанында орыш-тукыш булдыя.
Ул орыштан булмады, Казан шәһәрен алмады
Ошбу Зөя тавында урыс кала салдыя.

Мөселманнарның Иван IV кылган бу гамәл белән килешмичә, ризасызлык белдереп, урыслар белән сугыша башлавы турында бәетнең алдагы 2 юлы хәбәр итә. Аннан соң текстка Чура батыр исеме килеп керә:

Бар иде бер мәрди (*биредә*: *батыр, кыю* мәгънәсендә)
Ходa, исеме аның Чура
Күп урысны кырырга Ходай мәдәд (*ярдәм, булышлык*) бирде йа.

Чура, татар халык иҗатының барлык жанрына хас булганча, ханлыкта атаклы пәһлеван, азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән шәхес итеп бирелә. Ул – Казан халкы өчен бердәнбер өмет, шуңа да авыр минутта халык аңа мөрәҗәгать итә:

Диделәр аңар, җә, Чура, булырсың мәрди Хода,
Алланың хөкеменә нидер чара? Ибан урысны син тура.

Бу урында бәет дастан жанры хасиятләренә бик нык якыная кебек. Аларның һәр икесендә дә Чура курку белмәс батыр дип тәкъдим ителә, аңа дан җырлана. Чура батыр образы бәеткә иң киеренке урында килеп керә, аның эш-гамәлләренә киң урын бирелә. Дастандагы кебек, бәеттә дә Чура батыр идеаллаштырылган, хәтта Алла бәндәсе итеп күрсәтелгән. Бәет герое дастаннар каһарманы рухына шактый якын тора, хәтта мәгълүм Чура образын тулыландыра да. Дини-героик дастаннардагы кебек, биредә Чура батырга дини миссия дә йөкләтелгән булуны күрәбез. Аны «Русия мөселманлыгы» дәверенә хас идеяләр белән сугарылганлыгы һәм чорына муафыйк милли-дини азатлык көрәшчесе буларак яңартылганлыгы күпмедер

дәрәҗәдә үзенчәлекле итә. Әмма дастан версиясенә дә Чураның дини максатлары чит түгел. Саф борынгы төрки эпоста каһарман илен-җирен дошман явыннан саклап яуга күтәрелсә, биредә ислам дине йогынтысы да үзен сиздерә. Татар халык версиясендә Чура Казанга «Күк чобарына атланып», «урыс гаскәрен куалап», «Күк чыбыгы кара канга батканчы» «Шагали ханның җорты өчен, Сарыканиның күңеле өчен» көрәшү белән бергә ислам җиңүе өчен көрәшергә дип тә бара. Дастанда Чураның Казан өчен көрәшкәндә җыр белән әйткән түбәндәге сүзләре жанрга ислам позициясе тәэсирен чагылдыра:

Ак мәсҗедләр салдырмый,
«Аллаһ»лап азан әйттерми.
Морадыма җиткерми.
Кайтмам да, кайтмам да![1]

Дастан версиясендә ислам идеяләре саф төрки дастан кануннары белән аралашкан булса, бәеттә бу фикер ачыктан-ачык уздырылган. Бу – дастан версиясенең «Казан тарихы» бәетенә караганда иртәрәк оешкан булуы белән аңлатыла.

Тарихи чыганаклар күрсәтүенчә, Казан алынганда Чура Нарыков үтерелгән була. Бәетне иҗат итүче гади халык вәкиле тарихи фактны исәпкә алып бетермәгән. Чура урыс патшасына килеп, аның чатырына үтеп керә, патшаның башын чабып өзә. Бу вакытта дошман патшасы ашап утырган була, өзелгән башы ашына килеп төшә. Алдарак урысларның күп, көчләре җитәрлек булуы әйтелгән иде. Патшаның үлемен артык самимиләштерүгә аклангандай, я булмаса, урыс патшасын каралтыбрак күрсәтер өченме, бәеттә түбәндәге юллар китерелә:

Акылы җуктыр башында, күп халкы бар кашында
Ник боермады бер башына: ыстрог торың каршымда
*(ягъни строго тор, яхшы сакла мәгънәсендә)*.

А.С. Орлов «Казахский героический эпос» дигән хезмәтендә татар һәм казакъ халкында сакланган 12 строфалы җыруны телгә алып үткән иде[2]. Бу әсәрдә алла рәхмәте белән күп урыс гаскәрен кырып Казанга кергән Чура батыр турында сөйләнә. Халык аннан урыс

[1] Өзек түбәндәге монографиянең кушымта өлешеннән алып китерелә: *Ибраһимова Л.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 158.

[2] *Орлов А.С.* Казахский героический эпос. М.: Изд-во АН СССР, 1945. С. 112.

Иванны үтерүен сорый. Чура, Иван кичке ашын ашап утырган җиргә килеп, аның башын чабып өзә. Хезмәтчеләре Иван патшаның өзелгән башын аш тәлинкәсендә табалар. Бу урында әлеге җыруның татар халык бәетендә сөйләнгән сюжет белән аваздашлыгын искәртеп үтәргә кирәк.

Бәет – татар халык иҗатының трагик жанры. Иван IVнең Чура тарафыннан үтерелүе бу очракта трагедия булып санала алмый. Ә инде Чура батырның үлеме турында «Казан тарихы» берни дә сөйләми.

Чураның батырлыгын, урыс патшасының үлемен тасвир иткәннән соң бәет чын мәгънәсендә фаҗигале вакыйгага күчә – Казанны урыс явы басып алу турында сөйли. Биредә иң аянычлы вакыйга – Казанның алынуы, бәет нигездә шул хакта сөйли.

Чура батыр образының дастан һәм бәет жанрындагы уртаклыгы ил белән кемнәр генә идарә итмәсен, халык арасында Чура кебек пәһлеваннар булган, дигән идеядә; чит ил баскынчыларына каршы чыккан шәхесләрнең халык тарафыннан хуплануында; вакыйгалар уртаклыгында (Казан алыну) һәм татар китаби эпосына ислам идеясенең эзлекле рәвештә үтеп керә баруында чагылыш тапкан дип күрсәтергә мөмкин.

Халык иҗатына күбрәк күз салган саен, Чура образының прототибы шул бер үк шәхес булуына да ышаныч арта. Казан ханлыгында кылган эш-гамәлләре һәм, бәлки, тарихи документларда билгеләнеп калмаган ниндидер гаҗәеп батырлыгы аны халык арасында популярлаштырган, дастан, бәет, риваятьләрдә идеаллаштыру дәрәҗәсенә күтәргән. Гомумән, бу процессны тарих белән бәйләүдән азмы-күпме читкә китеп, халыкның милли-азатлык каһарманын үз иҗатында чагылдырырга омтылышы, Чура батырны исә шушындый каһарманның җыйнама образы дип карау да хата булмас.

Чура турында татарларда янә бер язма игътибарга лаек. Бу образга халыкның әле XX гасыр башында да мөрәҗәгать иткән булуын дәлилли торган бу әсәр – Казанның гадәттән тыш батыры Чураның газиз шәһәрен дошманнардан азат итеп көрәшүе турындагы шигъри дастан. Текст үзе «Чура батыр» исеме белән XX гасыр башында «Аң» журналында Кыям Юлдаш исемле кеше тарафыннан (аның мөгаллим булуы, 1890–1955 елларда яшәве мәгълүм) бастырылган[1]. Бик нык

[1] *Юлдаш К.* Чура батыр // Аң. 1916. 5 сан. Б. 85–86.

әдәбиләштерелгән вариант, әмма халык иҗатыннан киң файдаланып язылган. Бу әсәрдәге

> Шул шәһәрдә бар пәһлеваннардан өстен зур батыр –
> Хәйләле, эшлекле, гайрәтле икән Чура батыр, –

дигән юллар татар һәм башка төрки халыкларда мәшһүр Чура образыннан торгызылган. Казан ханлыгында аның пәһлеванлык намын алуы, шәһәргә һөҗүм итүче дошманнар белән көрәштә батырлыгы, кыюлыгы, хәйләкәрлеге аркасында җиңеп чыгуы, бөтен Казан халкын куандыруы – шигырьдә сөйләнгән вакыйгалар. Дошманнар ролендә биредә кешеләр түгел, ә куркыныч аждаһа-еланнар. Алар, дәүләттәге иң матур һәм бай урыннарны биләп, Казансу елгасының суын теләгәндә эчеп бетереп, теләгәндә шул ук суны кире чыгарып, ханлык халкына куркыныч салып яшәп яталар. Шушы хәшәрәтләр белән сугышып, зәһәр бер юханы җиңеп, Чура пәһлеван исемен ала. Казан шәһәре салынуга багышланган мәгълүм риваятьтәгечә, хан еланнар мыжгып торган урынга каланы күчерергә ният кылгач, «хәйләле, эшлекле, гайрәтле» Чура батыр бу эшне – еланнардан чистарту эшен оештыра, үзе дә шул сугышта катнаша. Көрәш каты була. Чура батыр шушы көрәштә һәлакәтен таба.

Бу – фольклорның берничә жанр әсәренә, аерым алганда шәһәр урынын билгеләү һәм Чура батырга багышланган тарихи риваятьләргә, шулай ук мәгълүм дастан вариантларына таянып иҗат ителгән тезмә текст. Чураның еланнар белән көрәшү һәм һәлак булу вакыйгасы башка мәгълүм вакыйгаларга ишарә итә төсле. Тулаем алганда ул – Чура батырга багышланган төрки дастаннар рухына тәңгәл әсәр.

Галимә Ф. Әхмәтова болай дип язган иде: «Чура батырның юлда кара урманнар, биек таулар аша үтеп, арыслан, аждаһалар үтерүе кыргыз (казакъ) версиясендә яхшы сакланган. Безнең хикәяттән ул эпизодлар төшеп калган. Әмма Кыям Юлдаш дигән шагыйрьнең «Чура батыр» исемле әдәбиләштерелгән әкиятендә бу геройның нәкъ шул еланнар белән баһадирларча көрәшүе тасвирланган»[1]. Кыям Юлдаш әкиятендә дастанның казакъ версиясе белән аваздашлык юк. Автор күбрәк Казан ханлыгына багышланган тарихи риваятьләргә таяна. Биредә су юлында бер килennнең билен чыгаруы, шуның өчен Казанны яңа урынга күчерү, ул урынны балык эләккән җирдә билгеләү, Яңа Казан территориясендә еланнар бихисап булу

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан, 1984. Б. 347.

турында һ.б. риваятьләр[1] бергә берләштерелеп, шигъри формада бирелгән, мәшһүр Чура образы да аларга кушылып, әсәр яңа яңгыраш алган. Чура батыр исә биредә дә үзәк каһарман булып калган.

Китаби «Чура батыр» тәэсиреннән булса кирәк, бездә бу образ телдән сөйләнгән жанрларда да сакланган. Мәсәлән, татар халкында Чура батырга багышланган риваять[2] шулай ук мәгълүм дастаннар рухына туры килә. Биредә дә Казан ханлыгы фаҗигасенә бәйле вакыйгалар тасвирлана һәм әсәр халык каһарманы буларак Чура образын идеаллаштыра.

Бу риваять «Карауҗа» дип атала[3]. Карауҗа – Казан арты территориясенә керә торган авыл. Әсәрнең эчтәлеге бик каршылыклы. Монда тарихи вакыйгалар да, этимологик мәгълүматлар да, халык әкиятләреннән сюжет та бар. Казан тирәсендәге Каравай авылында ил тотып яшәгән Кара бинең улы Карауҗа, Рече Карауҗа урынына килеп, авыл корып утыра. Су сорап кергән картка су бирмәгәч, карт авылны каргап чыгып китә. Картның сүзләреннән шомга калган Карауҗа улларына ук аттыра, уклары кая төшсә, уллары шунда нигез кора. Чура би – Карауҗаның икенче улы, аның угы хәзерге Зур Карауҗа авылы тирәсендәге Чура би чокыры тирәсенә төшә, алар атасы белән шунда төпләнәләр. Шуннан соң риваять Казан алыну вакыйгаларын бәян итә башлый. Иван Грозныйга каршы сугышта Карауҗа Казан ханына хыянәт итә, бу эшне сизеп алган хан Карауҗаның авызына эретелгән алтын тутырып җәзалый. Ә Карауҗаның улы Чура бинең Чура батыр исемле улы исә «Иван Грозный Казанны алган вакытларда» иле өчен көрәшеп һәлак була. Бу риваять нигездә Карауҗа авылының килеп чыгышын һәм тарихын бәян итүгә корылган. Әсәрнең «Чура батыр» вакыйгалары белән кисешүе исә дастан тексты белән казан татарларының шактый нык таныш булганлыгыннан килә. Тарихи-этимологик риваятьтә мәгълүм дастаннар рухы чагылыш табу китаби дастан белән традицион фольклор арасындагы ныклы бәйләнеш турында сөйли.

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 51–53.

[2] Шунда ук. Б. 51–53; Энҗе чәчтем – энҗе җыям. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Мәгариф, 2001. Б. 78.

[3] Энҗе чәчтем – энҗе җыям. Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 2001. Б. 78; Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987. Б. 50.

Ә 1975 елда галимә Ф. Әхмәтова Казан шәһәрендә Каюм Ибраһимов исемле информанттан (1903 елгы) «Чура батыр» хикәятенең телдән сөйләнгән вариантын язып алган һәм текст , «дастанның риваять варианты» дип, «Татар эпосы. Дастаннар» җыентыгына кертелгән[1]. Бу текстның сюжеты И. Березин җыентыгындагы вариант белән тәңгәл килә диярлек, әсәрне кыскача сөйләп бирү характерында, әмма информант вакыйгаларны кайчандыр кемнәндер ишеткән хәлләре хакында сөйләү формасында бәян итә: «Чура батыр ул Казанны төрле яулардан саклаган кеше дип сөйлиләр иде. Анасы Миңсылу атлы булган. Атасы Нарык икән. Чура Нарыков дип тә йөрткәннәр...» һ.б. Чыгышы белән Кырымнан булган Нарык Казан кызы Миңсылуга өйләнә, хатынына гашыйк ханны үтереп, үз иленә кайтып китә. Юлда Миңсылу бала таба, исемен Чура дип кушалар. Чура үскәч, кире Казанга әйләнеп кайта, информант исемнәрен хәтерләмәгән «батыр юлдашлары» белән Казанны күп яулардан саклый. Дошманнар белән көрәштә аягы яраланып, аты өстеннән Иделгә егылып төшеп үлә.

Әлеге текст үзенең характеры белән дастан булудан бигрәк риваять жанрына туры килә. Ул тоташ чәчмә тексттан гыйбарәт, күләме артык зур түгел, дастанның төп вакыйгаларын искә төшереп, аның кыскача эчтәлеген сөйләп бирүгә нигезләнгән.

Биредә Миңсылуның ханга сөйләп күрсәткән «бүре авызыннан калган ризыкны арысланның ашамавы» турындагы һәр милли версиядә диярлек очрый торган хикәяте, Чураның үлеме «я улыннан, я атыннан» булачагын алдан күрү, Чура батырның дошман кызына өйләнүен махсус оештыру мотивларының һәм нугай версиясендә генә тасвирланган, Чура үлгәннән соң анасы Миңсылуның улын эзләп Казанга килү эпизоды һ.б. моментлар урын алу әһәмиятле. Бәяны соңында информант: «Бу хәл чын булган, мин аны бер китаптан укыган идем», – ди. Информант телдән сөйләгән вариантның төп чыганагы – язма мәгълүматлар, ә бу очракта – дастанның басма варианты. Димәк, нигездә информант әүвәлге һәм тулы китаби вариантка таянган.

1991 елда исә язучы Ф. Латыйфи «Чура батыр. Татар халык дастаны» дигән исемдә гаҗәеп кызыклы, күп өлеше шигъри тексттан гыйбарәт әсәрне китап итеп бастырып чыгарган иде[2]. Төзүче үзе бу

[1] Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан, 2004. Б. 397 – 398.

[2] Чура батыр. Татар халык дастаны / хәзерге әдәби телгә күчерүче Ф. Латыйфи. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 64 б.

дастанны Румыниядә яшәүче Добруджа татарлары бастырган китаптан алуы хакында әйтеп киткән. Дастан нугай версиясендәге күләмле генә бер вариант белән шактый охшаш. Әмма чынлыкта Ф. Латыйфи, дастанның берничә халыктагы версия-вариантларын файдаланып, үзебезнең телдә яңа бер вариант барлыкка китергән. Бу иҗат күпмедер дәрәҗәдә Ә. Кормаши, Баһави, М. Юмачыков, Р. Баязит, К. Юлдаш һ.б.ның XIX йөз ахыры – XX йөз башындагы дастани иҗатына охшый төшә һәм хәтта татар китаби дастанының XX гасыр азагында дәвам иткән иң яшь үрнәге дип бәяләнергә дә хаклыдыр.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкында популяр Чура батыр образы дастан, бәет, риваятьләр аша эпик биография югарылыгына күтәрелә. Төрки халыкларның героик эпосы үрнәгендә, фольклор әсәрләре аны чын каһарманга әверелдерә. Бу образ һәм аның белән бәйле эпик мирасыбыз – тарихыбызның кыйммәтле кыйпылчыгы, үткәннәребезнең фольклордагы онытылмас кайтавазы.

## § 3. «Күр углы» дастанының татар версиясе

Китаби дастан буларак «Күр углы» исеме белән мәгълүм эпик әсәр игътибарны аеруча җәлеп итә.

Бу исемдәге дастаннар Себер, Кавказ, Урта Азия һәм Казахстанның, Якын Көнчыгыш һәм хәтта өлешчә Европаның төрки телле һәм башка халыкларында гаять популяр булган. «Күр углы» сюжетлы дастаннар төрекмән, үзбәк, таҗик, казакъ, каракалпак, азәрбайҗан, төрек, аҗар, абхаз, кумык, көрд, әрмән, грузин, гарәп, һ.б. халыкларда фольклор әсәре буларак билгеле. Кайбер сюжет уртаклыклары булса да, болар һәр халыкта аерым бер үзенчәлеккә ия. «Кёр углы», «Кёроглы», «Кер углы» «Күр углы», «Гёр углы», «Гёроглы», «Гороглы», «Гүр углы», «Гургули», «Гургули-шо» һ.б. исемнәр белән мәгълүм, дөресрәге, аталышы җәһәтеннән нигездә тел үзенчәлекләренә бәйле төрле фонетик яңгырашка ия дастаннарның шигърияте, стиле, күләме дә төрле. Әмма аларны берләштерә торган, боларның күпчелеге өчен характерлы уртак күренешләр бар. Һәр халыкта бу дастаннар – авторсыз аноним ядкарьләр, халык иҗатының героик эпосы үрнәкләре.

Кайбер халыкларда «Күр углы»ның популярлыгы шул кадәр зур булган, бу циклдан сюжетларның күплеге хәтта башка сюжетларны халык иҗатыннан кысрыклап та чыгарган. Әйтик, В.М. Жирмунский төрекмән-угызларның соңгырак чор дастани иҗатында атаклы

«Алпамыш», яисә «Коркыт» циклларының очрамавын шушы сәбәп белән, ягъни XVI I– XVIII йөзләрдән биредә милли каһарман турындагы «Күр углы» эпосының гаять киң таралганлыгы белән аңлата[1].

«Күр углы» дастанына безнең халык та битараф калмаган. Безгә бу әсәр чагыштырмача соң – XIX йөз ахырларында гына һәм һичшиксез язма истәлекләр аша килеп кергән. Башка халыкта беренчел чыганагы ашуг-озаннар иҗатына барып тоташкан, ягъни иң әүвәл авыз-тел әсәре булган очракта да татарлар бу әсәр белән соңрак язуга теркәлгән текстлар аша танышкан. Ашуг авызыннан язып алынган кайбер төрки версияләрнең XVIII йөз уртасында ук инде басылып та чыккан булуы турында мәгълүматлар бар. Дастан жанрында Идел буе татарлары күбрәк китаби төргә өстенлек биргән, шуңа күрә шушы сюжетка үз җирлегебездә яңа нөсхәләр барлыкка килүгә этәргечне ашуг-озаннар иҗаты түгел, ә «Күр углы»ның язма текстлары биргән булу ихтималы зуррак. Чыганагы язуга теркәлгән эпоска барып тоташуы әлеге әсәрнең бездә китаби булып формалашуын турыдан-туры тәэмин иткән. «Күр углы» версиясенең бездә чичән авызыннан түгел, ә язмача таралган булуы популяр сюжетлы бу әсәрне китаби дастаннарның югарыда билгеләнгән беренче тибына нисбәттә карауны таләп итә. Татар халкындагы «Күр углы» – бездә сөйләмә вариантлары булмаган, язма нөсхәләрдә генә сакланган, фәкать күчерелеп һәм укылып йөргән дастаннардан.

«Күр углы» сюжетлы дастан версияләрен шартлы рәвештә көнбатыш һәм көнчыгыш версияләр дигән ике төркемгә бүлеп карау бар. Көнбатыш версияләр дигәндә аҗар, төрек, азәрбайҗан, ә көнбатыш версияләр дигәндә төрекмән, үзбәк, казакъ, таҗик эпик истәлекләре күздә тотыла. Көнбатыш версияләр көнчыгышныкыннан чынбарлык вакыйгаларын ышанычлырак яктыртулары белән күпмедер дәрәҗәдә аерылып торалар[2].

Дастанның күп кенә көнчыгыш һәм көнбатыш версияләренең атаклы бахшылар авызыннан аларның музыкаль башкаруында язып алынган булуы мәгълүм. Күпчелек версияләрнең иң зур өлеше тезмә тексттан гыйбарәт булу да игътибарга лаек. Әйтик, төрекмән

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 167.

[2] Азербайджанцы: историко-этнографический очерк / URL: http://www.myazerbaijan.org/index.php?p=history/27 (дата обращения – 6 июля 2012 г.); *Короглы Х.Г.* Героический эпос «Кёроглы» // *Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. С. 169–248.

версиясе вариантлары импровизаторлардан – Мустак бахшы, Пәлван бахшы, Махтумкули бахшы, Бабаджан Сапаров, Нәдир бахшы, Овлиякули Гоч оглы һ.б.дан – язып алынган, алар әлеге күләмле текстны өлешләп-өлешләп көйләп әйтә торган булганнар[1]. Азәрбайҗан ашугларының исә «Кёроглы»ны җыру белән әйтүне дастан вакыйгаларына чәчмә текстлы тарихи аңлатмалар бирү белән аралаштырып шулай ук телдән әйтүләре мәгълүм[2]. Үзбәкләрдә «Күр углы» дастанын әйтүче Абдулла-шаир, Фазил Юлдашев, Эргаш Джуманбулбул-оглы, Букок Пирмат, Мухаммедкул Джамрат-оглы (Пулкан-шаир) һ.б. импровизаторлар теркәлгән[3]. Тыңлаучының ихтыярына бәйле рәвештә теләсә кайсы мәҗлес (бүлек, хикәят, цикл) ашуг, бахшы, шаирләр тарафыннан әнә шулай телдән башкарыла торган булган.

Безнең халыкта таралган вариантлар арасында да тел-стиле ягыннан сөйләмгә нигезләнгәнгә тартымы бар (себер татарлары варианты турында сүз бара), әмма аның конкрет кем авызыннан язып алынган булуы күрсәтелмәгән, әлеге чәчмә текст бер генә нөсхәдә сакланган һәм татар халкында бу дастан сөйләмә формада таралыш та тапмаган. Бу – татар халкында дастани эпос жанрына хас китабилашу тенденциясе тәэсире. Бу мәсьәләгә алда тулырак тукталырбыз.

Төрле халыкта популярлашкан «Күр углы»ның сюжет вакыйгалары нигезендә кайчандыр булган реаль хәлләр ята, төп каһарман образы тарихи шәхескә барып тоташа. «Күр углы» – төрле халыкта фәнни яктан шактый җентекле өйрәнелгән, текстлары безнең көннәрдә кабат басып чыгарылган әсәрләрдән һәм эпос белгечләре әлеге сюжетны Азәрбайҗан һәм Кече Азия территориясендә барлыкка килгән дип санылар. Дастанның азәрбайҗан, төрек һ.б. версияләрендәге төп вакыйгаларның XVI йөз ахыры – XVII йөз башында географиянең шушы өлешендәге җәләлидләр хәрәкәте белән

---

[1] *Гёр-оглы.* Туркменский героический эпос. М.: Гл. ред. восточной лит-ры, 1983. С. 7–32.

[2] *Жирмунский В.М., Зарифов Х.Т.* Узбекский народный героический эпос. М.: Гос. изд-во худ. литер., 1947. С. 166; Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 643.

[3] Народные сказители // *Жирмунский В.М., Зарифов Х.Т.* Узбекский народный героический эпос. М.: Гос. изд-во худ. литер., 1947. С. 22–58.

тәңгәллеген раслый торган шактый зур материал да тупланган[1]. Эпостагы кебек үк, җәләлидләр зур юлларда сәүдә кәрваннарына, үз дошманнарының шәһәрләренә һөҗүм иткәннәр, талау белән шөгыльләнгәннәр. Х. Короглы җәләлидләрнең төп массасы төрекмәннәр булган дигән фикердә тора, аларның башлыгын – шагыйрьләр нәселеннән булган атаклы үч алучы Хәсәнбәкне телгә ала, фикерен Габбас I Сефевидның Искандербек Туркман исемле тарихчысы китергән фактларга таянып нигезли[2].

Чыннан да, тарихта тасвирланган җәләлидләр чуалышы күп яклап тикшерелә торган дастан вакыйгалары белән аваздаш. Хәсәнбәк исеменең дастанның күпчелек версияләрендә шактый әһәмиятле фигура, ә Күр углының исә атаклы башкисәр булуы белән бергә шагыйрь-ашуг буларак тасвирлануы да бик кызыклы. Әмма бу әле дастан версияләре шушы хәрәкәтләрнең турыдан-туры чагылышы дигән сүз түгел. Шулай булса да, эпосның үзәге Күр углы исемле мәшһүр зат һәм аның көрәштәшләре буыны дәверендә я бераз гына соңрак формалашкан булу фактын да инкарь итеп булмый. Фольклор процессына хас булганча, алга таба каһарман үзе дә, тарихи вакыйгалар да әкренләп эпиклашканнар. Мәдәниятләре һәм этногенезлары төрле булган күп халыклар иҗатында бу эпос урын алганчы тагын берничә дистә, ә бәлки тагын да күбрәк еллар узган булырга мөмкин. Әмма дастан вакыйгаларына кагылышлы фактларның булган кадәре бу әсәр XVII–XVIII йөздән дә иртәрәк барлыкка килә алмаган, дигән нәтиҗә ясар өчен җирлек тудыра. Димәк, «Күр углы»ның татар халкына килеп керүе тагын да соңгырак чорга караганлыгы да раслана.

Эпосның төрекмән версиясендә («Гёроглы») вакыйгалар Азәрбайҗанның Иран белән чиктәш көньяк районнарында, каһарманның Чамлыбел исемле ныгытма-кальгасында бара. Дастандагы бу урын – теке дип аталган төрекмән кабиләсе яши торган Балкан иле. Төп каһарман да – төрекмәннәрнең теке кабиләсеннән. Күр углына багышланган дастаннарның күпчелегендә бу хакта искәртелгән. Күр углы Хункарга, ягъни госманлы төрекләре ягына барганда да, кире әйләнеп кайтканда да Аракс дигән елга аша үтә. Моннан тыш эпоста

[1] *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 134–146.

[2] Шунда ук. Б. 144.

каһарманның Ширвән-шемаха, Эрзрум һәм Грузия аша кичеп хәрәкәт итүе мәгълүм. Дастан вакыйгалары төрекмәннәрнең Урта Азиядән көнбатышка таба күченү юлларында бара. Дастан версияләрендә дә төп каһарманның башта ата-бабалары ватаны Төркестанда гомер итеп (монда игътибар дастан версияләрендә еш телгә алынган Болы провинциясенә юнәлә, бу – Төркиянең төрекмәннәр тупланып яшәгән урыны), биредә гаскәр җыеп, көч туплап, соңрак Азәрбайҗанның көньяк өлешенә күченеп яшәгәнлеге хакында сөйләнә. Болар барысы да эпосның башлап Кавказдагы һәм Кече Азиядәге төрекмән кабиләләрендә туган булу ихтималының зурлыгы турында сөйли.

Димәк, дастанның төп каһарманы прототибы – теке кабиләсеннән чыккан төрекмән булып, XI гасырларда ук, ә бәлки тагын да иртәрәктер, Сәлҗүкләр мәмләкәте составында Азәрбайҗанның таулы көтүлек далаларында яшәгән булырга мөмкин. XI–XII гасырларда Азәрбайҗан территориясендә яшәгән төрекмән-угызларның соңрак азәрбайҗан этногенезы формалашуда җитди роль уйнаган булу факты тарихтан моңа аңлатма була ала. Әмма соңрак бу образ җәләлидләр хәрәкәте вакыйгалары, шул чор реаль шәхесләренең игътибарга лаек гамәлләре нәтиҗәсендә тулылана төшкән, әсәр XVI йөзнең икенче яртысыннан соң формалаша башлап, тагын да соңгырак чорда героик эпос булып оешкан. Эпик үсә бару процессында каһарман образы үзенең тарихи прототибыннан бик нык ерагайган, әмма шул ук вакытта эпос тукымасында тарихилык белән бергә борынгылык барыбер сакланып калган. Дастан версияләре шушы серлелек синтезы белән кызыклы да.

Әлбәттә, төрле милли версияләр вакыйгаларны һәм төп каһарманны үз җирлегенә тартудан азат түгел. Әйтик, азәрбайҗан версиясендә теке-төрекмәннәр шактый үзенчәлекле рәвештә – Айваз һәм Рәйхан гарәпкә бәйле генә телгә алыналар, ә төрек версиясендә төрекмәннәр турында гомумән бер сүз дә юк. Дастанның тәүге версиясе йогынтысында туган соңгырак версияләрендәге мондый үзгәреш-үзгәртүләр үз версияләрен булдырганда килеп кергән җирле билгеләр булырга бик мөмкин. Моннан тыш дастанның төрле төрки версияләрендә топонимика бик нык бутап та бирелә. Әйтик, биредә бахшы үзенә таныш түгел шәһәр исемнәрен үзе теләгәнчә үзгәртә. Мәсәлән, Х.Короглы дастанның төрекмән версиясендә ике исем белән атала торган бер үк шәһәр (рәсми һәм халыктагы исемнәре төрле) турында ике шәһәр кебек сүз алып баруга игътибар итә. «Среди го-

родов, – ди ул, – находящихся во владениях Хункара, упоминаются Испыхан, Нусбыджахан. Испыхан – город в центральном Иране; он был столицей Сефевидов. Нусбыджахан – определение этого города («Полмира»), данное ему народом»[1]. Шулай ук эпоста төрек династиясен аңлата торган «госман» («осман») термины географик төшенчә буларак ныгыган.

Әмма дастанның төрки версияләрендәге күпчелек топонимнарның реаль тарихи булуларын да инкарь итеп булмый. Чорына һәм урынына мөнәсәбәттә тарихта булып узган хәлләр, сәяси һәм дин дошманлыгы шулай ук дастанда чагылыш тапмый калмаган. Хулагуидлар (Азәрбайҗан территориясендә үзләренең төп базасын тоткан, башкаласы Теәбриз шәһәре булган монгол империясе) идарәсеннән соң Дәрбәндтән Багдадкача территорияләрдә төрекмән-угызларның Ак Коюнлу һәм Кара Коюнлу исемле дәүләтләре барлыкка килә. Алар үзара гел көрәшеп-сугышып яшиләр. XV гасырда бу көрәштә Ак Коюнлу җиңгәч, җиңгән дәүләт Госманлы империясе белән сугыша башлый. Тарихта госманлы төрекләре белән үзара сугышлар алып барып яшәгән әлеге кабилә Кызылбашлар дигән исем белән мәгълүм[2]. Болар – исламның шиизм юнәлешендәге азәрбайҗаннар һәм көнчыгыш иранлылар (икенче төрле әйткәндә, нишабурлар – Хорасандагы (Иран) шул исемдәге шәһәр исеменнән) булганнар. Кызылбашлар белән Госманлы төрекләренең тыныша алмаулары дүрт гасырга сузылганлыгы мәгълүм. Башта алар Кара диңгезгә чыгу, Көнчыгыш Анатолия җирләре өчен сугышсалар, XVI гасырдан Шаһ Исмаил Сәфәви үткәргән шигыйлар инкыйлабыннан соң сугыш дини характер ала – шигыйлык һәм сөннилек байрагы астында алып барыла. Бик озак вакытны иңләгән бу сугыш тарихка кызылбаш-госманлылар сугышы яисә фарсы-госманлы сугышы дигән исем белән кереп калган.

Урта Азия төрекмәннәре исламның шигый юнәлешен тоткан кызылбашларны үзләренең гомерлек дошманнары дип санаганнар.

---

[1] Короглы Х.Г. Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 138.

[2] Азербайджан – Википидея. Материалы из Википедии – свободной энциклопедии. / URL: http://ru.wikipedia.org/wiki/%D0%90%D0%B7%D0%B5%D1%80%D0%B1%D0%B0%D0%B9%D0%B4%D0%B6%D0%B0%D0%BD.(Дата обращения – 5.07.2012г.)

Дастан версияләре шушы вакыйгаларга да һәр яклап бик нык бәйле. Биредә баш каһарманның төп дошманнары – госманлылар һәм кызылбашлар. Дастанның төрекмән версиясендә төрек солтаны Хункар турында сөйләүче ашуг төрекләр белән кызылбашларны «берләштергән». Моны бахшының, тарихи нечкәлекләргә кереп тормый гына, төрекмәннәрнең дошманнары итеп гомумиләштерелгән җыйнама образ тәкъдим итүе дип аңларга кирәк.

Эпоста XVII–XVIII гасырларда төрекмәннәр яу чапкан күрше Иран шәһәрләре Нишапур, Сабзивар, Дамган, Тәһран еш телгә алына. Хункар белән сугышка әзерләнгәндә Күр углы, шура җыеп, төрекмән кабиләләрен дошманга каршы күтәрелергә өнди. Х. Короглы нәкъ шушы эпизодның XVIII йөз төрекмән язучылары Махтумкули, иҗаты XIX йөзгә караган Молланепес әсәрләрендә дә очравын искәрткән иде[1]. Дастанны халыкка җиткерүче импровизаторлар ерак тарихтагы хәлләрне тасвирлау белән бергә сюжетка үз чоры вакыйгаларын һәм шәһәрләрен дә бик киң кертеп җибәргән. Дастанның төрекмән версиясендә, азәрбайҗан версиясенең ахырында һ.б. версияләрдә эпос өчен традицион ук, кылыч кебек кораллардан тыш утлы корал да телгә алына. Хункар гаскәренә каршы көрәштә Күр углы һәм аның яклы үч алучы халык вәкилләре шундый корал – туп, тупенг – кулланып сугышалар. Утлы коралның Урта Азиядә XIV йөз ахырында гына пәйда булып, эпоска аның XV–XVII йөзләрдә генә килеп кергәнлеге – ачыкланган мәсьәлә[2]. Димәк, дастанда утлы корал белән эш итүне иркен тасвирлау шулай ук бахшыларның үз чоры казанышларын эпоска кертеп җибәрүләре буларак бәяләнә ала.

Моннан тыш «Күр углы» версияләрендә борынгы язма тарихи чыганакларда телгә алынган реаль шәхесләр белән тәңгәл образлар шактый. Дастанның көнчыгыш һәм көнбатыш версияләре Күр углының авантюраларга оста көрәшче булуы белән бергә ашуг булын да искәртәләр. Әрмән тарихчысы Аракель Тавризский танылган музыкант, шагыйрь-импровизатор Кёроглу турында, аның соңрак дастанда да телгә алыначак көрәштәш-фикердәшләре Гизироглу, Косе Сафаре турында язып калдырган. Аракельдә шулай ук билгеле шәхесләрнең «Юлга сыймас», «Тәңре танымас» дигән кушаматлары

[1] *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 139.

[2] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 59.

да теркәлгән[1]. Шушындый ук исемнәр, кайберләре бераз үзгәргән рәвешендә (әйтик, төрек версиясендә «Кабергә сыймас»дип үзгәртелгән исем бар) дастан версияләрендә дә очрый.

Гомумән, Күр углы исемле атаклы ашуг тарихи әдәбиятта шактый еш телгә алына. XVIII йөз төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби, төрек солтаны хезмәтендә торган, шулай ук кызылбашлар составындагы мәшһүр шагыйрь-импровизаторлар турында сөйләгәндә, мәсәлән, бу исемне зур талантка ия популяр шәхес буларак тәкъдим итә, башка шагыйрьләргә бәя биргәндә аларны Күр углы (Кёроглы) белән чагыштыра[2]. 1665 елда дәүләт эшләре белән бәйле сәяхәте вакытында Әүлия Чәләби һәм аның юлдашлары җәләлидләр хәрәкәте исеме белән мәгълүм крестьян чуалышларына юлыга. Әлеге талаучы банда Әүлия Чәләби төркеменә һөҗүм итә, банда башлыгы сәяхәтченең биленнән аның хәнҗәрен тартып ала. Шул вакыт Әүлия Чәләби: «Сез кылган явызлыкны бу урыннарда Гуроглы да кылмаган иде», – ди. Тарихчының «бу урыннар» дигәненең «Чардаглы – Чаглибиль» дип аталган урыннар булуы аеруча әһәмияткә ия. Билгеле булганча, барлык версиядә шушы атамага аваздаш Чамлыбел Күр углы урнашкан крепость, ә кайбер очракта хәтта ил буларак тасвирланган. Сәяхәтче бу территорияләрне Төркия биләмәләре буларак тасвирлый. Моннан тыш Әүлия Чәләби җәләлидләр башлыгы дип Чыгалыбәкне телгә ала, төрекмән-текеләр турында да мәгълүмат бирә. Билгеле булганча, төрекмән версиясендә Чыгалыбәк – Күр углының бабасы, ә Күр углы үзе – һәр версиядә диярлек төрекмән-теке кабиләсеннән.

Кеше исеме булудан тыш, тарихи чыганакларда «күруглы» исемле кабилә дә телгә алына. Бу хакта Х.Короглы түбәндәгеләрне яза: «Искандербек Туркман непосредственно не упоминает имени Кёроглу (или Гёроглы). Только в двух случаях он называет кёроглы как туркменский род из племени зулкадар. О туркменском роде кёроглы, жившем в Хорасане и Азербайджане, сообщает также историк XVIII в. Мирза Мехдихан»[3]. Чыннан да, әлеге этноним «Күр углы»ның

---

[1] *Brosset M.F.* Collektion D'Historiens Armeniens. V. 1. St.-Petersbourg, 1874. P. 87.

[2] *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма... С. 141.

[3] Шунда ук. Б. 143.

азәрбайҗан версиясендәге эпик җырда да очрый, биредә каһарман үзенең җиңелү белмәс күруглы кабиләсеннән булуын әйтә[1].

Дастанда төп каһарман үзенең атасын сукырайткан өчен һәм халыкны тиран идарәсеннән коткару максаты белән шаһтан үч алучы буларак тасвирлана. Әсәр Күр углының фаҗигале үлеме белән тәмамлана. Тарихи яктан караганда, биредә көнбатыш версияләрнең чынбарлык вакыйгаларын, чыннан да, объективрак яктыртуы сизелә.

Төрекмән версиясендә Күр углы госманлы Хункар кешеләре кулына төшә һәм үтерелә. Төрек пашасы аның башын бөтен кеше дә күрә торган урынга элдертә.

Ә көнбатыш версияләре каһарман үлемен, тарихи детальләрне киң кулланып, бераз башкача тасвирлый. Күр углы, картлыгы якынлашканны сизеп, хатыны Нигяр белән, үзенең Чамлыбелдәге резиденциясен калдырып китеп барганда шаһ Габбас II Сәфәвид сараена эләгә. Шаһ Күр углын үзенә хезмәткә чакыра. Героик эпос каһарманы буларак, Күр углы, әлбәттә, мондый тәкъдимнән баш тарта, хан сараеннан чыгып китеп, юлын дәвам итә. Шаһ Габбас аны башка эзәрлекләмәскә вәгъдә биреп калса да, аларның артыннан куа чыгарга боера. Эзәрлекләп килүчеләр тигезсез көрәштә каһарманның атын – Гыратны үтерәләр, Күр углының башын кисәләр, баш тиресен салдыртып, эченә салам тутырып, Исфаханга алып кайталар.

Игътибар итсәк, Күр углына карата бу явызлыкны көнчыгыш версиядә – төрек солтаны, ә көнбатыш версиядә Сефевидләр, ягъни кызылбашлар династиясе вәкиле Габбас II кыла. Бу – көнчыгыш версияләрдә, каһарманның дошманнарын бер-берсенә каршы гасырлар буе сугыш алып барган кызылбашлар һәм төрек солтаны белән фольклорча контаминациядә берләштереп, гомуми дошман образы барлыкка китерү алымы.

Ә төрек версиясенең Мырат Сертоглу вариантында исә Күр углы, куып килүчеләрнең үзенә ут ачуларын күреп, үзен-үзе үтереп һәлак була[2].

«Күр углы» дастаны кайсы халыкта нинди генә тарихи вакыйгаларга бәйләп каралса һәм төп каһарман прототибы кем дип кенә расланса да, биредә тарихи дөреслекне ачыклау түгел, ә шушы

---

[1] Кёроглу. Баку. 1959. С. 154.

[2] *Partev Naili.* Koroglu destani. Istambul, 1931.

гаҗәеп эпосның һәм аның версияләренең халык иҗатында булу факты үзе кыйммәт. Бу урында Х. Короглының әлеге әсәр версияләренең тарихилыгына мөнәсәбәттә нәтиҗә ясап әйткән сүзләрен китерү урынлы булыр: «Следует отметить, – ди ул, – что упомянутые в эпосе имена героев, хотя и обнаруживаются в том или ином контексте, однако нет надобности искать каких-либо прототипов героям или историческую основу сюжета эпоса. Эпос “Гёроглы” – подлинное народное творчество, отразившее героическую борьбу народа против своих угнетателей. Он вобрал в себя несколько исторических эпох многих древних тюркоязычных родов, вошедших впоследствии в племенное объединение огузов»[1]. Дастанның төрле милли версияләрендә чынбарлык вакыйгаларының объективлыгы төрле дәрәҗәдә булуны да тарихилыктан эпиклыкка күчү процессында һәр версия кичкән индивидуаль юл белән аңлатырга мөмкин. Чынбарлык вакыйгалары хронологик, географик һәм этногенетик яктан ерагая барган саен, аларның дастан версияләрендә чагылышы да тарихи әһәмиятен җуя төшә.

Бу әсәрнең тарихи тамырларын барлау нинди генә нәтиҗәләргә китермәсен, безнең өчен бер хакыйкать бәхәссез булып кала: безнең халыкта да әлеге мәгълүм сюжетлы эпик текстлар бар һәм бу тарихи вакыйгаларның Идел буе татарларына һәм гомумән татарларга турыдан-туры бернинди катнашы юк. Татар халкында укылып-күчерелеп йөргән вариантлар алар – безнең халык рухи культура алмашып яшәгән мәдәниятләрдән язмача килеп кергән истәлекләр. Халкыбыз аны иң беренче чиратта традицион китап культурасына омтылышы һәм әсәрнең мавыктыргыч сюжеты аркасында үз иткән, этноним, топоним, антропонимнарны үз фонетик үзенчәлекләренә яраштырып, әсәргә төрле үзгәртүләр керткән, кыскартулар ясаган. Татар вариантлары күләме белән көнчыгыш һәм көнбатыш версияләр кебек зур түгел, алар белән чагыштырганда, сюжет системасы да күпкә җыйнак, һәм, әлбәттә, ашуг-озаннар тарафыннан башкарылмыйча, язма формага нигезләнгәннәр. Нәтиҗәдә, популяр дастанның безнең халыкка хас китаби үз версиясе хасил булган. Татар версиясе өчен иң әһәмиятлесе дә әнә шул – дастанны башкалардан үзгә рәвештә тәкъдим итү.

[1] *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 145.

Шул ук вакытта уртак сюжетның тарихилыгына күзәтү ясау безнең версия-вариантларга да шактый ачыклык өстәве белән әһәмиятле. Татар вариантларында сөйләнгән вакыйгалар, биредә теркәлгән топонимик һәм антропонимик мәгълүматлар, тарихи вакыйгаларга һәм башка версияләрдә чагылган эпизодларга таянып, аларга нисбәтән тикшергәндә генә бөтен тулылыгы белән ачыла. «Күр углы»ның татар вариантлары да, башка кардәш халык версияләре кебек үк, реаль вакыйгаларга бәйле булуы белән гаять дәрәҗәдә кызыклы. Моны дастанны күчереп таратучы «авторларыбыз» да, аны укыган затларыбыз да тәгаен белгән, аңлап эш иткән булырга тиеш.

Дастанның татар халкында таралган вариантлары көнчыгыш һәм көнбатыш версияләр дип карала торган төркемнәрдән һәрвакыт читтә кала килде, әлеге сюжетка бездә дә берничә нөсхәдә эпик әсәрләр сакланган булуга игътибар аз юнәлтелде. «Күр углы»ның төрекмән, таҗик, үзбәк, казакъ яисә азәрбайҗан, төрек версияләре тематик яктан бер-берсе белән бәйләнмәгән дистәләгән, хәтта берничә дистә мәҗлестән (хикәяттән) гыйбарәт, бу хикәятләрне төп каһарман Күр углы һәм калган персонажлар, аларның язмышлары уртаклыгы бер әсәр итеп туплаган. Ә татар китаби версиясе мондый мөстәкыйль циклларны берләштерә торган зур әсәр булудан бик ерак. Безнең китаби дастаннар арасында том-том текстлардан торган эпопеялар гомумән юк. Бу – татар китаби дастанына хас билге. «Күр углы» дастаны вариантлары очрагында да бу закончалык сакланган. Бу мәшһүр эпосның татар вариантлары да, Урта Азия версияләре кебек үк, эпик фольклор традициясе инде тәмам ныгып, жанрның үз милли үзенчәлекләре ахыргача формалашып беткән чор ядкаре, шуңа күрә әсәрнең барлыкка килүендә дә, таралу формасында да һәр халыкның үз эпик үзенчәлекләре чагылыш тапкан булу табигый.

«Күр углы» – версияләре шактый тирән өйрәнелгән, текстлары фәнни әйләнелешкә кертелгән дастан. Әле 1842 елда ук Лондонда А. Ходзько авторлыгында «Народная поэзия Персии» дигән китап чыгарыла. Бу китапның төп өлеше нәкъ менә «Күр углы» эпосына, аның азәрбайҗан версиясенә багышланган[1]. Димәк, әле татар халкы бу әсәр белән танышуының башлангыч стадиясендә генә булган бер вакытта дастанның Урта Азия вариантлары инде фәнни әйләнелешкә кертелә. 1856 елда шушы ук дастанның «Кёр Оглу. Восточный поэт-

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 351.

наездник» дигән исем белән инглиз теленнән рус теленә тәрҗемә ителеп бастырылуы да аерым әһәмияткә ия[1].

Алга таба да эпосның төрле милли версияләре күпләгән галимнәрдә зур кызыксыну уята. Үзбәк галиме Х.Т. Зарифов 20–40 нчы еллар аралыгында гына да төрле халыкта «Күр углы» циклы дастанnarының дистәгә якын фәнни басмасы дөнья күргәнлеген әйтеп узган иде[2]. Чыннан да, бигрәк тә XX гасырның 30 нчы елларыннан фәнни даирәдә азәрбайҗан, әрмән, грузин, төрекмән, таҗик, үзбәк, казакъларның Күр углына багышланган дастаннары һәм аларга фәнни күзәтү – игътибар үзәгендә[3]. «Күр углы»ның төрле халыклар фольклорында очрый торган әһәмиятле әсәр булуы күп кенә галимнәрнең хезмәтләрендә теге я бу уңайдан һәрвакыт телгә алына килде, кайбер атаклы галимнәр, мәсәлән, И.С. Брагинский[4], Х.Г. Короглы[5] һ.б. тарафыннан дастанның төрле версия-вариантларына махсус тәфсилле анализ да ясалды.

Бу уникаль тарихлы, гаҗәеп сюжетлы эпик әсәргә игътибар шулай ук Төркия һәм төрек галимнәре тарафыннан күптәннән бирелә килә. XX гасыр башында ук алар «Күр углы» дастаны текстларын җыйнаган һәм аларны махсус тикшергән китаплар чыгару эшенә керешкәннәр иде[6], соңгы чорга кадәр биредә әлеге эпоска багышлап

---

[1] Кёр-Оглу. Восточный поэт-наездник. Полное собрание его импровизаций, с присовокуплением его биографии / перев с англ. С.С. Пенн. Тифлис, 1856.

[2] Цикл Гороглы // *Жирмунский В.М., Зарифов Х.Т.* Узбекский народный героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 165.

[3] Кёр-Оглы. Азербайджанский народный эпос / составил Г. Ализаде; перев. А. Шарифа, ред. и предисловие Г.К. Шарифова. Баку, 1940; Кёр-Оглы. Народный эпос. Ереван: АрмФАН, 1941; Гёроглы. Туркменский народный эпос. Ашхабад, 1941; Гуругли. Таджикский народный эпос. Сталинобад. Л., 1941; Цикл Гороглы // *Жирмунский В.М., Зарифов Х.Т.* Узбекский народный героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 165–278 һ.б.

[4] *Брагинский И.С.* О таджикском эпосе «Гургули» и его художественных особенностях//Вопросы изучения эпоса народов СССР. М.: Изд-во Акад. наук СССР, 1958. С. 127–149.

[5] Героический эпос «Кёроглы» // *Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М.: Наука, 1983. С. 169–247; *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 134–145 һ.б.

[6] Koroglu destani. Istamul, 1931.

махсус халыкара фәнни конференцияләр үткәрелә, фәнни җыентыклар дөнья күрә[1].

Татарларда «Күр углы» дастаны, аерым алганда аның В.В. Радлов тарафыннан язып алынган версиясе[2] турында төрекмән галиме Б.А. Каррыев[3], үзебезнең галимнәребез Ф.И. Урманчеев[4], М.И. Әхмәтҗановның[5], И.Г. Закированың[6] фәнни мәкаләләре мәгълүм. М. Әхмәтҗанов исә, В. Радлов вариантыннан тыш, «Күр углы»ның татарлардагы башка кулъязма һәм басма вариантларына да әһәмият бирде. Әлеге хезмәтләрдә «Күр углы»ның татар дастаннары арасында һәм шул исемдәге башка халык эпосы янәшәсендә тоткан урыны турында кайбер фикерләр әйтелә. Әмма татар халкының «Күр углы» дастанына татар фольклористикасында тиешле игътибар бирелеп беткән дип әйтеп булмый. Татар китаби дастаны буларак та, этник тарихыбызны, төрки-татарларның әдәби-мәдәни бәйләнешләрен барлау һәм гомумән татар версиясенең башка халыклар эпосы яссылыгында үз әһәмиятен ассызыклау җәһәтеннән дә ул махсус фәнни өйрәнүгә лаек.

Татар халык дастаннарының чичән-импроизатордан язып алынганнары сирәк. Мондый саф традицион дастаннар татар халкының көнбатыш диалектына караучы этник төркеменә күбрәк хас булуны алдарак әйтеп узган идек. Әмма шул ук себер татарлары иҗатына да китабилык һич ят түгел. Бу бигрәк тә соңгырак чор дастаннарына карый. «Күр углы» дастанының В. Радлов вариантын

---

[1] «Koroglu» dastani (Əli Kamali arxivindəki variantlar). Baki: Nurlan, 2009. 396 səh.; Halk kulturu ve Koroglu bilgi soleni bildirileri (2–4 Kasim 2006, Bolu). Dolu, 2009. Б. 271; 21 Yuzyilda Koroglu ve Bolu Arastirmalari. Uluslararasi Koroglu, Bolu tarihi ve kulturu sempoziumu bildileri. 17–18 Ekim 2009. Bolu, Dortdivan/Turkiye. Bolu. 2011. S. 782.

[2] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, ч. IV. Наречия барабинцев, тюркских , тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. С. 258–261.

[3] *Каррыев Б.А.* Эпические сказания о Кер-углы у тюрко-язычных народов. М.: Наука, 1968. С. 250–254.

[4] *Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. С. 164–170.

[5] *Әхмәтҗанов М.И.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 186–192.

[6] *Закирова И.Г.* «Күр углы» дастанының татар версиясе // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. Казань: Ихлас, 2010. С. 371–372.

себер татарларының китаби төр дастаны дип карыйбыз. Себер татарларыннан В. Радлов язып алган кыска гына «Күр углы» дастаны татар халкында бай язма әдәби традицияләр белән бер рәттән ерак гасырлардан килә торган эпик традицияләрнең дә яшәп килгән булуын раслый.

«Күр углы» дастанын В.В. Радлов XIX йөз ахырында Төмән өлкәсендә яшәүче себер татарларыннан язып алган. Дастан прозаик характерда, фәкать берничә урында диалог яисә баш каһарман әйткән сүзләр генә ике-дүрт юллы тезмәләрдә җиткерелә. Мәсәлән:

Күрнең улы әйтте:
– Килсен ханларым, солтанларым!
Башлары миңа караган кеше килсен!
Боерылган әмерләрем инде алсын!

Яисә Күр улының Ага Цаус белән ат өстендә торып әйтешүеннән бер мисал:

Ага Цаус әйтте:
– Эстәрсәң дә инде малымны,
Син күрерсең минем көчемне.
Мине үлтерсәң, ал малымны,
Мин кайтмыймын, син кит илеңә!

Шушы берничә шигъри юлдан тыш дастанның калган өлеше кыска җөмләле тезмә юлларда бәян ителә. Текстның күләме чагыштырмача зур түгел – дүрт биттән артмый. Вакыйгалар корылышы да артык катлаулы түгел, төп каһарман гамәлләренә нигезләнгән бер генә сюжет сызыгыннан гыйбарәт.

Күр батыр исемле вәзир Истанбул патшасына көтүдәге бер биянең озакламый толпар колынлаячагын хәбәр итә. Колын тугач, күк биянең әлеге кара колынчагын патша хуп күрми, аның толпар булачагына ышанмый, шуңа Күр батырны сукырайтып җәзалый. Ә колынчак, бераз үсә төшкәч, чыннан да толпарга әйләнә. Шуннан кызу канлы Күр батыр, улына кара айгырны җитәкләтеп, алдан әйткән сүзләренең хак булуын расларга дип, патша янына бара, аны каргый:

– Күрдеңме? Син минем күземне чыгардың, синең дә күзеңне чыгарсыннар! – ди. Патшаның ачуы чыга. Күр һәм аның углы качалар.

«Күр» исеменең килеп чыгышын Б.А. Каррыев ике төрле аңлата: «гүр» сүзе (таҗик, үзбәк версияләрендә төп каһарман, чыннан да,

анасыннан кабердә, ягъни гүрдә туа) һәм кайбер төрки телләрдә күр сүзенең «сукыр» мәгънәсен аңлатуы белән бәйли[1]. В. Радлов вариантына икенче аңлатма, ягъни патша тарафыннан сукырайтылган сукырның улы буларак каһарманны Күр углы исеме белән атаулары күбрәк туры килә, ә кабердә туу мотивы исә биредә урын алмаган. Алай да үзенең төрки телләрдәге төп мәгънәсе белән «күр/гүр/кер» сүзе каберне аңлата, төп каһарманның исеме дә шуңа бәйле булу ихтималы зуррак. Шул ук вакытта бу исемнең тарихи тамырлары булу мөмкинлеген дә алдарак карап узган идек.

Күр батырның улы атасын патша эзәрлекләвеннән коткарып кала, үзе Шәмливил дигән шәһәрдә «егетләр башы булып, узган-барганны коткармый, кәрванны талап тора», ягъни байлар-солтаннарны талау һәм үтерү белән шөгыльләнә. Башка милли версияләрдә вакыйгалар озын-озак итеп тәфсилләп сөйләнсә, В. Радлов вариантында шул ук вакыйга турында мәгълүмат кыска гына бер-ике җөмләдә җиткерелгән. Бу – соңгырак чор эпик стиль чагылышы, себер татарлары вариантының әүвәлге милли версияләреннән чагыштырмача соңрак формалашкан булуны раслый.

Алга таба Күр углының бер төркем батырлар башлыгы Ага Цауз (башка халыкларда, шул исәптән казан татарлары вариантындагы төрдәше – Ага Чауз) белән сугышуы һәм җиңүе, аның малын тартып алып, үзен әсир итүе тасвирлана.

Бер көнне боларга бер карт килә. Күр углы төркеме бу картның булган акчаларын талап ала. Карттан: «Бу дөньяда улың юк, кызың юк килеш үләрсең», – дигән сүзләр ишеткәч, Күр углы аннан үзенә яраклы кыз турында сораша. Карт аңа Истанбулдагы Никар ханым дигән кыз турында әйтә. Әлеге карт образы гади генә карт булмыйча, башка милли версияләрдәге, әйтик, таҗик дастанында тәфсилләп сөйләнгән Хозыр образының бераз үзгәртеп китерелгән варианты булырга тиеш. Бу хакта татар дастанында бер сүз дә әйтелмәсә дә, картның Күр углы янына үзе килеп кергән булуы, рәнҗетелгәч, Күр угылының язмышын юрап әйткән сүзе, аңа яраклы кыз турында мәгълүмат җиткерүе карт образын изге Хозыр белән тәңгәлләштерү мөмкинлеген тудыра. Хозыр – борынгы Иран мифологиясе аша

[1] *Каррыев Б.А.* Эпические сказания о Кер-оглы у тюркоязычных народов... С. 227.

татар эпик иҗатына килеп кергән, дастаннарда еш телгә алына торган персонаж.

Шуннан Күр углы Истанбул каласына дип чыгып китә. Дастан каһарманының, кәләш эзләп, үз иленнән читкә чыгып китүе – төрки халыклар эпосында киң таралган мотив. Бу мотив махсус «героик ярәшү мотивы» дигән исем белән билгеле. Гадәттә Себер һәм Урта Азия төркиләре кәләшне башка кабиләдән ала торган булганнар. Казакъларда, мәсәлән, җиде буынга кадәр кан кардәшлеге булмаган очракта гына никахлашу рөхсәт ителгән[1]. Кәләшне читтән эзләү мотивының экзогамиягә бәйле булуы турында Себернең төрки-монгол халыклары иҗатына мөнәсәбәттә Е.М.Мелетинский җентекләп яза[2]. Алтай әкияте «Кан-Пудей»[3]да «алтын күкрәкле, көмеш аркалы» каһарман күк кызын бик еректан, «җир белән күк тоташкан урыннан» алып кайталар. Төрки һәм монгол халыклары өчен уртак әлеге сюжетның ерак кайтавазы Чура батырга багышланган дастаннарда да чагылыш тапкан булуга игътибар иткән идек[4]. Себер татарлары «Күр углы» вариантында каһарманның Никарны эзләп чыгып китүе дә әлеге традицион ярәшү-никахлашу мотивына килеп тоташа. Биредә ул үзгәргән, бу мотивка киң тукталу юк, сүз нигездә Күр углының атасын һәм үзен рәнҗеткән социаль гаделсезлеккә каршы көрәше турында бара.

Юлда әсир төшкән Күр углын зинданга ябалар, Никар ханым аны коткара. Патриархаль күчмә тормыш шартларында барлыкка килгән төрки халыклар эпосына каһарман хатынын яисә аның кәләшен бик теләп аның тигез хокуклы, акыллы ярдәмчесе итеп тасвирлау хас. Моңа мисалны без «Алпамыш»та (Барчин), «Кобланды батыр»да (Кортка), «Манас»та (Каныкей), «Чура батыр»да (Миңле Сылу яисә Гөлханыс, Акменде) һ.б. эпоста очратабыз. «Күр углы»нда да борынгыдан килә торган шушы эпик традиция чагылыш тапкан. Зинданда думбра чиртеп утыручы Күр углын күреп алган Никар

---

[1] *Ауэзов М., Соболев Л.* Эпос и фольклор казахского народа // Литературный критик. 1939. № 10/11. С. 215.

[2] *Мелетинский Е.М.* Происхождение героического эпоса. М.: Изд-во восточ. лит., 1963. С. 259–260.

[3] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы северных тюркских племен. Ч. I. СПб., 1886. С. 68–86.

[4] *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 40.

ханым ярдәмендә төп герой юлын дәвам итә. Күр углы Бул бәк ханның сараена кереп, аннан бер кызны, кара атны урлап кача. Бул Бәк үзенең гаскәре белән боларны куа чыга. Ук атышып, Күр углы белән бик каты сугышалар. Күр углына ярдәмгә аның егетләре килеп җитә. Бул бәкнең гаскәрен җиңеп, үзен Шәмливилгә әсир итеп алып кайтып китәләр. Күр углы Бул Бәкне бик нык җәзалап үтертә:

– Бул Бәк, сине тоткан көннәр ни булды?
Инде тиреңне суйдырам, суйдырам.
Йиреңә, халкыңа куйдырам, куйдырам,
Истамбулның капкасына илтеп куйдырам.

Күр углы Бул Бәкнең эченә салам тутырылган гәүдәсен Истамбул патшасының капкасы төбенә китереп куя. Бу эшкә бик ярсыган патша даны илгә таралган Күр батырның кара атын тотып китергән кешегә үзенең кызын вәгъдә итә. Хәйлә юлы белән бу эшне Хәзәл исемле егет башкарып чыга.

Истанбул патшасы тарафыннан Күр углын һәм аның кара атын алып кайтырга дип җибәрелгән Хәзәл, Шәмливилгә килеп, Күр углына хезмәткә керә, аның ышанычын яулый. Дастанда Хәзәлнең еллар буе Күр углының малчысы булып торуы әйтелә, соңыннан ул, Күр углының кара атын урлап, Истанбул патшасына качып китә.

Күр углы аны куа чыга, тиз арада хыянәтчене куып та җитә. Юлда тегермән ишегенә бәйләнгән кара атын күреп, атыннан төшкән Күр углын Хәзәл, хәйлә юлы белән, төп башына утырта: Күр углы тегермәннең бер ишегеннән кереп киткәч, үзе икенче ишектән чыгып, кара атны ияртеп, Күр углы атланып килгән туры атка менеп кача. Хәзәл белә: атын калдырса, Күр углыннан мәрхәмәт булмаячак, ә качып котылса, Истанбул патшасы аңа кызын бирергә әзер. Әлеге тактик алым Хәзәл өчен уңай, әмма ул Күр углы белән дә арасын бозмый, киресенчә, аны туйга чакыра, шунда кара атны кире кайтарырга вәгъдә бирә. Соңыннан, сүзендә торып, вәгъдәсен үти.

Хәзәл – традицион героик эпос өчен типик образ түгел. Хәзәл белән Күр углы арасындагы конфликтның ике батыр арасындагы көрәш-алыш формасында түгел, ә хәйлә-мәкер катнашында чишелүе – соңгырак чор эпик традиция чагылышы. Батырлар арасындагы сугыш-орыш картинасына акыл-мәкер көрәше килеп керү белән башка китаби дастаннарда, әйтик «Каһарман Катил» героик дастанында да очрашабыз. Хәзәлнең кыйлган гамәлләре ил өчен,

идея өчен түгел, ә үз амбициясеннән чыгып – патша кызына өйләнү, үзен күрсәтү өчен башкарыла. Әмма әлеге эпизод дастанда төп каһарманның дәрәҗәсен һич төшерми, киресенчә, күтәрә. Моны шул ук Хәзәлнең патша кызын, ягъни үзенең хатынын, Истанбул патшасы янында калмыйча, туйдан соң ук үзе белән алып, Күр углы артыннан Шәмливилгә качып китүе үк раслый.

Дастан каһарманы Күр углы – курку белмәс батыр, җитез җайдак, үтә катлаулы хәлләрдән дә шома чыга белүче, нинди генә көчле дошманны да җиңә алучы елгыр егет, оста оештыручы-җитәкче. Әмма шул ук вакытта бу егет – кеше үтерүче, талаучы куркыныч башкисәр, аны, атын тотып китерә алган кешегә кызын бирергә риза булып, Истамбул патшасы үзе эзләтә. Шуңа күрә бу яктан җинаятьчене аклап булмый кебек. Әмма героик дастан батырының үз-үзен тотышы бүгенге этика кагыйдәләренә һәрвакыт туры килеп бетмәве – эпос өчен табигый хәл. Күр углы холкына, һәрбер дастан каһарманына хас булганча, намуслылык, вөҗданлылык та ят түгел. Әйтик, Никар ханым зинданнан коткаргач, Күр углының качып китү я яшеренеп яту мөмкинлеге була, ә ул бу юлдан китми:

– Егетлек алай булмас, – ди, һәм, кире шәһәргә кайтып, дошманыннан каты итеп үч ала. «Егетлек алай булмас!» дигән гыйбарә текстта берничә урында кабатлана. Бу – каһарманның курку белмәс батыр булуын тасвирлау алымы, әсәрнең героик дастаннар рухына тәңгәллеген искәртә. Тагын шунысы бар: Күр углының дошманнары – һәрвакыт социаль дошманнар, алар – бай кәрванчылар, ханнар һәм патша. Әлеге факт вакыйгаларның тамырына – Күр углының җинаятьче-батыр булып әверелү сәбәпләренә алып кайта. Чыннан да, каһарманның атасы Күрне хаксызга рәнҗеттеләр, шуның нәтиҗәсендә карт күзсез калды, иленнән качарга мәҗбүр булды. Рәнҗетүче – үзенең хакимиятеннән явыз файдаланучы Истанбул патшасы. Дошманлыкның, явызлыкның сәбәбе әнә шул. Күр углы кыйлган гамәлләр үч кайтару мотивы белән башкарыла, шуңа да мантыйкый рәвештә аклана.

Биредә Күр углының үз егетләре-көрәштәшләре арасында зур авторитет булуын да истә тотарга кирәк. Һәрвакыт, һәр җирдә бу егетләр җитәкчеләренә ярдәмгә килергә әзер һәм бу бирелгәнлек көч кулланып түгел, фәкать Күр углының кодрәтен, чын батыр булуын тану бәрабәренә башкарыла.

Әле батыр туганчы ук ат белән аның арасында якын мөнәсәбәтләр урнашу – күп кенә төрки дастаннар өчен уртак күренеш. «Күр

углы»ның азәрбайҗан версиясендә Хәсән бәк атасы-баһадирның Гырат («кыр аты») кушаматлы тулпарыннан туасы җирән колын белән дуслаша. Кыргызларның «Манас»ында да шуңа охшаш эпизод бар. «Чура батыр»ның казакъ версиясендә исә Гөлханыс, каршыларына чабып килгән тулпарны күреп, «Туачак баламның аты булыр бу», – ди, һәм аның юравы чынга аша. Себер татарлары «Күр углы»нда да каһарман янында, аңа тугры кырык көрәштәш егет белән бергә, әлбәттә, төрки эпосның аерылгысыз атрибуты – каһарман үзе генә иярли ала торган тулпар аты тасвирланган.

Эпик герой – һәрвакыт горур, гаделсезлеккә түзеп тора алмый, кызу канлы һәм үз көченә нык ышанучан. Күр углына әлеге сыйфатларның һәммәсе дә хас. Дастанда ул гаделлек өчен көрәшүче курку белмәс батыр образын гәүдәләндерә.

Дастанның тел-стиль һәм шигъри үзенчәлекләренә килсәк, бу әсәрне сөйләмә вариантка якын тора дип билгеләү дөрес булыр. Халык сөйләменә хас артык озын булмаган гади яисә тезмә кушма җөмләләр, чәчмә стиль дастанны сөйләмә характердагы иҗатка якынайта. Себер (тобол) татарлары варианты халык стиленә хас билгеләргә ия килеш теркәлеп калган. Әмма көнбатыш һәм көнчыгыш версияләр дип билгеләнгән, әллә ничә циклдан гыйбарәт эпос янәшәсендә тобол вариантының саф аутентик булмавын, стилистик үзгәреш кичереп, китап культурасына якынайганлыгын яисә соңгы чор эпик стилендә оешканлыгын күрми узу да дөрес булмас иде. Чынлыкта әсәрне «автор»ның әдәби үзгәртүләренә бөтенләй дучар түгел дип әйтеп булмый. Әмма дастандагы мондый үзгәртүләр күбрәк индивидуаль иҗатка түгел, ә китаби эпик традицияләр кысасына җиңел сыешалар. Дастанга килеп кергән «яңалыклар» нигездә кайбер образ-персонажларның соңгырак чорда әдәби-китаби характерлар һәм сюжетлар йогынтысында формалашкан булуыннан гыйбарәт. Шул ук вакытта китабилашу процессында әсәргә килеп кергән кайбер мондый билгеләрнең (китаби холыклар, китаби идеяләр) саф традицион эпос геройлары, аларның холык-фигыле, эш-гамәлләре белән гармонияле керешүе күзәтелә.

Урта Азия белән янәшәлек дастанның себер татарларына шул яклардан язма чыганаклар аша килеп кергән булуын тәэмин иткән булырга бик мөмкин. Моны тобол татарларының XVI йөздә иң беренче чиратта Урта Азия мөселманнары йогынтысында ислам кабул итүләре, ә Идел буеннан күчеп килгән казан татарлары йогынтысын-

да исә әкренләп язма культурага омтыла башлавы нәтиҗәсе буларак аңлатып була. Татар халкында жанрның китабилык үзенчәлеге традициясендә текст язмага теркәлгән. Шул ук вакытта «Күр углы»ның Урта Азиядә ашуг-бахшылар иҗатында телдән яңгыраган үрнәкләре белән якыннан танышлык тобол татарлары текстының сөйләмә характердагы дастаннар традициясеннән дә бөтенләй читләшүенә юл куймаган.

XIX йөз ахыры – XX йөз башларынача Урта Азия белән чиктәш татар төбәкләрендә икетеллелек күренеше булган. Берничә кардәш халык эпосын белгән импровизаторлар да мәгълүм. Мәсәлән, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге архивында «Алпамыш» дастанын казакъча да, татарча да әйткән татар кешесеннән язып алынган текст саклана[1]. Гомумән, кардәш төрки халыкларда ике телле чичәннәр һәм аларның эпосны ике телдә дә белүләре аерым очракта гадәти хәл булган. Таҗик һәм үзбәкләр мисалында В.М. Жирмунский бу хакта түбәндәгеләрне яза: «Взаимопроникновение языков обусловлено этническим смешением таджиков и узбеков (в Самаркандской и Бухарской областях и в соседних районах Таджикской ССР), широкораспространенным двуязычием вообще и наличием двуязычных сказителей»[2].

Татар дастанының тобол вариантына беренчеләрдән булып игътибар иткән Б.А. Каррыев әлеге мәсьәләдә түбәндәге фаразын җиткерә: «Допустимо предположить, что татарский «Кур-улы» восходит первоначально к письменному среднеазиатскому источнику, завезенному в Сибирь. Рукописный источник «Кур-улы» был доступен некоторым малограмотным людям из тюркоязычных племен Тобола. В этом отношении заслуживает внимания сообщение академика Радлова о том, что «татары около городов Тары и Тобольска славились издавна ученостью... значительная часть тарских и тобольских татар сделались учителями киргизов (т.е. казахов)»[3]. В.В. Радлов җыентыгына кергән бер генә нөсхәдә сакланып калган булуы, шушы

---

[1] ТР ФА Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, колл. 39.

[2] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 20.

[3] *Каррыев Б.А.* Эпические сказания о Кер-оглы у тюркоязычных народов. М.: Гл. ред. восточной лит-ры, 1968. С. 254.

бердәнбер варианттан тыш, эпик җыр рәвешендә генә булса да авыз-тел иҗатында башкача очрамавы себер татарлары ядкарен татар дастаннарына хас китаби типка кертеп карау ихтыяҗын тудыра. Әмма биредә язуга күчә бару тенденциясе белән бергә жанрның традицион төренә хас үзенчәлекләрнең дә яхшырак сакланган булуына игътибар иттек.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкының себер татарларындагы «Күр углы» варианты – тубыл татарларының иҗади эшкәртүенә дучар булган, бай эпик җирлеккә ия китаби дастан. Ул Урта Азия чичәннәре белән язма культура арасын үзенчәлекле тоташтыру функциясен үти. Китаби дастан буларак ул үзе үк синкретик характердагы, ягъни үзендә индивидуаль башлангычны да, фольклор традицияләрен дә үзенчәлекле берләштергән әсәр булуы белән кызыклы. Татарлардан тыш башка бик күп төрки һәм төрки булмаган халыкларда популяр «Күр углы» дастанының XIX йөз ахырында себер татарларында табылганы башка версия һәм вариантлар өчен дә характерлы булган уртак сюжет сызыклары, эпизод, детальләргә ия. Бу вариант төрки героик эпосы рухын саклый торган дастан буларак кыйммәт. Авантюралы сюжетының социаль-көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы булуы, күрәсең, дастанның халыкта киң һәм төрле формада таралуына сәбәп булган.

Дастанның Татарстанда табылган кулъязма варианты бар. Аның хакында галим М. Әхмәтҗанов хәбәр итә[1]. Ул кулъязма бүгенге көндә Мирасханәдә тасвирланган хәлдә саклана[2].

Кулъязма фәкать ике генә битлек, гарәп язуында. Текст шәмәхә кара белән 1920 елларда эшләнгән кәгазьгә язылган. Әлеге дастан бары фрагменттан гыйбарәт, 26 тезмә юлны тәшкил итә. Дастан кулъязмасының 13 нче һәм 14 нче шушы ике битеннән кала башка өлеше сакланмаган. Өзектә Күр углы уллыкка алган Хәсән ханның гаскәрдәге егетләрне яуга өндәгән чыгышы китерелә. Менә, мәсәлән, әлеге текстан берничә юл:

Фәрәмуш булмасын (онытылмасын. – *Л.М.*) имди хәтерләр.
Корыңызлар сарә (сөенеч, шатлык уңаеннан. – *Л.Х.*) пәрдә чатырлар.

---

[1] *Әхмәтҗанов М.И.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар кит. нәшр, 2000. 187 б.

[2] Татарстан ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инстутының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, 39 колл. Сакл. бер. № 5013.

Ак керүгә савыт кигән (ак түгәрәк көбә күлмәк, кольчуга. – *Л.М.*) батырлар,
Я алыңлар, я үлеңләр егетләр.
Йулымызда күзе Күр углы солтан,
Гаваз ханны килтерер дип кырык арслан.
Ук үтмәгәй, кирек тиресе бу калкан (киергегә тарттырылган калкан. – *Л.М.*),
Я үлеңләр, я алыңлар егетләр.

Фрагмент кына булуга карамастан, кулъязманы китаби «Күр углы»ның бер варианты дип бәяләргә мөмкин. Бу шигъри өзекнең табылуы «Күр углы»ның татарларда укылганлыгын, ә димәк, популярлыгын раслый. Әлеге вариант себер татарларыннан язып алынган дастан сюжетыннан ерагая төшкән. Кайбер антропонимик һәм топонимик уртаклыклар, мәгълүм Күр углы турында каһарман характерындагы дастан булуы һәм бердәй мотивлар (әйтик, Күр углының баласы булмау) гына аларны бер үзәккә тупларга мөмкинлек бирә.

Аның каруы әлеге фрагмент кулъязма дастанның басма варианты белән аваздаш. Әйтик, дастанның 1894 елгы басмасында кулъязмадагы шушы өзек юлга-юл кабатланган[1]. Чагыштыру өчен югарыда мисалга китерелгән сигез юлның басма вариантта ни рәвешле кабатлануын күзәтеп үтик:

Фәрәмуш булмасын имди хәтерләр.
Корыңызлар сарә пәрдә чатырлар.
Ак керүгә савыт кигән батырлар,
Я алыңлар, я үлеңләр егетләр кырык егетләр.
Йулымызда күзе Күр углы солтан,
Гаваз ханны килтерер дип кырык арслан.
Йамылкан (атылган. – *Л.М.*) ук үтмәс кирек тиресе калкан,
Я алыңлар, я үлеңләр егетләр.

Татарларда әүвәл кулъязмада таралган дастаннарның китап басу дәверендә китап булып басылып чыгулары мәгълүм. «Каһарман Катил» дастанына мөнәсәбәттә XIX йөз башыннан китаби дастаннарның китап булып дөнья күрүләре нәкъ менә халыкта алдарак таралган кулъязма нөсхәләре нигезендә башкарылган булуга игътибар

[1] Хикәяте Күр углы солтан. Казань: Типо-литография Имп. ун-та, 1894. Б. 13–15.

иткән идек. «Күр углы» вариантлары очрагында да шушы ук закончалык кабатлана: безнең көннәргә кулъязма текстның зур өлеше югалган булса да, җирле наширләр аны тулы вариантында китап формасына күчереп калырга өлгергәннәр.

Мәгълүм булганча, XIX йөз – XX йөз башында Казан типографияләрендә «Хикәяте Күр углы солтан» исеме белән күләмле әсәр кат-кат басыла. Әйтик, бу дастанның 1889 дан алып 1916 елгача 11 тапкыр басылып чыгуын беләбез. Югарыда каралган кулъязма фрагменттагы юллар, кайбер лексик, морфологик һәм орфографик үзгәрешләр кичереп, нәкъ менә шушы басма хикәяттә очрый.

«Хикәяте Күр углы солтан»ның теле гарәп-фарсы алынмалары белән чуарланган һәм бүгенге көн укучысына шактый кыен аңлашыла. Күләме зур – 90 битне тәшкил итә, гарәп язуында.

Әсәр ханнар тарихын риваять итеп, хронологик төстә берничә ханның исемен атап, шул тәртиптә Күр углының да унбиш яшендә хаким булуын бәян итеп башлана. Кайбер милли, әйтик, төрекмән версиясендәгечә, Күр углының бала чагыннан алып егет булганга кадәрге тормышын, геройның могҗиза юлы белән туган атын җентекле тасвирлау-бәян итү кебек элементлар татар дастанында юк. Татар китаби дастаны Күр углы тормышындагы вакыйгаларның кайберләренә генә тукталган. Әмма әлеге вакыйгалар башка милли версияләрдәге эзлеклелеккә һәрвакыт туры килеп торалар дигән нәтиҗә ясап булмый, бер үк исемнәр, охшаш вакыйгалар төрле уңай белән сюжетның төрле урынында очрарга мөмкин. Төрекмән, таҗик, азәрбайҗан һ.б. версияләр бер-берсеннән аерылып торган кебек, татар дастаны да яңа җирлектә яңача корылган, әлеге иҗат процессында күп үзгәрешләргә дучар булган.

Күр углы утыз яшькә җиткәндә моның янына Хозыр галәйһиссәлам, кырык изге җан, унике имам киләләр һәм аңа изге дога багышлыйлар. Кырык яшендә болар Күр углына кабат килеп, «бездән ниләр теләр идең» – дип сорыйлар. Күр углы дан-шөһрәткә ия булып озак яшәүне сорый, ә үзенең варисы итеп калдырырлык бала сорарга башына килми.

Дастанда аның күп хатыннар алып та, берсенең дә моннан бала тапмаулары турында сөйләнә. Варис кирәклеген аңлап, Күр углы, йөз яшенә җиткәндә, Исфаһан шәһәреннән Хәсән ханны алып кайтып, аны үзенең улы дип игълан итә, батыр егетләренә шул Хәсәнне башлык итеп куя.

Алга таба дастан Хәсән хан җитәкчелегендәге кырык егетнең Хункар иленә баруы турында сөйли. Бирედә «Булдырык исемле итченең бер бик чибәр улы» яши икән, Күр углының шушы Гаваз ханны күрәсе, аны үзенең варисы итәсе килә. Шуңа күрә ул: «Хәсәнне тыңлап, буйсынып торыгыз», – дип, Гаваз ханны алып кайтырга Хункар иленә яу җибәрә.

Татар версиясендәге Гаваз төрле милли версияләрдә телгә алынган Айваз (Овез, Иваз, Аваз) исемле бик чибәр үсмер егет образы белән тәңгәл килә. Дастанның көнбатыш һәм көнчыгыш версияләренең һәркайсында талау-буйсындыру сугышларының берсендә Күр углының Айваз исемле бик чибәр яшь ир баланы урлап китү эпизоды бар. Әлеге үсмер егет башта Күр углы хезмәтендә аның шәраб коючысы булып тора, соңыннан үч алучы-башкисәрнең көрәштәше-фикердәшенә әверелә. Дастан версияләрендә тасвирланган әлеге эпизодның чынбарлык вакыйгаларына барып тоташуы һәм тарихи документларга нигезләнеп раслануы әһәмиятле. Җәләлидләр түнтәрелеше турында Төркиядәге архив документларын барлаганда Х. Короглы бу турыда гаять кызыклы тарихи мәгълүматларга юлыга. Ул менә нәрсәләр турында хәбәр итә: «Самые достоверные сведения о джалалидском движении во главе с Кёроглу сохранились в государственых архивах Турции[1]. В указе от 1580 г. , адресованном правителю Болы (главный враг героя во всех версиях эпоса) и кадию Гереде, говорится о бесчинствах, совершаемых неким Кёроглу, которого следует поймать и наказать согласно закону. Чрезвычайно любопытно, что в этом же указе упоминается о том, что Кёроглу увел с собой красивого подростка. Об этих же событиях рассказывают другие архивные документы, датированные 1579–1581 гг.»[2]. Димәк, реаль вакыйганың дастанга килеп кергән булу ихтималы бар. Әмма татар версиясенә бу вакыйга турыдан-туры кагылмый, бирегә ул фольклорлашу процессында туган башка милли версияләр аша килеп кергән.

Кырык егете белән Хәсән хан Хункар дәүләтенә килеп җитеп, Бәдбәхет тавында туктала. Бу тау Гөрҗестан җирендә була. Таудан

---

[1] Тарихи аламараи Аббаси. Искандербек Туркман. С. 766–770.; см. так же: Эвлия Челеби. Т. II. С. 473, т. IX. С. 343.

[2] *Короглы Х.Г.* Туркменский эпос «Героглы» и особенности его историзма // Специфика фольклорных жанров. М.: Наука, 1973. С. 143.

түбән карап, каланың зурлыгын, капкаларының күплеген күреп каушап калган егетләргә Хәсән бәк кулъязма вариантта да теркәлгән 26 юлдан торган шигъри тезмәдә бәян ителгән сүзләрне әйтә. Ул юлларның эчтәлеге егетләрне орышка үгетләүдән, Күр углы солтанның ышанычын акларга өндәүдән гыйбарәт.

Татарча «Күр углы солтан» – төрки героик эпосы рухын тулысынча саклый торган әсәр. Әйтик, баһадирга даими рәвештә изге картларның ярдәмгә килүе – төрки халыкларның дастаннарында еш очрый торган күренеш. Мәсәлән, «Алпамыш» дастанында батырга Хозыр үзе булыша[1]. «Гашыйк Гариб»нең азәрбайҗан версиясендә каһарман шул ук Хозыр Ильяс ярдәме белән кирәкле вакытта тиешле җиренә барып өлгерә[2] һ.б.

«Күр углы солтан»да бу мотив төрки дастаннар өчен гаять популяр икенче бер әһәмиятле күренешкә – баласызлык мотивына барып бәйләнә. Баласызлык мотивы казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак кебек төрки халыклар эпосы өчен бик популяр. Мәсәлән, казакъ халык героик эпосы «Кобланды батыр»да Токтарбай сиксән яшенә җитә, әмма баласы булмый[3]. Кыргыз эпопеясы «Манас»та улы булмаган Якуп кайгысыннан кан-яшь түгә[4]. Киң таралган бу мотив Чура батырга багышланган казакъ дастаннарында да күзәтелә[5].

«Күр углы солтан»да баласызлык мотивы дастанның төп нигезе булып әверелгән дисәк тә хата булмас, чөнки нәкъ менә шушы проблема Күр углын башта Хәсән хан, аннары Гаваз хан өчен көрәшергә мәҗбүр итә һәм дастан сюжетын төзи.

Халкыбызның «Күр углы солтан» дастаны, Казан типографияләрендә кат-кат басылып чыкса да, Идел буе татарларында сөйләмә формада таралмаган. Бу дастанның басма варианты һәм кулъязма фрагменты төрки-иран мәдәни һәм әдәби бәйләнешләре нәтиҗәсендә безгә килеп ирешкән китаби дастан буларак кыйммәт.

---

[1] *Диваев А.К.* Памятники киргизского народного творчества. Алпамыс-батыр. Ташкент, 1901. С. 77.

[2] Антология азербайджанской поэзии М.: Гослитиздат, 1939. С. 214–217.

[3] Антология азербайджанской поэзии М.: Гослитиздат, 1939. С. 228.

[4] *Кыдырбаева Р.Р.* Манас эпосунун варианттары. Фрунзе: Илим, 1988. 160 с.

[5] *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 119.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Күр углы» исеме белән бәйле дастаннар безнең халыкта кулъязма һәм басма формаларда очрый. Китаби дастаннар формалашуның билгеле бер этабында «Күр углы» хикәятенең, халыкның язма әдәбиятка ихтыяҗын канәгатьләндерә торган, борынгыдан килгән традицияләребезне язуга күчереп тарата торган әсәр буларак, әһәмияте зур. Үзенең сюжет корылышы, образ-персонажлар бирелеше, вакыйгалар эзлеклелеге, күләме һ.б. ягыннан татар версиясе башка халык версияләрен кабатламавы белән үзенчәлекле. Татар дастанының китаби төренә карый торган иҗат буларак та, этник тарихыбызны, төрки-татарларның әдәби-мәдәни бәйләнешләрен барлау җәһәтеннән дә, маҗаралы героик әсәр буларак та «Күр углы» дастаны – гаять кызыклы, бай хәзинә.

## II бүлек

# МӘХӘББӘТ ДАСТАННАРЫ

Вариантларының күплеге, актив таралышы һәм халык арасында яратып укылуы җәһәтеннән татар китаби дастаннары арасында романик характердагылары әһәмиятле урын алып тора. Болар – мәгълүм Таһир белән Зөһрә, Йосыф, Сәйфелмөлек, Ләйлә белән Мәҗнүн, Шаһсанәм һәм Гариб, Бүз егет һ.б. атаклы сюжетларга иҗат ителгән дастаннар. Мондый әсәрләрнең үз чорында гаять популярлыгын эмоциональ-маҗаралы әсәрләргә халыкта заманына хас зур ихтыяҗның булуы белән аңлатырга мөмкин.

Мәхәббәт темасына багышланган романик дастан борынгы төрки һәм фарсы әдәбиятындагы мәшһүр поэмалар белән тыгыз бәйләнгән. Башкача әйткәндә, бу – индивидуаль язма иҗат, әдәбият белән үтә җитди керешкән өлкә. Фольклорның башка жанрлары, әйтик миф, әкият, бәет, мөнәҗәт, риваять, афористик һәм йола фольклоры янәшәсендә дастан жанрының төп хасияте дә нәкъ менә шунда. Әмма дастаннарның романик характердагыларында әдәбият белән керешкәнлек аеруча нык күзгә ташлана. Татарларда мондый әсәрләр – Урта гасырлардан Яңа чорга күчү чорыннан алып, XX гасыр башынача дәвердә язма әдәбият составындагы иң продуктив иҗат.

Урта гасырлар иҗат методы бер үк сюжетның төрле милли версияләрдәге эпик әсәрләр буып таралуын тәэмин иткән. Шушындый «күчмә» сюжетлар, әлбәттә, Идел буе татарларына да килеп җиткән. Сюжет традицияләре кысаларыннан чыкмаса да, биредә әсәр булып оешкан әлеге сюжетлар җирле традицияләргә туры килә торган яңа яңгыраш алганнар, әдәби-мәдәни процесска фольклор стилендә, әмма китаби версия рәвешендә кушылып киткәннәр. Идел буе татарларында фольклор дастаны текстлары язмача барлыкка китерелгәннәр һәм кульязмалар булып таратылганнар, фольклор традициясенә

хас булганча, халыкта нәкъ шул юл белән бу әсәрләрнең яңадан-яңа вариантлары барлыкка килеп һәм таралып торган, басма китап дәверендә исә аерым китапчыклар яисә калын китаплар булып басып та таратылган.

XVII йөз урталарыннан соң һәм, сәяси вазгыятьнең кырысланып яки йомшарып китүенә бәйле рәвештә, алга таба да, романик характердагы дастаннар халык өчен зур юаныч ролен үтәп килгән. Безнең романик китаби дастаннар алдарак карап үткән икенче типка карый, ягъни алар нигездә «авторлы». Монда индивидуаль авторлыкның аноним фольклор традициясеннән күпмедер дәрәҗәдә аерылып чыгуы күзәтелә.

Романик китаби дастаннар белән Борынгы һәм Урта гасыр әдәби әсәрләре арасында һәм шул ук сюжетка традицион (башкарыла торган) эпик текст арасында төгәл чикне билгеләү гаять авыр. Иҗатка хирыс шәхесләр мәгълүм сюжетларга дастаннар язу белән бергә оригиналь әсәрләр иҗат итү белән дә шөгыльләнгәннәр. Мәсәлән, татар шагыйре Әхмәтҗан Тубылиның, йөзләгән шигырь һәм дини-фәлсәфи характердагы прозаик әсәрләр авторы булуы белән бергә, мәгълүм сюжетларга дастаннар да иҗат иткәнлеге мәгълүм. Мондый төр иҗат белән шөгыльләнүчеләр каләмендә фольклор принциплары гадәттә үтә җиңеллек белән әдәби традицияләргә үрелеп китә, шуңа да романик китаби дастаннар дигәндә аларга гына хас чик сызыгын тотып алу һәм аерып чыгару җиңел эш түгел.

Бу төркем дастаннарны билгеләүдә «романик» терминын куллану бераз шартлы, әлбәттә. Күләме һәм эчтәлеге ягыннан мондый дастаннарның материалы Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларында барлыкка килгән роман жанрын колачлый, әмма һич тә роман жанрының бөтен хасиятләрен дә сакламый. Роман жанры тематик (автобиографик, хәрби, детектив, документаль, мәхәббәт, интеллектуаль, тарихи, сәяси, маҗаралы, сатирик, сентименталь, иҗтимагый, фантастик, фәлсәфи һ.б.) һәм структур (шигъри роман, роман-памфлет, роман-сага, роман-кыйсса, роман-сага, роман-фельетон, эпистоляр роман һ.б.) яктан шактый күп төркемнәргә бүленсә, хезмәтебездә романик китаби характердагы дастаннар дип карала торган әсәрләрнең тематикасы шактый чикле (аларның һәркайсы, гадәттә, бер генә теманы ача – ике гашыйкның мәхәббәт тарихын бәян итә), алар шулай ук төзелеше белән дә артык катлаулы түгел. Шул ук вакытта китаби романик дастаннар, роман жанры (тарихи романнардан

кала) кебек, шәхси тормыш вакыйгаларына нигезләнә, гади кешеләр язмышын тасвирлый. Романик китаби дастаннар бигрәк тә Яңарыш әдәбиятында шәхси тормыш эпосы буларак мәйданга чыккан романнарга якын торалар, адәм балаларының шәхси омтылышларын, шатлык-кайгыларын, уңыш-фаҗигаләрен тасвирлыйлар.

Яңарыш чоры романында шәхеснең кичерешләре һәм гамәлләре иҗтимагый мотивлаша, чөнки яңа җәмгыятьтә шәхси һәм иҗтимагый тормыш – кеше яшәешенең бер дәрәҗәдәге яклары. Мондый әсәр үзәгенә үзенең аң дәрәҗәсе, үзаңы белән башкалардан аерылып, җәмгыятьнең әдәби сурәтләнештәге хәл-халәте белән каршылыкта торучы шәхес куела. Роман жанрындагы әсәрдә «бер язмышта, бер кеше тормышы мисалында шул чор өчен иң характерлы шартлар әдәби гомумиләштереп тасвирлана, тормышның ниндилеге бер образ итеп җыеп сурәтләнә»[1] Роман бүгенге чынбарлыкны якындагы үткән белән бәйли.

Ә романик характердагы китаби дастаннарда вакыйгалар һәрвакыт ерак үткәнгә карый, биредә роман жанрына хас тенденциозлык, әсәрдә шәхси тормыш мисалында тормыш-яшәеш мәгънәсен ачарга, яшәү рәвешен чагылдырырга омтылу кебек әдәби концепциянең булуы артык сизелми. Романик китаби дастаннар аерым бер темаларны һәм традицион мотивларны кабатлый, бәхетсез тәгәлләнә торган сюжеты белән дә, кайбер геройларның чынбарлыкта яшәгән шәхесләргә барып тоташуы ягыннан да алар гаять мавыктыргыч.

Китаби дастаннарның романик дип билгеләнгән төркемгә карый торганнары, билгеле бер тема-мотивларны үстерүләре һәм текст эчтәлегендә романтик иҗатка хас шәркый кануннар, кайбер эстетик алымнар, бизәклелек кулланылу ягыннан романтизм (нем. romantic, фр. romantisme, ингл. romantism) әдәби юнәлешенең Көнчыгыш романтик иҗат тибына да бик нык якын торалар. Романик китаби дастаннарда романтизм иҗат юнәлешенә хас булган кайбер сыйфатлар күзгә чалына, әйтик, хисләр байлыгы, тәэсирлелек, геройны идеаллаштырып сурәтләү, рухи башлангычка өстенлек бирү. Романик дастаннар әдәбияттагы роман жанры һәм романтизм юнәлешенең икесенә дә берьюлы һәм төрле яклап тартылуы кайвакыт мондый

[1] Әдәбият белеме сүзлеге. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 163.

әсәрләргә карата «романтик дастаннар» дигән билгеләмә куллануны мөмкин хәл итә. Фольклор белән әдәбият арасында тора торган, халыкта берничә вариантта һәм версиядә таралыш алган, мәхәббәт темасына багышланган уртак сюжетлы дастани әсәрләрне әдәбият һәм фольклор галимнәре романик дастаннар дип тә, романтик дастаннар дип тә атыйлар. Шулай да дастани эпоска бай халыкларда очрый торган мондый төр иҗатка карата «романик дастаннар» дигән термин куллану «романтик дастаннар»га караганда ешрак очрый. Е.М. Мелетинский[1], П.А. Гринцер[2], В.М. Жирмунский[3], С.Ю. Неклюдов[4] кебек галимнәр төрле халыкларның мондый категориядәге эпик әсәрләре турында сүз барганда «романик» терминына өстенлек бирәләр.

Тематик принципка һәм романтизм методына хас кайбер сыйфатлары булуга карап, татар китаби дастаннарының мондый төрен романтик дастаннар дип атау да хата булмас иде, әмма китапка якынлыгы, традиционлык һәм индивидуальлек җәһәтеннән әдәби иҗатка да бик нык якын торулары сәбәпле, мондый әсәрләрнең эчтәлеген «романик» термины төгәлрәк ача дип табылды, шуңа күрә, хезмәтебездә теоретик концепцияләре нигез итеп алынган атаклы галимнәр фикеренә кушылып, роман жанры чалымнары кергән, идея-эчтәлегендә романтизм юнәлешенең бер агымына хас сыйфатлар чагылыш тапкан дастаннарны атау өчен терминнарның әүвәлгесенә тукталыйк.

Мәхәббәт темалы эпик иҗатта фольклор спецификасын ачыклар өчен җирлек дөнья әдәбияты һәм фольклористикасында да бар. Әйтик, Урта Азия һәм Якын Көнчыгышта киң билгеле халык романнары аерым халыкларның авторлы әсәрләре булып саналалар. Мәсәлән, Мәгърипинең «Йосыф һәм Әхмәт»е, Молла Непеснең «Таһир һәм Зөһрә»се, Шабәндәнең «Сәят һәм Хәмра»сы һ.б. XVIII йөз – XIX йөз башының әлеге шагыйрьләре барысы да төрекмән язма әдәбияты вәкилләре һәм аларның һәркайсы үз иҗатында фольклорга таяна.

[1] *Мелетинский Е.М.* Ввведение в историческую поэтику эпоса и романа. М.: Наука, 1986. С. 140–168.

[2] *Гринцер П.А.* Две эпохи романа (вводная статья) // Генезис романа в литературах Азии и Африки. Национальные истоки жанра. М.: Наука, 1980. С. 3–44.

[3] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л: 1974. С. 19, 643 и др.

[4] *Неклюдов С.Ю.* От эпоса к роману // Неклюдов С.Ю. Героический эпос монгольских народов. М.: Наука, 1984. С. 251–267.

В.М. Жирмунский казакъ акыны Нурпеис Байганинның (1860 – 1945) классик казакъ эпосы «Кобланды батыр» авторы булып саналса да, әлеге «автор»ның «Кобланды батыр»ны остазыннан – икенче бер җыручы-акын Максуттан өйрәнгән булуы турында әйткән иде[1]. Галим шулай ук казакъларның «Кыз-Җибек» дастанына мөнәсәбәттә Саим җырауның, үзбәк дастаннары «авторлары» Фазил-шагыйрьнең, Ислам-шагыйрьнең һ.б.ның бу әсәрләрнең авторлары булып китү сәбәбе чорның язма әдәбият барлыкка килгән дәвергә туры килгәнлегеннән генә килә дип аңлата: «Их «авторство» применительно к старым среднеазиатским «народным романам» международного происхождения означает только, что авторство классических вариантов этих произведений народной поэзии приписывалось великим певцам, исполнявшим их в период, когда складывалась письменная литературная традиция»[2]. Европа антик эпосы «Песнь о Роланде»ның Оксфордта саклана торган кулъязмасының авторы саналган Турольдусның, һинд эпосы «Махабхарата» һәм «Рамаяна»лар турында сүз барганда легенда дәрәҗәсендә генә булса да автор буларак телгә алына торган Вьяс һәм Вальмикиның авторлыкларына мөнәсәбәттә дә шундый ук нәтиҗә ясарга мөмкин.

Татарларда популяр «Таһир белән Зөһрә», «Гашыйк Гариб», «Ләйлә белән Мәҗнүн» кебек әсәрләр мисалында В.М. Жирмунский романик китаби дастаннарның сюжетын әдәби чыганаклардан башлангыч алган дип саный, мондый эпосны традицион «тере» героик эпостан аерылып тора торган соңгырак чор иҗаты дип карый, аларга карата «мәхәббәт темасына багышланган халык романнары», «китаби чыгышлы эпос» кебек терминнар куллана, язма әдәби традицияләр тәэсирендә мондый күчмә сюжетларга иҗат ителгән текстларның яисә дастан вариантларының кайберләре классик формадагы әсәр булырга дәгъва итә башлавын да күрсәтә[3].

Халык иҗатының китаби дастаннар төркемендә иң беренче чиратта китапка якынлыгы, индивидуаль язма әдәбият белән урталыгы нәтиҗәсендә урын ала торган романик дастаннарда яктыртыла торган төп тема, чыннан да, – мәхәббәт. Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбияты традициясендә илаһи мәхәббәткә дан

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 637.
[2] Шунда ук. Б. 638.
[3] Шунда ук. Б. 638, 642 һ.б.

җырлаган әсәрләр китаби дастаннарның иң зур өлешен алып тора. Романик китаби дастаннар һәркайсы диярлек үзләренең күләмле булулары белән аерыла.

Татар романик китаби дастаннарын Урта Азиядә мәгълүм «Рөстәмхан», «Сәят-Хәмра», «Асли-Кәрәм» һ.б. дастаннар кебек саф романик әсәрләр дип әйтеп булмый. Безнең дастаннар алардан, шигъри эшләнешенең күбесенчә тезмә аралаш чәчмә булулары, күләменең чагыштырмача кечкенәлеге, сюжет җепләренең артык катлауланмыйча, бер я берничә сызыктан гына баруы, төгәл структуралы булулары, милли җирлек чагылыш тапкан сюжет үзенчәлекләре һ.б. сыйфатлары белән аерылып торалар.

Идел буе татарлары романик дастаннарының нигездә барысына да китаби стильгә тартылу хас. Бу төркем дастаннарда халык иҗаты әдәби сюжетларны үзләштерү белән бергә әдәбиятның поэтик формаларын да нык кына үзенеке иткән. Боларның күбесендә персонажлар сөйләме «тере» башкарылуга хас булган билгеләрне бөтенләй юып ала торган, әдәби телгә якын шома нейтраль тел белән бәян ителә. Идел буе татарларында романик дастани эпос – татар китаби дастаннары формалашуының иң соңгы чоры күренеше, мондый төр иҗат үз чорында масса төсен алган булган һәм интенсив таралган.

Эчтәлеге белән әдәби һәм фольклор чыганакларга таянган, кабатлана торган эпик сюжетларга күп очракта импровизатор-җыручылар мөрәҗәгать иткән, бу исә бик күп кенә төрки халыкларда дастанның традицион вариантларын барлыкка китергән. «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир белән Зөһрә», «Гашыйк Мәхмүд» кебек дастаннарның, әйтүчесенең исеме күрсәтелеп, кире китапка кайтарылган очраклары шул хакта сөйли. Болар – чичән башкаруында кабат халык теленнән язып алынган беренчел «тере» вербаль текстлы романик әсәрләр[1]. Боларда да индивидуаль башлангыч традицион башлангыч белән бик тыгыз үрелгән. Казакъ, үзбәк, каракалпакларның кабат фольклорлашкан мондый дастаннары – популяр сюжетны кабат фольклорча эшкәртеп барлыкка китерелгән иҗат. Дастан тексты үзе үк индивидуаль һәм традицион-типик башлангычлар арасында

[1] Дастаны. Ашик Махмуд. Сказитель – Махмуджон Юсупов. Ташкент: Фан, 1970. 80 с. ; Лайли ва Мажнун (достон) / айтувчи – Фозил Йулдош угли. Тошкент: Фан, 1968. 85 б. һ.б.

үзенчәлекле күпер ролен башкара торган, укучы тарафыннан автор әсәре кебек укыла торган әдәби бөтен ул. Әмма мондый истәлекләр оригиналь әсәр булудан да бик ерак торалар, аларга халык эпик традицияләренең тәэсире зур.

Идел буе татарлары язма фольклорындагы мәхәббәт дастаннарында, шул ук сюжетка жанрның «тере» традицион төре белән чагыштырганда, әлбәттә, динамикалык, башкарудагы киң диапазон, телдән хикәяләүдә очрый торган энергия инде юылган, шигырь төзелешендә халык стиле буларак кулланылып килгән силлабикага нигезләнү дә бик нык кимүгә йөз тоткан. Әмма татар халкында язмача таралган романик дастаннарның да халык телендә йөри торган кыска сөйләмә вариантлары да бар. Бу – татар дастаннарының китаби төренә хас билге, әлеге күренеш жанр төрендә фольклор белән кире бәйләнеш булуны күрсәтә. Сөйләмә вариантлар гадәттә бик кыска – эчтәлек сөйләп чыгу яисә фрагментар характерда, я булмаса зур дастаннан эпик җыр рәвешендә генә мәгълүм. Кагыйдә буларак, алар һәрвакыт күләмле кулъязма дастанның кайсы белән булса да тәңгәл киләләр. Бу исә язмача таралган камилрәк һәм күләмлерәк дастанның яңадан фольклорлашуы, ягъни китаби дастанның авыз иҗаты белән кире бәйләнешне тәэмин итүе дигән сүз.

Романик китаби дастаннарда героика чалымнары да чагылып китә. Әйтик, «Сәйфелмөлек», «Бүз егет», хәтта «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә бу ачык күренә. Ә атаклы «Түләк», гәрчә ул мәхәббәт дастаны булса да, үзенең архаиклыгы белән һәм алыплар турындагы хикәятләргә якынлыгы ягыннан күбрәк каһарманлык дастаннары төркеменә якын тора, шуңа да без аны героик китаби дастаннар төркемендә карыйбыз.

Романик китаби дастаннар, каһарманлык дастаннары кебек үк, төп герой исеме белән аталып йөртеләләр, ягъни әсәр эчтәлеген аның исеме үк әйтеп тора. Мәхәббәт тарихы төп эчтәлекне алып торган романик китаби дастаннар парлы исемнән гыйбарәт: «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн», Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга һәм Һәмра» һ.б.

Мәхәббәт тарихын бәян итә торган дастаннарыбызның янә бер үзенчәлеге дип дастан вакыйгаларының фаҗига белән тәмамлануын күрсәтергә кирәк. Бәхетле кавышу мотивы фәкать «Йосыф китабы»нда һәм «Хурлуга белән Һәмра»да гына сакланган. Башка төрки халыкларда гашыйкларның бергә булулары белән тәгәлләнә

торган «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннарның татар версиясендә дә әлеге фаҗигале үлем идеясе киң таралган. Романик китаби дастаннарыбызда трагик мәхәббәт тематикасының популярлыгы турыдан-туры борынгы гарәп риваятьләреннән килә. Әйтик, татар халкында «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжеты бик киң таралган булган, мәхәббәт дастаннарының фаҗигале бетеменә бу әсәр зур йогынты ясаган. Шулай ук XIII–XV йөзләрдә төрки халыклар иҗатында киң таралган «Кузы Күрпәч белән Баян-Сылу» дастанының да тәэсире зур булган. Әсәрне трагик ноталарда тәмамлау дастанны тагын да тәэсирлерәк, эмоциональрәк ясаган, шуның белән укучыны ныграк җәлеп иткән. Бу җәһәттән казан татарлары романик дастаннары күпмедер дәрәҗәдә Е.М. Мелетинский Көнчыгыш новеллалары дип характерлаган язма истәлекләргә, аерым алганда «Мең дә бер кичә»гә якын тора. Е.М. Мелетинский мәхәббәт темасы өстенлек иткән романик новеллаларда егет-геройның, кагыйдә буларак, бик пассив, самими, әмма үтә намуслы, вөҗданлы, ә кыз-геройның исә актив һәм инициатива күрсәтүчән булуының гомуми планда алга чыгуына игътибар итә[1]. Татар романик дастаннарында аңлы рәвештә холыкны тасвирлау турында сүз алып барырга бик иртә булса да, һәр заман өчен таныш затлылык, гомуми олы хисләр пәрдәсе артында безнең геройларны да нәкъ шул сыйфатларыннан танып алырга мөмкин. Татар халык дастаннарында кыз-герой хәтта үзенең зирәклеге, тапкырлыгы, кыюлыгы, сөйгәненә карата демократик холкы белән Көнчыгыш новеллаларыннан, шулай ук дастаннарның Көнчыгыш халыклардагы версияләреннән хәтта аерылып та тора.

Татар романик китаби дастаннары Көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә туганнар һәм озак гасырлар дәвамында шул әдәбият йогынтысында формалашканнар, шул сәбәпле аларда Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әсәрләреннән килә торган консервативлык традицияләре үзен бик нык сиздерә. Боларда заман таләпләрен канәгатьләндерерлек дөньявилык, Европа культурасына, әдәбиятына, фәненә омтылыш идеяләре бөтенләй юк. Әмма татар әдәбиятын һәм мәдәниятен борынгыдан азыкландырып килгән Шәрык мәдәнияте һәм аның аша романик дастаннарыбызга үтеп кергән идеяләр,

---

[1] *Мелетинский Е.М.* Историческая поэтика новеллы. М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1990. С. 34.

стиль-үзенчәлекләр билгеле бер чорга кадәр милләтебезнең табигатенә гаять ярашлы булган. Романик китаби дип билгеләнгән төргә керә торган әсәрләребезнең бездә XX гасыр башынача популярлыгын шул сәбәп белән генә аңлатырга мөмкин.

Романик китаби дастаннарның һәркайсында әдәбият кануннары белән фольклор кануннары табигый үрелештә чагылыш таба. Бу төр китаби әсәрләр – гашыйклык дастаны гына түгел, ә «гомумән мәхәббәт, кешенең бөтен барлыгын биләгән олы хис»[1] турындагы дастан. Мәхәббәттән дә зуррак көчнең булмавы идеясе романик китаби дастаннарның һәрберсендә үтә җете кызыл җеп булып сузылган. Мондый дастаннар Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятына хас суфичылык идеяләреннән дә азат түгел. Бу төркемгә керә торган дастаннарда китап традицияләре фольклор үзенчәлекләре белән бик тыгыз аралашкан. Татар халкының романик китаби дастаннары Көнчыгыш романтик иҗат методыннан бик күп сыйфатлар алган. Шул ук вакытта бу төр дастаннарыбыз татар әдәбиятында XX йөз башында иҗат методы булып формалашып өлгергән роман жанры формалашуга да йогынты ясап, роман жанры үсешендә мәгълүм бер баскыч ролен дә үтәгәннәр. Хәлбуки романик характердагы дастаннарыбызның татар китаби дастаны дигән специфик бөтен барлыкка китерүдә бик зур роль уйнавы бәхәссез.

## § 1. Татарларда Ләйлә белән Мәҗнүн тарихы

Ләйлә белән Мәҗнүн – Көнчыгышта гаять популяр гарәп риваяте каһарманнары, бичара гашыйклар. Риваять буенча, Ләйлә белән Кайс (егетнең исеме) кечкенә чагында бергә дөя көтүе көтәләр, тора-бара аларның араларында кайнар мәхәббәт кабына. Ләйлә белән Кайс һичничек кавыша алмыйлар, Кайс, үз кабиләсеннән китеп, чүлдә ялгыз яши башлый, мәгъшукасы турында җырлар иҗат итә. Аңа Мәҗнүн кушаматы тагалар, «мәҗнүн» акылын җуйган, шашкан дигәнне аңлата. Чыннан да, Кайс мәхәббәттән акылын җуя : ул беркем белән аралашмый, беркемне тыңламый, фәкать Ләйлә исемен ишеткәч кенә аңына кайта, кеше белән сөйләшә алыр хәлгә килә, мәхәббәт җырлары җырлый. Ике гашыйк мәсьәләсендә Кайсның атасы Ләйләнең атасы белән уртак фикергә килмиләр, Ләйләнең атасы

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан, 1984. Б. 23.

кызын Мәҗнүнгә бирмим дип ант итә. Мәҗнүн мәхәббәт чиреннән савыга алмый. Нәтиҗәдә Ләйлә дә, Мәҗнүн дә, бер-берсеннән читтә, сагынып-саргаешып үләләр[1].

Бу риваятьнең тамырлары белән реаль вакыйгаларга барып тоташуы мәгълүм. Галим И.Ю. Крачковский, мәсәлән, Мәҗнүн образында VII гасырда яшәп, шигырь-җырлар иҗат иткән шәхес Кайс Ибне-Мөләүвәх (кайбер чыганаклар буенча Ибн-Муад дип тә бирелә) шәхесе чагыла дип күрсәтә, аның Бәни Әмир (Бәни Джагда дигән вариант та бар) исемле гарәп кабиләсеннән булуын әйтә[2]. Әлеге вакыйгага мөнәсбәтле риваятьләр бик күп, эчтәлеге белән баналь булсалар да, аларның һәркайсы вакыйгага үз үзенчәлеген кертә. Бу риваятьләрнең кайберләре төрле чыганакларга теркәлеп тә калганнар[3].

Бертельс Ләйлә белән Мәҗнүн турындагы риваятьләрнең XII гасыргача бик аз фактларны гына атап, җыйнак вакыйга рәвешендә йөргәнлеге турында яза: «Хотя предания, связанные с именем Маджнуна, к XII веку еще и не облеклись в форму законченного произведения, но стержень романа наметился уже вполне отчетливо. Характерно, что для первоначальной версии крайне мало фактов. Развития действия почти нет»[4]. Хәлбуки фольклор әсәре өчен болар – табигый, Е.Э. Бертельс санаган фактлар, Ләйлә белән Мәҗнүн турындагы сюжетның чишмә башы фольклордан булуны ассызыклый торган аргументлар буларак, аерым әһәмияткә ия.

Әлеге сюжет алга таба фарсы һәм төрек романтик дастаннарына, шулай ук Дәһләви, Нәвои, Физули, Җами һ. б. кебек суфи шагыйрьләр иҗатына килеп керә. Шундый әсәрләр арасында иң мәшһүре – азәрбайҗан шагыйре Низами Ганҗәви поэмасы (1188 елда язылып беткән)[5].

Низами Ләйлә белән Мәҗнүн турындагы мәгълүм гарәп риваятенә әдәби бөтенлек, төгәллек өсти, каһарманнарның холыкфигылен билгели, аларның гамәлләрен әдәби поэмаларга хас

---

[1] Литературная энциклопедия. Т. VI. М.: Советская энциклопедия, 1932. С. 155.

[2] *Крачковский И.Ю.* Избранные сочинения. Т. 2. М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1956. С. 588.

[3] *Бертельс Е.Э.* Низами. Творческий путь поэта. М.: Изд-во Акад. Наук СССР, 1956. С. 132–137.

[4] Шунда ук. Б. 137.

[5] *Ганҗәви Низами.* Ләйлә вә Мәҗнүн. Казан: Таттосиздат, 1950. 182 б.

психологик мотивлар белән ныгыта. Поэманың гомуми трагик концепциясе – Кайс һәм Ләйләне яндыручы, бер-берсен сөйгән бу ике җанны рухи дәрәҗәдә кушылуга этәрүче көчле илаһи мәхәббәт. Шушы мәхәббәтне максатчан-әдәби тасвирлап бирү, драматик коллизияләр, әдәби структурага кертеп урнаштыру Низами әсәрен индивидуаль авторның бербөтен әдәби поэмасы итә.

Шул ук вакытта Низами поэмасында Ләйлә белән Мәҗнүннең мәхәббәт тарихын дастан итеп халыкка җиткергән шагыйрь образының булуы кызыклы. Бу – Зәед исемле дәрвиш, Мәҗнүн кебек, мәхәббәтеннән газап чигүче бер егет. Әлеге персонажга Низами поэмасында шактый зур урын бирелгән. Ахырда ул Мәҗнүннән үзе ишеткән яисә башкалар сөйләгән мәхәббәт шигырьләрен язып алып, аларны халыкка укый. Низами Зәедне Ләйлә-Мәҗнүн тарихына багышланган эпосны кешеләр алдында укып бирүче чичән буларак тасвирлый:

Меджнуном сочиненный каждый бейт
Собрал и записал достойный Зейд,
Что помнил сам, что слышал от других,
Чтоб не забыт был ни единый стих.
И люди, восхищаясь без конца,
Хвалили вдохновенного чтеца.
Так все узнать с волнением смогли
Сказанье о Маджнуне и Лейли[1].

Урта гасырлар әдәби-мәдәни тарихында мондый иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең чыннан да булганлыгы мәгълүм: «Эти произведения обычно устно исполнялись грамотными професиональными сказителями на разного рода собраниях. Традиция сказочников – профессионалов восходит к древности: известно существование сказочников – равиев и декламаторов в Сасанидской империи (III–VII вв.)»[2]. Низами поэмасындагы Зәед-шагыйрь образы – әнә шул чынбарлык чагылышы. Әсәрдә авторның үзеннән тыш та дастан әйтүче Зәед образы – фольклор эпосы белән әдәби әсәр арасын тоташтыра торган күпер. Димәк, Низами үзенең поэмасында фольклордагы эпик традицияләргә киң мөрәҗәгать иткән. Поэмадагы бу һ.б.ш. мисаллар Урта

---

[1] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т. 3 / перевод с фарси Татьяны Стрешневой. М.: Худ. литер., 1986. С. 302.

[2] История всемирной литературы: в 9 т. Т. 2. С. 266–267.

гасыр Көнчыгыш поэзиясенең фольклор белән бик күп уртаклыклары турында сөйли.

VII–VIII гасырлардагы реаль вакыйгаларга, шәхесләргә барып тоташа торган бу сюжетка гомуммәгълүм әдәби поэманың торабара гарәп, фарсы, таҗик, көрд һәм күпләгән төрки телләрдә яңа версияләре туган. «Ләйлә белән Мәҗнүн» поэмасына ияреп язылган әсәрләрне исәпкә алып бетерерлек тә түгел. Е.Э. Бертельс, мондый әсәрләрнең иң зурларын һәм билгелеләрен генә санап та, түбәндәге саннарны китерә: «Из более известных можно назвать: на персидском языке двадцать, на среднеазиатско-тюркском (староузбекском) – одну, на азербайджанском – три, на анатолийско-турецком (османском) – четырнадцать, на курдском – одну, на таджикском – две, возникшие уже в конце XIX века»[1].

Тамыры белән фольклорга барып тоташа торган классик әдәбият үрнәкләре әнә шул рәвешле халык өчен илһам чыганагына әверелгәннәр. Сюжет халык иҗаты стилендә эшкәртелгән һәм күптөрле вариантлар булып таралган. Күп кенә халыкларда «Ләйлә-Мәҗнүн» сюжеты, саф эпос традициясендә, эпик җыручылар иҗаты булып киткән[2], ягъни импровизатор тарафыннан телдән сөйләнгән мәхәббәт темалы традицион саф эпос булып формалашкан. Дөнья әдәбиятында һәм фольклорында импровизатор авызыннан язып алынган, «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетлы зур-зур әсәрләр мәгълүм. Алардан башка бу бөек әсәрдән турыдан-туры тәрҗемәләрне, иркле тәрҗемәләрне, сюжетның музыка, сынлы сәнгать, драматургиядә һ.б.да чагылышын истә тотканда, бу әсәрнең дөнья культурасы үсешендә тоткан урыны бииһая булуы аңлашыла.

Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган гарәп риваятенең популярлыгын Европада киң таралган «Ромео һәм Джульетта» белән чагыштырып, Е.Э. Бертельс беренчесенең таралашы күпкә масштаблырак булуына игътибар иткән иде. Күренекле галим мондый популярлыкны хаклы рәвештә сюжетның нәкъ менә фольклор белән тыгыз бәйләнешендә һәм Низами поэмасының атаклылыгында күрә: «Если сравнить распространение “печального предания” о Лейли

[1] *Бертельс Е.Э.* Низами. Творческий путь поэта. М.: Изд-во Акад. Наук СССР, 1956. С. 153.

[2] Краткая литературная энциклопедия. Т. 4. М.: Советская энциклопедия, 1967. С. 98–99.

и Маджнуне с близкой к нему по характеру повестью о Ромео и Джкульетте, то придется признать, что поэма "Лейли и Маджнун" распространена значительно шире. Знакомство с "Ромео и Джульетта" происходит в Европе, как правило, через литературу и театр; предания о Маджнуне во всех странах Ближнего Востока давно слились с фольклором, и образы двух несчастных влюбленных с раннего возраста являются близкими и привычными друзьями даже неграмотных. Не приходится сомневаться в том, что этому содействовала прекрасная поэма Низами»[1].

Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган сюжетның татар халык фольклорындагы урыны мәсьәләсе әлегәчә ачык кала килде. Хәлбуки татар халкында да бу сюжет белән бәйле материал шактый күп. XVIII йөздән башлап, әле безнең чоргача романик характердагы бу үлемсез тема татар халкын гаять кызыксындырган, аңа багышлап күпләгән вариантта кулъязма дастаннар гына түгел, фарсы телендә язылган әдәби әсәрдән һ.б. чыганаклар аша татар әдипләре тарафыннан турыдан-туры һәм иҗади тәрҗемәләр дә эшләнә килгән[2], шушы ук сюжет 1922 елда язылган драма әсәренең дә нигезенә яткан[3].

Шулардан Ф. Халиди тәрҗемәсенә тукталсак, автор үзе бу әсәр турында болай дип яза: «Ошбу мәшһүр «Ләйлә вә Мәҗнүн» китабын Русиядә булган мөселманнар төркисенә тәртип кылдым. Казанлык мәхдүм Мөхәммәтфатих Халиди 21 нче октябрьдә 1901 елда»[4]. Текстның үзе һәм аңа бирелгән автор искәрмәсе буенча фикер йөрткәндә, Ф. Халиди бар иткән әлеге әсәр – мәгълүм «Ләйлә белән Мәҗнүн» әсәренең бер тәрҗемәсе.

Ф. Халиди иҗатына бәя биргән хезмәтендә бу ядкарьгә З. Мөхәммәтшин аерым игътибар бирде, Ф. Халиди тәрҗемәсенең «татар-

---

[1] *Бертельс Е.Э.* Избранные труды. Низами и Фузули. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1962. С. 230.

[2] *Ганҗәви Н.* Ләйлә белән Мәҗнүн (Мәхмүд Максуд тәрҗемәсе). Татгосиздат, 1950. 150 б.; Халиди Ф. Мәшһүр гашыйк – мәгъшук Ләйлә илә Мәҗнүн хикәясе. Казан: Ун-т тип., 1902. 45 б.; Рәшиди Г. Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе. Казан: Центр. тип., 1917. 45б.

[3] *Әмири К.* Ләйлә вә Мәҗнүн. Фаҗига, 5 пәрдәдә, музыкалы, җыр-бию, такмак, дуэт һәм башкалар. Казан, 1925. Кулъязма КФУ китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә 1825 т шифры белән саклана.

[4] Мәшһүр гашыйк-мәгъшук Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе. Казан: Ун-т табыгханәсе, 1902. Б. 45.

лар арасында киң таралган дастан варанты белән тулысынча туры килүен» искәртте[1].

Әмма әлеге ядкарь шактый үзенчәлекләргә ия. Халык версиясе буларак таралган кулъязма вариантлар белән чагыштырганда тәрҗемә тексты мәгънә ягыннан күпкә аерылып тора. Ф. Халиди вариантын әдәбияттагы «ирекле тәрҗемә» (иҗади тәрҗемә) дигән төшенчә аша аңлату отышлырак булыр. Авторның үзенең әсәрне «Русия мөселманнары төркисенә тәртип кылдым» дип әйтүе үк кайсыдыр башка телдәге, дөресрәге, башка төрки телдәге «Ләйлә белән Мәҗнүн»не татарчага әйләндергән булуы хакында сөйли. («Русия мөселманнары төркисе» дигәндә XX йөз башындагы татар теле күздә тотылган булу шик уятмый). Шул ук вакыта монда нигез итеп кайсы чыганакның алынган булуы мәсьәләсе дә килеп туа.

Язучы Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятында мәгълүм авторлар Низами, Нәвои, Физули поэмалары белән таныш булган. XX йөз башында татар-төрек әдәби багланышларының җитди төс алган булуы сәбәпле, Ф. Халиди тәрҗемәсенә «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең төрек версиясе[2] дә зур тәэсир иткән булырга тиеш.

Ф. Халиди тәрҗемәсендәге «Ләйлә белән Мәҗнүн» проза белән язылган, текстта ике юллык тезмәләр дә очрый. Алар – нигездә унбишкә унбиш иҗекле строфалар. Сюжетына килгәндә, Ф. Халидидә Физули, Низами, Нәвоидан килә торган сюжет нигез итеп алынган, әмма иҗади якын килгән урыннар да күзгә ташлана. Әйтик, Нәвои поэмасында бик җитди урыннарны алып торган кайбер вакыйгалар Ф. Халиди тәрҗемәсендә бөтенләй яктыртылмый калган. Мәсәлән, Нәвои әсәреннән Нәүфәл белән Ләйләнең атасы арасында бик нык көрәш-орыш булганлыгын, Нәүфәлнең җиңүен сизеп, атасының Ләйләне үтерергә карар бирүен беләбез. Бу хәлне төшендә күргән Мәҗнүн сугышны туктатырга кирәклеген әйтеп ялвара. Сахрадан кайтарып, Мәҗнүнне Нәүфәл кызына өйләндерәләр. Туйдан соң ук Мәҗнүн, кире сахрага качып, илаһи мәхәббәтенә багышланган җырлар җырлый[3]. Ф. Халиди төп сюжет буларак ике гашыйкның үзара

---

[1] *Мөхәммәтшин З.* Фатих Халидинең иҗат мирасы. Таң-Заря. Казан, 2001. Б. 36–42.

[2] Лейле ве Меҗнүн. XVI–XVII. Кулъязма Казан (Идел буе) федераль университетының сирәк китаплар бүлегендә саклана. Шифр 15 Готв, 107 кәгазь.

[3] *Навои Алишер.* Лейла и Маджнун // Соч.: в 10 томах. Т. 5. Ташкент: Фан, 1968. С. 89–91.

мәхәббәт тарихын бәян иткән вакыйгаларны үстерә, күп кенә икенчел, өченчел характердагы вакыйгаларны төшереп калдыруны яисә тәрҗемә итүне һәм ни рәвешле тәрҗемә итүне үз карамагына калдыра, ягъни Урта гасырның мәшһүр әсәренә, татар әдәбиятындагы традицияләргә таяну белән бергә, күп кенә урыннарда үз алымнары белән якын килә. Болар – Ф. Халиди тәрҗемәсендә авторлык билгеләренең максатчан күзәтелүе турында сөйли.

З. Мөхәммәтшин Ф. Халидинең төрек кулъязмасына да таянган булуы файдасына түбәндәгеләргә игътибарны юнәлтә: «Беренчедән, башка вариантлардан аермалы буларак, – ди ул, – Бәни Әмир кабиләсе, аның байлыгы калку бирелә. Икенче охшашлык – бәетләрнең бер-берсен кабатлап килүләре»[1]. Чыннан да, Ф. Халиди тәрҗемәсендә, төрек вариантындагы кебек үк, Кайс кабиләсе, аның атасының байлыгын тасвирлауга бик зур урын бирелгән. Моннан тыш биредә төрек кулъязмасында гына гына очрый торган топонимик атамалар, кеше исемнәре дә шактый урын алган. Бәетләр, ягъни ике юллык шигъри юллар охшашлыгына килсәк, Ф. Халидидә аларның саны унҗиде, төрек кулъязмасында исә унике, ә Физули поэмасында исә егерме икегә җитә. Ф. Халиди тәрҗемәсендә төрек вариантын сүзгә-сүз кабатлаган юллар да, мәгънә төсмерен бераз үзгәртеп биргән юллар да бар. Мәсәлән, төрек вариантыннан Б. Урманче тәрҗемәсендә бирелгән түбәндәге юллар Ф. Халиди тәрҗемәсенең бишенче кәгазендә сүзгә-сүз кабатлана:

Фәләк угын җәясеннән атты җанга аерылу,
Калмады үлмәктән үзгә бер чара бу – аерылу.
Мин бу михнәт баласымын кем, замана даясе
Туганымнан бирле имезә ул шәрабтан аерылу.

Моннан тыш башка шигъри юлларга игътибар итү Ф. Халидинең төрек телендәге чыганакның телен үз чорындагы татар теленә якынайтырга омтылышы сиземләнә. Ф. Халиди тәрҗемәсе, ихтимал, бер генә чыганакка нигезләнмәгән. Төрек кулъязмасы буенча фикер йөртсәк, төрек «Ләйлә вә Мәҗнүн»е үзе сюжеты, композициясе белән Физули поэмасына гаять якын тора, әсәрнең кереше үк, Физулидәге кебек, багышлау белән башланып китә. Димәк, әсәрне татарның XIX йөз ахыры – XX йөз башындагы китап телендә яңгырату

---

[1] *Мөхәммәтшин З.* Фатих Халидинең иҗат мирасы... Б. 42.

максатыннан, әдип берничә чыганакка мөрәҗәгать иткән дигән фикер алга чыга. Халык арасында таралган, күчерүчесе мәгълүм яисә мәгълүм булмаган кулъязмалар белән чагыштырганда, Ф. Халиди тәрҗемәсе үзенең тулылыгы, күләме, төгәлләнгән характердагы ядкарь булуы белән аерылып тора.

XIX йөз ахыры – XX йөз башы әдибе Ф. Халидинең иҗаты күпкырлы. Драматург булуы белән бергә, ул – Урта гасыр Шәрык әдәбиятында һәм фольклорында киң таралган сюжетларга да игътибар биргән, мәгърифәтчелек идеясен уздыру максатыннан, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «иске китаплардан җыеп язган»[1], төрле язма чыганакларны кулланып, яңа текст төзегән. «Ләйлә белән Мәҗнүн» әсәрен татар теленә аударып эшләп чыгуы – аның шушы юнәлештәге эшчәнлегенең бер үрнәге.

Ф. Халидинең «Ләйлә белән Мәҗнүн»е фольклор белән бик ерак бәйләнеш тота. Бу сюжетка мөрәҗәгать итеп, әсәрнең иҗади тәрҗемәсен эшләгән чорда әдип сюжетның халык арасында телдән сөйләнеп яисә күпсанлы кулъязмалар рәвешендә кат-кат күчерелеп йөргән вариантларына да игътибар биргән дигән нәтиҗә ясап булмый. Шул ук вакытта Ф. Халиди тәрҗемәсенең халык иҗатына кире әйләнеп кайткан булуына да мисал юк.

Ф. Халидинең Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятында популяр сюжетларга ирекле тәрҗемәләр ясавы – татар китаби дастаннары тәмам формалашып җиткәннән соңгы күренеш. Иҗатның мондый төре дә татар дөньясында популярлык казанган, чөнки халыкның язганны укырга, бигрәк тә мавыктыргыч сюжетка корылган язмаларга ихтыяҗы-омтылышы бик зур булган. Ф. Халидинең «Ләйлә белән Мәҗнүн»е 1902, 1908 елларда 2400 тираж белән басылган булуы мәгълүм. Аны татар халкының китаби дастаннан әдәби иҗатка күчү процессындагы яңа бер баскычы дип бәяләргә кирәк.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына мөрәҗәгать итеп тәрҗемә эшләгән әдипләрдән шушындый ук гомумиләштерүләрне Галләм Рәшиди иҗатына карата да кулланабыз. Ф. Халиди иҗади тәрҗемәсе белән Г. Рәшидинеке сюжет төзелеше белән шактый аерылып торсалар да, иҗат һәм тәрҗемә итү принциплары, шулай ук тәрҗемәнең фольклор белән бәйләнеше җәһәтеннән биредә дә нәтиҗә – анало-

---

[1] Болгарның Солтан Гадел Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе. Казан: М. Чиркова табыгханәсе, 1897. Б. 2.

гик. Мондый төр иҗатта телдән башкарылу элементларының бер генә билгесе дә сакланмаган. Соңрак XX гасыр уртасында дөнья күргән Мүхмүд Максуди тәрҗемәсе исә татар фольклоры традицияләреннән тагын да ныграк ераклашкан – Низами Ганҗәвидән тәрҗемә икәнлеге күрсәтелеп, әдәби нормаларга таянып, турыдан-туры тәрҗемә эшләнгән.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татарларда Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган тәрҗемәләр турыдан-туры халык иҗатына таянып барлыкка килмәгәннәр, аларның авторлары иң беренче чиратта язма әдәби чыганаклар белән эш иткән, шуңа күрә мондый төр ядкарьләрдә фольклор белән кире бәйләнеш юк. Мондый төр авторлы тәрҗемәләр – китаби дастаннар иҗат ителү процессының тармаклануы, профессиональ тәрҗемәчелек өлкәсендәге беренче карлыгачлар буларак та бәяләнергә хаклы. Классик «Ләйлә белән Мәҗнүн»не татар теленә иркле тәрҗемә итү эшенә татар әдипләре чагыштырмача соң – әле XX йөз башында гына мөрәҗәгать иткәннәр.

Археографик экспедицияләр вакытында табылган кулъязмалар арасында «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының татарча текстлары да булу игътибарны җәлеп итә. Димәк, иркле яисә турыдан-туры тәрҗемәләрдән күп алда татар халкы «Ләйлә – Мәҗнүн» белән кулдан кулга күчерелеп укылган кулъязмалар аша таныш булган. Бу кулъязмаларның язылу вакыты XVIII–XIX гасырларга туры килә. Гарәп язулы, татар телле әлеге фактик материал татарларда «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына дастанның башка халыклардан аермалы үз версиясе булуын дәлилли.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»нең татар версиясе Низами Ганҗәви, Физули, Нәвои, Җами әсәрләренең яисә башка язма чыганакларның турыдан-туры яисә иркле тәрҗемәләре түгел, ә берничә вариантта таралган, Идел буе җирлегендә барлыкка килгән мөстәкыйль әсәрләр булуы белән әһәмиятле. Болар – нигездә чәчмә характердагы, чагыштырмача гади сюжетлы, әллә ни күләмле булмаган дастаннар. Әлбәттә, алар чичән авызыннан язып алынмаган, әмма мондый ядкарьләрдә, китаби эпоска хас булганча, фольклор белән бәйләнеш сакланган, шуңа да аларны халык вариантлары буларак карыйбыз.

Фольклор белән бәйләнеш дигәндә иң беренче чиратта, әлбәттә, аларның тел-стиль җәһәтеннән халыкчанлыгын, текстның кайчандыр телдән башкарылуга корылган булуын дәлилли торган элементлар табылуны, шулай ук бер үк текстның кат-кат күчерелеп

таратылуын, вариантлылыкны һәм, әлбәттә, әсәрдә типологик мотивларга бирелгән игътибарны күздә тотабыз.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына милли вариантларыбызның барысына да хас бер сыйфат – алар соңгырак чор татар тормышына яраклаштырылганнар, шул чор татар менталитеты белән сугарылганнар. Сюжеты кыска һәм гади, төп каһарманнары тыйнак һәм сабыр. Текстлар геройларның эмоциональ хәле-халәте өчен укучыны борчылырга мәҗбүр итә торган итеп корылган, китаби информант-авторның яисә информант-күчерүченең төп максаты – кыйссаны укучы-тыңлаучыдан бу ике бичараны кызгандыру, аларга психологик тәэсир ясау. Әсәрләрнең һәркайсының трагизм белән сугарылган булуының нигезендә әнә шул мотив ята. Эпос жанрының тыңлаучы тарафыннан эмоциональ-экспрессив кабул ителү традициясе исә китаби версиядә барлык тулылыгы белән язмага күчкән. Көнчыгыш Ләйләсе белән чагыштырганда безнең версиядәге Ләйлә – шактый кыю, иркен яшәүче, мәхәббәтенә тугры, үз дигәне өчен өчен көрәшергә әзер, әмма шул ук вакытта башбаштаклыклар кылуга сак якын килүче кыз.

Дастанның кулъязмалар булып таралган нөсхәләренә килсәк, «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең кулъязма текстларыннан иң күләмлесе – татар журналисты Борһан Шәрәф (1883–1943) китаплары арасыннан Флора Әхмәтова тапкан вариант. Ул 32 битне тәшкил итә. Язылу вакыты, урыны, күчерүче-авторы күрсәтелмәгән. Әсәр Бакый ага Урманче тарафыннан хәзерге язуга күчерелеп, «Татар халык иҗаты» җыентыгында урын алган[1]. Бүгенге көндә без бу ядкарь белән тел-стиль һәм структура-композиция җәһәтеннән фәкать адаптацияләнгән вариантында гына таныша алабыз, чөнки чыганак кулъязма үзе фәнни әйләнешкә кермәгән, оригиналның шәхси архивта – Б. Шәрәф кызы Сара ханымда саклануы турында гына мәгълүмат бар[2].

1984 елда төзелгән җыентыкта да, соңрак 2004 елда дөнья күргәнендә дә Ф. Әхмәтова укучы игътибарына Б. Урманче эшкәртеп, татар укучысына аңлаешлы телгә күчергән вариантны тәкъдим итә. Ул үзе бу хакта түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Кулъязманы

---

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 174–206.

[2] Татар халык эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. Б. 272.

хәзерге татар теленә күчереп, сүзләрне аңлатып, җыентыкка кертүгә Россиянең һәм Татарстанның халык рәссамы Бакый Идрис угылы Урманче (1897–1990) күп ярдәм итте. Шигырьләрен, рухланып, тулаем үзе тәрҗемә кылды...»[1].

Шулай итеп, Борһан Шәрәф варианты дигәндә без Б. Урманче тарафыннан эшкәртелүгә дучар булган нөсхә белән эш итәбез. Дастаннарыбызның мондый язмышын жанрның китабилаша бару процессындагы соңгы чор үрнәге, иҗади шәхесләребезнең тынгысыз эшчәнлеге аша дастаннарыбызның кат-кат китабилашуы нәтиҗәсе дип бәяләү дөрес булыр. Информант сөйләмендә сакланмаган, тел-авыз иҗаты буларак татар халкында язып алынмаган булу сәбәпле, китаби «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең дә бүгенге укучы хозурына шушындый юллар үтеп килеп ирешүе – табигый хәл. Бу – китаби дастаннар таралышының һәм халыкта яшәешенең аермачык күренеп торган конкрет бер мисалы һәм саллы мисалы. Уку-язуга зур әһәмият бирелгән китаби эпослы һәр халыкта мондый мисаллар һичшиксез бар.

Шартлы рәвештә Борһан Шәрәф варианты дип аталган, Б. Урманченың да талантлы кулы аша үткән әлеге әсәргә киңрәк тукталыйк.

Эчтәлеге белән дастан Низаминың атаклы әсәренә якын тора, әмма аермалар да шактый. Б. Урманченың төрек кулъязмасы белән дә эш иткән булуы мәгълүм, шуңа да «автор» өчен биредә чыганак ролен Борһан Шәрәф кулъязмасы гына түгел, фарсы телле поэмалар да, төрек кулъязмасы да уйнаган булуы ихтимал. Чыннан да, текст төрле бүлекләргә бүленеп, күпмедер дәрәҗәдә әдәби-структур йогынты кичергән. Әмма Б. Урманче дастанның һәр деталендә халыкчанлыкка, фольклор традицияләренә гаять игътибарлы.

Вакыйгалар эзлеклегеннән чыгып, текст унбиш бүлеккә аерылган, һәр бүлеккә эчтәлекне ачып бирә торган баш куелган. Исемнәр символик мәгънә белдермиләр, бу бүлектә сүзнең нәрсә турында барачагын аңлатып бирү характерында булып, алда сөйләнәчәк вакыйганы тулысынча колачлыйлар.

«Мәҗнүннең дөньяга килеп, җиде яшенә кергәннән соң атасы мәктәпкә биргәне» дип исемләнгән беренче бүлектә аудитория Кайсның дөньяга килүе, ата-анасының теләп алган бик кадерле

[1] Татар халык эпосы. Дастаннар. Казан: Раннур, 2004. Б. 179.

баласы булып, җиде яшенә җитүе, яшьтәшләре арасында акылы, зиһене, матурлыгы белән аерылып торуы гаять компактлы бәян рәвешендә бирелгән. Монда фольклордан килә торган баласызлык мотивы чагылыш тапкан. Бәнигамир дигән затлы, бай кабиләнең шөһрәтле әмире баласызлыктан хәсрәт чигә. Дөньяда башка һичбер мохтаҗлыгы булмаса да, әмирнең угылы юк.

Кайбер халыклар эпосында бала булмау мотивы киң таралган. Мәсәлән, «Алпамыш» дастанының үзбәк версиясен искә төшерик. Анда агалы-энеле Байбүре һәм Байсарының баласы булмый, әлеге җитешсезлекләрен телгә алып, мәҗлестә аларга төрле мыскыллау сүзләре әйтәләр. Шуннан соң Байбүре белән Байсары, бала теләп, Шаһимәрдән каберлеген зиярәт кылалар. Шаһимәрдән каберлегеннән бер өн чыгып, Байбүре белән Байсарыга теләкләре кабул булачагын әйтә.

Әлеге мотив казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак кебек төрки халыклар эпосы өчен бик популяр. Изге кешеләр каберлегенә барып ялвару казакълар өчен, мәсәлән, культ дәрәҗәсендә булган. Әйтик, бик күпләр изге Хорхут (Коркыт) кабере төрле авырулардан йола дип ышанганннар. Бу турыда В.М. Жирмунский Ә.Ә. Диваевның түбәндәге сүзләрен китерә: «Анда бик еш изге Хорхутка табынырга дип кыргыз ирләре һәм хатыннары (ягъни казакъ ирләре һәм хатынары) килә һәм төрле чирләрдән, бәлаләрдән котылу, бигрәк тә «әрвак» дип аталган шайтан чиреннән арыну өмете белән кабер янында төне буе күз яше коеп, дога кылалар»[1].

Әлеге гореф-гадәт казакъ һ.б. халыкларда мәҗүсилек тамырларының шактый нык булуын чагылдыра. Чура батырга багышланган дастаннарның казакъ версиясендә дә шуңа охшаш эпизод бар. Алардагы бер вариантта Нарык, балалары булуын теләп, әүлиялар, изгеләр каберенә бара. Корбаннар чала. Яисә Нарыкның хатыны Бабай-тукты-Чәч каберен зиярәт иткәннән соң, ир белән хатынның теләкләре кабул булып, уллары Шора туа[2].

Героик төрки эпос традициясеннән аермалы буларак, Борһан Шәрәф «Ләйлә белән Мәҗнүн»ендә исә проблема Аллаһ ярдәмендә хәл ителә. Әмир күп сәдакалар бирә, малын хак тәгалә юлында

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 546.

[2] *Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. Б. 115.

тарата. Нәтиҗәдә, «Хак тәгалә рәхмәте берлә хатыны хамилә булды. Вакыты тәмам булып. Ай парәсе кебек бер һилал (яңа туган ай. – *Л.М.*) кашлы углан дөньяга килде». Бу – соңгы чор дастани иҗатка хас күренеш, эпик иҗаттагы мондый үзгәреш халык тормышын эпик сурәтләүнең дөньяны исламча күзаллауга барып тоташуына бәйле. Шул рәвешле, бик борынгыдан ук килә торган эпик мотив «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә китаби үзгәреш кичерүгә дучар ителгән – максатына җитү юлында каһарманга Аллаһ үзе булышкан.

Әлбәттә, мәсъәләнең чишелешенә Аллаһ ярдәме белән ирешү «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең генә үзенчәлеге түгел. Бу – тормышкөнкүреш шартлары үзгәрү нәтиҗәсендә соңгырак чор эпосында борынгы эпик мотивларның да билгеле бер эволюция кичерүе, эпик чикләнгәнлекнең башка калыпка күчүе нәтиҗәсе. «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә бу үзгәрешләр табигый төс алган, ислам чоры ядкарендә балалы булуга ирешүнең башка альтернативасы юк һәм була да алмый.

«Ләйләнең мәктәбе башланып, Кайсның гашыйк улдыкыдыр» дигән бүлектә укучы-тыңлаучы Ләйлә белән таныша. Ләйләнең гүзәллеген тасвирлауда Борынгы Көнчыгыш әдәбияты традицияләре киң файдаланылган. Аның рөхләре (йөзе) – гөл, саче – сөмбел, бәге гамбәр (чәче хуш исле), кашы камәр (айдай), гамзәсе (керфек кагуы) хәнҗәр, күзләре мәзмүр, ягъни сөрмәле, көмеш тәне, бәдәне бер маһитаптыр (ай нуры). Ләйләнең санап кителгән шушы чибәрлеге көннән-көн арта.

Борһан Шәрәфтә чәчмә юллар белән тасвирланган бу гүзәллекне Низами Ганҗәви сынландыруында карасак, карала торган дастан белән әдәби поэма арасында охшашлык та, зур аерма да булуын күрербез:

С ним вместе обучалась в школе той,
Жемчужной ослепляя крастой,
Дочь племени соседнего одна.
Была она прелестна и умна,
Нарядней куклы и луны светлей,
И кипариса тонкого стройней.
Мгновенный взгляд, скользящий взгляд ее
Был, как стрелы разящей острие.
Газель с невинной робостью в глазах
Властителей земли ввергала в прах.

Арабская луна красой лица
Аджамских тюрков ранила сердца.
В кудрях полночных лик ее сиял,
Казалось – ворон в когти светоч взял.
Медвяный ротик, сладость скрыта в нем,
Был чуть приметным оттенен пушком[1].

Игътибар итсәк, татар кулъязмасында сурәтләнгән Ләйләнең чәче – сөмбел. Сөнбел – хәзерге татар телендә дә кулланыла торган фарсы сүзе, «башак, ашлык башагы» яисә гиацинт исемле чәчәк дигән мәгънәсе бар, «сөнбелә» рәвешендә исә август ае һәм шулай ук ашлык башагы дигән мәгънәне белдерә[2] Ефәктәй тере, алтындай ялтырап торган кызлар чәчен сөмбел белән чагыштыру – төрки халыклар фольклоры һәм әдәбияты өчен традицион сурәтләү чарасы. Татарларда аксыл чәчле кыз балаларны сөмбеләгә тиңләү, аксыл йөзле балага Сөмбелә, Сөмбел исемнәре кушу гадәте әле хәзер дә бар. Татар кулъязмасында тасвирланган Ләйләнең дә чәче сөмбел белән чагыштырылган. Бәс шулай икән, татар Ләйләсе кара түгел, ә ак тәнле, саргылт чәчле итеп күзаллана.

Ә Низами Ләйләсенең исеме җисеменә тәңгәл (Ләйлә – төн, караңгы төн дигән сүз[3]. Төн – караңгылык символы, димәк, чыннан да, кара чәчле кыз балага күбрәк туры килә. Низамида кызның төндәй кара чәч бөдрәләре арасыннан ап-ак йөзе балкып торуы гаҗәеп осталык белән күз алдына бастырылган: «Казалось – ворон в когти светоч взял». Низами Ләйләсе, шиксез, брюнетка булып чыга.

Борһан Шәрәф текстына кайтсак, биредә дә Кайс белән Ләйлә мәктәптә укыйлар, хәтта бер үк хәлфәдән белем алалар. Кайс, Ләйләнең чибәрлеген күреп, бар дөньясын оныта. Ләйлә дә Кайска үлеп гашыйк була. Гашыйкларның бер-берсенә мөнәсәбәтен күреп, «Бу нинди ярамас эш?», дип гаепләүчеләргә алар:

Кил и насих, куй нәсыйхәт, күңелдән бихәбәрсең,
Бәни дивана итте ул, белмәм, нә диярсең сән, –

дип, ике юллык шигырь белән җавап бирәләр.

---

[1] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т.3. перевод с фарси татьяны Стрешневой. М.: Худ. литер., 1986. С.67.

[2] Арабско-татарско-русский словарь заимствований. (Арабизмы и фарсизмы в языке татарской литературы). Т. 2. Казань: Иман, 1993. Б. 533.

[3] Шунда ук. Б. 242.

Тексттагы тезмәләр текстта һәр очракта «бәет сөйләде», «бу бәетне әйтте» рәвешендә китереләләр. Шигъри төзелеше ягыннан алар арасында гарузның рамәл-и мусаман-и махзуф дип атала торган унбишкә унбишле, рамәл-и мусаддас-и салим дип аталган уникегә уникеле, рамәл-и мусаддас-и махзуф дип атала торган унбергә унбер иҗек белән язылган, хазадж-и мусаддас-и махзуф дип аталган кыскарак үлчәмдәге ритм системалары[1] кулланылган. Мәсәлән, рамәлнең унбишкә унбиш белән бирелгән юллары:

И, нәсим, җанны сихерләп, кайдан исеп киләсең?
Былбыл и, кундың бу талга, ни хәбәрең бар сәнең?

Яисә уникегә унике иҗекле калыпка бер мисал:

Үз хәленнән булыр һаман гашыйк сүзе,
Булмас әйтергә торырлык җитди сүзе.

Шул ук вакытта дастандагы барлык тезмә юллар да билгеле бер шигырь калыбына кереп утырган, билгеле бер ритмик системага нигезләнгән дигән нәтиҗәне ясап булмый. Борһан Шәрәф кулъязмасында төрле урында очрый торган шигырь юлларында ритмик системаның гаять чуар булуын искәртеп үтәргә кирәк. Биредә борынгы төрки-мөселман шигырь төзелешендә кулланылган гарузның төрле үлчәмнәре, ягъни төрле вәзеннәре кулланылыш тапкан, гаруз дип бәяләп булмый торган үлчәмнәр дә шактый. Һәр мисрагъ, ягъни бәетнең бер строфасы гаять ирекле төзелгән. Әйтик, күп очракта шигъри юллар унбишкә унбишле иҗеккә туры килсә дә, еш кына бу кагыйдә сакланмаган, мисрагъка артык иҗекләр килеп кергән. Менә, мәсәлән:

Яндырырмын гөрләтеп ут, мәхшәр-гарасат көннәре,
Күкрәгемнән китмәс әгәр бу авырлык – аерылу.

Монда унбишкә унбишле иҗек рәтенә уналтыга унбишлесе килеп кергән. Шунда ук тугызга ун, унбергә ун, унбергә тугыз, унга сигезле мисрагъларны берләштергән бәетләр дә бар. Әйтик, бер урында мондый юллар китерелә:

---

[1] *Курбатов Х.* Ритмика татарского стиха. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2005. Б. 28–51.

Җан бәлагә очрагач, и дуст,
Рәхәт көенеч булды миңа, и дуст.
Чибәрлегең белән күңелем биләдең,
Корбан булсын җаным синә, и дуст.
Синең өчен тулаштым мин, күрәсең,
Кил, мәрхәмәт ит миңа, и дуст.

Билгеле бер шагыйрьнең индивидуаль иҗаты өчен мондый стиль чуарлыгы әдәби нормаларга сыешмый, әмма фольклор белән бәйләнеш тота торган иҗат стиле буларак әлеге төрлелек җиңел кабул ителә. Борһан Шәрәф кулъязмасында урын алган тезмә юлларга ясалган күзәтү дастанда гаруз үлчәме системасының камиллектән ерак булуын күрсәтә.

Шигъри юлларда гаруз куллану белән бергә автор-күчерүче силлабик иҗатка да тартылган. Синтаксик һәм фонетик стилистикасы җәһәтеннән шигъри өлешнең гел бер үлчәмгә генә нигезләнмәве һич кенә дә стильнең тотрыклы булмавы түгел, ә бәлки әсәрнең нәкъ менә фольклор белән бәйләнешен югалтып бетермәү нәтиҗәсе ул. Мондый стиль чуарлыгы татар дастани эпосында, бигрәк тә аерым авторлар эшкәртүенә нык дучар ителгән романик әсәрләрдә еш күзәтелә. Моны шул ук «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең төрле кулъязмалары, шулай ук «Таһир – Зөһрә» сюжетлы кулъязмалар, «Шаһсәнәм һәм Гариб»нең М. Юмачиков варианты, хәтта шигъри эшләнеше шактый камил саналган «Бүз егет» дастаннарының стиле үк раслый.

Бер стильдән җиңел генә башкасына күчеп кую, бер үк әсәр эчендә төрле үлчәмдәге бәет-шигырьләрдән текст төзү Идел буе татарларында таралган дастаннар өчен табигый күренеш саналган. Текстның мондый катнаш ритм һәм рифмага ия булуын татар китаби дастаннарына гомумән хас үзенчәлекле билге буларак та күрсәтергә мөмкин.

Текстта төрле ритмик системага карый торган тезмә юллар чәчмә өлешләр белән аралашкан.

Әсәрнең проза белән бирелгән өлешенең күп урыннарында дастан теленең гаять дәрәҗәдә сурәтле булуына игътибар итми мөмкин түгел. Монда гашыйкларның бер-берсенә сәламен «җан зөлфенең исе белән» җил китерә; Ләйлә ягыннан очып килгән күгәрченнәр кошларның канатлы булуларына кызыгып торучы Мәҗнүннең «күңеленә утлар ташлый»; гашыйкларның «һиҗранлы (аерылудан

хәсрәтле) күзләреннән энҗү danәсе кеби яшьләре ага», Ләйләнең матурлыгы «айның ундүртенче кичәсе» белән һ.б. чагыштырыла; Мәҗнүн «хәсрәт уты чигә», гашыйклар вафатыннан соң аларның «рухлары кошы кавышу галәменә оча» һ.б.

Мәҗнүннең проза белән әйтелгән сүзләре төгәлләнгән монолог кебек кабул ителәләр. Әйтик, Ләйләгә әйткәненнән бер өзек: «...Мөбарәк җәмалыгызны күрмәк идем. Хакка шөкерләр кем, ул дәүләткә ирештем вә сине күрдем. Морадым улды. Янында утырдым, әмма хакыйкатьтә үземдә җан әсәре калмады...» һ.б. Мәҗнүн лексикасында күп очракта халыкның эпик иҗатында очрап куя торган сарыннар характерындагы монологка да юлыгырга мөмкин. Әйтик, үзен үгетләргә килгән Зәеткә ул болай ди:

– И Зәет! Мондый сүзләр күптер. Бу сүзләрне сөйли торган кеше син түгелсең. Әгәр җанымнан хәбәр илә килгән булсаң, мине үз хәлемдә калдыр, чөнки синең аңлавың кыйсса түгелдер. Ашау-эчү кайгысында булган кеше гашыйк була алмас. Кыяматкә кадәр мондый гашыйк даирәсен төшеңдә дә күрмәдең».

Геройның теле искиткеч дәрәҗәдә тәэсирле, образлы. Стилистик төзеклек, сурәтлелек, әдәплелек белән сугарылган мондый сөйләм – укымышлы югары даирә сөйләменә хас китап стиле. Эмоциональ-экспрессив тәэсир итүгә корылган мәхәббәт дастаннарында геройларның мондый сөйләме – әдәбилеккә омтылу яралгысы. Әмма сурәтләү чаралары аша образлылыкны бирү биредә оригинальлектән бик ерак, чөнки әсәр телендәге сурәтләү чаралары әсәрне камилләштерүгә көч керткән, сюжетны яңача иҗат итүдә катнашкан аерым шәхесләрнең шәхси табышы дип бәяләнә алмый. Күздән яшь китерерлек эмоциональ тасвирның нигезендә борынгы төрки-мөселман әдәбияты традициясеннән килә торган сурәтләү чаралары ята.

Дастан вакыйгаларына әйләнеп кайтсак, мәхәббәттән Кайс шулкадәр бәргәләнә, мондый көчле хисне аның психикасы хәтта күтәрә алмый башлый. Ул, сахрага китеп, хәленә туры килә торган шигырьләр сөйләп йөри, әкренләп авыруга сабыша. Кайсның атасы, улының дәртле гыйшкыннан хәбәрдар булып, Ләйләне Кайска хатынлыкка бирүне сорап килә. Ләйләнең атасы, «Кызыбыз бик яшь әле» дигән сылтау белән, кызын дивана-дәрвишкә бирүдән баш тарта. Кайс кабиләсе, Ләйләдән өмет өзеп, кайтып китәләр.

Сюжет Низами әсәреннән әллә ни аерылмый, әмма Низами сюжетыннан үзгә булган урыннар да шактый. Низами варианты,

авторның оригиналь әсәре буларак, вакыйга уңаеннан автор тарафыннан бирелгән бәягә, индивидуаль фикергә, персонажларны гәүдәләндерүдә психологик сурәткә һ.б. нечкәлекләргә гаять бай. Борһан Шәрәф вариантында исә вакыйгаларны сөйләү никадәр генә эмоциональ булмасын, асылда тасвир нейтраль характер ала.

Мәсәлән, кызны сорап килеп тә максатларына ирешә алмаган кабилә өйрәнелә торган текстта сүзсез кире борыла, Кайска: «Ләйләдән гүзәл кыз алырбыз» кебек нәсихәтләр бирәләр. Низамида исә кыз ягының авыру кияү егетеннән баш тарту моментына аерым әһәмият бирелгән. Монда кыз ягы, татар дастанындагы кебек: «Эшеңне үти алмыйм, кичер. Хәтереңез калмасын! Кызын диванага бирде дип телләрдә дастан булудан куркам» кебек сүзләр сөйләп, хәтер саклап тормый. Җавап шактый кискен яңгырый:

Пусть благороден ваш старинный род,
Но сын твой болен, слух о том идет.
А если он безумьем одержим,
Мы за него Лейли не отдадим.
Лечи его молитвой и постом,
Повремени пока со сватовством.
Не предлагай нам жемчуг свой больной.
Не затевай напрасный торг со мной.
С изъяном жемчуг темен, не блестит
И ожерелья он испортит вид[1].

Тискәре җавапны ишеткән егет ягы кичергән халәт тә биредә җентекле һәм максатчан тасвир ителгән:

Отказ услыша, каждый амирит
Почувствовал и боль, и жгучий стыд.
Обиженно, окольной стороной,
Вернулись амириты в край родной[2].

Низами поэмасында сюжетның психологик моментлар белән баетылган, әдәби тасвирга мөрәҗәгатьнең классик дәрәҗәдә эшкәртелгән булуын күрәбез. Татар кулъязмасында мондый нечкәлекләргә урын бик күп бирелгән дип әйтеп булмый, әсәр укучының

---

[1] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т. 3 / перевод с фарси Татьяны Стрешневой. М.: Худ. литер., 1986. С. 80.

[2] Шунда ук. Б. 81.

сөйләнгән вакыйганы эмоциональ кабул итүен күздә тотып, вакыйгалар турында читтән торып тасвирлауга корылган.

Дастани эпос героеның кыз ярәшү-кыз алу сюжетына бәйле маҗаралары һәр халыкта актуаль саналып, бик күп дастаннарда чагылыш тапкан. Романик дастаннарда да очрый торган бу сюжет героик эпостагы кәләш эзләү, батырларча өйләнү сюжетын хәтерләтә. Фольклористикада әлеге сюжетның борынгы мифтан үсеп чыкканлыгы мәгълүм[1]. «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә бу сюжет бар һәм ул мәңгелек мәхәббәт темасы белән баетылган, теләгәне белән кавыша алмау, сөйгәненнән аерылу мотивлары аша бирелгән.

Кайс белән Ләйлә бер-берсенә тартылалар, берсен-берсе сөяләр, әмма кызның атасы һәм кыз кабиләсе яшьләрнең бәхетенә каршы төшә. Бу ике яшь кешенең бергә булганда гына тынычланып, үз бәхетен табачагы, киресенчә булганда фаҗигагә киләчәге әсәрдә мантыйкый ачык. Шулай булса да, каршылык барыбер тудырыла. Кызларын бирүдән баш тартып кына калмыйча, Ләйлә кабиләсенең бай, көчле кабилә баласы булган Кайсны үтерү уе белән йөрүләре («Ләйләнең кабиләсе Мәҗнүнне үлдерергә касд итте (ният итте, уйлады)») бөтенләй аңлашылмый. Юкса текстта Мәҗнүннең атасы «җиһанда һичбер мохтаҗлыгы булмаган», «гаять маллы һәм дәүләтле» олы әмир буларак тасвирлана. Бай әмир белән дошманлык кылганга караганда, кызны бай баласына бирү хәерлерәк чишелеш булыр иде, әлбәттә. Логик яктан акланмый торган әлеге каршылыкны Ф. Урманчеев «дастандагы әкияти-мифологик, ә бәлки шигъри-мифологик фикерләү нәтиҗәсе» дип аңлата[2]. Ягъни бу дөньядагы кавышу – ул әле кавышу түгел, шуңа да әсәрдә конфликтның ничек чишелүе бу очракта әллә ни роль уйнамый. Аның каравы, гашыйклар үлгәч, «Мәҗнүннең якыннары сөякләрен Ләйләнең мәзаре янына дәфен итеп (җирләп), ике гашыйкны бер йиргә китерделәр. Вә болар инде чын кавышуга ирештеләр». Ләйлә белән Мәҗнүннең чын кавышуы башка дөньяда – ислам мифологиясе яссылыгында карасак, Ахирәттә, ә мәҗүси мифологиядән аңлашылганча, Җир асты патшалыгында тормышка аша. Көнчыгышның күпләгән эпик язма истәлекләрендә мифологик теге дөнья һәм бу дөнья сюжеты, алар арасындагы каршылык,

---

[1] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда. Т. 2. (Д–С). Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 194.

[2] Шунда ук. Б. 195.

конфликтның фәлсәфи чишелеше татар кулъязма дастанында әнә шул рәвешле чагылыш тапкан.

Ләйлә белән аерылу хәсрәтеннән сөйләгән бер шигырендә Мәҗнүн болай ди:

> Башым өстендә оясын ләйләк ясаган булса да,
> Гәр төшерсә күләгәсен кош һома, ачылыр өмид.

«Ләйләк», «һома кошы» – шулай ук мифология белән бәйле образлар. Ләйләк (ә бәлки ләк-ләк?) ясаган оя гыйбарәсен Ф. Әхмәтова «башына кайгы төшү мәгънәсен аңлаткан шигъри сурәт» дип аңлата[1]. Ә «кош һома» – «бәхет кошы». Күләгәсе кемгә төшсә, шуңа чиксез бәхет китерә дип саналган мифик кош»[2]. Кош – халыкара мифологиянең гаять популяр символы. Татар мифологиясе һәм фольклорында да күп төрле мөнәсәбәттә кулланыла. Шулардан һома кошы, һомай – аеруча тирән мифологик мәгънәгә ия борынгы образ. Ф. Урманчеев һәм М. Бакиров аны Иран мифологиясеннән килә дип күрсәтә[3].

Күп кенә галимнәр фикеренчә, бәхет кошы дип саналган Һомай кошы белән борынгы төркиләргә яхшы таныш Умай алиһә образы арасында бәйләнеш бар. «Умай – борынгы төрки мифологиядә хатын-кыз башлангычын гәүдәләндерүче образ, үрчем, уңдырышлык алиһәсе. Орхон ташъязмаларында каганның анасын мактау өчен «Умайга тиң» дигән чагыштыру кулланылган»[4]. Һомай кошы да борынгы төркиләрдә уңыш китерә торган образ буларак мәгълүм. Кемнеңдер башына Һомай кошының күләгәсе төшсә яисә шул кош иңеңә килеп кунса, ул бәхетле булачак , дип уйлаганнар[5].

Дастанда геройның Һома (Һомай, Һумай, Һумайун) кошы күләгәсе төшүгә өметләнүе – әсәрдә мифологик ышану чагылышына мисал. «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә очрый торган әлеге мифологик деталь борынгы Көнчыгыш сюжеты аша кергән булуы ихтимал. Әмма Низами поэмасында да, башка авторларныкында да бу образга юлыкмадык. Шулай булгач, кош һомай һәм аның бәхет китерә

---

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 370.

[2] Шунда ук. Б. 370.

[3] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда. Т. 3. Казан, 2011. Б. 148, 195; *Бакиров М.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 44.

[4] *Мәхмүтов Х.* Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкарьләрендә афоризмнар). Казан: Фикер, 2002. Б. 145, 152.

[5] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. 3. Казан, 2011. Б. 148.

торган күләгәсенә ышану татар кулъязмасына җирле мифологик ышанулар аша да кергән булырга мөмкин. Һомайның борынгы төрки мифологиясендә дә, борынгы Иран, фарсы чыганакларында да телгә алынуы «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанына төрки мифологиясе дә, ислам мифологиясе дә тирән йогынты ясаган булуны күрсәтә. Шул рәвешчә, дастанның мифологик нигезләре шактый тирәннән килүе аңлашыла.

Монда ислам йогынтысы һәм ислам мифологиясенә килсәк, әлеге катлам дастанда артык тирән яшерелмәгән. «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә Хак тәгаләне искә алу, Аллаһ ярдәменә өметләнү, төп каһарманның һәм аның атасының хаҗ кылуны ният итүе һәм хаҗ сәфәре кылулары, вакыт бүленешен «ахшамга кадәр», «ахшамнан соң», «кыяматкәчә» кебек дини төшенчәләр аша ачыклау-аңлау (мондый элементны алдарак татар дастаны «Каһарман Катил»дә күзәткән идек), ислам гадәтенчә, кызны ярәшү-никахлап алу тәртибе, ниһаять, иң зур бәхет ул – теге дөньяда табылачак бәхет дигән фикернең уздырылуы шул хакта сөйли. Димәк, ислам мифологиясе әсәрнең иң өске катламында тора. Дастан ике гашыйк тормышында булган гаять әһәмиятле вакыйганы ислам мифологиясе элементларын кулланып сурәтли.

Татар китаби дастаннары традициясендә зур әсәрдән кечерәк күләмле әсәр аерымлану күренешенә алдагы бүлекләрдә шактый киң тукталган идек. «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең Борһан Шәрәф кулъязмасында әлеге традиция барлык тулылыгы белән күренә. Дастанның зур күләмле һәм катлаулы эчтәлекле булуы әлеге традициянең тормышка ашырылуына шактый мөмкинлек тудырган. Биредә аерым сюжетлар «әлкыйсса» исеме белән дә, «хикәят» дип тә аерымланган.

Менә, мәсәлән, «Мәҗнүн вәхши хайваннар белән дуслыкта булып, даимә яннарында торуы» дигән исем астына туплап бирелгән бүлек эчендә мөстәкыйльлеге ягыннан әсәрнең алда сөйләнгәннәрдән күпкә аерылып тора торган шундый хикәят аерылып чыккан. Бу бүлектә Мәҗнүн, кешеләрдән читкә – тауларга китеп, Ләйләгә гыйшкыннан аңы китеп йөргәндә, анда хайваннар белән дуслаша. Үз ризыгын алар белән бүлешеп ашый, җәнлекләрне кулга ияләштерә. Хайваннар да, әлбәттә, ашатучыларын үз итәләр – Мәҗнүн кая барса, аның артыннан калмый ияреп йөриләр. Хайваннарның, ризык хакын белеп, Мәҗнүннән аерылмый йөрүләре дастаннан аерымланып бирелгән хикәят мисалында укучыга җиткерелә. Хикәят

үзенең эчтәлеге белән дастанда сөйләнә торган вакыйгаларга бәйләнмәгән. Аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт.

Бер патша, тамаша кылу һәм теләгән кешеләрен җәзалау максатыннан ач арысланнар тота торган була. Чишендереп арысланнар алдына атылган кешене усал арысланнар шул минутта өзгәләп ташлыйлар. Патшаның бик акыллы һәм һөнәрле егете, бердәнбер көнне шушы язмышның аңа да килергә мөмкин булуын аңлап, арысланнар караучыга бүләкләр бирә. Арысланнар караучы исә егетнең еш кына арысланнар янына килеп, аларны сыйлавына күз йома. Егет килгән саен арысланнарга куй ите китерә, аларны сыйпый, әкренләп кулга ияләштерә. Шул рәвешчә, патшаның акыллы егете ерткычлар белән арасын ныгыта.

Алга таба хәлләр нәкъ егет уйлаганча килеп чыга: бер көн патша, егеткә ачуы чыгып, аны да арысланнар алдына ташларга боера. Арысланнар аңа тими. Егет исән кала. Тамаша кылучылар егетнең бер төгенә дә зыян килмәвенә, сау-сәламәт калуына гаҗәпсенәләр. Яраткан колының сөякләрен булса да җыеп җирләргә боерган патша да бу хәлне күрә. Бик аптырап, егетнең исән калуы сихерме, бер-бер догамы булуы белән кызыксынгач, акыллы егет исән калуының сәбәбен аңлатып бирә.

Әлеге хикәяттән соң дастан кабат Ләйлә-Мәҗнүн сюжетына әйләнеп кайта. Низамида да бу сюжет бар[1]. Поэмада ул «притча» (мәсәл, гыйбрәтле хәл) дип исемләнеп, аерым бүлек итеп бирелгән. Низами притчасында арысланнар урынына явыз этләр турында сөйләнә, тиран-шаһ образы, аңа сабак бирүче хезмәтче яшь егет образы, шаһның егеткә булган аеруча әйбәт мөнәсәбәтеннән көнләшүче хезмәтчеләре, егетнең шаһка биргән сабагы турында шигъри юлларда гаять сурәтле тасвир тудырылган, притчадан нәтиҗә чыгарылган, социаль тигезсезлек, кешелеклелек проблемаларына игътибар юнәлтелгән, үгет-нәсихәт бирелгән. Притча поэма стиленә тулаем ярашкан, әсәр вакыйгаларына шигъри осталык белән китереп бәйләнгән:

Постигнуть смысл сей притчи поспеши:
«Благодеянье – крепость для души».
Меджнун кормил зверей, за это он
Был как стеной их дружбой огражден.

---

[1] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений: в пяти томах. Т. 3 / перевод с фарси Татьяны Стрешневой. М.: Худ. литер., 1986. С. 188–191.

Ә татар кулъязмасындагы хикәяттә тенденциозлык әллә ни чагылыш тапмаган, патшаның рәхимсезлегенә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә бәя бирелмәгән, ахырда Мәҗнүнгә ияреп йөри торган хайваннарның да, шушы хикәяттәге кебек, «нигъмәт хакын белүләре», шуңа күрә Мәҗнүнне үз итүләре турында әйтеп, сюжет кабат дастан вакыйгаларына әйләнеп кайткан. Эпик тасвирлауның нейтраль позициядән яктыртылуы – халык иҗатына хас алым. Бу җәһәттән Б. Шәрәф кулъязмасы эпик иҗат традицияләрен саклаган.

Зур дастаннан кечкенә хикәят аерымлануны алдарак төрки героик эпосына хас цикллаштыру, зур сюжеттан кечерәге аерымланып, мөстәкыйль әсәр булып популярлашу традициясеннән килә дип күрсәткән идек. Эпосның сөйләмнән язмага күчү процессында әлеге традиция бик нык тарайган. Татар дастаннарында сюжетка килеп керә торган мондый хикәятләр еш очрый, әмма аларга чагыштырмача бик кыска урын бирелә. Без моңа мисалны «Чура батыр» дастанында да күргән идек. Чура батырга багышланган дастанда, Нарык читкә киткәч, аның хатыны янына хан (яки ханның улы) килә. Миңлесылу, ханны ниятеннән кире кайтару уе белән, аңа кыйсса сөйли. Кыйссада сүз бүредән калган ризыкны ашаудан баш тарткан арыслан турында бара. Татар версиясендә Миңлесылу белән хан арасында булган сөйләшүдә шушы кыйссаның кечкенә сөземтәсе генә сакланып калган булса, эпос әйтүче чичән авызыннан язып алынган версияләрдә исә кыйссага шактый зур урын бирелгәнен күрәбез. Әйтик, кырым татарлары «Чура батыр»ында Миңлесылу белән хан улы диалогында Миңлесылу сөйләгән кыйсса шуңа мисал була ала[1].

Татар кулъязмасында сюжет Низами поэмасы белән гаять охшаш булса да, һәр ике әсәрдә вакыйгалар гел параллель бара дип әйтеп булмый. Мәсәлән, поэмадагы сюжеттан аермалы буларак, Борһан Шәрәфтә Мәҗнүн Нәүфәл кызына өйләнми, сюжет башкача юнәлеш ала. Мәҗнүн, Нәүфәлгә хәтере калып, кабат сахрага китә. Ахырда, Ләйләнең вафатын ишетеп, Ләйләдән читтә түгел, ә Ләйлә кабере янында үлә. Поэмада Зәед, Ләйлә белән Мәҗнүннең җәннәткә эләгеп, ахирәттә бәхетле булуларын төшендә күрә,

---

[1] Кырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгы / төз. Джафар Бекиров. Ташкент. Укитувчи, 1991. С. 57–72.

«Весь мир земной – всего лишь тлен и прах,
А чистота и вечность – в тех мирах»[1], –

дип нәтиҗә ясала. Борһан Шәрәфтә шул ук фикер алга сөрелсә дә («вә инде чын кавышуга ирештеләр»), чын бәхеткә теге дөньяда гына ирешеп була дигән идеяне Зәеднең төш күрүе аша укучыга җиткерү биредә юк. Алдарак Ф. Халидинең тәрҗемә варианты буларак каралган текстта исә Низами поэмасындагы төш күрү эпизоды барлык тулылыгы белән китерелгән.

Татар дастанында Ләйлә, Мәҗнүннең үзе хакында сөйләгән бәетләрен ишетеп, аларга каршы үзе дә сөйли. Әйтик, кешеләр авызыннан Мүҗнүннең үзе хакында җырлаган җырларын ишетеп, Ләйлә аларга каршы җыр белән җавап бирә:

Ярабби, дәртемә мәдәт дәрманымны күстәр!
Я җанымны ал, я җананымны күстәр!
Ягкуб сыйфатындай күзләрем ачылсын,
Еглатма мине, Йосыф Кәнганыны күстәр!

Ләйлә җавабының эчтәлегенә игътибар итсәк, биредә Ләйлә – Мәҗнүн сюжетына бөтенләй чит сюжет элементлары килеп кергәнен күрәбез. Татар укучысы «Ләйлә белән Мүҗнүн» кулъязмасына кадәр «Йосыф кыйссасы» белән күп элек таныш булган. Ләйләнең, үзенең хәләтенә туры китереп, Йосыф вакыйгасын исенә төшерүе дә шуны дәлилли. Йосыф белән бәйле сюжет татарларга Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы аша яхшы таныш, шушы ук сюжет соңыннан халыкта әллә ничә вариантта кулъязмалар булып та таралган, «Йосыф китабы» исеме белән кулдан кулга күчеп укылган, көйләп сөйләнгән. Халыкта гаять популяр Йосыф кыйссасы – мәхәббәт темасына багышланган романик дастан. «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанында Ләйлә әйткән җырда телдән телгә күчеп сөйләнә торган шушы дастанның персонажлары искә алынган. Эчке кичерешләрен берәүгә дә сөйләмичә, сөйгәне хәсрәтеннән гел кайгыда йөргән Ләйлә Аллаһыга ялвара, яшерен генә юлга багып, сөйгәне белән кавыштыруны сорый һәм бәет әйтә.

Бер дастанда икенче бер популяр әсәр каһарманнары исемнәрен телгә алу – башка романик дастаннар өчен дә традицион күренеш.

---

[1] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т. 3. С. 304.

Мәсәлән, «Шаһсәнәм һәм Гариб» кулъязмасында (М. Юмачиков варианты) Гарибнең вафаты уңаеннан Акча кыз, аларның да дөньядан кичкән булуларын мисал итеп китереп, Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасы каһарманнары Җәмшидне, Рөстәмне телгә алган бәет әйтә. Низами Ганҗәви «Ләйлә белән Мәҗнүн»енең «Об отказе от служения царям» дип исемләнгән бүлегендә дә, укучыга үгет-нәсыйхәт бирү максатыннан, «Шаһнамә» Җәмшиде телгә алынган:

Стань тем лучом, что согревает мир,
Не для тебя Джамшида пышный мир.

Шулай итеп, бу һәм башка мисаллар мондый алымның Урта гасыр әдәби ядкарьләренә гомумән хас булуын раслый. Татар романик дастаннарына да мондый традиция нәкъ менә язма поэмалар аша килеп кергән. Урта гасыр язма истәлекләре белән таныш татар укучысы, шул ук сюжетка үз җирлегендә яңа әсәр иҗат иткән вакытта, гомумбилгеле популяр әдәби образларны мисалга китерә, шул рәвешле үз әсәренең тәэсир көчен арттырырга тырыша. Татар дастаннарында әдәби әсәр персонажларына мөрәҗәгать Идел буе татарларында дастани иҗатның язма культура белән тыгыз бәйләнештә булуын ассызыклый, дастани иҗатның авторлы әсәрләргә хас алымнарны җиңел үзләштерүенә мисал булып тора. Шул ук вакытта Ләйләнең, Йосыф, Ягъкуб образларын да телгә алып, Мәҗнүнгә җыр белән биргән җавабы әлеге сюжетка башка халыклар версияләре арасында татар версиясе табышы буларак бәяләнергә хаклы, чөнки эчтәлеге белән моңа охшаш җыр башка версияләрдә, шул исәптән авторлы поэмаларда да табылмады.

Ә менә Мәҗнүн белән Ләйләнең бер-берсенә сәламнәрен җырбәет аша ирештерүләрен ике кеше арасындагы шигъри диалогтан гыйбарәт эпик элемент буларак карасак, «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең татар кулъязмасында каһарманнар сөйләме бирелешенең («Ләйлә бәет әйтте», «Мәҗнүн бу бәетне әйтте») соңгы чор китаби дастанында фольклор чагылышы, төрки эпос традициясе тәэсире булуы исбатлана.

Татар халык иҗатының төрле жанрларында, әйтик, Нәүруз йола бәйрәме вакытында кара-каршы шигъри сөйләшү, сөрән салу йола бәйрәмендә сөрәнчеләр һәм хуҗаларның үзара шигъри диалогы, туй йола фольклорында (кыз елату җырларында, туй йоласы белән бәйле «Яр-яр» җырларында, кыз һәм егет ягының табын җырлары аша

үзара әңгәмә корулары һ.б.), уен иҗатында, балалар фольклорында очрый торган һәм күп кенә очракта фольклорда кайбер жанрларны оештыруда төп чара булып торган җыр әйтешеп аңлашу, җырлы сөйләм аша тирә-юньгә мөнәсәбәт белдерү бик еш күзәтелә.

Мондый драматик күренешләр фольклорда драма (драма – гр. drama – грек теленнән кергән сүз , хәрәкәт дигәнне аңлата) башлангычы булуга ишарә итә, әмма күргәзмәле тамаша фольклорда махсус рәвештә тудырылмый, мондый җырлы әңгәмәдә катнашучылар шартлы рольләр башкармый. Күп кенә очракта фольклорда драмага хас элементлар мифологик ышанулар белән бәйле булып, тамашачыга уйнап күрсәтү өчен түгел, ә миф-йола традициясендә, борынгы ышанулар белән бәйле башкарыла.

Шушындый драматик төсмерләрне дастаннардагы геройлар арасындагы шигъри әңгәмәдә дә очратырга мөмкин. Борынгы дастаннардан «Ак Күбәк»тә, мәсәлән, Ак Күбәк белән Мангышның әйтеше, «Йиртөшлек»тә каһарманга юлда очраган карчыкның, кара кошның шигъри җавабы, «Алыпмәмшән»дә ирен эзләп килеп тә, кире борылып кайтып киткән хатыны Мәрҗәнсылуга мөрәҗәгать итеп, Алыпмәмшән әйткән җыр-монолог, соңгырак чор китаби дастаны «Күр углы»нда Күр углының Ага Чауз белән тезмә юллардан торган әңгәмәсе сакланып калган. Героик эпостагы бу традиция социаль




kөнкүреш темасын ача торган соңгырак чор романик дастаннарында да дәвам иткән. Димәк, дастани эпоста каһарманнарның үзара җыр әйтешеп сөйләшүләре, бер-берсенә биргән җавапларының «аңа каршы җыр белән әйтте», «аңа карап әйтте», «бу бәетне әйтте», «җыр әйтте», «гарыз әйтте» дип бирелүенең тамырлары фольклор традицияләренә барып тоташа.

Татар дастаннарында мондый драматик элементлар миф-йола традициясе белән бәйле дип әйтеп булмый, әлбәттә. Кара-каршы җырлашып сөйләшү дастаннарда, бигрәк тә соңгы чорга карый торганнарында борынгы ышанулардан чыгып башкарылмый, әлеге жанр миф-йола иҗатыннан күптән аерылган. Фольклорда гаять популяр булган шигъри диалоглар халыкның эпик иҗатына хас кара-каршы әйтешеп җырлау яисә сөйләү традициясе белән тирәнтен бәйле.

Импровизаторлык сәнгате нык үскән халыкларда җыр яки тапкыр сүз әйтеп ярышу гадәте булган. Шундый сүз көрәштерү мәҗлесләрендә чичәнлек сәләте ачылган. Мәсәлән, казакъ фольклорында мондый әйтешләр (казакъча – айтыс) соңгы чорларгача

сакланып калган, анда катнашучыларны акыннар дип йөртәләр[1]. Әйтеш текстлары безнең гасырда казакъ галимнәре тарафыннан казакъ телендә бастырып та чыгарылган[2]. Сүз көрәштерү ярышы, оста сөйләү бәйгесе, ике кешенең җыр әйтеп диалог корулары, табигый, дастан сюжетына да үтеп кергән. Үзара җыр әйтешеп сөйләшү күп кенә очракта эпос-дастанның стиленә дә әйләнгән. Төрки героик һәм романик эпосында әлеге традиция бик нык таралган, тотрыклы урын алган. Татар халык иҗатында мондый төр бәйгеләрнең үткәрелүенә турыдан-туры мисалны халык әкиятләреннән табарга мөмкин. Татар халкының «Өч сорау», «Өч килен», «Укымышлы кыз», «Мәгънәле кыз» һ.б. әкиятләрендә төрле максат белән шундый бәйгеләрнең үткәрелүе хакында сүз бара[3].

Татар халкының дастаннарында сүз әйтешү ярышы нигездә әсәрнең стилен чагылдыра торган чара буларак кына сакланган. «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанында Мәҗнүн белән Ләйләнең бәет әйтешеп аралашулары – моңа мисал. Дастанда кара-каршы җыр әйтешүгә мисаллар бар, әмма кайбер романик дастаннардагы кебек (әйтик, «Бүз егет»), сюжет тулысынча мондый алымга корылган дип тә әйтеп булмый. Алай да дастанда шигъри диалоглар шактый әһәмиятле урын алып тора. Кем дә булса Ләйлә турында сораганда Ләйлә турында яки аңа багышлап Мәҗнүн сөйләгән бәетләр әсәрдә еш китерелә, ә Ләйләнең аңа җавабы сюжет корылышына бәйле рәвештә генә килеп керә.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»дә каһарманнар сөйләменең җыр-бәет әйтүгә корылган булуына ясалган күзәтү түбәндәге нәтиҗәгә китерә. Дастандагы кара-каршы җыр әйтешү традициясе үзе, шиксез, фольклордан килә. Бу – эпик текст төзүдә катнаша торган традицион алымнарның берсе. Шул ук вакытта әдәби-фольклор персонажлары телгә алынган Ләйлә җавабының эчтәлеге исә әсәр текстының индивидуаль язма иҗат белән бәйләнеше турында искәртә. Дастан сюжетына чит дастан персонажлары килеп керү традициясе – Урта гасыр Көнчыгыш язма әдәбиятыннан соңгырак чор татар романик дастаннарына килеп кереп, халыклашкан элемент. Индивидуаль

[1] *Исмаилов Е.* Акыны. Алма-Ата: Худож. лит., 1957. С. 25–29.

[2] Aitьs (Айтыс). / под ред. Сабита Муканова и Есмагамбета Исмагилова. Т. I. Алма-Ата, 1942; Айтыс. Т. I / под ред. Сабита Муканова. Алма-Ата, 1964.

[3] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 31, 33, 34, 35.

иҗат һәм традицион башлангыч, әнә шулай тирән керешеп, бер үк әсәрдә чагылыш тапкан. Бу – романик характердагы татар китаби дастаннарына гомумән хас күренеш, китаби дастанда әдәби-фольклор элементлары үзара керешеп китүнең ачык мисалы. Монда борынгы төрки эпик традицияләр әдәби-язма традицияләр белән тыгыз бәйләнеп, татар романик дастанында үзенчәлекле бизәк барлыкка китергән.

Татар кулъязмасында мәңгелек мәхәббәт темасы барлык тулылыгы белән ачылган. Бу – Урта гасыр Көнчыгыш һәм татар әдәбиятыннан килә торган тема.

Дастан укучыны Мәҗнүннең һәм Ләйләнең мәхәббәттән ничек тилмерүләрен тасвирлап мавыктыра, аларны кызгандыра. Эмоциональ-экспрессив тәэсиргә ирешү максатыннан Мәҗнүннең суфиларча гашыйклыгы, сөйгәне белән кавышуга ирешә алмаудан газаплануы тасвирлана, әмма Мәҗнүн һичничек тәнкыйть ителми. Шул ук вакытта дастанда Мәҗнүнне авыруга сабышу халәтеннән чыгарырга тырышучы образлар да бар. Ул – улы өчен бик нык кайгырып, малын-мөлкәтен калдырыр кешесен шушы хәлдән чыгарырга омтылып йөрүче атасы, Ләйлә белән Мәҗнүнне кавыштырырга теләп тә, теләгенә ирешә алмаган Нәүфәл, сөйгәненең мәхәбәтеннән елап йөргәнен ишетеп-белеп торучы, аның белән бергә булу теләге белән янучы, әмма атасының бәддогасыннан куркучы, Мәҗнүннән аеручы көчләргә хәленнән килгәнчә каршы торучы Ләйлә, Ләйләгә карата җир кешесенә хас хисләр кичереп, аны яратучы Ибне-Сәлам һ.б.

Әмма Мәҗнүн Ләйлә образы аша илаһи мәхәббәткә омтыла. Дөньяви фикергә, җир кешесе тормышына өндәүчеләргә каршы Мәҗнүннең җавабы: «Минем җананым, бөтен вөҗүде (барлыгы) белән кальбемә (күңелемә) кереп, аңа хәфтан (кием) кеби улмыштыр...». Мәҗнүн, Ләйлә белән үзенең сурәтен күреп, Ләйлә сурәтен бозып ата. Ник болай эшләвенә аңлатма сорагач, ул әйтә: «Мин җананым илә бер улдым. Арабызда синлек вә минлек китмештер», – ди. Мәҗнүн сөйгәне белән рухи кавышуга омтыла. Ул хәтта үлемгә дә суфиларча карый. Ләйләнең атасының гаскәре белән сугышта Нәүфәл гаскәре җиңелгәч, Мәҗнүн, Ләйлә яши торган җиргә килеп, Ләйлә иленә авырлык китерүе өчен гафу сорый. «Һәлак итсәгез дә ризамын, сезнең кылычыгыз миңа әбелхәяттер (тереклек суы)», – дип, Ләйлә капкасы янында үлүне бәхеткә санавын белдерә.

Шулай итеп, Мәҗнүн – мәхәббәткә суфиларча, илаһи якын килүче, ә тирә-юньдәгеләр, шул исәптән Ләйлә дә – җир кешесенә хас реаль мәхәббәт яклы төркем. Әлеге ике төркемдәгеләрнең икесенә дә дастанда кискен бәя бирелми, аларның халәте тәнкыйтьләнми, автор-информант мондый катлаулы мөнәсәбәтләрне нейтраль сурәтләп бирүче позициясендә тора.

Татар дастанында мәхәббәт хисе илаһи хис булу белән бергә җиргә якынрак характерга да ия. Монда мәхәббәтне ике төрле аңлау бар: Мәҗнүнчә аңлау һәм Мәҗнүннең әлеге халәтенә җир кешесе күзләре белән карап аңлау. Дастан эчтәлегендә мәхәббәткә карата әлеге ике төрле мөнәсәбәт кискен аерыла, әмма хикәяләүче боларның берсенә дә өстенлек бирми, һәр очракта объективлыкны сакларга тырыша, субъектив мөнәсәбәтен белдерми, мәхәббәттән газап чигүче ике яшь кешенең бу дөньядагы хәлен тасвирлап, укучыдан аларны кызгандыра. Дастанның сюжет үстерелешендәге әлеге рухны принципиаль саклавы әсәрнең традицион-типик характерга ия булуын күрсәтә һәм аның индивидуаль иҗат белән параллель рәвештә фольклор белән дә бәйләнешен тәэмин итә.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» кулъязмасында яңа вакыйгага керешер алдыннан «шул хакта риваять улыныр», «рави әйтер», «риваять кылыныр ки», «равияни әхбар риваять итте» кебек гыйбарәләр бик еш кулланылган. Булачак вакыйга алдыннан сүзне «әлкыйсса» дип башлау, вакыйганы вакыйгага бәйләп киткәндә эзлеклелекне саклау өчен «шулай булгач, димәк, нәтиҗәдә, күренә ки» дигән мәгънәдәге «бәс» сүзен файдалану да дастанда гадәти алымга әверелгән. Болар – өйрәнелә торган дастанның гына үзенчәлекләре түгел. Бу хакта алдагы бүлекләрдә дә сүз алып барылды. «Ләйлә белән Мәҗнүн» кулъязмасында да шул ук чараларның кулланылуын әсәрне сөйләүчедән ишеткән тәэсирне тудыра торган стиль буларак билгеләп үтәргә кирәк. Мондый чаралар татар китаби һәм романик дастаннарында традициягә әверелгән. Әмма биредә сөйләмә эпос традициясенең Урта гасыр Көнчыгыш поэзиясе стиле белән тыгыз үрелгән булуын да күрми калып булмый. Рави, ягъни төрле вакыйгалар турында хикәят сөйләүче образы белән әдәбият Урта гасыр Шәрык язма әсәрләре аша да яхшы таныш.

Әсәр ахырында кабат килеп кергән Зәед образы Ләйлә – Мәҗнүн мәхәббәте тарихын алдагы буыннарга җиткерүче инфрмант образын хәтерләтә. Гашыйклар вафатыннан соң аның, рухларына дога кылып,

боларның хәлләре турында «назым әйтеп, җиһан халкына дастан ясавы» әйтелә. Зәед дастанда Ләйлә белән Мәҗнүн ваыйгаларыннан якыннан хәбәрдар, аларның бергә булуларына хәерхаһ шәхес буларак тасвирланган иде. Боларның хәлләрен аннан да яхшырак белүче юк, шуңа күрә аның образы ахырда Ләйлә белән Мәҗнүн хакындагы дастанны халыкка җиткерүче буларак тәкъдим ителә. Икенче төрле әйткәндә, фольклорга хас булганча, дастанның беренчел чыганагы барлыгы аңлашылып тора, ул – Зәед.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»нең Борһан Шәрәф архивында сакланган кулъязмасына ясалган күзәтүгә гомуми нәтиҗә ясап әйткәндә, текстны анализлау барышында түбәндәгеләр мәгълүм булды: вариант фольклор материалына нигезләнгән, халыкның эпик иҗатына төрле яклап якын тора, төрки эпос традицияләренә таяна. Дастанның поэтикасында, теләсә кайсы фольклор әсәрендәге кебек үк, тыңлаучыга мөрәҗәгать алгы планга чыгарылган, әсәр укучының текстны укуын гына түгел, ә аудиториянең тыңлавын да күздә тотып иҗат ителгән. Стиле, халык иҗатына хас булганча, гаять дәрәҗәдә чуар. Персонажлар арасында шигъри әңгәмә, эчтәлектә чагылып киткән мифологик карашлар, чорына хас дини катлам, популяр эпик мотивлар әсәрнең халык иҗатына хас синкретик характерда булуыннан килә. Тулаем алганда, әсәр күпчелеккә йөз тотып, халык кызыксынуын, зәвыгын бик нык истә тотып эшләнгән. Әсәрнең үзендә үк дастанны әйтүче информантның кем булуы хакында да мәгълүмат җиткерелгән.

Шул ук вакытта биредә романик китаби дастаннарга хас иң җитди билге – индивидуаль иҗат кырының да гаять көчле үсеш алган булуын күрдек. Әмма шәхсилек сыйфаты биредә башкалар тарафыннан кабатлана алмый торган оригиналь әсәр иҗат итүдә түгел, ә булган әдәби тәҗрибәне иҗади файдалануда чагылган. Низами поэмасы белән шактый зур сюжет охшашлыгы, образлар системасы берлеге, хәтта әсәрнең структур корылышы да татар телле әлеге кулъязманың әдәби чараларны, алымнарны, формаларны актив үзләштергән булуын күрсәтә. Кулъязманың авторы билгеле түгел, «Ләйлә – Мәҗнүн» сюжетына кагылышлы моңа кадәр тупланган бөтенлекне яңа җирлектә яңача яңгырату эшендә берничә кеше катнашкан булырга мөмкин. Безгә билгелесе – авторсыз әлеге нөсхә иң соңыннан Б. Урманче кулы аша үткән, әлеге талантлы шәхес тарафыннан гына да кайбер үзгәртелүләргә дучар булган. Әсәр барлык билгеләре белән

китаби дастан категориясенә туры килә, үзендә тупланган эпик үзенчәлекләре белән татар романик дастаннары рәтен тулылындыра.

Борһан Шәрәф кулъязмасы дастанның татар халкында табылган татар телле башка милли вариантлары белән шактый ук аваздаш. Алга таба, «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына язылып, халык арасында популярлык тапкан башка берничә эпик кулъязмага тукталырбыз. Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтен бәян иткән әлеге хикәят-күчермәләр Борһан Шәрәф кулъязмасыннан күләме, нигездә чәчмә тексттан гына гыйбарәт булуы белән аерыла. Боларның сюжетында да җитди үзенчәлек бар – аларда Низами Ганҗәви, Физули, Нәвои поэмалары белән аваздашлык, дастанның әле генә тикшерелгән варианты белән чагыштырганда, бөтенләй юк. Болар – чагыштырмача мөстәкыйль сюжетлы текстлар.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»нең берничә милли варианты Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге (алга таба – Үзәк) архивында[1], шулай ук Казан (Идел буе) Федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә[2] саклана.

Үзәктә 5014 саны белән теркәлгән вариант безнең көннәргә гарәп язулы борынгы кулъязма составында килеп җиткән. Әлеге кулъязма җыентыкта Ләйлә – Мәҗнүн сюжетына караган тексттан тыш та берничә борынгы хикәя туплап бирелгән. Текстлар барысы да татар телендә. Үзәк фондындагы бу кулъязма 1973 елда Татарстанның Арча районы Түбән Көек (хәзер Әтнә районына керә) авылында табылган. Кулъязманы тапкан кеше буларак, документка текстолог М. Әхмәтҗанов тарафыннан кул куелган.

Кулъязма составындагы Ләйлә – Мәҗнүн сюжетлы әлеге хикәят, М. Әхмәтҗанов һәм М. Гайнетдин тарафыннан текстологик эшкәртелеп, ягъни хәзерге язуга күчерелеп, тексттагы кайбер алынма сүзләргә аңлатмалар белән, 1979 елда матбугатта дөнья күрде[3].

Кулъязмадагы текстның башына «Ләйлә белән Мәҗнүн хикәяте» дигән исем куелган. Текст үзе бит саны күрсәтелмәгән гарәп язулы алты битлек өч кисәк кәгазьдән гыйбарәт. Язу стиленнән чыгып,

---

[1] 39 колл, сакл. бер. № 5014, 5015, 6058, 3164 һ.б.

[2] Фонд научной библиотеки им. Н. Лобачевского КФУ. ОРРК: шифр Т – 493, Т – 497.

[3] *Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М.* Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссаның татарча варианты // Казан утлары. 1979. № 6. Б. 170–171.

М. Әхмәтҗанов бу кулъязманың XVIII йөз ахырларында төзелгәнлеген ачыклаган[1].

Күчерүче кешенең исеме билгеле – Ишнияз бине Ширнияз, истәлекнең бер битендә шушы исем күрсәтелгән. М. Әхмәтҗанов һәм М. Гайнетдин әлеге шәхеснең Ш. Мәрҗани, К. Насыйри хезмәтләрендә[2] телгә алынган Ишнияз бине Ширнияз белән тәңгәл килүен билгелиләр. Алар, югарыда телгә алынган галимнәрнең мәгълүматларына нигезләнеп, Ишнияз бине Ширнияз исемле мөгаллимнең XVIII йөз урталарында Урта Азиядән күчеп кайтканлыгы, кулъязма табылган Түбән Көек авылыннан ерак булмаган Казаклар дигән авыл мәдрәсәсендә, соңыннан, Оренбург якларына күчеп китеп, 1776 елдан андагы Каргалы мәдрәсәсендә укытканлыгы, 1791 елда вафат булганлыгы турында язалар[3]. Әлеге шәхеснең Казан өязе Кариле авылы имамы атаклы Габдессәлам хәзрәт (татарның атаклы шәхесләре турында Ш. Мәрҗани язып калдырган хезмәттә бу кеше мелла Гыйззетдин Габдессәлам бине Хәсән әл-Карили дип телгә алына[4], Р. Фәхретдинов хезмәтләрендә дә аның турында мәгълүматлар табарга мөмкин) белән эшлекле мөнәсәбәтләрдә торганлыгы, мәҗлесләрдә аларның үзара сүз көрәштергән булулары билгеле.

М. Әхмәтҗанов һәм М. Гайнетдин шулай ук: «Кайбер хәбәрләргә караганда Ишнияз бине Ширнияз Кышкарда да укыткан булырга мөмкин», – дип язалар[5]. Бу фаразның ихтималлыгын яклап, Н. Исмәгыйлев «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге китапханәсендә В-3433 саны белән саклана торган кулъязма турында хәбәр итә. «Җыентык үзе, – ди ул, – «Мәҗмугаи хикәйәт мәнкалат вә мөнакиб» («Данлыклы вә файдалы риваять-хикәятләр җыентыгы») дип атала. Китап Кышкар мәдрәсәсендә Мөхәммәдшакир бине дамелла Фәйзулла тарафыннан

[1] *Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М.* Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссаның татарча варианты // Казан утлары. 1979. № 6. Б. 171.

[2] *Мәрҗани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхфәли Казан вә Болгар. II том. Казан, 1900. Б. 216; Насыйри К. Календарь: 1878 елга. Б. 30–31.

[3] *Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М.* Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссаның татарча варианты // Казан утлары. 1979. № 6. Б.171.

[4] *Мәрҗани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 238.

[5] *Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М.* Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссаның татарча варианты // Казан утлары. 1979. № 6. Б. 170.

төзелгән»[1]. Әлеге кулъязмага язылу датасы куелмаган, Н.Исмәгыйлев аны якынча XVIII гасыр ахырларына нисбәт итә. Күчермәнең эчтәлеге белән Түбән Көек вариантына бик нык якын торуын исәпкә алып, бер үк географик атамаларның телгә алынуына нигезләнеп, Н. Исмәгыйлев Петербург кулъязмасын да Ишнияз бине Ширнияз шәхесенә мөнәсәбәтле дип таба.

Чыннан да, Петербургтагы әлеге кулъязманың Ишнияз бине Ширнияздагы вариантыннан турыдан-туры күчерелгән булуы мөмкин. Татар кулъязма дастаннарының укымышлы кешеләр – муллалар, шәкертләр һ.б. тарафыннан куллан-кулга күчереп таралган булуы – китаби дастаннарның халык арасында таралу ысулы булганлыгы һич шик уятмый. Ишнияз бине Ширнияз исеменең «Ләйлә белән Мәҗнүн» кулъязмаларының башкаларына да мөнәсәбәтле булуы (бу хакта сүз дастанның Нәҗип Исмәгыйлев тапкан вариантын тикшергәндә алдарак булыр) әлеге фикерне тагын да ныгыта.

Шулай итеп, күчерүченең Ишнияз бине Ширнияз исемле кеше булуы, аның турында тупланган биографик мәгълүматларның хронология һәм география ягыннан кулъязма күчерелгән чор һәм территория белән туры килү фактлары, бер-берсен тулыландырып, кулъязманың чыннан да XVIII йөз урталарына каравын, бер даирә кешеләре – мәдрәсә укымышлылары арасында күчерелеп таратылу фактларын раслый.

Түбән Көектә табылган хикәят борынгы заманнардагы игътибарга лаек мавыктыргыч вакыйганы укучыга сөйләп җиткерүдән гыйбарәт. Әмма дастан тексты тулысынча сакланмаган, соңгы берничә бит югалган. Әсәр вакыйгалары түбәндәге эзлеклелектә бәян ителә.

Ләйлә дә, Мәҗнүн дә – гаять күркәм яшь кыз белән яшь егет, икесе дә Зәед дигән остазның шәкертләре. Борһан Шәрәф архивында табылган кулъязмада да Зәед образы бар. Ул үзенең әтисе белән бертуганның кызына гашыйк булып, фәкыйрьлеге аркасында кызның атасы тарафыннан кире кагылган, ягъни Мәҗнүн кебек үк бәхетсез мәхәббәткә тарыган, гыйшык уты белән янучы егет буларак тасвирлана. Биредә исә Зәед хәлфә буларак бирелгән, ул ике гашыйкның мәхәббәт тарихын якыннан белүче, бу икәүгә теләктәшлек белдерү-

---

[1] *Исмәгыйлев Н.Ф.* «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетының татарча прозаик версиясе // Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар. Казан, 1991. Б. 7.

че сыйфатларын да үзенә алган. Зәед образы әсәр укучыны тиешле психологик юнәлешкә кертеп җибәрүче ролен дә үти.

Беренче булып Ләйлә Мәҗнүнгә гашыйк була. Аның гыйшкы шулкадәр көчле була, кыз бөтенләй гаҗиз кала. Ни кадәр генә үзенә игътибар иттерергә теләсә дә, Мәҗнүннең аңа күңеле төшми дә төшми. Әлеге кулъязмада, Борһан Шәрәфнекеннән аермалы буларак, егетнең чын исеме, «мәҗнүн» сүзенең нәрсә аңлатканлыгы, ни сәбәпле егетнең исеме Мәҗнүнгә әйләнү турында бер сүз дә әйтелми. Аның исеме беренчел чыганактан ук – Мәҗнүн. Аның кайчандыр Кайс исемле булганлыгы, Бәни Әмир исемле гарәп кабиләсеннән чыгуы һ.б. турында биредә бөтенләй искә алынмый. Мондый үзенчәлек – борынгы гарәп риваятеннән һәм соңрак Низами Ганҗәви һ.б. әдипләр иҗатыннан килә торган традицияләрнең җирле үзгәрешләр кичерүе нәтиҗәсе. Дастан XVIII йөз укучысын күздә тотып төзелгән. Кулъязмага мәдрәсә мөгаллиме Ишнияз бине Ширниязның мөнәсәбәтле булуы дастанның мәдрәсә шәкертләре арасында укылган булуын күрсәтә. Текстның шәкертләргә тәрбия бирү максатын күздә тотып оештырылган булуы да ихтимал.

Дастан вакыйгалары бик тиз алышына, җөмлә саен диярлек укучыга яңа вакыйга җиткерелә, яңа мәгълүмат бирелә. Ләйлә, Мәҗнүнне үзенә гашыйк итә алмау чарасызлыгыннан мөзәйинәгә (косметика табибына) бара, табибтан үзен зиннәтләүне, ягъни кыяфәтен үзгәртүне сорый: «Бәнем кебек җиһанда булмасын», – ди. Табиб моның теләгән үти, күргән һәркем хәйран калырлык кыяфәткә ия булып, Ләйлә өенә кайтып китә. Кайткач, Раббыга ялварып, мондый зиннәтләрне кире алмавын сорый. Таң аткач караса, зиннәтләре китмәгән, аның теләге кабул булган.

Шуннан соң Мәҗнүн, Ләйләне күреп, «мең җан илә гашыйк булды» диелә кулъязмада. Аның әлеге хисе дастанда шулкадәр тәэсирле һәм калку итеп сурәтләнә: Мәҗнүн янына барган кешегә аның сулаган сулышыннан «Ләйлә!» дигән аваз ишетелә торган була, диелә.

Ләйләнең чибәрлегеннән Мәҗнүн чарасыз кала. Биредә дә, Борһан Шәрәф кулъязмасындагы кебек, ике төрле мәхәббәт хисе тасвирлануга юлыгабыз. Ләйлә җир кешесенә хас хис кичерә, хәтта ярамаган адымга барып, кыяфәтен үзгәрттерә, шушы юл белән Мәҗнүннең игътибарын яуларга тели. Теләгенә дә ирешә: Мәҗнүн аңа бихуш гашыйк була. Әмма Мәҗнүннең мәхәббәте Ләйлә мәхәббәтеннән бик нык аерыла. Мәхәббәтеннән Мәҗнүн Ләйлә янына

түгел, ә сахрага чыгып китә. Ләйлә аны, кешеләр җибәреп, эзләтә. Мәҗнүнне «Ләйлә!» дип кабатлап, җирдә аһ-ваһ итеп ята торган хәлдә табалар. Моны ишетеп, йөгереп янына барган Ләйләгә Мәҗнүн әйтә: «И җаным, сән – бәнем, күңелемгә сәнең мәхәббәтеңдин гайри нәрсә сыймыйдыр, сән киткел». Мәҗнүн, әнә шулай, Ләйләгә булган мәхәббәтеннән аһ ора, аның образы белән саташа, ә җисми Ләйләдән баш тарта. Бу – суфичыл әдәбият һәм суфичыл идеяләрнең татар дастанына үтеп керүе, Ләйлә белән Мәҗнүн сюжетына багышланган башка ядкарьләрнең күпчелегенә хас тенденция тәэсире.

Шуннан соң Ләйлә, бик нык елап, өенә кайтып китә, оак та тормый, хәсрәтеннән вафат була. Суфичыл мәхәббәт иясе булуына карамастан, Мәҗнүн аны эзләп артыннан кайта. Аның «Ләйлә кайда?» – дигән соравына каршы мәгъшукасының үлеп китүе хакында әйтәләр. Мәҗнүн, елый-елый, каберләрне зиярәт кыла. Бу урында Мәҗнүннең бер кыз белән сөйләшүе әһәмияткә ия. Кызның кем булуы да, аның Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәте тарихыннан хәбәрдар булуы турында да дастанда алдан берни сөйләнми. Әмма кыз барысын да белә булып чыга. Каберләр янында Мәҗнүн кыздан сорый:

– Әй, кызчыгаз, кани Ләйләнең кабере? Миңа күргәзгел.

Моңа каршы кыз әйтә:

– Мән гашыйкмын, дәю дәгъва кылырсән, хакыйкый мәгъшук улсаң, Ләйләнең каберене белер идең, – ди, Ләйләнең каберен егеткә күрсәтми.

Бу – мәхәббәт хисен җир кешесенә хас сынау чарасы. Ә очраклы тап булган ниндидер бер кыз белән төп каһарманның үзара диалогы исә эпик элементны хәтерләтә. Төрки эпоста читкә чыгып киткән каһарманның юлында кем дә булса (гадәттә ул хатын-кыз була) очрап, каһарманның аның белән әңгәмә коруы дастани эпос традициясенә туры килә.

Мондый эпизод героик эпоста каһарман образын тулы гәүдәләндерү, аның батырлык сыйфатларын тагын да төгәлрәк ачу максатыннан китерелә. Геройның якыннарыннан аерылу күренеше төрки халыклар эпосында бик тәфсилләп, елау-сыктаулар аша бирелә. Әйтик, татар, нугай, казакъ, кырым татарларының Чура батырга багышланган дастаннарында каһарман, Казанга чыгып китәр алдыннан, атасы Нарык, анасы Миңлесылу, кыз кардәше Канибәк, юлда очраган Алтынбикнең, шулай ук очраклы рәвештә юлына

чыккан ниндидер бер киленчәкнең һәркайсы белән аерым-аерым саубуллаша. Аларның үзара әйтешкән сүзләре, мәсәлән, нугай версиясендә, шигъри формада китерелгән булуы белән әһәмиятле. Каһарманның батырлык сәяхәте юлында очраган хатын-кыз белән әңгәмәдән башлану турындагы сюжет-мотив безнең татар дастаннарыннан «Идегәй», «Кузы Көрпә белән Баянсылу», «Таһир – Зөһрә», кыргыз халкының монументаль дастаны «Манас», казакъ халкының «Кобланды батыр» һ.б.ш. әсәрләрдә очрый. Геройга очраган хатын-кыз образы, аның белән корылган әңгәмәнең дастани эпоста шундый әһәмиятле урын алып торуын Ф. Урманчеев түбәндәгечә аңлата: «Төрки дастаннарның күбесендә батырның бүгенгесен һәм киләчәген, гомумән, аның язмышын кыз-хатыннар билгели. Гадәттә дастан батыры анасының, хатынының, апа-сеңелләренең киңәшен берсүзсез тыңларга тиеш. Югыйсә ул, котылгысыз рәвештә фаҗигале үлемгә дучар булачак»[1]. Безнең фикеребезчә, дастанда хатын-кыз образына шактый урын бирелү, аңа карата ихтирам күрсәтү, аннан киңәш сорау һәм ул әйткәннәргә колак салу иң борынгы төркиләрдән үк килә торган гадәт булырга тиеш.

Ә романик «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә каһарманга ниндидер бер кызның очравы, гашыйк каһарманның аның белән әңгәмә коруы Мәҗнүннең мәхәббәт хисен калку сурәтләү өчен бирелгән. Бу кыз нинди кыз, дастан вакыйгалары белән аның бәйләнеше ни дәрәҗәдә – төрки дастаннардагы кебек үк, әсәрдә бу сорауларга ачык кына җавап юк. Әмма образ үзе бар. Кыз Ләйләнең каберен күрсәтми, аның биргән җавабы Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтенең телләрдә риваять урынына сөйләнеп, барлык кешеләргә дә мәгълүм булганлыгын раслый. «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының татар вариантында Ләйләне эзләп йөрүче Мәҗнүнгә очраклы тап булган әлеге кыз образы әдәби версияләрдә очрамый. Әсәрдә аның чагылышы күбрәк төрки эпосы традицияләреннән килә булса кирәк.

Кызның җавабын ишетеп, Мәҗнүн ары китә, Ләйләнең каберен борыны белән иснәп эзли. Йөри торгач, бер кабердән Ләйләнең исе борынына килеп кереп, шул вакытта Мәҗнүн үзе дә вафат була. Ләйләнең кабере ярылып, Мәҗнүн кабергә иңә.

Шуннан соң текстта Зәеднең төш күрүе турында сөйләнә.

---

[1] *Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. 1995. № 10. Б. 95.

Борһан Шәрәфтә төш күрү мотивы бөтенләй юк, дастан текстына Флора Ваһапова аңлатмасында гына Зәеднең төш күрүе, төшендә Ләйлә белән Мәҗнүннең җәннәттә бергә булып, бәхетле гомер сөрүләре хикәя ителгәнлеге хакында мәгълүмат җиткерелгән иде. Ә менә Низами помасында Зәеднең төшенә бик киң урын бирелгәнлеген алдарак карап үттек. Борһан Шәрәф кулъязмасына Зәеднең төше турындагы өлеш Ф. Ваһапова яисә Б. Урманче тарафыннан искәрмә рәвешендә генә нәкъ менә Низами поэмасы тәэсирендә кертелгән булырга мөмкин.

Тикшерелә торган текстта Зәед төшендә зур бер бакча күрә. Бакчада төрле агачлар һәм җимешләр күп, имеш. «Бостанның бер тарафынада...» дигән сүзләрдән соң текст өзелә. Аның ахыры юк, битләре югалган.

Шулай итеп, Зәед белән башланган сюжет Зәед белән, дөресрәге, аның төш күрүе белән тәмамлана. Логик эзлеклелектә барып, әсәрнең ахырын күзаллау кыен түгел. Төш күрү мотивы – борынгы фольклорда да (әйтик, әкиятләрдә), шулай ук Урта гасыр Көнчыгыш әдәбиятында да (шул исәптән Ләйлә белән Мәҗнүн сюжетына язылган поэмаларда да) бик популяр булган. Татар кулъязмасында аның булуы – фольклор һәм әдәби традицияләрнең уртак чагылышы. Идел буе татарларының Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган китаби дастанына мондый уртаклык әсәрнең индивидуаль һәм традицион иҗат башлангычларын берләштергән булуыннан килә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Ләйлә белән Мәҗнүн вакыйгасы әлеге кулъязмада шактый үзенчәлекле сюжет белән бәян ителгән. Дастан – тыгыз сюжетка корылган компактлы вариант.

Татар кулъязмалары Ләйлә белән Мәҗнүн сюжетын XVIII йөздән башлап шактый еш мәйданга чыгара. Әле генә карап үткән, өч кәгазьдән торган кулъязма белән орфографик-синтаксик яктан гына аерылып торган, сюжет вакыйгалары гаять охшаш булган, хәтта беренчесенең өзелеп калган өлешенең дәвамы итеп карап булырлык татар телле икенче бер кулъязманың табылуы бик зур әһәмияткә ия.

Сүз дастанның 1985 елда археграфик эзләнүләр вакытында М. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган икенче бер нөсхәсе турында бара. Кулъязма Казан шәһәрендә табылган. 1973 елда Түбән Көек авылында табылган вариантның ахыры юк, дидек. Ә менә унике елдан соң Казанда табылган кулъязма текст күп кенә сорауларга ачыклык кертә.

Әлеге кулъязма Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә 5015 нче берәмлек буларак саклана[1].

Кулъязмаларның монысы әле генә тикшерелгәненә караганда күләмлерәк – унөч кәгазьдә (26 битлек) теркәлгән. Кулъязмада бердән алып егерме алтыга кадәр битләр саны күрсәтелә барган. Бу нөсхә Казан шәһәрендә яшәүче Рабига Замановаңың 1984 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивына тапшырган кулъязмалары арасыннан табылган. Кулъязма бик авыр укыла, бигрәк тә титул битендәге язуның сыйфаты начар. М. Әхмәтҗанов күчермәнең XIX гасыр башларына каравын әйтә[2]. Әмма кулъязманың титул битендә бу кулъязма китапның 1895 елда күчерелгәнлеге хакында мәгълүмат бар. Димәк, күчерелү вакыты турында фикер йөрткәндә, язып теркәлгән фактка таянып, без кулъязманың XIX йөз ахырына караганлыгын ачыклыйбыз. Текстның теле буенча фикер йөрткәндә исә әлеге кулъязмада гарәп-фарсы алынмалары, бүгенге татар укучысы өчен авыр аңлаешлы грамматик формалар XVIII йөзгә нисбәтле Түбән Көек кулъязмасына караганда да күбрәк, хәзерге әдәби телдән шактый ерак, тел-стиль җәһәтеннән кулъязмада XIX йөз татар язма теленә өстенлек бирелгән. Болар – Рабига Замановаңың шәхси архивында сакланып, бүгенге көндә килеп җиткән «Ләйлә белән Мәҗнүн» кулъязмасының XIX йөз ахырында борынгырак кулъязмадан күчерелгән булу ихтималы турында сөйли торган әһәмиятле фактлар.

XXI гасыр башында Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган әлеге кулъязма дастанның тексты, М. Әхмәтҗанов тарафыннан хәзерге язуга күчерелеп, алынма сүзләргә аңлатмалар белән басылып та чыкты[3]. Дастанга М. Әхмәтҗанов биргән аңлатмада «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең бу варианты Түбән Көек кулъязмасы белән аваздаш нөсхә дигән фикер әйтелгән.

Чыннан да, җөмлә төзелешендәге кайбер стилистик үзенчәлекләрне санамаганда, әлеге нөсхәдә дастан вакыйгалары Түбән

---

[1] Колл. 39, сак. бер. № 5015.

[2] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 193.

[3] Ләйлә белән Мәҗнүн // XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 305–308.

Көек язмасын кабатлый, әсәр нәкъ шул эзлеклелектә Ләйлә белән Мәҗнүннең мәхәббәт тарихын тасвир итә.

Текст «Хикәйәти Ләйлә белән Мәҗнүн будыр» дип башланып китә. Ләйлә белән Мәҗнүннең Зәед исемле остаздан белем алулары, икесенең дә «бигаять (чиксез) назнин (назлы), зифа, күркәм» булулары, башлап Ләйләнең Мәҗнүнгә гашыйк булып, мөзәйинәдән үзен зиннәтләттерүе, таңгача аллаһыдан үзенең кыяфәтен шушы зиннәтле килеш кадлыруын ялварып чыгуы, аннан соң Мәҗнүннең, Ләйләне күреп, гашыйк булуы, мәхәббәтеннән тилереп, сахрага чыгып китүе, Ләйләнең аны эзләп барып та, Мәҗнүн җавабын ишетеп, өенә кайтып китүе, хәсрәтеннән вафаты, Мәҗнүннең аны эзләп килеп, кызчык белән сөйләшүе, Ләйлә каберен иснәп, үзенең дә мәгъшукасы киткән дөньяга китеп баруы дастанда бик җентекләп тасвирланган.

Ике кулъязмада да сюжет тәңгәл, иҗат стилендә генә кайбер аермалар бар. Әйтик, Түбән Көек кулъязмасында мәгъшукын эзләп сахрага килгән Ләйләгә Мүҗнүн болай ди: «И җаным, сән – бәнем, күңелемгә сәнең мәхәббәтеңдин гайри нәрсә сыймыйдыр, сән киткел». Сюжетның шул ук урынында Рабига Заманова тапшырган кулъязмада исә Мәҗнүннең җавабы түбәндәгечә яңгырый: «Әй, җан, сән бәним күңлимгә сәгыйрсез (газап уты), минем күңлим сәниң гыйшкың илә тулды, гайре нәснәгә (нәрсәгә) урын калмады, бәним йанымдин киткел!». Яисә Аллаһ исеме кулъязмаларның беренчесендә «Аллаһы тәбарәкә вә тәгалә» дип телгә алынса, икенчесендә «Аллаһы тәгалә» дип бирелә. Ләйлә каберен эзләп йөргән Мәҗнүннең кырда очраган кызчык белән әңгәмәсенең эчтәлеге дә соңгы кулъязмада бераз аерыла:

«Әйди:

– Әй, кызчыгыз, кани (кая) бәним Ләйләйемниң каберени, мәңа күстәргил (күрсәт)! Буны ишетдикчә, ул кызчык җавап виреп әйди:

– Әй, Мәҗнүн, үзең гашыйкмын дип дәгъва кылырсын, мәгъшукаңның каберени кешидин сорайсын. Әгәр сән раст гашыйк улсаң иди, мәгъшукаңның каберени белмәсми иде? Гашыйклыйк дәгъваси батыйль (дөрес түгел) ирмеш». Беренче кулъязмага караганда биредә кызчыкның монологы тулырак.

Димәк, ике кулъязмада вакыйгалар барышындагы аерма җөмлә корылышындагы әнә шундый стилистик үзенчәлекләрдән генә гыйбарәт, ә вакыйгалар эзлеклелеге, образ-персонажлар, тема-идея – бер үк.

Түбән Көек кулъязмасы да, Рабига Заманова архивында табылган да гашыйкларның вафатыннан соң Зәед остазның төш күрүе турында хәбәр итә, дидек. Беренче кулъязма нәкъ шул эпизодка күчү белән өзелсә, дөресрәге, битләре югалган булса, соңрак табылганында исә сюжет алга таба дәвам итә, Зәеднең төшендә оҗмах бакчасындагы Ләйлә белән Мәҗнүнне күрүе турында хәбәр ителә. Остазлары алардан сорый: «Әй, сезләр, бер-береңизгә кавыштыгызмы?» Ләйлә белән Мәҗнүннең җавабы биредә гаять фәлсәфи яңгырый: «Әй, остаз, безләргә бу йир-күк бозылмаганча кавышмакга әмер юкдыр. Аның өчен безниң туемызга бу йирне күтәргән үгезне суеп туй кылыныр». Шул рәвешчә, әсәрдә Ләйлә белән Мәҗнүннең кавыша алмаулары сәбәбенә зур мәгънә салына.

Димәк, бу икәүнең кавышуы кыяматкәчә мөмкин хәл түгел. «Әгәр безләр дөньяда кавышырга улсак иди, харап улып ирди. Адәмләргә мәкян (торыр урын, торган җир. – *Л.М.*) калмас», – диләр алар. Дөньяда дигәндә монда ислам мифологиясендәгечә теге һәм бу дөньялар күздә тотыла. Кыямәт көненә кадәр («йир-күк бозылмаганча») бу икәү кавыша алмый, чөнки моның ахыры начар бетәчәк.

Ә инде җирне күтәреп тора торган үгез – дөнья картинасын космогоник күзаллауда очрый торган бик борынгы мифологик образ. Дөнья халыклары мифологиясендә Җирне үзенең мөгезендә күтәреп тора торган үгез турындагы миф еш очрый[1]. Борынгы заманда кешеләрнең Җирне хәзерге шикелле түгәрәк шар формасында дип түгел, ә бәлки үгез мөгезендә тора торган тигез, яссы урын дип күзаллаулары, ә үгез үзе очсыз-кырыйсыз суда йөзеп йөри торган балык мыегына беркетелгән дип уйлаулары мәгълүм[2].

Мондый борынгы ышанулар белән бәйле мифологик легендалар безнең борынгы ата-бабаларыбызда да сакланып калган. Дөньяны мифологик күзаллау картинасы кыйпылчыкларын татар халкында әле соңгы чорда да очратырга мөмкин. Татарстан Фәннәр кадемиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институның

---

[1] Мифы народов мира в 2-х томах. Т. 1. М.: Сов. Энцикл., 1987. С. 177; Мифы народов мира: энциклопедия: в 2-х т. 2-е изд. М.: Сов. Энцикл. Изд-во малого предприятия «Останкино», 1991. С. 67 һ.б.

[2] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: өч томда. Т. 3 (С–Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 151.

2013 елда Мамадыш районы татар авылларына үткәрелгән фольклор экспедициясендә, мәсәлән, автор тарафыннан түбәндәге мифологик хикәят язып алынды. «Җир өч китта тора икән дип сөйлиләр иде. Өч кит өстендә – бәк зур үгез. Шул үгез Җирне тотып тора икән. Җир читенә барып чыксаң, су башлана. Китлар бетеп, су башланган урынга барып чыккан буласың инде. Китлар иксез-чиксез суда, имеш. Җир читеннән су, океан башлана. Бәләкәй вакытта ишеткән нәрсәләр инде бу. Төрле кешедән ишетеп, башка шулай кереп калган. Әкият бит инде». (Информант – Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында яшәүче Ибраһимов Мөбәрәкша Ибраһим улы, һөнәре белән комбайнчы-механизатор, хәзер пенсиядә, 1931 елгы, 83 яшь). Яисә шул ук темага түбәндәгечә сөйләнә: «Үгез Җирне менә шулайттырып (ике кулын башы өстенә күтәреп, бармакларын тырпайтып күрсәтә. – *Л.М.*) күтәреп тора иде дип сөйләгәннәр. Мөгезенә куеп. Үгез үзе нәрсәдә торгандыр, белмим. Җир үгез мөгезендә торган, яссы булган. Әкият инде бу. Бездән көлә торган булмасын. Элекке кеше сөйләгән бит». (Информант – Мамадыш районы Ишки авылыннан Мөхәммәтханова Флёра Зиннур кызы, 1939 елгы, 75 яшь, һөнәре белән – махсус урта белемле педагог, хәзер пенсиядә.)

Моңа охшаш хикәятләрне халык үзе «әкият инде» дип билгеләүгә карамастан, мондый хикәятләрнең нигезендә бик борынгы мифологик ышанулар ятканлыгы шик уятмый. Үзенең фәнни монографисендә филология фәннәре докторы И.Г. Закирова да безнең халыкта Каф тавы белән уратып алынган Җирне үгез мөгезендә, үгезне – балык өстендә, балыкны – суда, суны исә һавада эленеп тора дип күзаллауның традицион космогоник концепция булуы хакында искәртеп китә[1]. Гомумән борынгы төркиләрдә үгезне изгеләштерү, үгез культы булган. Бу тема тарих фәннәре докторы Г. Дәүләтшин хезмәтендә шактый тәфсилле яктыртыла[2]. Филология фәннәре докторы, профессор Ф. Урманчеев мифологик үгез образының килеп чыгышын борынгы Авеста белән бәйләп карый, русчага Первозданный бык дип тәрҗемә ителә торган бу җан иясенең Авестада Ахура-Мазда тарафыннан барлыкка китерелгән булуы турында яза. Борынгы Шәрекътә, бигрәк тә зәрдөштлек хөкем сөргән илләрдә (Көнчыгыш

---

[1] *Закирова И.Г.* Болгар чоры халык иҗаты. Казан: Фикер, 2003. Б. 53.

[2] *Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 199.

Иран һәм Урта Азия, б.э.к. XII–X гасырлар) , – ди галим, – Үгез, бигрәк тә Күк Үгез культы, аны изгеләштерү, аллалар дәрәҗәсенә күтәрү, аның килеп чыгышын, формалашуын һәм төп вазифаларын Галәм белән бәйләү югары дәрәҗәдә була»[1].

Ләйлә белән Мәҗнүн турындагы татар дастанына фәлсәфи-легендар үгез образының килеп керүе – татар версиясе үзенчәлеге. Җирне күтәреп тора торган үгезнең һәлакәте белән Коръәндә һәм ислам мифологиясендә тасвирланган Кыямәт көнен бергә бәйләп карау татар эпосында фәлсәфи-мифологик фикерләүнең булуын күрсәтә. Мондый фикерләү фольклорга гомумән хас. Бу очракта Җирне күтәреп тора торган үгезнең дастанга килеп керүе – гади халыкның дөньяны мифологик күзаллавы белән бәйле космогоник мифның әсәрдә чагылышы, дөнья картинасын дини-мифологик сурәтләү үрнәге ул.

Ә инде Ләйлә белән Мәҗнүннең теге дөньяда да һаман кавышмаулары – әсәрдә суфичыл карашның бер чагылышы. Төп игътибарның илаһи мәхәббәткә бирелү тенденциясе Низами поэмасында бар: Зәед күргән төштә бу икәү оҗмах бакчасында ике фәрештә булып, гаять тә бәхетле яшиләр, әмма аларның мәхәббәте – иң беренче чиратта Аллаһыга мәхәббәт.

Весь мир земной – всего лишь тлен и прах,
А чистота и вечность – в тех мирах[2], –

ди поэма авторы, Ләйлә белән Мәҗнүннең илаһи мәхәббәтләрен тасвирлап.

Татар кулъязмасына килсәк, биредә әсәр Урта гасыр язма поэзиясе өчен характерлы булган суфичыл юнәлешне генә алга сөрүдән бик ерак. Текст ахырында Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәте турында сөйләгән «кыйссадан хисса» (кыссадан нәтиҗә) чыгарыла. Бу урында гашыйклыкның өч төрле булуы аңлатыла: аның беренчесе – гыйшык әгъла, ягъни Аллаһыга гашыйк булудан гыйбарәт иң бөек хис, икенчесе – гыйшык оста, ягъни Ләйлә белән Мәҗнүннең гыйшкы кебек гыйшык, ә өченчесе – гыйшык әдна – дөньялыкка хас шәһвәти

---

[1] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: өч томда. Т. 3 (С–Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 154.

[2] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т. 3 / перевод с фарси Татьяны Стрешневой. М.: Худ. литер., 1986. С. 304.

гыйшык. Дастан адәм балаларында бу өч төрле гыйшыкның өчесе дә булырга мөмкин дигән фикергә урын калдыра, димәк, әсәр һич кенә дә тулысынча суфичыл мәхәббәткә дан җырлауга гына кайтып калмый.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының татар кулъязмаларының барысында да геройлар сахрага чыга. Әйтик, Борһан Шәрәф архивында табылган кулъязмада Мәҗнүн сахрага китә, сахрада яши. Борһан Шәрәфтә тасвирланган сахра – каядыр тауларда, анда Мәҗнүн «кояшның эсселегеннән гаять сусый». Дастанның ул вариантында сахра дигәндә Идел буе климатына караганда чит гарәп климатын тасвирлауга күбрәк якынлык сизелә, әсәр вакыйгалары уртача климатлы Идел буенда түгел, ә эссе кояш кыздыра торган гарәп чүлендә, безнең өчен гайре табигый тауларда бара дип күз алдына килә. Бу – Борһан Шәрәф кулъязмасында гарәп телле поэмалардан килә торган тасвирның тәэсире күп булуны аңлата торган күренеш. Мәсәлән, Низамида сахра дигәндә шул җиргә хас табигать, ягъни чүл күздә тотыла һәм, географик территориягә нисбәтән, мондый тасвир – табигый[1]:

И сквозь пустыню, в край святой земли,
Верблюды нагруженные пошли.

Яисә:

Вдруг на пустынном, выжженном пути
Пыль заклубилась цвета тутии.

«Сахра (сәхрә)» сүзенә «Татарча-русча сүзлек»тә түбәндәге аңлатма бирелә: 1. Пустыня; пески. 2. Открытый простор с прекрасными видами; раздолье; поле[2]. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә исә «сахра» сүзе «дала, кыр, япан; ком чүле (степь; песчаная пустыня, безводная, голая степь)» дип аңлатыла[3]. Татар телендә «сахра (сәхрә)» – хәзер дә актив кулланылыштагы сүз. Гарәп-фарсы сүзе буларак, аның иң әүвәлге мәгънәсе, чыннан да, чүл, ком чүле. Татар теленә кереп, бу сүз, «чүл җире, ком даласы» булудан бигрәк,

---

[1] *Низами Гянджеви.* Собрание сочинений в пяти томах. Т. 3. С. 88, 199.

[2] Татарско-русский словарь: в двух томах. Т. 2 (М–Я). С. 277.

[3] Гарәпчә-татарча русча алынмалар сүзлеге (Татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). 2 томда. Т. 2. Б. 504.

«бик матур күренешле җәйге табигать, чәчәкле, саф һавлы болын һ.б.»[1] мәгънәне алган.

Борһан Шәрәфтәге «сахра»дан күпкә аермалы буларак, Түбән Көек, Рабига Заманова, бераз алга китеп әйткәндә, алардан башка тагын ике кулъязмада (М. Арсаев күчермәсе һәм Петербургта саклана торган кулъязмалар күздә тотыла) сахра Идел буе табигатенә якынрак мәгънә алган, ягъни «бик матур күренешле җәйге табигать» дигән мәгънәдә кулланылган. Мәҗнүннең сахрага чыгып китүен, Ләйләнең аны эзләргә сахрага кешеләр җибәрүен, соңыннан үзенең сөйгәне артыннан сахрага чыгуын, ахырда кире өенә кайтып вафат булуын тасвирлаганда «сахра» дигәндә кешеләр яши торган өйләрдән читтәге кыр күздә тотыла. Боларда эссе кояш та, таулар да юк. Мәҗнүн, Ләйләгә булган гыйшкыннан, «сахрада күзен күккә текәп ята». Соңыннан «дәхи (янә, кабат) эвинә (өенә)» әйләнеп кайта. Мондый тасвир вакыйгаларны утрак тормышлы татарлар мохитенә якынайта. Димәк, югарыда телгә алынган дүрт кулъязма дастан сюжетын Идел буе татарлары яши торган тормыш шартларына яраклаштырып бирүе ягыннан шактый үзенчәлекле.

Шулай итеп, Урта гасыр Көнчыгыш авторлары поэмалары тәэсирендә барлыкка килүенә карамастан, татар язма эпосы үз чорына хас җирле карашларны үткәрә, җирле күзаллауларга бәйле рәвештә, «Ләйлә белән Мәҗнүн» хикәятендә дөньяның (ә бәлки дөньяларның дип әйтү дөресрәктер) үзенчәлекле дини-мифологик картинасын тудыра. Җир-күкне күтәреп тора торган гигант үгез бар, ул үгезгә кыяматкәчә бердәнбер бурыч йөкләнгән, әмма үгез үзе дә, башка барлык җан ияләре кебек үк, Аллаһы ихтыярында, тәкъдиргә буйсынганнар. Ләйлә белән Мәҗнүн, бу дөньядан китеп, теге дөньяда «бер олуг бостан эчендә» бергә булсалар да, аларга әлегә «кавышмага әмер юк». Ләйлә дә, Мәҗнүн дә язмышларына буйсынганнар. Алар теге дөньяда кавышу сәгатен көтәләр, әмма бу кавышу Низами поэмасындагыча Аллаһы белән кавышуга омтылу түгел, җир кешесе аңына хас чынбарлык гыйшкы, тексттагы сүзләр белән әйткәндә, «гыйшык оста», ягъни әгъла гыйшкы белән әдна гыйшкы арасында тора торган, ике җенестәге кешеләргә хас бөек хис. Хикәятнең төп хасияте – укучыга әнә шул бөек хис турында тәэсирле итеп сөйләп бирү, бөтен кешелек исәнлеге өчен бу ике гашыйкның корбан

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. Т. 2 (К–С). Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. Б. 712.

ителүенә укучыны кызгандыру. Әлеге максат дастан вариантында фольклор мотивлары, дөньяны дини-мифологик күзаллау, шулай ук әдәби сюжет һәм чаралар катнашында тормышка ашырылган. Зәеднең Ләйлә белән Мәҗнүнне төшендә күрүен тасвир итеп, гыйшыклык төрләре турында мәгълүмат бирелгәннән соң, дастан тәмам була.

Югарыда карап үткән соңгы ике нөсхә белән бик нык охшаш янә бер кулъязма Казан федераль университетының сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана[1]. Бу кулъязмага текстолог Нәҗип Исмәгыйлев тарафыннан махсус игътибар юнәлтелеп, текст хәзерге язуга күчерелеп, басылып та чыкты[2]. Н. Исмәгыйлев әлеге кулъязмага 1978 елда юлыккан, Ләйлә белән Мәҗнүн сюжетлы татар телле башка кулъязмалар белән чагыштырган. Галим Көнчыгышны өйрәнү күләмендә бу сюжетның бездә әлегәчә ныкап өйрәнелмәгәнлеген искәртә, әсәрне моңа кадәрге фәнни тикшеренүләрдә телгә алынмаган үзенчәлекле мөстәкыйль вариант дип билгели[3].

Текст үзе Казан (Идел буе) федераль университетының сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә кыска хикәятләр тупланган кулъязма җыентыкта урын алган. Кулъязмага бит саннары куелган, әмма җыентыкның кырыйлары бик нык таушалган булу сәбәпле, «Ләйлә белән Мәҗнүн» тексты урнашкан битләрне ачыклап булмый. Бу кулъязмадагы текстлар мәдрәсә шәкертләре өчен уку китабы сыйфатында төзелгән җыентык хикәятләре булырга бик мөмкин. Түбән Көектә табылган җыентыкта без шуның мисалын күргән идек.

Кулъязманың ахырында төзүче тарфыннан бирелгән мәгълүматлар сакланган. Анда мондый сүзләр теркәлгән: «Язылды 1848 сәнә һәм тәмам булды шул ук йылда 27 мартда. Язучы – Мөхәммәдгали бине Корбангали Арсаев. Шәһри Казанда язылды». Димәк, бу очракта без күчерүченең исемен, кулъязма төзелгән вакытны һәм урынны тәгаен беләбез. Н.Исмәгыйлев Арсаевның гаять билгеле шәхес булуы (атасы да, соңыннан үзе дә, уллары да эре сәүдәгәрләр) турында хәбәр итә[4].

---

[1] Казан (Идел буе) федераль университетының Н. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, шифр Т-493.

[2] *Исмәгыйлев Н.Ф.* «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетының татарча прозаик версиясе // Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар. Казан, 1991. Б. 5–14.

[3] Шунда ук. Б. 6.

[4] Шунда ук. Б. 6.

Арсаев нөсхәсе Түбән Көектә табылган Ишнияз бине Ширнияз нөсхәсе белән бик якын. Якынлык сюжет уртаклыгыннан, текстларның чагыштырмача тигез кимәлдә булуыннан, тел-стиль үзенчәлекләренең кайбер синтаксик-грамматик синонимнарга гына кайтып калуыннан гыйбарәт. Бу ике кулъязманы үзара якынайта торган тагын бер сыйфаты – кулъязмаларның тегесендә дә, монысында да Ишнияз бине Ширнияз исеменең телгә алынуы. Арсаев исеме белән мәгълүм кулъязманың «Ләйлә белән Мәҗнүн» тексты теркәлгән битләре ахырында XVIII йөз уртасы – XVIII йөз ахырында яшәгән мәгълүм шәхес исеме күрсәтелгән. Бу кыйммәтле мәгълүмат Мөхәммәдшакир Арсаев күчергән текстның Ишнияз бине Ширнияз исеме белән мәгълүм текстка турыдан-туры мөнәсәбәте булуны күрсәтә. Кулъязма дастаннар очрагында бу әлеге текстның борынгырак берәр кулязмадан, әйтик, Ишнияз бине Ширнияз кулъязмасыннан яисә арадашчы берәр шәкерт дәфтәреннән күчерелгән дигән сүз.

Түбән Көек кулъязмасы һәм Казанда Рабига Замановалар коллекциясендә табылган кулъязма кебек үк, М. Арсаев исеме белән мәгълүм текст та җыйнак, структурасы белән төзек, тәмамланган әсәр характерындагы ядкарь. Текст тоташ проза белән язылган. Татар кулъязма вариантларына гына хас булган эпизодлар – башлап Ләйләнең Мәҗнүнгә гашыйк булуы, табибка барып үзен зиннәтләтүе, Мәҗнүнне эзләп чүлгә килгән Ләйләне, «Син минем күңелемә сыймассың», дип, Мәҗнүннең куып җибәрүе, гыйшык хәсрәтеннән Ләйләнең вафат булуы, Мәҗнүннең кызчык белән әңгәмәсе, Мәҗнүннең Ләйлә каберенә иңүе, Зәеднең төше, Зәед белән теге дөньядагы гашыйкларның әңгәмәсендә чагылып киткән мифологик хикәятләр – М. Арсаев вариантында да чагылыш тапканнар. Әлеге уртаклыклар Ләйлә беән Мәҗнүнгә багышланган кулъязма нөсхәләрнең барысын бергә җыйный. Бу авараздашлык бигрәк тә Түбән Көек, Рабига Замановага мөнәсәбәтле Казан, М. Арсаев исеме белән мәгълүм Казан нөсхәләрендә, шулай ук Петербургта саклана торган күчермәдә ачык күренә.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына халыкта иң киң таралган вариант буларак та Түбән Көек, Рабига Заманова һәм Н. Исмәгыйлев тапкан кулъязмаларны (Казан һәм Петербург язмаларын) күрсәтәбез. Тикшерү күрсәткәнчә, бу нөсхәләр төп сюжеты белән бер-береннән әллә ни аерылмый. Барысының да прозаик характерда булуы да аларны берләштерә. Бу билгеләр барысы да әлеге нөсхәләрнең бер

үк чыганакка каравы турында сөйли. Беренчел чыганакның кайсы да булса чичән иҗатына барып тоташуы турында мәгълүматлар юк. Бу вариантлар язма рәвештә барлыкка килеп, язмача таралганнар дигән фикерне генә куәтләп була.

Шул ук вакытта боларда фольклордан килә торган элементлар да, әдәби-фәлсәфи идеяләр дә чагылыш тапкан. Күчерүче кешенең исеме кайвакыт билгеле, кайбер очракларда андый мәгълүматлар теркәлмәгән яисә сакланмаган. «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең әлеге вариантлары Борһан Шәрәф кулъязмасы белән теле-стиле, традицион һәм әдәби чараларның бер бөтен текст барлыкка китерүе белән, образ-персонажлар уртаклыгы, текстның язмача барлыкка килеп, язып таралуы ягыннан гаять уртак. Димәк, мәдрәсә шәкертләре һәм муллалар тарафыннан төзелеп, язып таратылган кысынкы прозаик текстлар соңрак Борһан Шәрәф кулъязмасы кебек күләмлерәк әсәрләр барлыкка килүне тәэмин иткән. Мондый эзлеклелек татар халкының дастани эпос тарихында «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең XVIII йөз ахырларыннан алып XIX йөз ахырынача мәйданга чыгуында традицион дәвамчанлыкның булуын күрсәтә. Халык тарафыннан укылып-күчерелеп йөргән бу кулъязмаларның табылуы аларны «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең башка халык версияләреннән һәм әдәби поэма булып танылган авторлы әсәрләрдән үзгә татар версиясе итеп карау ихтыяҗын китереп чыгара.

Шулай итеп, бу истәлекләр, берсен-берсе тулыландырып, татар халкында «Ләйлә белән Мәҗнүн»гә багышланган дастанның үз милли версиясен тәшкил итәләр. Татар версиясенең иң зур үзенчәлеге аның китаби-язма характердагы романик дастан булуыннан гыйбарәт.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының моңа кадәр карап үткән вариантларында авторлыкны билгеләү гаять дәрәҗәдә авыр, күп очракларда хәтта бөтенләй мөмкин дә түгел. Дастан жанрында индивидуальлек һәрвакыт саклана да, фольклор әсәре булуының бер билгесе буларак, биредә күмәк иҗат факторы зур роль уйный. Мәгълүм сюжетка иҗат ителгән әсәрнең авторы күрсәтелми генә таралу, ул әсәргә күчерүче керткән кайбер үзгәрешләрнең булуы яки булмавы – кулъязма нөсхәләрдә фольклор традициясе чагылышы.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» дастаны татарларда аерым авторлар иҗатында да да чагылыш тапкан. Исеме мәгълүм шагыйрьләр, Урта гасырлар иҗат методы үрнәгендә, билгеле сюжетка мөрәҗәгать итеп,

үз иҗатларында дастанны яңача яңгыратканнар. Мондый шәхесләр, электән популяр сюжетларга әсәрләр иҗат итүдән тыш оригиналь сюжетлы әсәрләр иҗат итү белән дә шөгыльләнгәннәр, үз иҗатларын кулъязма җыентыклар итеп төзегәннәр. Мондый шартларда, әлбәттә, «уртак» сюжетлы әсәрләр дә «автор»лы булып килеп ирешкән. Мондый әсәрләрнең авторлыгы шартлы, әлбәттә, әмма авторы мәгълүм дастанда индивидуаль иҗат башлангычын авторның башка әсәрләре белән (әгәр алар билгеле булса) чагыштырып күзәтү мөмкинлеге дә бар. Мондый әсәрдә бер үк каләм иясе стиленә хас уртак билгеләр табылырга мөмкин.

Шундый төр иҗат белән шөгыльләнгән шәхесләр арасында «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына да мөрәҗәгать иткән татар шагыйренең исеме мәгълүм. Ул – XIX йөз урталарыннан 1890 елга кадәр иҗат иткән Әхмәтҗан Тубыли. Тулы исеме – Әхмәтҗан бине Шәмсетдин әл-Әбеви әс-Самари әл-Болгари әт-Тубыли. Бу шәхеснең иҗат эшчәнлегенә бәйле чыганак-мәгълүматны иң беренчеләрдән булып филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов җиткергән иде. 1973 елда ул Татарстанның Лениногорск районы Сарабиккол авылында Әхмәтҗан Тубылиның зур кулъязма китабына юлыга һәм аны Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондына алып килеп тапшыра. Бу җыентыкка әдипнең дин мәсьәләләренә кагылышлы чәчмә әсәрләре, улы Мөхәммәтҗанга язылган хаты, васыятьнамәсе һ.б. тупланган[1].

Ә 1982 елда филология фәннәре докторы М. Әхмәтҗанов тарафыннан шул ук Сарабиккол (Әби) авылында Тубылиның тагын бер күләмле кулъязма җыентыгы табылды[2]. Җыентыкта әдипнең унлап шигыре, шигырь белән язылган хатлары, поэмалары, билгеле шәхесләр вафаты мөнәсәбәте белән язылган мәрсияләре, календарьлары, башка авторларның поэзия үрнәкләре һ.б. теркәлгән. Тубылиның шигырьләрен татар телендә генә түгел, фарсыча да язган булуы мәгълүм. Әлеге бай җыентыкта шагыйрьнең «Хикәйәте Ләйлә-Мәҗнүн» исемле әсәре дә кергән. Шагыйрь

---

[1] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге архивы, колл. 39, тасвир 1, сак. бер. № 444.

[2] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәге архивы, колл. 39, сак. бер. № 6058.

Әхмәтҗан Тубылиның тормышы һәм иҗаты турында беренчеләрдән булып галим М. Әхмәтҗанов язды, аның текстологик эшкәртүендә шагыйрь иҗатыннан үрнәкләр, шул исәптән Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган әсәреннән өзек тә матбугатта дөнья күрде.[1] Соңрак М.Әхмәтҗанов, «Татар кулъязма китабы» дигән хезмәтендә Ләйлә – Мәҗнүн сюжетының татарларда таралышына мөнәсәбәттә, хикәятнең Тубыли вариантына аерым тукталып үтә[2].

Әхмәтҗан Тубылиның этик-эстетик карашларын махсус өйрәнгән фәнни хезмәт тә бар. Алсу Хасавнех 2002 елда «Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклады[3], соңрак аның шул ук исемдәге монографиясе дөнья күрде[4].

Ә. Тубылиның фән өчен гомумән мөһим мирасы арасында безне кызыксындырганы – аның «Хикәйәте Ләйлә-Мәҗнүн»е. Бу әсәр фәкать 58 тезмә юлдан гыйбарәт, ахырда тагын сигез юл фарсы телендә язылган. Сюжетының Түбән Көек, Рабига Заманова, Арсаев, С. Петербург нөсхәләре белән уртаклыгы да, аермалары да бар. Уртаклыгы, иң беренче чиратта, сөйләнә торган вакыйганың җыйнаклыгыннан, образлар системасының бертөрлелегеннән гыйбарәт.

Хикәяттә Ләйлә белән Мәҗнүннең гыйшкы турында сөйләнә.

Багдад эчендә булып мәшһүр хәбәр,
Ләйлә илә Мәҗнүннең гыйшкы мәгәр.

Әмма югарыда телгә алынган дүрт кулъязмада Багдад турында мәгълүмат юк. Алдан ук вакыйганың Багдадта булуын хәбәр итеп кую – Ә. Тубыли әсәренең үзенчәлеге. Алга таба Ләйлә белән Мәҗнүннең уртак остазлары – «әдәпле холыклы мөселман мөгаллим» турында әйтелә. Мөгаллим образы (башка вариантлар аша

---

[1] *Әхмәтҗанов М.* Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли // Казан утлары. 1997. № 1. Б. 147–153.

[2] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 194–195.

[3] *Хасавнех А.А.* Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли: дис. … канд. филол. наук. 216 с.

[4] *Хасавнех А.А.* Ахметзян бине Шамсетдин аль-Тубыли. Бугульма: ОАО «Бугульминская типография», 2009. 135 с.; *Хасавнех А.А.* Ахметзян Тубыли: жизнь и творчество татарского поэта-суфия XIX века. Saarbucen: LAPLAMBERTA Publishing, 2012. 206 с.

аның исеменең Зәед икәнлеге билгеле) әдәби версияләрдә (Низами, Физули, Нәвои поэмалары) дә, китаби версиядә дә Ләйлә белән Мәҗнүннең мәхәббәт тарихын халыкка җиткерүдә төп рольне башкаручы буларак тасвирлана. Әдәби поэмаларда, татар версиясенең Борһан Шәрәф вариантында бу образга дастанны халыкка җиткерүче чичәнлек функциясе йөкләнгәнлек ачыктан-ачык чагылса, Ә. Тубыли вариантында бу хакта җентекле сөйләү юк. Әсәр башында ук аңа бирелгән аерым игътибардан соң башка урында (һәр хәлдә әсәрнең татар телле өлешендә) мөгаллим образы телгә алынмый.

Мөгаллим турындагы юллардан соң әсәрдә төп игътибар Мәҗнүннең Ләйләне күреп гашыйк булуына юнәлтелә, гашыйклык хәләтен тасвирлауга шактый урын бирелә:

Чөнки Ләйлә гыйшкы дөшде Мәҗнүнә,
Белмәс улды кәндүзин (гакылын. – *Л.М.*) кем, кәнди нә
(шәһәре кайсы. – *Л.М.*).

Яисә:

Мисле булды гыйшкы Мәҗнүн күрдеки,
«Ләйлә!» – дип, гыйшкыйна җанын вирдеки һ.б.

Бу хәлне белеп, Ләйләнең атасы кызын Мәҗнүннән читләштерә – аны мәктәпкә җибәрми башлый. Ләйләдән аерылуны егет авыр кичерә. Биредә Ләйлә белән Мәҗнүн мәхәббәтенә багышланган борынгы гарәп риваятеннән үк килә торган, соңрак әдәби поэмаларга, татар версиясенең Борһан Шәрәф кулъязмасына да килеп кергән элемент игътибарны җәлеп итә – биредә дә егетнең үз исеме Кайс була:

Андин уңдин (әүвәл. – *Л.М.)* Кайс иде Мәҗнүн ады,
Мәҗнүн улды бәгъдәзан (соңыннан. – *Л.М.*) Кайс ады.

Ягъни Ләйләдән аерылганнан соң ул нәүмизлектә кала, мәҗнүнгә әверелә.

Әсәргә күзәтү ясау түбәндәге нәтиҗәгә китерә: автор традицион эчтәлектән читкә китмәгән, телдән-телгә йөргән мәшһүр мәхәббәт тарихын бәян иткән. Гыйшыклык халәте дигәндә биредә күбрәк Мәҗнүннең Ләйләгә гашыйклыгы күздә тотылган. Ә. Тубыли әсәренең татар кулъязмалары белән дә, әдәби версияләр белән дә (әйтик, А. Хасавнех аның идея-эстетик яктан М. Физули поэмасы белән уртак

якларын билгели[1]) уртаклыгы бар. Ихтимал, әдип бу чыганаклар белән таныш булган, үз иҗатында аларны киң файдаланган, «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына үзенә бер мөстәкыйль әсәр булган яңа вариант барлыкка китерүгә ирешкән. Авторлы вариант буларак та, шигъри юлларның әдәби стиль җәһәтеннән шактый эшләнгәнлеге белән дә бу вариантта индивидуаль иҗат билгеләре өстенлек алган. Шул ук вакытта сюжетның халык иҗатында популярлыгы, әлеге темага багышланган кулъязма китапларның киң таралганлыгы, мәхәббәт темалы дастаннар рухы әдипкә тәэсир итми калмаган. Шуннан чыгып, «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең Ә. Тубыли каләме нәтиҗәсе булган бу вариантың индивидуаль иҗатка бик нык якынайган поэма-дастан дип бәяләргә мөмкин.

Тубыли язмасы тезмә текст булуы белән дә, фрагментар характерда булуы белән дә 1979 елда М. Әхмәтҗанов тарафыннан Азнакай районы Чаллы авылында Мортазин Зөфәр исемле кешедә табылган кулъязма[2] белән бик нык охшаш. Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган татар телле әсәрләрнең монысы күләмле кулъязма китапка теркәлгән. Азнакай кулъязмасы Тубыли вариантына хронологик яктан да якын – язылу һәм таралу җәһәтеннән алар икесе дә XIX йөз уртасына карый. Мәҗмуга үзе 1844 елның 16 гыйнварында Мөхәммәдшәриф бине мулла Әхтәм тарафыннан күчерелеп беткән, битләр саны 336 дип күрсәтелгән, 163 кәгазьдән тора. Текстлар пөхтә рамкалар эченә алынган. Биредә татар, гарәп, фарсы телендә чәчмә, һәм шигъри әсәрләр тупланган. «Ләйлә белән Мәҗнүн» – тезмә текст, иске татар телендә, бүгенге көн укучысына авыр аңлаешлы. Күләме белән кечкенә генә – кулъязманың 41нче битенә сыйган. Шигырь стиле, эчтәлеге белән әлеге нөсхә Тубылиныкыннан аерыла. Тубылида төп игътибар Мәҗнүнгә бирелеп, әсәр аның хис-кичерешләре турында сөйләүгә багышланган булса, бу өзектә сүз Ләйлә белән Мәҗнүннең үзара көчле гыйшкы турында бара. Тубылиның теленә караганда Азнакай нөсхәсенең теле дә хәзерге әдәби телдән шактый ерак. Әлеге фрагмент үзенең булуы белән кыйммәт.

[1] *Хасавнех А.А.* Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли: дис. ... канд. филол. наук. С. 143.

[2] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фонды, колл. 39, ед. хр. 3164.

Бу факт үзе генә дә сюжетның төрле стильдә укылып һәм күчерелеп йөрүен күрсәтә.

К. Насыйриның «Җәваһирел хикәят» дип исемләнгән әдәби хезмәтендә дә Ләйлә – Мәҗнүн сюжетлы бер ядкарь булуы мәгълүм. К. Насыйри үзе бу хезмәтен «остазларның остазы имам Сүюти разыйаллаһу ганһуның «Әнисел җәлис» китабыннан тәзкирә өчен тасниф кыйлынган», ягъни сайлап алып язылган булуын әйтә[1].

Хикәят кыска гына сюжетлы чәчмә әсәрдән гыйбарәт. Вакыйгаларның борынгы хәбәрләргә нигезләнгән булуы турында алдан ук искәртелә. Монда күбрәк Мәҗнүннең Ләйләгә булган гыйшкы сурәтләнә. Электә Мәҗнүннең исеме Кайс булганлыгы искәртелә. Алга таба Кайсның Мәҗнүн исемен, дөресрәге кушаматын алу вакыйгасы турында сөйләнә. Имеш, Кайс бер аучы тоткан киекне күрә дә, Ләйләне исенә төшерә, киекнең күзләрен Ләйлә күзләренә охшата, бу турыда аучыга әйтә. Шуннан соң Кайсны Мәҗнүн дип атый башлыйлар. Гыйшкыннан акылы зәгыйфьләнгән егетнең атасы Ләйләгә килә, «Мәҗнүнгә йөзеңне күрсәтче», – дип ялвара. Кыз риза була. Мәҗнүн килеп, Ләйләнең битенә багуы була, һушы китеп егыла. Ләйлә әйтә: «Мәҗнүнгә йөземне күрсәтмәвемнең сәбәбе саранлыктан түгел, ә аңа шәфкать кылудан, аны кызганудан иде», – ди.

Шуннан соң автор вакыйганы дини темага күчерә, бу эшне, ягъни Мәҗнүннең Ләйләне күрәсе килеп, аңа күз салуын Муса галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләгә күз салу теләге белән чагыштыра. Ләйлә белән Мәҗнүнгә багышланган бу кечкенә хикәят алдарак сөйләнгән вакыйгаларга лирик чигенеш ясау характерында килеп кергән. Алдарак Муса Галәйһиссәламнең җирдәге җан ияләреннән баш тартып, аларның сүзен бөтенләй тыңламас булуы, Аллаһы сүзенә генә табына башлавы хакында языла. Аллаһы, аңа шәфкать итеп, аның бу эшенә риза булмавын белдерә. Ләйлә белән Мәҗнүнне мисалга китереп, автор нәтиҗә чыгара: Мәҗнүн Ләйләнең йөзен күрми түзә алмады, ә Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә бакмый ничек түзә алсын? Нәтиҗә ясап әйткәндә, К.Насыйри кагылып үткән бу хикәят – дини-дидактик хикәятләрдә әйтелгән фикерне ныгыту өчен китерелгән бер мисал. «Җәваһирел хикәят»кә аның килеп керүе – Ләйлә

---

[1] *Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 250.

белән Мәҗнүн сюжетының Борынгы Көнчыгышта, шулай ук татар халкында гаять популярлыгынннан.

Шулай итеп, «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына татар халкында төрле чорда төрле характердагы, төрле жанрга карый торган истәлекләр булуын күзәттек. XIX–XX йөз башына кадәр «Ләйлә – Мәҗнүн» сюжетына төрле харктердагы һәм үзенең сыйфатлары белән төрле жанрга тартыла торган әсәрләр иҗат итү дәвам иткән, аның кулъязмалары бүгенге көнгәчә табыла тора. Әле XX йөз уртасына якынайганда да Кәрим Әмири дигән авторның «Ләйлә белән Мәҗнүн» исемле драма әсәре сәхнәгә куелган булуы мәгълүм[1]. Әлеге сюжетка иҗади яисә ирекле тәрҗемәләр дә, индивидуаль иҗат башлангычы һәм суфичыл тенденцияләр өстенлек алган әдәби әсәрләр дә, текстларның китаби дастаннар исемлеген баета торганнары да халыкның уку-язуга һәм маҗаралы-эмоциональ характердагы күләмле әсәрләргә ихтыяҗын канәгатьләндерә һәм бер үк максатка хезмәт итә торган торган истәлекләр буларак кыйммәт.

«Ләйлә – Мәҗнүн» сюжетлы кулъязма истәлекләрнең күбесендә романик дастан жанры билгеләре өстенлек итә. Борынгы сюжетның гаять дәрәҗәдә популярлыгы татар дастаннары тарихында зур урын алып тора торган милли версия барлыкка китергән. Карап үтелгән күп кенә билгеләре татар версиясен дастанның китаби төре итеп карау ихтыяҗын китереп чыгара. М. Әхмәтҗанов та әлеге сюжетка иҗат ителгән кулъязмаларга махсус мәкаләсендә[2] «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастаны кулъязмаларын «дастанның яңарак дәвер татар тормышына яраклаштырылган версиясе» дип санавын әйтә.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжеты татар халкында чыннан да бик популяр булган. Әллә ничә вариантта Татарстан территориясендә табылган кулъязмалар шул хакта сөйли. Борынгы әдәбиятның гүзәл әдәби әсәрләре тәэсирендә үз җирлегебездә туган китаби дастаннарыбызның һәркайсы аерым игътибарга лаек. Аларның күбесе гарәп язуы белән язылган кулъязма килеш саклананалар. «Ләйлә белән Мәҗнүн» кулъязмаларының һәрберсен текстологик эшкәртеп, халыкка кире кайтару – бүгенге көндә актуаль мәсьәләләрдән.

---

[1] *Исмәгыйлев Н.* «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетының татрча прозаик версиясе // Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар. Казан, 1991. Б. 5.

[2] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 192–196.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкында Урта гасыр иҗат методы традициясендә әсәрләр язу бик киң таралган була. Бу метод мәгълүм сюжетка корылган мәшһүр бер әсәргә ияреп язу, аны тулысынча яки өлешләп тәрҗемә итү, шул сюжеттан илһам алып, үзебезнең җирлектә өр-яңа әсәр иҗат итү, ул әсәрнең халыкта популярлашып, әллә ничә вариантта таралуы аша туган ядкарьләрдә тормышка ашырылган. Һәрхәлдә татар халкында, аерым алганда Идел буе татарларында, әлеге методның нәкъ менә шундый – чагыштырмача иркен стильдәге юнәлеше өстенлек иткән. Шушы гаять күпкырлы һәм масштаблы күренешнең бер чагылышы булып, татар халык иҗатында «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастаны да жанрның китаби төрендә үсеш алган. «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең татарларда нигездә язмача таралып, безнең көннәргә дә кулъязмада килеп җиткән булуы шул хакта сөйли.

Халыкта борынгы чорларда ук популярлык казанган Ләйлә – Мәҗнүн сюжеты татрларда XX гасыр башынача гаять актив булган. Борынгы гарәп риваяте татар китаби дастанында үзенчәлекле чагылыш тапкан. Татар телендә ярым әдәби, ярым фольклор текстларны төзегән иҗатчылар китап теленә, китаби стильгә, китаби гыйбарәләргә һәм образларга мөрәҗәгать иткәннәр, шул ук вакытта традицион алымнардан да баш тартмаганнар. «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең милли китаби версиясе әдәби процессның һәм фольклорның татар китаби дастаннары барлыкка килү һәм ныгып формалашу этабында гаять зур роль уйнавы белән әһәмиятле.

### § 2 «Таһир – Зөһрә» сюжетлы дастаннар

Татар халык дастаннарының китабилашу дәрәҗәсе төрлесенеке төрлечә. Бер ишләре фәкать кулъязмада гына сакланган булса, күбесе аерым китап булып басылу дәрәҗәсенә җиткән, күчерүче-иҗатчы хәтта индивидуаль автор роленә керә башлаган. «Таһир белән Зөһрә» – шуңа мисал. Бу әсәрнең Сайадидән башлап, В. Радлов тарафыннан язып алынган, Ә. Кормаши күчергән һәм башка «авторлы» һәм «авторсыз» вариантлары бихисап. «Таһир – Зөһрә» сюжетлы татар дастанының өч төрле яшәеш формасы мәгълүм: алар бүгенге көнгә кулъязмада һәм сөйләм телендә, автор иҗатына күчкән җыйнама вариантлары аерым китап рәвешендә килеп ирешкәннәр.

Вариантлылыкның булуы – әсәрне һичшиксез халыкныкы итеп танытучы кире каккысыз дәлил. Татарларда берничә вариантта яисә

башка төрки версияләре булган эпик ядкарьләребез әдәбиләшкән очракта да фольклор белән кире бәйләнешен югалтмаганнар. Шуңа күрә аларда фольклор белән уртаклык бик зур. Әлбәттә, тыгыз фольклор-әдәбият бәйләнешләре нәтиҗәсендә индивидуаль авторныкы булып әверелгән әдәби әсәрләр дә бар, әмма әдәбиятның шактый четерекле әлеге этабында дөньяга туган бу әсәрләрдә дә фольклор башлангычын танымый мөмкин түгел.

«Таһир – Зөһрә» сюжетына Урта гасырлардан ук төрки халыклар мөкиббән киткән. Үзбәк версиясе, дүрт уйгыр, балкар, ике дистәдән артык азәрбайҗан, берничә төрек, казакъ, төрекмән, Башкортстан территориясендә табылган төрле күләмдәге текстлар мәгълүм.

Билгеле булганча, әлеге әсәр татар халкында да бик киң таралган. Бүгенге көндә дастанның татар версиясе вариантлары дистәдән артып китә. «Таһир – Зөһрә» сюжетлы дастан кулъязмалары татарлар яши торган төбәкләрдә әле безнең көннәрдә дә табылып тора. Кулъязмалар Казан фәнни үзәкләрендә, иң зур күпчелеге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана[1]. Хәлбуки татаралар арасында бу дастан Идел буенда да, Себер киңлекләрендә дә берничә гасыр буена яши.

Төрки әдәбиятында һәм фольклорында дастан шактый өйрәнелгән. Татар версиясе турында Х. Хисмәтуллинның[2], Ф. Әхмәтованың[3], һ.б. аерым мәкаләләре бар. Алар дастанның нигездә Сайади вариантына әһәмият бирәләр.

М. Әхмәтҗанов дастанның археографик экспедицияләр вакытында табылган вариантларын текстологик эшкәртеп, аларны матбугатта чыгарды[4]. Үзенең монографиясендә дә галим бу дастанга урын бирә, аның Сайадиныкыннан тыш вариантларын барлый,

---

[1] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Колл. 39. Сакл. бер. № 4896, 1861, 2811, 2016; ф. 41. Оп. 1, сакл. бер., № 6, 63 һ.б.

[2] *Хисмәтуллин Х.* Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе (Дастан Бабахан» әсәренә 550 ел тулу уңае белән) // Совет әдәбияты. 1965. № 7. Б. 147–148.

[3] *Әхмәтова Ф.В.* Дастаны Бабахан // Татар әдәбияты: 6 томда. Т. 1. Урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 312–321.

[4] *Әхмәтҗанов М.* «Таһир белән Зөһрә» дастаны // Казан утлары. 1987. №4. Б. 179–186; *Әхмәтҗанов М.* «Таһир белән Зөһрә»нең тагы бер билгесез кулъязмасы // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. Казан, 1989. Б. 67–72 һ.б.

кулъязма нөсхәләрдә дастанның милли үзенчәлекләренә туктала[1]. Аерым алаганда, галим «Таһир белән Зөһрә»нең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган кулъязмаларын телгә алган, башка халык версияләре белән чагыштырып, татар кулъязма вариантларына күзәтү ясаган. Әлеге күзәтүләр нигезендә Таһир белән Зөһрә сюжетлы дастанның татар халкында милли үзенчәлекләргә ия үз версиясе барлыгы расланган.

Филология фәннәре докторы, профессор Ф.И. Урманчеевның «Героический эпос татарского народа» хезмәтендә «Таһир белән Зөһрә»гә китаби чыгышлы дастан буларак игътибар юнәлтелгән.

Филология фәннәре докторы профессор Ф.З. Яхин үзенең «Татар шигърияте ндә дини мистика һәм мифология» исемле монографиясендә Сайади иҗатына һәм аның «Дастаны Бабахан» әсәренә аерым бүлекчә багышлаган, әсәрдәге мифологик вакыйгалар һәм алымнарга мөнәсәбәттә Сайади һәм Кормаши вариантларына чагыштырма характерда махсус тукталган[2].

Филология фәннәре докторы Р.Ф. Исламов, дастанның балкар версиясен табып, аны матбугатка чыгарды[3]. Текст алдыннан бирелгән кереш сүздә галим «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы әлеге әсәрнең төрле халыкларда таралган кулъязмалары турында бик күп чыганакларны күрсәтә, дастан версияләре хакында гаять бай мәгълүмат бирә.

Хәлбуки татар версиясенең барлык вариантлары да әлегәчә билгеле бер эзлеклелек белән анализланмаган, алар хакында фикер гомумиләштерелмәгән, кулъязма нөсхәләргә тиешле теоретик игътибар бирелмәгән, дастанның татар фольклорына һәм әдәбиятына ясаган тәэсире хакында махсус тикшеренүләр юк. Болар барысы да китаби дастан буларак «Таһир белән Зөһрә» дастанына мөнәсәбәттә теоретик гомумиләштерүләр әлегә эшләнмәгән дигән фикергә китерә.

---

[1] *Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 169–179.

[2] *Яхин Ф.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты, 2000. Б. 185–199.

[3] *Исламов Р.Ф.* Еще об одном варианте дастана «Таһир и Зухра» // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2005. № 2. С. 193–204.

Идел буе татарларында «Таһир белән Зөһрә» версиясенең үзенчәлеге – аның нигездә кулъязмада сакланып калуында. Дастанның кайбер өлешләре халыкта җыр рәвешендә йөргән. Күләме шактый зур булган бу дастан Себер татарларында телдән дә сөйләнгән. Ә менә Идел буе татарларында дастан беркайчан да тулысынча көйләп, ритмик сөйләм белән башкарылмаган. Бу аның китабилашкан иҗат булуыннан килә торган сыйфат.

Яшь егет белән кызның илаһи мәхәббәтенә багышланган әлеге сюжетның төгәл кайсы чорда барлыкка килүе билгесез. Фольклор материалларын эшкәртеп, дастанның татар-төрки телендә әүвәлге версиясен иҗат итүче Сайади исемле автор булган дип исәпләнелә. Сайадинең кайда һәм кайчан туганлыгы, биографиясе фәнгә хәзерге көнгә кадәр мәгълүм түгел, авторның борынгы кулъязмалары да сакланмаган. «Дастаны Бабахан»ның авторы Сайади дип күрсәтүдә атаклы «Махабхарата»ны – Вьяс, «Рамаяна»ны – Вальмики исемле шәхесләргә яисә «Одиссея»ны Гомерга нисбәт итүдәге кебек шартлылык бар, моны танымый мөмкин түгел.

«Сайад» сүзе гарәп теленнән «аучы», «сунарчы» дип тәрҗемә ителә. Әдипләрнең әдәби тәхәллүсне туган җирләренә нисбәтән алуларын нигез итеп, Ф. Яхин Сайадны географик атама булырга тиеш дип белдерә һәм Сайади тәхәллүсле шагыйрьнең чыгышын Аму-Дәрья буена урнашкан Саят шәһәреннән дип фаразлый.

Сайадига мөнәсәбәтле әсәр борынгы гомумтөрки телдә язылган. Аның кайчан иҗат ителгән булуы турында төгәл генә мәгълүмат юк. Текстта күрсәтелгән датага нигезләнеп, күпчелек галимнәр аны Урта гасырларга – 1414 елга нисбәт итә. Әмма бу дата шактый бәхәсле. «Бабабхан дастаны» XV йөз башына түгел, ә күпкә соңрак чорга – XVI яисә XVII йөзгә карый дигән фикерне алга сөргән фәнни караш та бар[1]. Бу әсәр – Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәт вакыйгаларына багышланган гаҗәеп шигъри роман, Сайади исемле авторның фәнгә билгеле бердәнбер әсәре.

Сайади вариантының зур бер өлеше Х. Хисмәтуллин эшкәртүендә «Борынгы татар әдәбияты» җыентыгына кертелгән[2]. Дастанның Ф. Яхин тарафыннан хәзерге әдәби телгә якынайтып

---

[1] *Яхин Ф.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан, 2000. Б. 191.

[2] Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 258–334.

эшләнгән искиткеч бай эчтәлектәге тулы тексты галимнең кереш сүзе белән безнең чорда аерым китап булып дөнья күрде[1]. Дастанның тәүге табылган нөсхәсе Санкт-Петербургның Көнчыгышны өйрәнү институты кулъязмалар бүлегендә саклана. Бу нөсхәне, 1918 елда Куян авылы Йосыф мулла кызы Бибигамбәр тарафыннан күчерелгән булуы турындагы мәгълүматка нигезләнеп, «Бибигамбәр күчермәсе» дип йөртәләр. М.Әхмәтҗанов «Петербург һәм Казан архивларында аның татар халкы вәкилләре тарафыннан эшләнгән биш күчермәсе бар» – дип күрсәтә[2]. Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербургтагы фондларында (В 3833, С 148, В 3245), Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында (№ 6357, 6359, 9194, 10236) һәм А.С. Пушкин исемендәге институтның әдәби музеенда (№ 95), Санкт-Петербургның М.Е. Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсендә (государственная публичная библиотека им. М.Е. Салтыкова-Щедрина) (№ 439), Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең Әдәбият институты фондларында «Таһир белән Зөһрә» кулъязмаларының саклануы турында мәгълүмат бар[3]. Әмма татар филологиясендә әсәрнең Бибигамбәр исеме белән билгеле нөсхәсеннән тыш башка күчермәләре фәнни әйләнешкә кертелмәгән.

Урта гасыр Көнчыгыш поэзиясе традициясендә әсәр Сайадиның үзе турындагы мәгълүматтан башланып китә. Укучыга мөрәҗәгать итеп, автор үзе белән таныштыра. Биредәге мәгълүматларга карагында, Сайади – ялгызлыкта гомер иткән хыялый бер бәндә, аның сөйгән яры да, баласы да юк.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»нең Борһан Шәрәф вариантындагы кебек, әсәр төрле бүлекләргә бүленгән, аларга исә эчтәлек турында мәгълүмат бирә торган исем бирелгән. Аллаһ исеме белән башланып киткән дастанда сөйләүче-герой, автор турында мәгълүматтан соң, Бабахан исемле ханга мөнәсәбәтле кыйсса сөйләячәген хәбәр итә. Бу юлларда әсәрнең укучыга түгел, ә тыңлаучыга юнәлтелгәнлеге аңлашыла. Бу – әсәрнең фольклор традицияләренә нигезләнгәнлеген күрсәтә торган билге:

---

[1] *Сайади.* Таһир – Зөһрә (Бабахан дастаны). Казан: Раннур, 1998. 192 б.

[2] Таһир белән Зөһрә // Түгәрәк уен. Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах. 2012. № 1. Б. 56.

[3] Исламов Р.Ф. Еще об одном варианте дастана «Таһир и Зухра» // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2005. № 2. С. 194.

Ай-һай, дуслар, ишетик бер хикәят,
Эчендә сүзләре бар чиксез гаять.
Бабахан дигән бер шаһ бар иде,
Аның иле-шәһәре Татар иде.

Әмма шагыйрьнең үз стиле бар, биредә тезмәне фольклор эпосындагы кебек халык шигыренә кору бик нык үзгәреш кичергән. Стиль гаять дәрәҗәдә шома эшкәртелгән, әдәбиләшкән. Әсәрнең структурасы оста уйлап төзелгән, әсәр вакыйгаларына бәйле эчке сәбәпләр аркасында (спонтан рәвештә) тигезле-тигезсез сикерешләр, кайбер вакыйгага тиешле игътибар биреп җиткермичә, кайберсе хакында озаклап сөйләү Сайади вариантына хас түгел, сюжет индивидуаль автор тарафыннан бик нык уйланылган әдәби югарылыкта эзлекле үстерелә. Болар бар да Сайади әсәрендә индивидуаль стиль дәрәҗәсе бик югары булуы хакында сөйли.

Фольклор эпосында баласызлык мотивы турында алдарак сүз алып барган идек. Сайади «Таһир белән Зөһрә»сендә дә сюжет оешуда әлеге мотив зур роль уйный. Биредә Бабахан исемле гайрәтле ханның баласы булмау турында бик җентекле сөйләнә. Бабаханның Баһир исемле тугрылыклы вәзире, ханның хәсрәтен үз хәсрәте кебек күреп, Аллаһыдан ханына бала сорый. Бабаханга сораганда «Үземә дә бер бала насыйп ит», – дип ялвара. Теләкләрен теләгән көнне Баһир төшендә Бабахан белән үзенең, Аллаһы катына килеп, бала теләүләрен аңа җиткерүләрен, Хак Тәгаләнең боларның теләген кабул кылуларын күрә. Баһир төшен ханга сөйли. Бабабхан шатлыгыннан «Угыл булсалар, бер-берсе белән дус булсыннан, кыз бала булып тусалар, бер-берсенә сердәшләр булсыннар» – дигән шарт куя.

Төш күрү, күргән төшне юрау – шулай ук фольклор мотивы. Алдарак бу хакта сүз алып барган идек. Фольклорда төш аша юрау, юраганның чынга ашуы гадәттә шарт кую, магия элементлары белән бәйләнгән була. Биредә без әлеге мотивның Аллаһ исеме, ислам традициясе белән керешеп китүен күрәбез. Әсәрнең мифологик нигезләрен җентекле анализлаган Ф. Яхин да бу урында төш күрү аша Аллаһыдан алдан бирелгән хәбәрне фольклор элементы дип карамый, аңа китап традициясе үзенчәлеге буларак бәя бирә[1]. Галимнең «Бу фольклорга хас күренеш булудан бигрәк китаплаштырылган,

[1] *Яхин Ф.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан, 2000. Б. 192.

мәдәниләштерелгән күренеш»[1], – диюе белән, чыннан да, килешергә мөмкин.

Төш күреп, аны юрау, мәсьәләне юралганча хәл итү язма әдәби-мәдәни истәлекләр аша да киң мәгълүм. Борынгы һәм Урта гасыр гомумтөрки әдәбиятында Кол Гали, Сәйф Сараи, Котб һ. б. иҗатында бер-берсен төштә күреп, төш аша бер-берсеннән хәбәрдар булып берсен-берсе яисә берсен икенчесе эзләп табу мотивы киң таралган. Зөләйха Йосыфны төшендә күрә, төштәге егетнең чакыруы буенча, сөйгәнен эзләп, Мисырга килә. Хөсрәү дә Ширинне төшендә күреп, төштәге мәгълүматлар нигезендә кызны эзләп таба һ.б.

Шулай итеп, борынгылык, мәҗүсилек элементлары белән аралашып, халык иҗатында, ислам кысаларында әдәби-язма әсәрләрдә бик еш таралган бу мотив романик китаби дастаннарда да чагылыш тапкан. Сайади «Таһир белән Зөһрә»сендә төш күрү сюжет үстерелешендә тәэсирле бизәк ролен үти. Моннан чыгып караганда, төш күрүнең эпик фольклор өчен дә, Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты өчен дә уртак мотив булуы ачыклана. Әдәбиятта ул һәрвакыт илаһият белән бәйләнгән була һәм авторның тенденциоз карашларына бәйле төрле борылышлар белән баетыла. Ә эпик фольклор, бигрәк тә архаик эпос төш күрү элементын сюжетка алдан күрүчәнлек, киләчәкне алдан белү интригасын кертү максаты белән файдалана. Эпоста да, әдәбиятта да төш күрү әсәр вакыйгаларын мавыктыргычрак итеп күрсәтә, сюжет кору чарасы буларак хезмәт итә. Шуңа күрә әдәбиятның әдәби сюжетларын гына түгел, әдәби чараларын да үзләштергән китаби дастаннарда төш күрү мотивын архаик фольклордагыча саф килеш сакланган дип әйтеп булмый, ул әдәби үзгәрешләргә дучар булган, әдәби коллизияләр белән керешеп киткән.

Төштә юралганча, Сайади дастанында Аллаһы рәхмәте белән ханның кыз баласы, ә бераздан вәзирнең улы туа. Кызга Зөһрә дип, ә малайга Таһир дип исем кушалар. Бала тууыны, яңа гына туган баланы тасвир иткәндә автор тарфыннан Урта гасыр татар әдәбияты метафоралары, образ һәм символлар оригиналь кулланылган:

Шулай үтте ай-көн, бөре ачылды,
Бу шаһның өстенә энҗе чәчелде. –

---

[1] Яхин Ф. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан, 2000. Б. 192.

Әлеге юлларда Зөһрәнең дөньяга тууы сурәтләнсә, яңа туган кызның үзен сурәтләгәндә исә автор Зөһрәнең үзен – гөл, авызын – бөре, иреннәрен – якутка, тешен – ак энҗегә, йөзенең кызылын – җәннәт гөленә, рухын – Ирам бакчасы былбылына, кашын – каләмгә, күзенең чагылышын гәүһәргә тиңләп, гаҗәеп матур һәм тәэсирле портрет барлыкка китерүгә ирешә. Мондый әдәби тасвир үзенең тәфсилле, тенденциоз булуы, Урта гасыр төрки әдәбиятына хас сурәтләү чараларының үзенчәлекле кулланылышы белән дастанның фольклордан бигрәк талантлы шагыйрь әсәре булуына ишарә итә.

Чибәрлектә бу икәү бер-берсенә гаҗәп дәрәҗәдә тиңнәр булалар, әмма Бабахан, Таһир туганчы ук:

– Угыл бирсә аңа, бер фикер итәрмен,

Ятимдер ки, башыга мән йитәрмен, – дип, биргән вәгъдәсеннән баш тартырга ниятли. Юраганы юш килеп, Таһирга биш яшь тулгач, Баһир вәзир вафат була.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»дәге кебек, Таһир белән Зөһрә дә бер үк мәктәпкә укырга йөриләр. Болар арасында кайнар мәхәбәт кабына, алар бер-берсенә сөю хатлары юллыйлар. Аларның хәленнән бөтен халык хәбәрдар булып тора. Әсәр вакыйгалары әле Таһирның газәле, әле Зөһрәнең газәле белән аралашып бара. Вакыйгаларны бәян итүче автор тезмәләре белән әлеге газәлләр дастан тукымасында гаҗәеп гармония тәшкил итәләр – әсәр структурасы театральләштерелгән тамашаны хәтерләтә. Шуннан чыгып, бу әсәрдә драма башлангычы да бар дип санарга мөмкин.

Монда рольләр оста уйланып бүленгән, персонажларның монологы һәм диалогы югары сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткерелгән. Туры сөйләмне биргәндә эпик фольклорда традициядә булган «ул әйтте», «җырлап болай әйтте» кебек формалар биредә сәнгати эзлеклелеккә салынган, авторның индивидуаль стиле белән баетылган. Әйтик, «Зөһрәнең бакчасарайга чыгып аһ-зар кылганы» дип исемләнгән бүлектә автор ясаулларның Таһир салынган сандыкны суга агызулары, Зөһрәнең, атасы кызына дип салдырган сарай бакчасына чыгып, шушы хәлне күреп сызлануын тасвир итә. Шуның артыннан килгән «Зөһрәнең газәле» дигән өлештә сүз сөйгәненнән аерылган Зөһрә авызыннан сөйләтелә:

Ярым китте, дусларым, үзем зар калдым тилмереп,
Мин бозылган хәстә җан – авыру калдым тилмереп.

Кулым көче җитмәде яр белән бергә китәргә,
Бала коштай йолкынып, начар кылдым мин тилмереп...

Ярыннан аерылуны кичерү сагышын автор гаять үтемле итеп бирүгә ирешкән. Моңа ул чагыштырулар (гашыйк җанны хаста җан белән, аерылу ачысын анасыннан аерылган кош баласы белән һ.б.), ритм-рифма камиллеге, сөйләм төзеклеге аша да, сүзне персонаж исеменнән алып бару алымы аша да ирешә. Нәтиҗәдә мавыктыргыч, тәэсирле мәхәббәт тарихы җанлы булып күз алдына баса.

Әсәрдәге образлар системасы шулай ук гаять дәрәҗәдә камил. Әсәрдә берничә урында Сайади исеме телгә алына. Монда Сайади автор буларак кына күзалланып калмый, вакыйгаларны укучыга җиткерүче буларак та катнаша, шушы тарихны сөйләп бирүче чичән-шагыйрь роленә керә башлый. Автор Таһир белән Зөһрә тарихын сөйли-сөйли дә, өченче затта үз исемен дә телгә алып куя. Мәсәлән, Зөһрәнең газәленнән соң ул, гашыйклык хәленең никадәр авыр булуын әйтеп, болай ди:

Бу кол Сайад гыйшкы өчен бу җиһаннан айрылган,
Яр алуны, дуслар, куя күр, мин алмадым һич тә[1].

Яисә бакчада Таһирның Зөһрәгә үзләренең туганчы ук үзара ярәшелгән булулары турындагы серне сөйләре алдыннан сүзне түбәндәгечә башлый:

Кил, и Сайад, син башла бу дастаның,
Кыш алдыннан ачылганын бакчаның.

Сайади шул рәвешле әсәр вакыйгаларына үз мөнәсәбәтен белдерә бара. Мондый алым дастанны билгеле бер кысаларда тота, сюжетны бер юлдан алып бара, әсәр структурасының тотрыклылыгын булдыра. Биредә Сайади образы, персонаж буларк, эпик фольклордагы чичән-шагыйрьне хәтерләтүе белән дастанны халык иҗатына якынайта. Шул ук вакытта дастанның мондый тотрыклы структурасы бер автор тарафыннан махсус уйланылган алым булуын да танымый мөмкин түгел. Бу исә әсәрдә индивидуаль башлангычның әһәмиятле роль уйнавын дәлилли.

[1] Өзекләр биредә һәм алга таба да филология фәннәре докторы, профессор Ф.З. Яхин әзерләгән тексттан алына: *Сайади.* Таһир – Зөһрә (Бабахан дастаны). Казан: Раннур, 1998. Б. 34.

Үзләренең ярәшелгән булуларын Зөһрә Таһирдан белә. Таһирның үзенә бу мәгълүмат юлда очраган бер хатын аша очраклы рәвештә җиткерелә. Бу хатын, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «бичара, илсез һәм ватансыз тол карчык» була.

Бу хатын Таһир белән Зөһрәнең икесен бергә очратып, алларына чыгып, боларга сүз ката:

Диде: – Шаһзадәләр, мин сүз куепмын,
Аның өчен килеп, монда торыпмын. – ди.
Сукбайларның догасыннан алыгыз,
Шелтәдән ул тарафка юл салыгыз, –

дип, үзенең сукбай-дәрвиш булуын җиткерә. Таһир белән Зөһрәгә очраган бу сукбай хатын болар белән сөйләшергә теләге барлыгын җиткерсә дә, Таһир, әдәпсезлек күрсәтә, аның әйткән һәм әйтәсе сүзләренә колак салмый, хатынга таба сөяк тотып ата. Таһир аткан сөяк килеп тигәч, хатын гарьләнә, сөйлисе сүзен сөйләми, Таһирга бөтенләй башка сүзләр әйтеп, китеп бара:

Тиеп сөяк хатынга, булды көлке,
Ул җирдә күп үзгә сүзләре килде.
Диде хатын: – Уйнама минем белән,
Уенда була күр Зөһрә ханым белән.

Хатын Таһирга серне ачмый, анасыннан сорарга кушып, максатына сабырлык белән җитәргә киңәш биреп, китеп югала.

Хәлиткеч минутта каһарманга изге картның яисә Хозыр Ильясның, я булмаса изгеләр өененең ярдәмгә килүе – төрки эпоста киң таралган күренеш. Күп кенә очракта батырга гадәттән тыш көчле кыз туганы, я хатыны, я очраклы бер хатын-кызның булышуы яисә алда санап үтелгән хатын-кыз образларның кайсы да булса егетне көрәшкә елап озатып калуы исә – төрки эпоста гомумән аерым зур мотивны тәшкил итә. Юлда очраган хатын белән каһарманның гапь коруы, каһарман язмышында әлеге образның күпмедер дәрәҗәдә роль уйнавы – матриархат чорына ук барып тоташа торган әһәмиятле мотив. Сайадиның «Бабахан дастаны»нда да шушы мотив чагылыш тапкан. «Бабахан дастаны» үзенең сюжеты белән «Кузы Күрпәч белән Баянсылу»га бик якын.

Әле генә телгә алынган мотив «Кузы Көрпе белән Баянсылу»-ның аеруча әһәмиятле мотивларыннан саналуы мәгълүм. Биредә

Кузы шемәкче (сихер, киләчәкне юрау белән шөгыльләнүче) башлыкның туз чиләгенә санагын төзәп өч кат ата, бу хәлгә ачуы килгән сихерче карчык Кузыга дөреслекне ачып сала: аның Баянсылу исемле ярәшелгән кызы (бер вариантта «әйттергән хатыны» дип бирелә) булуын әйтә, ул кызның кайдалыгын егеткә үз анасыннан кайтып сорарга, анасы сөйләсен өчен, учына кызган куырмач кысарга кирәк, дип өйрәтә. Сайади дастанында исә хатын белән әңгәмәдән соң, Таһир анасы янына кайтып, кыздырылган бодай ашыйсы килүен сәбәп итеп, анасыннан ашлык куырта, кызган ашлыкны анасы, улына каптырыйм дип учына салгач, анасының кулын кысып, теге хатын әйтеп бетермәгән серне үз анасыннан чиштерә, шуннан Зөһрә белән ярәшелгән булулары хакында белә. Күргәнебезчә, сюжет борынгырак чорга карый торган, башкорт һ.б. халыкларда тел-авыз эпик иҗаты буларак билгеле Кузы Көрпә һәм Баянсылу турындагы дастан белән шактый ук аваздаш. Аерма шунда: «Кузы Көрпә белән Баянсылу»да сүз күчмә тормыш алып баручы ханнар-ханзадәләр тормышын сурәтләсә, «Бабахан дастаны»нда исә шәһәр тормышы турында сүз бара. Әйтик, «Кузы Көрпә белән Баянсылу»да Кара ханның икенче бер җәйләүгә күчеп китүе турында әйтелсә, Таһир белән Зөһрәгә багышланган дастанда бу хәл шәһәр шартларында тормышка аша. «Кузы Көрпәдә әлеге һ.б. вакыйгалар нигездә чәчмә юлларда бәян ителсә, Сайада сюжетны шигъри югарылыкта яңгыратуга ирешкән, яңа мотивларга бәйләп үстергән, сурәтләү чараларына баеткан.

Зөһрәнең Таһир белән очрашуын белгән хан, Таһирны сандыкка салып, суга агызып җибәрә. Әлеге сюжетны Ф. Урманчеев «Борынгы Мисыр мифларыннан һәм Тәүраттан килгән сюжет» дип билгели, соңгысында яһүдләрнең беренче пәйгамбәре Моисейның (б.э.к. XIII–XII йөзләр) шундый ук маҗаралары хакында сүз бара дип күрсәтә[1]. Борынгы Мисыр мифларында исә сандыкка салып суга агызу теге һәм бу дөнья мотивы буларак гәүдәләнә. Ә бу исә дөньяны икегә – тереләр һәм үлеләр дөньясына бүлеп карый торган мифологик күзаллауга ук барып тоташа. Димәк, Таһир белән Зөһрәгә багышланган дастандагы әлеге мотив, беренчедән, гаять

[1] *Урманче Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. 3. (С–Я). Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 91.

борынгылыгы белән, икенчедән, язма чыганаклардан килүе белән игътибарны җәлеп итә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Бабахан дастаны»нда традицион төрки эпос мотивларының чагылыш табуы әсәрнең халык эпик традицияләре белән тыгыз бәйләнгәнлеген дәлилли. Бу яктан «Бабахан дастаны», романик әсәр булуына карамастан, төрки героик эпосы кысасында үстерелә. Әмма сюжет үстерелешендә дастан героик эпос кысаларыннан чыга, мәхәббәт дастаннары рәвешен ала, алгы планда бер-берсен яраткан егет белән кыз язмышы, бик борынгы язма истәлекләр үрнәгендә, максатчан тасвирлана. Сайади дастанын халык иҗаты мотивларын киң файдаланып, әсәрнең стиле, композициясе, сюжет корылышы, борынгыдан килгән эпик мотивларның әдәби интерпретацияләнүе җәһәтеннән исә язмачылык традициясенә өстенлек биреп язылган әсәр дип бәяләү хаклы булыр. Традиционлык һәм индивидуальлек кимәлендә караганда, Сайадиның «Бабахан дастаны» күбрәк индивидуаль автор әсәре билгеләренә ия. Әлеге сюжетка Сайадидан да әүвәлрәк мөрәҗәгатьнең әдәбиятка мәгълүм булмавы да аерым автор файдасына сөйли. Әмма гомумән алганда әсәр халык эпик иҗаты белән дә тыгыз керешкән, бу аның китаби эпос традициясендә иҗат ителгән классик эпос булуыннан килә.

Сайадидән соң Таһир белән Зөһрә сюжетына мөрәҗәгать итүчеләр күп булган. Алга таба бу тема күп кенә төрки халыкларның уртак мирасына әверелгән. Дастанның халык вариантлары белән бергә әдәбиләшкән вариантлары да мәгълүм. Әйтик, төрекмән поэзиясе классигы Молланепес (1810–1862) әлеге сюжетка классик дәрәҗәдә күләмле әсәр язган. Молланепес «Таһир белән Зөһрә»сенең рус һ.б. телләргә тәрҗемәләре дә бар[1].

Әлеге сюжетка әдәби вариантлар барлыкка килгәнче дә, әдәби вариантлар белән параллель рәвештә дә «Таһир белән Зөһрә»нең борынгы фольклор вариантлары яшәгән. Алары дастанның Сайади версиясеннән үзгә, чорына хас халык теленә якын торалар. Татарларда мондый вариантлар шактый күп. «Таһир белән Зөһрә» дастаны халык арасында иң укыла торган, иң киң таралган әсәр булган. Бу сюжетка халыкның үз арасыннан чыккан шагыйрьләр дә мөрәҗәгать иткән, андый очракта әсәр билгеле бер автор исеме белән мәгълүм

[1] *Молла-Непес.* Сказание о Зохре и Тахире. М.: Гос. изд-во худ. лит-ры, 1960. 252 с.

булган. Әйтик, Казанда Әхмәт Уразаев-Кормаши (Әхмәт мелла Мөхәммәтзариф углы Уразаев-Әлкызылҗарый Әлкормаши, туган елы билгесез – 1883 елда вафат) төзегән һәм бастырып чыгарган «Таһир илә Зөһрә» дастанына тукталыйк.

Ә. Кормашиның оригиналь сюжетка әсәр иҗат иткәнлеге әдәбият белемендә мәгълүм түгел. Ул «Көнчыгыш төрки халыкларында төрлечә вариантларда йөргән мәхәббәт поэмалары үрнәгендә»[1], үзе әйткәнчә, мәхәббәт поэмалары язу белән шөгыльләнгән укымышлы шәхес булган, Казанда 1874 елда «Бүз егет», 1876 елда «Таһир илә Зөһрә» кыйссасы»н бастырып чыгарган. «Таһир илә Зөһрә»дә казакъ телендәге кайбер фигыль формалары (мәсәлән, таңдап һ.б.), шактый гына казакъча лексик берәмлекләр (менән, канда, канча, алыс һ.б.) кулланылган. Бу – авторның шактый гомерен казакълар арасында уздыруы, казакъ телен белүе, казакъ фольклоры белән яхшы таныш булуыннан килә торган күренеш. Кульъязмасының ахырында автор болай ди: «Имде мин фәкыйрь бу хикәяте гаҗибияне госманлы тәварихларыннан күреп, җиңелрәк телемез нугай вә казакъ лөгатенчә чыгарып, ... бер-ике телгә тәсныйф кыйлдым»[2]. Димәк, бу әсәр Кормаши тарафыннан татар телендә генә түгел, казакъ телендә дә төзелгән булып чыга.

Эпос гадәттә я тоташ тезмә, я тезмә катыш чәчмә була. Кайбер әсәрләрдә проза белән эпос вакыйгалары бәян ителсә, каһарманнар сөйләме шигъри юлларда җиткерелә. «Күр углы»нда, мәсәлән, төп каһарман үз сүзен гел җыр аша җиткерә, «Алпамыш»та зур-зур шигъри өлешләр кыска прозаик юллар белән бер-берсенә ялгана, ә «Манас» исә, никадәр күләмле булуына карамастан, тулысынча шигъри әсәр. Эпосны халыкка җиткерүче тексттагы хикәяләүтасвирлау урыннарын декламация сөйләү характерында башкарса, каһарман сөйләмен һәм диалогларны җыр белән әйтә торган булган. Халык эпосы һәрвакыт үзенә генә хас гаять катлаулы һәм нечкә шигъри төзелешкә ия була. Җентекле сайланган, аллитерациягә бай, еш очрый торган кабатлаулар, ритмик-синтаксик параллелизмнар, тексттагы юлларның, строфаларның, тирадаларның югары таләпкә җавап бирерлек төзеклегеннән гыйбарәт рифмалы яисә рифмасыз

---

[1] Гайнуллин М.Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. Тулыландырылган икенче басма. Югары уку йортлары өчен. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 258.

[2] Шунда ук. Б. 304.

шигырь системасы һәм әсәрне халыкка җиткерүче оста иҗаты эпик текстны камил дәрәҗәле нәфис формага китерә. Сюжет традициясе кысаларында калып, эпос һәрвакыт күпләгән вариантларга ия була, фольклорча яңарып, халык тарафыннан яңа төсләр белән баетылып, эшкәртелеп тора. Эпик иҗат халык традицияләренең өзлексез һәм закончалыклы яңарышына нигезләнеп үсә.

«Төрле әсәрләр турында хикәят итүчеләр шундаг риваять һәм мундаг хикәят кылырлар...» дип башланып киткән беренче җөмләсе белән үк Кормаши дастаны да фольклор традицияләренә тугрылыгын дәлилли. Автор кемнәрдәндер ишеткән вакыйга турында сөйләячәген искәртеп куя.

«Таһир илә Зөһрә»нең Кормаши вариантында «олуг вә мәшһүр падишаһ»ның баласы булмый. Төрки эпоста бу күренеш «баласызлык мотивы» дигән махсус исем белән аталып йөртелә һәм ул бик борынгы чорларга ук барып тоташа. Мондый мотивны Борынгы Мисыр язма истәлекләрендә, Борынгы грек һәм Борынгы һинд мифологиясендә үк очратырга мөмкин. Угыз героик эпосында да баласызлык мотивы бар. Баласызлык темасы Урта гасыр кыргыз эпик ядкаре булган «Манас»та аеруча тулы чагыла. Шунысы кызыклы: татар дастанында бу мотив халык иҗатының б. э. к. язма истәлекләреннән башлангыч алып үстерелгән.

Әйтик, төрки эпос баланың могҗизалы юл белән тууына шактый әһәмият бирсә, бу хакта гадәттә тәфсилләп сөйләп, баланың кем булачагы билгеләрен туганчы ук белдерсә, Кормашиның «Таһир белән Зөһрә»сендә әлеге мотив, мәхәббәт дастаннары өчен кагыйдә буларак, шактый сүрелгән, аның героик дастаннардагы кебек турыдан-туры әһәмияте югала төшкән. Биредә каһарманның могҗизалы юл белән туу мотивы язмышны алдан хәбәр итү, багучылык элементлары, шул ук вакытта һәр эшнең Аллаһ ихтыяры белән башкарылуын искәртүләр белән кушылып киткән.

Баласы юклыгы хәсрәтеннән бакчасына чыккан падишаһ, вәзире белән йөргәндә, бер дәрвишкә мең алтын биреп китә. Дәрвиш аңа:

– Ходай Тәгалә морадыңны бирсен! – дип тели. Шуннан болар багучылык белән шөгыльләнүче икенче бер дәрвишкә киләләр, дәрвиш аларга берсенең падишаһ, икенчесенең вәзир булуларын, икесенең дә күңелләрендә бала теләге икәнен әйтеп бирә, киләчәктә әлеге ниятләренең ни рәвешле тормышка ашачагын сөйли.

Бу урында әһәмиятле бер деталь игътибарны җәлеп итә: хан һәм аның вәзиренең теләкләре үтәләчәген раслаганнан соң, дәрвиш, куеныннан бер алма чыгарып, догалар укып өрә, алманы тырнагы белән уртасыннан бүлеп, яртышар алманы боларның икесенә дә тоттыра. Сюжеттагы әлеге элемент героик ярәшү дип аталган популяр мотивта очрый торган, героик эпоста шулай ук шактый киң таралган алма биреп вәгъдәләшү вакыйгасы белән аваздаш. Әйтик, башкорт халкының «Урал-батыр» эпосында падишаһ Катилнең кызы, бер рәткә тезелеп баскан егетләр арасыннан Урал батырны сайлап ала һәм аңа алма тоттыра, хезмәтчесенә үзе сайлаган егетне, ягъни Урал батырны үз сараена алып барырга куша. Егет бу тәкъдимне кабул итмәгәч, аңа болай ди:

Егет, я выбрала тебя,
А ты в дворец не пошел,
Яблоко подарив, знак тебе подала –
Меня ровней себе не признал,
Мое приглашение отверг,
Перед всеми рабами
Ты опозорил меня[1].

Батырга бүләк итеп бирелгән алма биредә партнёр сайлау, уңдырышлылык (үрчем) идеясен символлаштыра. Алманың мондый символик функциясе башкортларның «Акбүзат» эпосында да очрый. Биредә дә хан кызы Айсылу, кулына алма тотып мәйданга чыга һәм егетләр арасыннан үзенә пар табу ритуалын башкара, әмма яр табуда алманың эпик функциясе әлеге очракта да тулысынча реальләшми: «Айсылу обошла всех батыров, но ни один из них не осмелился, говорят, взять яблоко. Потом Масем-хан дал батырам подумать до завтрашнего дня, говорят»[2].

Героик эпоста алманы каһарманга кыз бирсә, биредә аны кыз һәм егетнең аталары дәрвиш кулыннан кабул итәләр. «Таһир белән Зөһрә» дә сюжет интерпретациясе мәхәббәт дастаннарындагыча корылган: дәрвиш туачак балаларның ярәшелгән булуларын, балигълык яшенә җиткәч, Зөһрәне «Аллаһе Ттәгалә фәрманы берлә» Таһирга бирү тиеш икәнлеген әйтә. Аннары: «Әгәр дә бер-берсеннән

---

[1] Башкирский народный эпос. М.: Наука, 1977. С. 286.
[2] Шунда ук. Б. 406.

аерсаңыз, башларына Фәрһад илә Ширин, Ләйлә илә Мәҗнүн, Арзу илән Канбәр, Вамикъ илән Гарәр, Вака илән Гөлшаһ башларына килгән хәлләр шикелле гаҗәеп хәлләр килеп, кыяматкәчә телләрдә хикәят улып сөйләнер», – дигән сүзләр әйтеп, юкка чыга.

Шулай итеп, алма бирү вакыйгасы биредә, санап үтелгән героик дастаннардагыдан күпкә аерылып тора, биредә аны турыдан-туры кыз үзе түгел, чит кеше бирә, бу чит кеше, мәгълүм мәхәббәт дастаннарындагы персонажларны мисалга китереп, үзе үк бу гамәленең мәгънәсен аңлатып күрсәтә, бу эшнең Аллаһ кодрәте белән башкарылачагын, карышырга ярамаганлыкны да алдан кисәтә. Әмма образ буларак алманың биредә дә, героик эпостагы кебек үк, символик мәгънә – ярәшү-вәгъдәләшү мәгънәсен саклавы кызыклы. Әлеге элементның «Таһир – Зөһрә» сюжетлы мәхәббәт дастаннарына килеп керүе төрки героик эпос белән соңгырак чор мәхәббәт дастаннары арасындагы фольклор дәвамчанлыгын раслый торган билге буларак зур әһәмияткә ия.

Әдәби эшләнеш ягыннан Кормаши варианты Сайади дастаныннан күпкә гадирәк, кайбер урыннарда вакыйгаларны тасвирлаганда сурәтлелек бөтенләй икенче планда кала кебек. Әйтик, бала туу уңаеннан Сайади вариантында гаҗәеп тәэсирле тасвир китерелгән булса, Кормашида андый бәянга юлыкмыйбыз. Алга таба дастанда ханның – кызы, ә вәзирнең улы тууы турында коры гына хәбәрдән гайре тасвир юк. Моны дастан иҗат итүдә индивидуаль башлангыч дәрәҗәсе белән аңлатырга мөмкин. Сайади иҗаты тоташ тезмәдән торуы белән аерылып торса, Кормашида чәчмә өлеш күпчелекне тәшкил итә.

Кормаши дастаны – язмача иҗат ителгән әсәр. Текстның беркайчан да чичән тарафыннан «тереләй» башкарылмаганлыгы – факт. Дастанны халыкка җиткерүче (ә бу очракта ул – автор Кормаши) үзе үк әсәрнең нәкъ менә китап булуын, язылуын әйтә: «Әгәр гүзәлләкләрен бәян кылсак, бу китап дәхи бер китапны галәхидә (ягъни аерым рәвештә. – *Л.М.*) язсак кирәк». Әмма Кормаши әсәренең нигезендә телдән сөйләнгән хикәят ята дип фаразларга да тулы җирлек бар.

Елау-сыктау – гомумтөрки эпос өчен уртак мотив. Гадәттә, баласыннан аерылган ана, баһадир улы өчен өзгәләнеп, чагыштыру-эпитетларга бай сыктау әйтә, мондый урыннар төрки дастанның гаҗәп тәэсирле урыннарының берсен тәшкил итә. Бу хакта алдарак

та сүз алып барган идек. Әйтик, төрки эпосның нугай версиясе булган «Айсул улы Ахмәт», «Копланды батыр», «Мамай», «Адел солтан», «Эр Күсеп, «Елкилдек батыр» һ.б. дастаннарның ахырында, каһарман үлеменнән соң, шундый елау-сыктау монологы сөйләнүе мәгълүм.

Мәхәбәт дастаны буларак, Кормаши әсәрендә каһарманның елавы сөйгәненнән аерылуны авыр кичерү белән бәйле. Елау-сыктау тезмәләре дастанда гаять күп, Әйтик, Мәрдингә сөрелгән Таһир, елый-елый, болай ди:

Карый-карый калдың син, күп кыеннар салдың син,
Сөйгәнеңнән аерылып, еглый-еглый калдың син.
Бутасыннан (дөя баласы. – *Л.М.*) дөядәй буздый (бузнап,
дөядәй кешнәп. – *Л.М.*) калдың син.
Күп тубыннан аерылган коштай моңдый (моңланып. – *Л.М.*)
калдың син.
Ботагыннан аерылган гөлдәй сулып калдың син.
Анасыннан аерылган баладай еглап калдың син... һ.б.

«Чура батырга багышланган дастаннарның нугай версиясендә Шора һәлакәтеннән соң анасы Миңлесылуның елавын алдагы бүлектә мисал итеп китергән идек. Анда баласын югалткан ана баласы үлгән дөягә тиңләнә, чарасызлыктан ананың дөядәй бызлый-бызлый китүе әйтелә, елап-сыктап, Миңлесылу болай ди:

Баласы үлгән дөядәй,
Бызлый-бызлый китәем.

«Таһир белән Зөһрә» дастаныннан китерелгән өзектә дә шундый ук чагыштыруның булуы хронологиясе, таралыш географиясе һәм тематикасы төрле эпик әсәрләрдә уртак детальләр табылу ягыннан кызыклы. Мондый элементлар – уртак төрки тамырлар һәм бердәй традицияләр сакланышына турыдан-туры мисал.

Шушы ук мисалда «Таһир белән Зөһрә» дастанында Аллаһның телгә алынуы да игътибарга лаек. Таһирның ярыннан аерылып читкә сөрелүе дастанда үлемгә тиңләштерелә. Сайади вариантында бу халәт сандыкка салып суга агызу мотивы аша җиткерелгән булса, традицион эпостан күпмедер дәрәҗәдә аерылып, язма-китаби юнәлештә үскән китаби дастан буларак, Кормашида Аллаһ телгә алына. Ә мәҗүсилек чорына караган борынгы төрки эпоста Аллаһ

ярдәменә таяну, каһарманның үлемен Аллаһ каршына бару буларак интерпретацияләү гомумән юк. Бу мәсьәләгә алдарак, II бүлекнең «Каһарман Катил»гә багышланган өлешендә тәфсиллерәк тукталган идек. Биредә, теге дөньяга китүче Таһир, сөйгәнен «ике дөнья дәүләте», дип атый, ягъни Зөһрә – бу һәм теге дөньяларда Таһирның яры. Зөһрәне «рух рәваны (җан китүе. – *Л.М.*)», «дил нәвазы (күңел назы. – *Л.М.*)», «җан юлдашы» һ.б. тиңләп, аның белән хушлашкан Таһир Аллаһ тарафына китүче булып күзаллана. Елап-сыктап әйткән монологын Таһир:

> Бар серләрне белгүче, яр юлларын төзгүче,
> Тапшырыпмын Аллага, онытма, җаным, онытма! –

дип тәмамлый. «Таһир белән Зөһрә» дастанында әсәр сюжетында әледән-әле Аллаһ телгә алыну – табигый, чөнки әсәр, алдарак карап үткән «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастаны кебек үк, китабилык традициясендә барлыкка килгән әсәрләрдән. Ә мондый әсәрләрдә исламча дөньяга карашның булуын алдагы бүлекләрдә китергән мисаллар аша да, «Таһир белән Зөһрә» дастаны аша да күрергә мөмкин.

Татар мәхәббәт дастаннарының күбесенә хас булганча, Кормашиның «Таһир белән Зөһрә»сендә дә вакыйгаларны берберсенә бәйләү «әлкыйсса» (кыскача, бер сүз белән әйткәндә), «рави әйтер» кебек сүзләр кулланып алып барыла. Биредә дә каһарманнар сөйләме җыр белән бирелә. Текстта әлеге шигъри өлеш «назым әйтте», «бу шигырьне әйтте», кайбер урыннарда исә «бәет әйтте» кебек сүзләр белән тәкъдим ителә бара, шундый аңлатмалардан соң гашыйкларның диалогы яисә монологыкитерелә. Әйтик, Таһирның Зөһрә тәрәзәсенә карап әйткән тезмәсе текстта «бер назым әйтте» дип бирелгән:

> Бирик дигән вәгъдәңне онытыпсың, Зөһрәҗан,
> Камил биргән күңелене суытыпсың, Зөһрәҗан,
> Җан юлыңда гашыйктан хәбәрең юк, Зөһрәҗан,
> Зар-сәргардән, гариптән хәбәрең юк, Зөһрәҗан,
> Гашыйк ярлар мәгъшукка хәбәр бирмәс булырмы?
> Чын хакыйкать яр булса, хәбәр салмас булырмы?

Зөһрәнең, апасының тәрәзәне ачмаска үгетләвен дә тыңламыйча, йөзен Таһирга күрсәтеп биргән җавабы «бер шигырь әйтте» дип китерелгән:

Кайгы булган юлдашым, мәхбүс булган гөл башым,
Таһир, күңлем калдырма, гыйшкың – минем юлдашым.

Текстта кара-каршы әйтешеп елау эпизодлары еш кабатлана. Әле Таһир, әле Зөһрә, зар елап, бер-берсенә мәхәббәт аңлаталар, елашып шигырь әйтеп, күңелләрен юаталар. Кабатланып килә торган мондый эпизодлар еш кына бер үк сүзләр белән интерпретацияләнә. Мәсәлән, «зарилык кылып әйткәне будыр», «бүсәләр һәм шәфталулар алыштылар», «таң вакытынача кәеф-сафа корып утырдылар», гашыйклар җыр әйтешеп «назым әйттеләр», Зөһрәнең Таһирга каршы әйткән назмы» һ.б. кебек яисә шуларның турыдан-туры синонимы булган җөмләләр текстта гаять күп. Сюжет үстерелешендә «рави әйтер», «рави риваять кылыр» кебек сүзләрнең дә (рави – сөйләүче, башка бер кешедән ишетеп сөйләүче дигән сүз) текстта әледән-әле кабатланып торуы күзәтелә.

Кормаши варианты нигездә китаби тел белән язылган. Әдәби стильгә хас катлаулы җөмләләр, «нәркис күзләреннән гөл йөзләре өсләренә энҗү яшьләр сил (көчле агым. – Л.М.) булып агып төште» кебек эмоциональ-экспрессив лексика актив кулланылган булу әнә шулай дип әйтергә җирлек тудыра. Сайади версиясеннән аермалы буларак, дастанның теле бүгенге көн укучысына аңлаешлырак. Әмма китаби чыгышлы архаик сүзләр Кормашида да шактый. Әмма шул ук вакытта текстның кайбер урыннарында шигъри тезмәләрнең халык шигыре стиле белән аваздаш булуын да күрми мөмкин түгел.

Бер үк мәхәббәт тарихын яктыртса да, Кормаши вариантының сюжеты шактый зур үзенчәлекләргә ия. Әйтик, биредә бер-берсен сөйгән ике ярны аеру эшендә инициатива күрсәтүче кеше, Сайадидагы кебек, вәгъдәсендә тормаучы хан (Зөһрәнең атасы) түгел. Бу икәү арасындагы мәхәббәт хәлләрен сизеп алган бер көнчел гарәп белгәнен башта кызның анасына сөйли. Гарәпнең монологы әсәрдә шигъри тезмә белән бирелгән. Кызның анасы бу хәлгә бик ачына, ханга барып, аңа әлеге хәбәрне җиткерә: «Ышанмасаңыз, гарәпне хозурыңызга чакыртып сораңыз», – ди. Гарәп Таһир белән Зөһрәнең бакчада очрашып, кочаклашып-үбешеп йөрүләрен ханга да әйтә. Хәбәр ханга Таһирга явызлык теләү максаты белән җиткерелгән булса да, хәлне ишеткән хан гаделлек белән эш итә. Бу уңайдан аның әйткән сүзләре түбәндәгечә:

Бер уй кылсам кирәктер, йортым җыйсам кирәктер,
Кызым кушып Таһирга,туен кылсам кирәктер,
Алтын сарай төзетеп, гәүһәр белән бизәтеп,
Уенчылар уйнатып, туен кылсам кирәктер.
Алтын өйләр салдырып, йортым җыйсам кирәктер,
Торгын атлас (кытай ефәге. – *Л.М.*) җәйдереп, туен кылсам кирәктер.
Араб-шәраб кайнатып, гәүһәр белән бизәтеп,
Пәһлеваннар сыйлатып, туен кылсам кирәктер.
Мең аргамак җаратып, шаһзадәләр алдырып,
Уенчылар соратып, туен кылсам кирәктер.
Алтын тирәк җундырып, асыл кошлар кундырып,
Гәүһәр касә сондырып, туен кылсам кирәктер.
Хәзинәмне ачтырып, энҗе-мәрҗән сачтырып,
Йөк-йөк биюм арттырып, инде кушсам кирәктер.
Вәгъдәм көне җиткәндер, бирер көнем җиткәндер,
Җан кызымның туены күрер көнем җиткәндер.

Игътибар итсәк, югарыда китерелгән шигъри монолог – бер үк төрле гыйбарәләрнең кабатланып килүенә нигезләнгән («туен кылсам кирәктер», «бирер көнем җиткәндер» яисә «күрер көнем җиткәндер» һ.б.) аллитерацион шигырь үрнәге. Мәгълүм булганча, мондый ысул чичән тарафыннан башкарыла торган традицион «тере» эпос өчен популяр. Сурәтле тел тудыруда әһәмияте зур булган әлеге ысулның Кормаши дастанында кулланылган булуы – әсәрдә төрки эпик традициягә тугрылык, язма-китаби традициядә тел-стиль җәһәтеннән халык шигыренә мөрәҗәгать үрнәге. Шуңа күрә Кормашиның «Таһир белән Зөһрә» дастаны тел-стиль ягыннан әдәби-язма поэзияне дә, халык иҗатын да бердәй үзләштереп язылган әсәр дип әйтү гаделлекккә туры килә.

Шул рәвешле, хан туйга әзерләнә башлый. Әмма ханбикә аңа каршы төшә, Зөһрәне Таһирдан биздерер өчен сихерчегә бара. Тегесе, кабер туфрагы алып, әфсен укып өрә, шуны, ширбәтенә салып, падишаһка эчертергә куша. Ханбикә ул кушканны төгәл үти. Шул хәлдән соң падишаһның күңелендә «нәфрәт һәм салкынлык пәйда була».

Димәк, Сайади вариантыннан аермалы буларак, биредә сюжет падишаһның әүвәл кызын Таһирга бирергә риза булып та, хатыны ханбикә мәкере һәм сихер аркасында үз фикереннән кире кайтып, вәгъдәсен бозуы белән катлауланган. Сюжет аермасына мисал

буларак китерелгән әлеге мисал гына да Кормаши дастанының халыкчан интригага гаҗәеп бай булуын күрсәтә. Сихер һәм җадулар хезмәтенә мөрәҗәгать – төрки дастаннарда еш кулланыла торган элемент. Моңа мисалларны «Каһарман Катил», «Чура батыр», «Кыйссаи Сәкам», «Кузы Көрпә белән Баянсылу» һ.б. дастаннарның татар һ.б. версияләрендә табарга мөмкин. Бу очракта ханбикәнең мәкерле уен чынга ашыру өчен сихерче кулланган ысуллар (кабер туфрагыннан файдалануы, аңа әфсен укып төкерүе, аны сыеклыкка салып, сиздерми генә тиешле кешесенә эчертү һ.б.) халыкта киң таралган им-том, ырым, сихер ысулларына барып тоташкан булуы белән кызыклы. Шунысы әһәмиятле: дастанда тасвирланган, күңелгә шом сала, фольклористикада имләү йоласы жанрында карала торган торган әлеге ысуллар халыкта әле дә яши.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Кормаши исеме белән мәгълүм «Таһир илә Зөһрә» – Сайадиныкыннан күпкә үзенчәлекле сюжетка ия, мәшһүр мәхәббәт вакыйгасына багышланган ярым фольклор, ярым әдәби әсәр. Кормаши вариантының үзенчәлекле сюжеты, әсәрдә сурәтлелек тудыру, әдәби коллизияләрнең индивидуаль автор иҗатыннан үзгәрәк дәрәҗәдә булуы, кабатлауларның очравы, бер үк төрле эпизодларның еш кабатлануы, текст төзелешендә сарыннар, елау-сыктау элементларының кулланылуы һ.б. – дастанның телдән башкарылуына, дөресрәге сөйләмә вариантка нигезләнүенә ныклы ишарә. Болар – Кормаши вариантында телдән башкарылу техникасы эзләре, китаби дастанны фольклор белән якынайта торган билгеләр. Халыкта язма вариант буларак таралган «Таһир илә Зөһрә» нигездә төрки эпик традицияләрне туплаган, әмма китаби үзгәрешләргә дә бик нык дучар булган вариант. Әдәби чараларның кулланылуына һәм ни дәрәҗәдә индивидуаль иҗат булуына бәя биреп, шуны әйтергә мөмкин: әлбәттә, дастанның Кормаши варианты, Сайади дастаны кебек классик эпос булудан шактый ерак. Әмма биредә шул ук төрки эпос кагыйдәләренең, халык эпосына хас традицияләрдән читләшеп, язма-китаби юнәлеш алуын да күрдек.

Урта гасырлар төрки поэзиясе стилендәге, сентименталь характердагы мәхәббәт дастанының XIX йөздә татар халкы арасында кабат активлашуының сәбәбе – бу чорда татарларда эмоциональ-сәнгати көчкә ия халык китабына ихтыяҗның гаять зур булуында. «Таһир белән Зөһрә»нең Кормаши варианты – татар китаби дастанының иң камил формалы үрнәге. Дастанның XIX йөздән татар халкында

таралышында һәм популярлыгында Кормаши вариантының роле гаять дәрәҗәдә зур булган. 1876 елдан әсәр Казан типографияләрендә китап итеп бастырыла башлаган. Кормаши варианты Казанда 1879, 1888, 1889, 1891, 1895, 1896, 1897, 1898, 1902, 1905, 1907, 1908, 1911, 1914, 1915, 1917 елларда басылган.

Таһир белән Зөһрә мәхәббәтенә багышланган дастанның Сайади һәм Кормашиныкыннан тыш вариантлары шактый күп. Күләме, мөстәкыйль әсәр булулары ягыннан алар бер-берсеннән шактый нык аерылалар, әмма уртак сюжет һәм мотивларның кабатлануы бу дастаннарны бергә туплый, аларны татар халкында популяр бер үк дастанның төрле вариантлары итеп карау ихтыяҗын китереп чыгара.

Алга таба 1872 елда Санкт-Петербургта В. Радлов бастырып чыгарган текстка тукталырбыз[1].

Галим әсәрне себер татарларыннан язып алган. Дастан күләмле, себер татарлары диалектында бәян ителә. Әсәрнең исемендә дә көнчыгыш диалект үзенчәлеге чагылыш тапкан: дастан «Тайыр менән Сәүрә» дип атала. Информантның исеме теркәлмәгән, ягъни әсәрнең кемнән язып алынган булуы билгесез. Дастанны шартлы рәвештә Радлов варианты дип атарбыз.

Дастанның сюжет составы нигездә халыкчан-традицион. Текст көнчыгыш лиро-эпик әсәрләре рухында башланып китә. Ал хан һәм Гөл хан исемле ике хан турында кыскача гына хәбәр ителә. Алар икәүләп сәхрәгә ауга чыккач, тауга таба чабып менеп бара торган куянны күреп алалар. Куян көмәнле була. Ханнарның өлкәнрәге – Көл хан, өйдә калган көмәнле хатынын уйлап, куянга атмый. Баштарак Көл ханга куянны атарга тәкъдим иткән Ал хан да, Көл ханның фикеренә кушыла, куянга тими. Ал ханның да хатыны көмәнле икән. Бу эпизодлар Радлов вариантының халыкның кайсы эпик әсәренә иярүен ачыкларга ярдәм итә. Бу – һичшиксез «Кузы Көрпә һәм Баян сылу» дастаны. «Кузы Көрпә һәм Баянсылу» вариантлары белән Радлов «Таһир белән Зөһрә»сендә хәтта ханнарның исемнәре дә авазлаш – Ак хан һәм Кара хан, алар да икесе бергә ауга чыга, икесенең дә хатыннары көмәнле калган була.

---

[1] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч. IV. Наречие барабинских, татарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. 412 с.

Кормаши вариантында да «Кузы Көрпә һәм Баянсылу»га охшашлыкларга тап булган идек. Әмма Сайадида да, Кормашида да хан үзенең вәзире белән ауга чыга яисә сүз куеша, вәгъдәләшә. Боларда социаль каршылык идеясе үзен сиздерә. Ә Радлов вариантын карасак, биредә кызның атасы да, егетнеке дә ханнар буларак тасвир ителгән. Ал ханның ир баласы, Көл ханның кыз баласы туа. Ике ата Кормашида багучы алдан хәбәр иткәнгә күрә кодалашырга уйлаган булса, монда исә аларга бу эштә киңәш бирүче булмый, болар фәкать үз ирекләре белән генә вәгъдә куеша. Шул ук вакытта сюжетка артык үзгәреш тә кертелми: кызны егеткә бирмәү максатыннан каршылык биредә дә туа. Әмма Радлов вариантындагы каршылык Сайади яисә Кормашидагы каршылыктан күпкә аерылып тора. Моны тасвир итү өчен әсәргә үзенчәлекле эпизодлар килеп кергән. Атында аудан өенә чабып кайтканда Таһирның атасы Ал хан аттан егылып төшеп үлә. Кызын ятим балага бирмәс өчен, Көл хан башка шәһәргә күчеп китә.

Шулай итеп, фольклор әсәренә хас булганча, биредә әсәрнең социаль мәгънәсен ассызыкларга омтылыш юк. Сюжет составындагы бу һ.б эпизодлар аша түбәндәгеләр исбатлана: Сайади һәм Кормаши вариантларында әдәби-язма традицияләр өстенлек алган, ә себер татарларыннан язып алынган вариантта исә фольклор чагылышы күбрәк, текст борынгы халык эпосына якын. Радлов вариантында хәл алга таба да халыкчан-типик юнәлештә дәвам итә: әле тагын башка күп кенә эпизодлары белән «Кузы Көрпә...» дастаны белән кисешә. Радлов вариантында әсәрнең халык эпосы булуын искәртүче эпизодлар, мотивлар гаять күп.

Дастанда кайбер вакыйгалар шулкадәр нечкәләп, тәфсилләп сөйләнә, вакыйгалар үстерелеше, образлылык ягыннан халык дастаны хәтта әдәби әсәргә охшый башлый. Әйтик, «утырса – башы, сузса аягы тимәслек, эче көмеш, тышы алтын, эченнән ачкычы булган су кермәслек» сандык ясатып, Таһирны агызып җибәрү һ.б. Сандыкның сыйфатларын тасвирлаганда биредә әдәби алымга өстенлек бирелгән. Алдарак сандыкка салып суга агызу мотивының үзен дә б.э.к. берничә меңъеллыклар элек яшәп киткән цивилизацияләрнең язма эпик традицияләреннән килә торган сюжет буларак караган идек. Таһирны сандыкка салып суга агызу, теге дөнья белән очрашу мотивы буларак, борынгы мифологик күзаллауларга һәм алар теркәлеп калган Борынгы Мисыр язма истәлекләренә үк барып

тоташа. Әлеге интригалы сюжетның Радлов вариантында да очравы татар эпосында халык традицияләренең борынгы язма мәдәният белән кисешүен күрсәтә[1].

Радлов вариантында Урта гасыр феодаль шәһәр шартлары белән бәйле эпизодларның булуы да әсәрне әдәби-язма традицияләргә якынайта. Дастанда Ал хан белән Көл ханның җәйләү түгел, ә шәһәр тотучы ханнар булуы, Ал хан үлгәч, Көл ханның башка шәһәргә күчеп китүе тасвир ителә. Ә алга таба, Сайади һәм Кормаши вариантларындагы кебек үк, Таһир белән Зөһрәнең бергә мәктәпкә йөрүләре турында сөйләнә. «Кузы Көрпә...»дәге ысул белән анасыннан ярәшелгән кызы турында белгәч, биредә каһарман, атына менеп, юлга шәһәрдән кузгала, гәрчә «Кузы Көрпә...»дә шәһәр шартлары турында бер генә искәртү дә булмаса да. Димәк, традицион халык дастаны рухын саклаca да, Радлов варианты китаби үзгәрешләр дә кичергән.

Төрки дастаннарның шигъри эшләнешендә елау-сыктау эпизоды әһәмиятле урыннарның берсен тәшкил итә, дигән идек. Әсәрнең телдән башкарылу үзенчәлеген билгеле торган мондый эпик бизәкләр нугай, кырым татарлары, казакъ һ.б. төркиләр эпосында гаять популяр булуын карап үттек. «Таһир белән Зөһрә»нең В. Радлов вариантында Таһир, кәләшен эзләп юлга чыгып киткәч, егетнең әнисе, алда булачак хәвефне сизеп, елау-сыктау сүзләре әйтә:

Баламны инде күрмәем,
Баламны куып барып китәем,
Өйгә алып кайтараем!
Өер бияне алып килең!

Биягә менеп, «үз шәһәрендән цыгып», Таһир артыннан чапкан әнисе, аны куып җитеп, кире кайтырга үгетли. Ана белән баланың үзара сөйләшүе бер-берсенең җавабын бераз үзгәргән вариациядә кабатлауга кайтып кала. Мондый кабатлаулар, даими кулланыла торган тәгъбирләр төрки героик эпосындагы борынгы эпик клишеларны хәтерләтә:

Кайт, балам, кайт, балам!
Бу юлдан син кайтмасаң,
Мин сине тагы күрмәсәм,
Бу өемдә тормаен!

[1] Повесть Петеиса // Древнеегипетская проза. М., 1978. С. 42; Темкин Э.Н., Эрман В.Г. Мифы Древней Индии. М., 1982. С. 104, 124, 136 и др.

Кыйгудан (елга ярындагы тар урын. – *Л.М.*)
цыкса кырык бүре,
Аннан ницек цыгарсын?
Айгайдан (куе кыяклык. – *Л.М.*) цыкса кырык бүре,
Аннан ницек цыгарсын?
Цыцкан үтмәс цытырман,
Цытырманнан ницек цыгарсын?
Агынып (менеп. – *Л.М.*) йитмәс ала тау,
Аннан ницек цыгарсын?
Кыелып яткан тиңесне (диңгез, су. – *Л.М.*)
Аннан ницек цыгарсын?

Таһир анасына биргән җавабында анасы санаган каршылыкларның һәркайсын шул ук эзлеклелектә кабат телгә ала, шундый ук шигъри тезмә юллар белән аларны ничек итеп җиңәчәген әйтә, төрки эпос каһарманы рухында сүзеннән кире кайтмаячагын белдерә.

Бу эпизод та «Кузы Көрпә...»дә Кузы белән аның анасының әйтешен хәтерләтә. «Кузы Көрпә...»дә каһарман, үзенең хатынының кайдалыгын анасыннан белгәч, атасының кылыч-сөңгеләрен алып, анасыннан ризык әзерләтеп, атасының акбүз атына атлана да, хатынын эзләп китәргә җыена. Шул вакыт анасы белән Кузы арасында әле генә «Таһир белән Зөһрә»дә карап үткән кебек үк шигъри диалог урын ала, анасы Кузының юллыгын төшендә күрүен сөйли:

Бүгендә яман төш күрдем, балам,
Уйның утыз бүресе, балам,
Аннан кайдан чыгарсың, балам?
Кырның кырык бүресе, балам,
Аннан кайдан чыгарсың, балам?

Кузының анасы, улын озатканда «тычкан үтмәс карурман», «атлар әйләнмәс ала тау» һ.б. каршылыкларны да телгә ала. Күргәнебезчә, болар – «Таһир белән Зөһрә»нең Радлов вариантында каһарман үтәргә тиешле каршылыклар. Кузы да, анасына биргән җавабында, анасы саный барган эзлеклелектә ул каршылыкларны ничек үтәчәге турында әйтә.

Игътибар итсәк, «кырык» В.Радлов вариантында әллә ничә урында кабатлана: кырык бүре, кырык кыз, Зөһрә җыйдырган кырык пәри, падишаның кырык хәзинәсенең ачкычы һ. б. Әлеге санның төрки эпоста еш очрый торган эпик сан булуы мәгълүм. Шул ук кырык

бүре һ.б. «Кузы Көрпә...»дә дә (кырның кырык бүресе, кырык кызак һ.б.), башка төрки героик эпоста да еш очрый. Әсәр сюжетында кулланылулары ягыннан «Таһир белән Зөһрә»дәге «кырык»лар «Кузы Көрпә...»дәгеләре белән аеруча аваздаш.

Югарыда телгә алынган даими тәгъбирләр, кабатлаулар, аллитерациягә нигезләнгән тезмә диалоглар, каһарманның ярәшелгән кызын эзләп читкә чыгып китүе, анасының каршы төшеп елап-сыктап ялынуы, Таһирның үз кәләшен эзләп табу юлындагы барлык каршылыклар белән көрәшен тасвирлау – гадәттә чичәнимпровизаторларның халык алдында телдән башкарыла торган дастаннарына хас алымнар. «Таһир белән Зөһрә»нең В. Радлов вариантына чичәнлек традициясе шактый нык сакланган. Әйтик, Кормаши варианты белән чагыштырганда, биредә телдән башкарылу техникасының ныграк сакланган булуы «Таһир белән Зөһрә»нең себер татарларыннан язып алынган вариант булуыннан килә.

Чыннан да, безнең халыкның Себер татарларыннан язып алынган дастан вариантлары гадәттә казакъ, нугай, кырым татарлары, төрекмән һ. б. халыкларның сөйләмә формадагы традицион дастаннарына якын тора. Бу аларның күчмә яисә ярымкүчмә тормыш шартларында озаграк яшәүләренә, исламга һәм шәһәр тормышына Идел буе татарларына караганда бераз соңрак килгән булуларына, эпос жанрының чичән-импровизатор иҗаты белән бәйле төре өстенлек алган халыклар белән озак еллар күршелек итүләренә һ.б. факторларга бәйле.

Текстта шигъри өлешләр проза белән аралашып килә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, В. Радлов варианты үзенең сюжеты, идеяләре белән татар һәм төрки эпос традицияләренә таяна. Әсәргә XIII–XV йөзләрдә төрки халыклар иҗатында киң таралган, күчмә тормышны һәм көнкүрештәге архаик шартларны чагылдыра торган «Кузы Күрпәч һәм Баян-сылу» дастанының тәэсире зур. Әмма шул ук вакытта дастан ярым әдәби, ярым фольклор текстлары булган Сайади, Кормаши әсәрләре йогынтысын да урап узмаган. Бу – себер татарларының соңгы чор эпик иҗатында китаби үзгәрешләр күзәтелүне күрсәтә торган факт. Бу әсәрнең мәхәббәт дастаны булуыннан да килә. Бу җәһәттән Радлов вариантын әлеге темага башка, әйтик, «Гашыйк Гариб» яисә «Ләйлә белән Мәҗнүн» һ.б. дастаннарның татар халык версияләре белән дә янәшә куярга мөмкин. Төп сюжеты, мотивлары уртак булу мондый әсәрләрне бер үк типологик рәткә куя.

Таһир – Зөһрә сюжетына багышланган текстлар татар халкында болар белән генә чикләнми. Халыкта кулъязмалар рәвешендә йөргән, әле бүгенге көндә дә табыла торган вариантлар үзенең күләме белән дә, шигъри эшләнеше ягыннан да Сайади, Кормаши, Радлов вариантларыннан күпкә калыша, әмма сюжетының мөстәкыйльлеге, традицияләренең борынгылыгы һәм халыкта гаять популярлыгы җәһәтеннән алар шактый әһәмиятле чыганак булып торалар. Дастанның телдән язып алынган вариантлары да бар. Безнең көннәргә кулъязма булып килеп җиткәннәрен дә, халык сөйләгәннән язып алынганнннарын да берләштерә торган бер сыйфат бар. Соңгырак чорга карый торган әлеге чыганаклар барысы да Идел буе татарларына карый һәм алар барысы да, дастан булудан бигрәк, әкият жанрына якынлашканнар. Эпос жанрының казан татарларына хас мондый үзенчәлеге хакында «Алпамыш» дастанының казан татарлары варианты мисалында беренче бүлектә сүз алып барылган иде. Башка халыкларда традицион дастан буларак яшәгән, галимнәр тарафыннан язып алынган текстларның шул ук сюжетка татар версияләре еш кына әкиятләшкән булуы турында В.М. Жирмунский да язган иде. «Алпамыш», «Сәйфелмөлек», «Таһир белән Зөһрә» һ.б. сюжетларга Идел буе татарларыннан язып алынган сөйләмә характердагы ядкарьләрне күздә тотканда, «В Поволжье эпическо творчество сохранилось в виде народных сказок»[1], – диюе белән галим гаять хаклы. Биредә китаби дастаннар булып яшәгән эпос сөйләмгә күчкән очракта, чыннан да, әкиятләшүгә йөз тоткан.

Әкияти эпос – халык иҗатының борынгы, әмма үтә яшәүчән төре. Бу аның, дастани эпостан аермалы буларак, гади халык өчен аңлаешлы, чагыштырмача гади формалы мавыктыргыч сюжетка ия жанр булуыннан килә. Әкият текстлары җирле халык кулланылышындагы сөйләмгә корылган булган, тиз истә калган, шуңа да аларны кәгазьгә төшерү ихтыяҗы булмаган, әкият, кагыйдә буларак, телдән-телгә сөйләнгән. Әкият жанрының әлеге үзенчәлеге эпиклыгы ягыннан әкияткә тартым булган дастани эпосны да әкиятләштергән. Дастаннарның сөйләмгә күчеп әкиятләшүе казан татарларының соңгы чор эпик иҗатында закончалыкка әверелгән. Бу закончалык Идел буе татарларында дастани иҗатның нигездә китабилашкан иҗат булып формалашкан булуыннан килә.

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. С. 20.

Таһир – Зөһрә сюжетына әйләнеп кайтып, аның халык теленнән язып алынган бер вариантына тукталыйк. Дастан «Таһир белән Зөһрә» исеме белән теркәлгән. Бу истәлекне татар шагыйре Ш. Маннур 1940 елда Татарстанның Мамадыш районына керә торган Тулбай авылында Мәгърифә Хәмидуллинадан язып алган. Текстның оригиналы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана[1]. Ш. Маннур әлеге вариантны фольклорчы Х. Ярми, язучы Г. Бәширов составындагы фольклор экспедициясе вакытында язып алган. Текст хәзерге татар әдәби телендә. Ул, Ф. Әхмәтова тарафыннан әзерләнеп, «Татар эпосы. Дастаннар» китабында[2] беренче кат дөнья күрде. Тексттан мисаллар шушы чыганактан алынды.

«Борын заманда...» дип башланып китүе белән үк бу әсәр әкиятне хәтерләртә. Бу вариантта Таһирның ятим бала булуы, апасы белән генә яшәве, җиде яшьтән мәктәпкә йөри башлавы һәм шул ук мәктәптә укучы Зөһрә белән туганнар кебек дуслашуы турында мәгълүмат җиткерелә, Зөһрәнең гади генә кыз булмыйча, шушы илнең патшасы булуы да әйтелә. Таһир «бик матур, бик гүзәл, бик уңган» һәм, өстәвенә, оста гармунчы була. Патша вәзирләре моннан бик көнләшә икән. Көннәрдән бер көнне Таһирның Зөһрә тәрәзәсе каршына гармун уйнап килеп басуын, ә Зөһрәнең исә аста басып торган Таһирга тәрәзәдән бау төшереп, шул бауга тотындырып Таһирны үз янына алдыруын көнче гарәп күреп тора һәм моны патшага җиткерә. Таһирны сандыкка салып суга агызалар. Зөһрә елый. Гөл патшасы кызлары тарафыннан суга батудан коткарылып калган Таһир, үзен бер күрүдә гашыйк булган чибәр кызларга күз дә салмыйча, «Зөһрәҗан белән вәгъдәм бар», дип, тегеләр йоклаган вакытны туры китереп, бер ак атка атланып, үз иленә кача. Кайтса, Зөһрәне икенче бер патша улына кияүгә бирергә җыенып яталар. Таһир туйга кыз киемнәреннән уенчы сыйфатында керә. Зөһрә моны уйнавыннан танып ала, алар бергә качып китәләр. Боларның чыгып киткәннәрен күргән гарәп тагын барып әләкли. Таһир белән Зөһрәнең артларыннан куа чыгып, Таһирны тотып алып кайталар, бармакларын кисеп җәзалыйлар.

---

[1] Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1940, колл. 7, п. 1, сак. бер. 3.

[2] Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. Б. 129–132.

Таһир, рәшәткәләрне җимереп чыгып кача, ерак ком сәхрасына китә, шунда каны агып бетеп, сусап, тилмереп үлә. Аны эзләп чыгып йөгергән Зөһрә дә, Таһирны табып, аны кочаклап үлә.

Әсәрнең ахыры бер-берсен сөйгән ике яшь кешенең үлеме белән тәмамлануга карамастан, сөйләнгән эчтәлеге, стиле, кыскалыгы, вакыйгаларның әкияткә хас җыйнаклыгы, тулысынча диярлек прозаик характерда булуы, чынбарлыкны эпик сурәтләүгә нигезләнүдән бигрәк уйдырмага күбрәк тартым булуы белән Ш. Маннур варианты дастан кысаларыннан чыгып, әкияткә әверелгән. Уртак дастани сюжеттан биредә Кормаши вариантында да очрый торган сандыкка салып суга агызу мотивы, Таһирның апасы, гарәп образы, тәрәз астына килеп җырлау эпизоды бар. Тезмә юллар ике урында гына китерелгән. Аның беренчесе – Таһирның тәрәз төбенә килеп әйткән ике юллык җыруы:

Таһирҗаның килгәндер,
Уян, Зөһрә солтаным.

Ә икенчесе исә, Таһирның үлеме турындагы хәбәрне ишеткәч, Зөһрәнең җырлаган җыруы:

И татарсыз, татарсыз,
Бер-берегезгә ук атарсыз,
Базарларда ит беткәч,
Таһир итен ашарсыз.

Юлларның һәр икесе бераз гына үзгә рәвештә Кормаши вариантында да бар. Кормаши вариантында Таһирның башын чапкач акылын югалткан Ләйләгә, сөйгәненең итен кисеп алып, аны кыздырып, алдына куялар. Моның нинди ит икәнен белеп алган Ләйлә югарыда китерелгән мисалга адекват сүзләр әйтә. Ф. Яхин, Кормаши вариантында бу урында очраган «татар» сүзенә бәя биреп, бу сүзнең, Ә. Ясәви һәм С. Бакыргани шигырьләрендәгечә, динсезлекне белдерүдә кулланыла торган сүзләрнең синонимы буларак («яһүд, христиан белән беррәттән, ислам диненең дошманнары буларак») кулланылган булуы турындагы фикерен әйткән иде[1]. Ул гаять хаклы. Бу мәсьәлә – «татар» этнонимы, аның халыкта үзэтноним булып китүе

[1] *Яхин Ф.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты, 2000. Б. 188.

бик соң башкарылган булу мәсьәләләренә барып тоташа торган четерекле мәсьәләләрнең берсе. Бу бәхәскә кереп тормый гына шуны төгәл әйтергә мөмкин: «татар» терминының бүгенге укучы аңлаганнан күпкә борынгырак мәгънәсе әсәрнең тарихи чынбарлыкны чагылдыруы, димәк, әсәр генезисының да борынгылыгы хакында сөйли.

Ә Ш. Маннур вариантында Кормашидан шушы юлларның килеп керүе исә әлеге истәлекне телдән бәян итүченең электә Кормаши әсәре белән таныш булуын күрсәтә. Сөйләүче, исендә калганнарны файдаланып, сюжетны өр-яңа вариантта үзенчәлекле рәвештә әкиятләштереп сөйләп биргән. Әсәр ахырында Таһир белән Зөһрәнең каберләре читтә булып, алар арасына көнче гарәпне күмүләре, күмгәч, ике гашыйк каберенә матур гөлләр үсеп чыгуы, ә гарәп кабере өстендә үсә торган чәнечкеле таякның аларга һаман комачаулап торуы да Кормаши вариантының бетем өлешенә бик якын.

Бу вариантлардан тыш та «Таһир белән Зөһрә сюжетына халыкта таралган кулъязмалар шактый. Аларның күбесе әдәбиятчы-текстологлар тарафыннан эшләнеп, башка вариантлары белән чагыштырылып, матбугатта басыла килә (аларны алдарак күрсәтеп үттек). Әйтик, Татарстанның хәзерге Әтнә районы Бәрәскә авылында Бикчәнтәй бине мелла Ибраһим мәдрәсәсе шәкертләре тарафыннан 1776–1801 елларда күчерелгән өч кулъязма, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондына Марат Кильдиев тапшырган яисә Гали Рәхим кулы белән күчерелгән булуы ихтимал кулъязмалар, Яңа Мәңгәр, Ишнарат, Куакбаш, Хәсәншәех авыллары кулъязмалары һ.б. күпләгән вариантлары һәркайсы – үз үзенчәлекләре булган мөстәкыйль ядкарьләр. Аларның һәркайсы XVIII йөз ахырларына нисбәт ителә, күләмнәре 1 биттән башлап, 6–7 биткәчә. Боларның булу факты казан татарларында сюжетның популярлыгын гына раслап калмый, ә XVIII йөздән соң фольклор әсәренең биредә тәмам әдәби әсәр тексты функциясен үтәүгә күчкән булуын да күрсәтә. «Таһир белән Зөһрә» дастанының татар халкындагы яшәеше фольклордан килә торган мотивларның бик уңышлы төстә язмада чагылыш табуын, кулъязмалар булып таралып, халыкның уку-язуга ихтыяҗын канәгатьләндерү чыганагына әверелеп китү фактын искәртә.

Шул ук вакытта дастанның Омск өлкәсендә, Пермь краенда, Төмән өлкәсендә, Татарстанның Тәтеш районы Олы Тархан авылында, Мордовия республикасында татар кешеләреннән татар

телендә язып алынган сөйләмә характердагы истәлекләр дә бар. Болар – дастаннан кыска фрагментлар, күпчелек очракта – дастанда Таһирның җырлап әйткән сүзләре. Җыр өлешләре гадәттә көйләп әйтелгән, алар дастанның мәгълүм язма вариантларындагы шигъри монологлар белән туры киләләр яисә шул монологлардан бер өзекне тәшкил итәләр. Кайбер очракларда информант язмадан укыганның кыскача эчтәлеген сөйли, дастаннан берничә шигырьне телдән әйтә. Әйтик, 1957 елда И. Надировның Мордовия республикасы Темников районында Фатыйма Акбулатовадан, 1972 елда Р. Ягъфәровның Пермь крае Барда районында Тәлгыя Буранголовадан, 1980 елда Ф. Әхмәтованың Төмән өлкәсе Тубыл районында Сәрбәр Бәхтиевадан, З. Сәйдәшеваның Татарстанның Тәтеш районында Рәхимә Андаевадан «Таһир белән Зөһрә» дастаныннан кыска гына җыр өлешләре язып алган булулары хакында мәгълүматлар теркәлгән[1]. 1978 елда Р. Ягъфәров Чиләбе өлкәсендә Сабира Гайнетдиновадан (1907 елгы), 1980 елда Ф. Әхмәтова Мәскәү шәһәрендә яшәүче Мөхәммәтша Кәримовтан (1911 елгы) әсәрнең кыскача эчтәлеген һәм берничә шигырен язып алган. Димәк, иң камил вариантлары язмада теркәлеп таралган булуга карамастан, XX йөзнең ахырларына кадәр татар халкында «Таһир белән Зөһрә»не телдән башкару да өлешчә саклана килгән. Бу – әлеге сюжетка мөнәсәбәттә татарларда фольклор традицияләренең югалып бетмәве дигән сүз. Мондый фрагментларның булуы «Таһир белән Зөһрә» сюжетының фольклор белән кире бәйләнеш тотуын тәэмин итә килгән әһәмиятле күренеш буларак кыйммәт. Дастанның язма вариантларында фольклор мотивларының күпләп очравы белән бергә кайбер очракларда дастанны телдән башкару традицияләренең онытылып бетмәгән булуы да «Таһир белән Зөһрә»нең татар версиясен үзенчәлекле итә.

«Таһир белән Зөһрә»нең татар вариантларына югарыда ясалган күзәтүләргә нигезләнеп, мондый гомуми нәтиҗә ясыйбыз. Дастан жанры дигәндә татар халкында аның һәм сөйләмә һәм китаби формада яшәгәнлеген истә тотарга кирәк. Халкыбызның «Таһир – Зөһрә» сюжетына корылган дастаннарның төрле вариантлары моны раслый. Төрки-татар эпосында сөйләмә һәм китаби дастаннар сюжет-мотивлары, идеяләре, шигъри эшләнеше һ.б. яклары белән бер-берсенә тирән керешкән, әмма гасырлардан ук килә торган традиция булып

[1] Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 371–372.

формалашкан ике юнәлешне тәшкил итәләр. «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы дастанның Казан татарларында таралган вариантларында китаби традицияләр өстенлек итә, ә себер татарлары вариантында сөйләмә характердагы эпос үзенчәлекләре күбрәк очрый. Казан татарлары иҗатында сөйләмә формада сакланган очракта әлеге сюжетның әкиятләшүгә йөз тотканлыгы ачыклана яисә әсәр фрагментар характерда гына очрый.

Барлыкка килгән тарихи алшартлар йогынтысында башка эпик әсәрләр рәтендә «Таһир белән Зөһрә» дастаны да Идел буе татарларында әдәби әсәр үрнәге кебек кабул ителгән, кулдан-кулга күчереләп укылган. «Таһир белән Зөһрә» дастанының татар халкындагы күпләгән вариантлары – халык иҗатының дастан жанрын баета торган, аның һәм язма һәм телдән иҗат ителә килгән эпик традицияләргә таянган ядкарь булуын ассызыклый торган гүзәл мисаллар.

# ЙОМГАК

Татар халкы гомер-гомергә китаплы халык булган. Язу культурасына, күп гасырлык бай язма мираска ия булуы аның фольклорына да тәэсир итми калмаган. Иң беренче чиратта нәкъ менә шушы сәбәп татар халкында дастан жанрының китаби булып формалашуын тәэмин иткән. Ә китаби дастаннар үз чиратында шул ук фольклор традицияләрен язмада дәвам итүләре, Идел буе татарларына хас җирле эпик үзенчәлекләр белән бергә башка халыклар рухи мирасын гасырлар буе саклап килеп, безнең көннәргә китереп җиткерүләре белән кыйммәт.

Китаби дастаннар әүвәл әллә ничә нөсхәдәге кулъязмалар булып таралсалар, соңрак халыкның рухи ихтыяҗын басма китаплар рәвешендә канәгатьләндереп килгәннәр. Татар эпосы-дастаннарының нәкъ менә язма-китаби юнәлеш алып формалашкан, кәгазьгә теркәлгән булу факты аларны бүгенге көнгә китереп җиткергән. Соңгы чорда татар халык иҗатында, жанрның сүнүгә йөз тоткан булуына карамастан, китаби дастаннарыбызның шактые безнең көннәргә текстуаль яктан тулы килеш килеп ирешкән, ә кайберләре хәтта китаби булып безнең күз алдында диярлек оешкан. Татар эпосында дастанчының хикәяләү энергиясен, вакыйгаларның дастанчы тарафыннан хәрәкәткә китерелүен, сөйләүче осталыгына бәйле рәвештә җанлануын, сөйләүченең тавыш диапозонын турыдан-туры күреп, ишетеп, тоеп, билгеләп булмый, чөнки татар эпосы тарихи үсеш процессында акциональ кырдан читләшкән. Әмма татар эпосы изоляцияләнгән хәлдә үсмәгән, гомумтөрки тамырлар уртаклыгы татар китаби эпосында телдән башкарылу билгеләренең дә, уртак эпик мотивларның, сюжетларның сакланып калуын да җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин иткән. Боларның барысын да истә тотып, татар халык иҗатында китабилык категориясен һәм китаби дастанннарны

төрки һәм гомумән дөнья әдәбиятындагы-мәдәниятендәге эпос жанрының әһәмиятле өлеше дип карау гаять мөһим.

Татар халкында эпик әсәр темасына ихтыяҗ иҗтимагыйтарихи борылышларга бәйле рәвештә арткан яисә кимегән, героик дастаннар да, романик дастаннар да билгеле бер тарихи этапта социаль-мәдәни функция үтәгән, шул һ.б. сәбәпләр аркасында төрле дастанның популярлыгы төрлечә булган. Әмма тарихның теләсә кайсы этабында Идел буе татарлары дастан жанрының китаби төренә өстенлек биргәннәр. Шул рәвешчә, бик борынгыдан килгән китабилык тенденциясе, төрле тарихи чорда төрлечә яңгыраш ала барып, эпик жанрда китаби дастаннар дигән катлам барлыкка китергәннәр. Күп гасырлык язма мираска ия халыклар өчен мондый күренеш табигый.

Күп кенә халыкларның эпик иҗатында бик еш циклләшуга, ягъни аерым әсәрләрнең бер сюжет кысасына я бер герой тирәсенә яисә бер эпик үзәккә берләшүенә тенденция күзәтелә. Мондый циклларда күп кенә очракта сюжет эзлеклелеге, вакыйгаларның бер-берсенә үзара бәйлелеге артык әһәмиятле роль уйнамаска да мөһим. Әйтик, Илья Муромец, Добрыня Никитич турындагы рус былиналарында үзәкләштерүдә төп функцияне кенәз Владимир үти, ә аерым алганда һәрбер былина тәмамланган һәм мөстәкыйль характерлы. Төрки халыклар эпосында да дастаннарның циклларга берләшү традициясе гаять көчле. Телдән башкарыла торган традицион эпос бу кагыйдәгә гадәттә тугрылыклы. Татар китаби дастаннарында исә әлеге традициягә дә җитди үзгәрешләр кергән. «Каһарман Катил», «Чура батыр», «Күр углы» кебек героик тематикалы дастаннарның да, «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир белән Зөһрә» кебек романик характердагыларының да татар милли версияләре цикллар тәшкил итә дип әйтеп булмый. Язма-әдәби формага күчү процессында бу дастаннарның һәр варианты мөстәкыйль укылып йөри торган текст рәвешен алган, фольклор катыш әдәбият сәхифәсе булып әверелгән.

Иран-фарсы, Кече һәм Урта Азия төркиләре, азәрбайҗан, төрек һ.б. халыкларда мәгълүм эпик әсәрләр сюжетына татарларның да мөрәҗәгате нәтиҗәсендә барлыкка килгән китаби дастаннар уртак мирасны үзенчәлекле рәвештә тагын да баета төшкән. Башка халыклар белән уртак мондый сюжетларга безнең халыкта яшәгән күләмле эпик текстлар әлеге әсәрләрне башка телдән турыдан-туры тәрҗемә итеп, татарларга аңлаешлы телдә тәкъдим итү механизмына

гына әверелмәгән булуы белән әһәмиятле. Китаби дастаннар категорисендә карала торган бу әсәрләр – берничә варианттан гыйбарәт әллә ничә нөсхәле, җирле-индивидуаль үзгәрешләр кичереп таралган, милли йөзле һәм үз колориты булган халык дастаннары. Татар халкы эпик сюжетларны Борынгы Көнчыгыш фольклорыннан һәм әдәбиятыннан да, гомумтөрки эпик фольклорыннан да үзләштергән, аларның төрлесен-төрле дәрәҗәдә эшкәрткән, үзгәрткән. Нәтиҗәдә хронологиясе белән тирән катламнарга барып тоташа, географиясе ягыннан татар халкы бәйләнеш тоткан һәр халыкның саекмас иҗатын һәм әдәби мирасын иңли торган берничә типтагы гаҗәеп катлам – китаби дастаннар барлыкка килгән. Индивидуаль иҗат белән традицион эпик иҗат төрле кимәлдә чагылыш тапкан татар китаби дастаннары – гомуммәгълүм күпкырлы эпос жарының бер төре.

Татар китаби эпосының ике канаты бар: бер канаты – төрки эпик традицияләр, ә икенчесе – борынгы Көнчыгыш әдәбияты. Китаби эпосыбыз гасырлар дәвамында шушы ике канатка таянып үскән һәм формалашкан. Әдәбиятка якынаю кичергән, әмма фольклор белән кире бәйләнешен һичкайчан югалтмаган язма формалы эпик ядкарьләребезне китаби дастан дип атыйбыз. Фольклор белән кире бәйләнеш төшенчәсенең гаять киң кырлы булуын истә тотарга кирәк. Фольклор белән кире бәйләнеш ул – индивидуаль автор әсәреннән башлангыч алып, фольклорга күчкән – фольклорлашкан әсәрдә; фольклор әсәрләренең аерым автор тарафыннан үзгәртелүе-эшкәртелүе нәтиҗәсендә кабат торгызылган әсәрдә; турыдан-туры язмача барлыкка килгән фольклор сюжетлы ядкарьләрдә эпик мотивлар кулланылу традициясендә саллы роль уйный торган әһәмиятле фактор. Фольклор белән кире бәйләнешен югалтып бетермәгән әсәрләр – чынлыкта ярым фольклор, ярым әдәби әсәрләр. Гасырлар дәвамында алар катлаулы юл узганнар, инде безнең көннәргә килеп җиткәндә дә, шик астына алынып (ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы 9 август карары күздә тотыла), өйрәнелүдән мәхрүм калганнар. Татар китаби эпосы халык иҗатында җитди урын били. Алардагы югары идеяләр һәм сәнгатьчә матурлык халкыбызда китап культурасының тагын да югарырак биеклеккә күтәрелүенә йогынты ясавы белән дә кыйммәт.

Фольклорда һәм гомумән әдәбиятта билгеле бер жанрның вакытлар үтү белән юкка чыгуы да табигый хәл. Китаби дастаннар иҗат итү традициясенең бүгенге көндә бөтенләй сүнгән булуы шушы

закончалык белән аңлатыла. Төрле тарихи шартларда татарларның таралып урнашуы, территориаль бөтенлекнең булмавы, утрак тормыш рәвеше бер яктан сөйләмә дастаннар иҗат итү традициясен сүндереп, аерым алганда Идел буе татарларында жанрның китаби төрен үстерсә, кайчандыр халык ихтыяҗын канәгатьләндереп килгән популяр жанр – китаби дастаннарның үзләренең дә яшәеш формалары гасырлар үтү белән тараеп кала, соңрак актуальлеген бөтенләй югалта. Кайчандыр бу жанрның үсүенә юнәлеш биргән, тамырлары бик тирәннән килә торган әдәби язмачылык традициясе тулысынча оригиналь әдәбият атрибутына әверелеп кала.

Жанрның сүнүенә китергән сәбәпләр күп төрле. Биредә төп фактор татарларның төрки дөньядан аерылып яшәве булса кирәк. Шулай ук Идел буе татарларына ислам диненең бик иртә көчле тәэсир ясап, фольклорда моңа кадәр яшәп килгән сюжетларның кысрыклануы һәм дини мотивларның өстенлек алуы да төрки эпос традицияләренә корылган китаби дастаннарның элекке әһәмияте югалуга китергән. Болардан тыш заманча шәһәр мәдәнияте, оригиналь әдәбиятның көчәеп, үсеп китүе, гарәп язуын башка язу системасына алыштыру, фән-техника казанышлары һ.б. тәэсирләр халык иҗатыннан бу жанрны кысрыклап чыгарган.

Романик китаби дастаннарыбыз билгеле бер тарихи чорда әдәбиятка якынаю кичерсәләр, героик китаби дип билгеләнгән дастаннарның тарихи җыр, социаль эчтәлекле бәет яисә тарихи елъязмага әверелә бару күренешен дә искәртү мөһим. Бу хәлне жанрның сүнеп баруы чорында жанр чикләренең җуелуы белән аңлатып була.

# БИБЛИОГРАФИЯ

## Кулъязма чыганаклар

Алпамыш // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, не описанный фонд.

Әхмәтҗан Тубыли // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Оп. 1. Ед. № 444.

Идегә (Н. Хәким) // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 52. Оп. 1. Ед. хр. 166, 167, 176, 177, 178.

Идегәй // Центр письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г Ибрагимова АН РТ. Ф. 4. Оп. 2. Ед. хр. № 52.

Идегәй // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39; Ф. 4. Оп. 1. Ед. хр. 52.

Каһарман Катил // Литературный фонд Национального музея РТ. Л 3027.

Каһарман Катил // ОРРК Научной библиотеки им. Н. Лобачевского КФУ. Т 141, Т 518, Т. 519, Т 646, Т 741, Т 762, Т 2262.

Каһарман Катил // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Ед. хр. 3497.

Каһарман Катил // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Ед. хр. 6121.

Каһарман Катил // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Ед. хр. 6026.

Ләйлә белән Мәҗнүн // ОРРК Научной библиотеки им. Н. Лобачевского КФУ.: Т-493, Т-497; № 1825т.

Ләйлә белән Мәҗнүн // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Ед. хр. № 5014, 5015, 6058, 3164.

Таһир белән Зөһрә // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Ед. хр. № 4896, 1861, 2811, 2016; Ф. 41. Оп. 1. Ед. хр. № 6, 63.

Таһир – Зөһрә // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. 1940. Колл. 7. Ед. хр. 3. П. 1.

Күр углы // Центр письменного и музыкального наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Колл. 39. Ед. хр. № 5013.

**Басылып чыккан чыганаклар**

*Әхмәтҗанов, М.* Таһир белән Зөһрә» дастаны / М. Әхмәтҗанов // Казан утлары. – 1987. – № 4. – Б. 179–186.

*Әхмәтҗанов, М.* «Таһир белән Зөһрә»нең тагын бер билгесез кульъязмасы / М. Әхмәтҗанов // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. – Казан, 1989. – Б. 67–72.

*Әхмәтҗанов, М.И.* Каһарман хикәяте / М.И. Әхмәтҗанов // Татар дәүләт гуманитар институты. Гыйльми язмалар. Ученые записки. 8 нче чыгарылыш. – Казан, 2000. – Б. 129–134.

*Әхмәтҗанов, М.* Шагыйрь Әхмәтҗан Тубыли / М. Әхмәтҗанов // Казан утлары. – 1997. – № 1. – Б. 147–153.

*Әхмәтҗанов, М.* Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссаның татарча варианты / М. Әхмәтҗанов, М. Гайнетдинов // Казан утлары. – 1979. – № 6. – Б. 170–171.

Баязит. Яңа кала. Чура батыр // Ак юл. – 1915. – № 16. – Б. 282–286.

*Березин, И.* Турецкая хрестоматия / И. Березин. – Казань: Тип. ун-та, 1862. – Т. 2.– С. 28.

Болгарның Солтан Гадел Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе. – Казан: М. Чиркова табыгханәсе, 1897. – 8 б.

*Ганҗәви, Н.* Ләйлә белән Мәҗнүн / Н. Ганҗәви; Мәхмүд Максуд тәрҗемәсе. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 150 б.

Дастан Хатәм тай. – Казан: Ун-т тип., Ш. Хөсәен нәшере. 1892. – 83 б.

Җәваһирел хикәят // Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Т. 2. – Казан: Татар. кит нәшр., 2004. – Б. 250–399.

Идегә дастаны // Татар эпосы. Дастаннар. – Казан, 2004. Б. 286–331.

Идегәй: Татар халык дастаны / төзүче-мөхәррире Г. Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 225 б.

*Исмәгыйлев, Н.Ф.* «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетының татарча прозаик версиясе / Н.Ф. Исмәгыйлев // Әдәби мирас: эзләнүләр, табышлар. – Казан, 1991. – 196 б.

Казан бәете // Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б. 25–26.

Казан тарихы // Насыйри К. Календарь 1881 елга. – Казан, 1880.

Казанская история // *Катанов Ф.* Исторические песни казанских татар. – Казань, 1899. – Б. 5–22.

Карауҗа // Татар халык иҗаты. Риваять һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 160.

Карауҗа шәҗәрәсе // *Әхмәтҗанов М.* Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар кит. нәшр., 1995. – Б. 33–34.

Каһарман Катил (дастан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 221 б.

Каһарман Катил. – Казан: Милләт, 1915. – 16 б.

Каһарман китабы. (XVIII Yuzyil) // Baslangicindan Gunumuze Kadar Turkiye disindaki Turk Edebiyatlari antolojisi. Т. 18. Tatar Edebiyati. II. – Ankara: Kultur Bakanligi, 2001. – С. 183–197.

Кыйссаи Алпамыш. – Казан: Домбровский тип., Ш. Хөсәенов варислары нәшере, 1912. – 46 б.

Кыйссаи Каһарман. – Казан: Ун-т тип., Ш.Хөсәенов варислары нәшере, 1913. – 14 б.

Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. – Казан: Бр. Кәримовлар нәшере, 1912. – 116 б.

Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы. – Казан: Матбагаи «Кәримия», 1914. – 116 б.

Кыйссаи пәһлеван. Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә алып укырга бик кызыклы. – Казан: Матбагаи «Кәримия», 1918. – 87 б.

Кыйссаи Чура батыр. – Казан: Вечеслав тип., 1884. – 16 б.

Ләйлә белән Мәҗнүн // XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2006. – Б. 303–308.

Мәшһүр гашыйк-мәгъшук Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе. – Казан: Ун-т табыгханәсе, 1902. – 48 б.

Нарык һәм Чураның хикәяте // Березин И. Турецкая хрестоматия. Т. 2. Казан: Тип. ун-та, 1862. С. 41 – 56.

*Насыйри, К.* Календарь 1881 елга / К.Насыйри. – Казан, 1880.

*Насыйри, К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда / К.Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Т. 2. – 400 б.

*Радлов, В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен / В.В. Радлов. – Ч. I–X. – СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1866 – 1907.

*Рәшиди, Г.* Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе / Г. Рәшиди. – Казан: Центр. тип., 1917. – 45 б.

*Сайади.* Таһир – Зөһрә (Бабахан дастаны) / Сайади. – Казан: Раннур, 1998. – 192 б.

Татар халык дастаны «Идегәй» // Совет әдәбияты. – 1940. – № 11. – Б. 39–76, № 12. – Б. 34–82.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Өченче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 360 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. – Казан: Татар кит. нәшр., 1984. – 384 б.

Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. – Казан: Раннур, 2004. – 640 б.

Таһир белән Зөһрә (М. Әхмәтҗанов сүз башы белән) // Түгәрәк уен. Татар халык иҗатын яктыртучы мәгъүмати-популяр альманах. – 2012. № 1. – Б. 56.

Түләк китабы: дастан. «Татар археографиясе» сериясе. 2 нче китап / төзүче-автор Р.Ф. Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – 76 б.

*Халиди, Ф.* Мәшһүр гашыйк-мәгъшук Ләйлә илә Мәҗнүн хикәясе / Ф. Халиди. – Казан: Ун-т тип., 1902. – 45 б.

Хикәяте Күр углы Солтан. – Казань: Типо-литография Имп.-го ун-та, 1894. 90 с.

Чора батыр // Кырымтатар халкъ агъыз яратыджылыгы / төзүчесе – Джафар Бекиров. – Ташкент: Укитувчи, 1991. – Б. 57–72.

Чура батыр. Татар халык дастаны / хәзерге әдәби телгә күчерүче Ф. Латыйфи. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 64 б.

Шора бьтир // Ногай давысы. – 1992. – № 46, 59–60, 93.

Этнографические материалы, собранные и переведенные А.А. Диваевым. Шура батыр: киргизская былина // Сборник материалов Сыр-Дарьинской области. Т. IV. – Ташкент: Тип. Бр. Каменские, 1895. – С. 1–88.

*Юлдаш, К.* Чура батыр / К. Юлдаш // Аң. – 1916. – 5 нче сан. – Б. 85–88.

### Рус телендә әдәбият

*Абилов, Ш.* Книга дастанов / Ш. Абилов // Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. – Казань: Фэн, 1999. – 240 с.

Авеста в русских переводах (1861–1996) / сост., общ. ред., примеч., справ. разд. И.В. Рака. – СПб.: Журнал «Нева» РХГИ, 1997. – 480 с.

*Акбиев, С.Х.* Связь времен и дружба литератур: некоторые вопросы развития дагестанско-татарских литературных связей / С.Х. Акбиев. Махачкала: Даг. кн. изд-во, 1985. – 128 с.

*Алишев, С.Х.* Болгаро-казанские и золотоордынские отношения в XIII–XVI вв. / С.Х. Алишев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. – 159 с.

Антология азербайджанской поэзии. – М.: Гослитиздат, 1939. – 428 с.

Антология татарской поэзии. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 605 с.

Арабско-татарско-русский словарь заимствований (Арабизмы и фарсизмы в языке татарской литературы). Т. 1. – Казань: Иман, 1993. – 448 с.

Арабско-татарско-русский словарь заимствований (Арабизмы и фарсизмы в языке татарской литературы). Т. 2. – Казань: Иман, 1993. – 855 с.

*Ауэзов, М.* Джамбул и народные акыны // *Ауэзов М.* Собрание сочинений. В 5-и томах. Т. 5. Литературно-критические и публицистические статьи 1936–1961 годов: пер. с казахского / М. Ауэзов. – М.: Худож. лит., 1975. – 568 с.

*Ауэзов, М.* Собрание сочинений в 5-и томах. Т. 5. Литературно-критические и публицистические статьи 1936–1962 годов: пер. с казахского / М. Ауэзов; сост. и примеч. Л. Ауэзовой. – М.: Худож. лит., 1975. – 568 с.

*Ахметзянов, М.И.* Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы: дис. ... докт. филол. наук / М.И. Ахметзянов. – Казань, 1998. – 421 с.

*Ахметова, Ф.* Татарская версия «Алпамыша» и другие новые записи эпоса сибирских татар / Ф.В. Ахметова // Эпическое творчество народов Сибири. – Улан-Удэ, 1973. – 96 с.

*Бадалов, Р.* Правда и вымысел героического эпоса / Р. Бадалов. – Баку: Изд-во «Элм», 1983. – 154 с.

*Базанов, В.Г.* От фольклора к народной книге / В.Г. Базанов. – Л.: Худож. лит-ра, 1977. – 342 с.

*Бакиров, М.Х.* Древнетюркская позия: неразгаданные тайны устного и письменного поэтического творчества наших предков / М.Х. Бакиров. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – 390 с.

*Бакиров, М.* Татарский фольклор / М. Бакиров. – Казань: Ихлас, 2012. – 400 с.

Башкирский народный эпос. – М.: Наука, 1977. 557 с.

*Березин, И.* Турецкая хрестоматия / И. Березин. Т. II. – Казань: Тип. ун-та, 1862. – 144 с. – С. 41–56.

*Бернштам, А.Н.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI–VIII вв. / А.Н. Бернштам. – М. – Л., 1946.

*Бертельс, Е.Э.* Низами. Творческий путь поэта / Е.Э. Бертельс. – М.: Изд-во Акад. Наук СССР, 1956. – 260 с.

*Бертельс, Е.Э.* Избранные труды. Низами и Фузули / Е.Э. Бертельс. – М.: Изд-во восточной лит-ры, 1962. – 555 с.

Большой Российский энциклопедический словарь. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2005. – 1887 с.

*Брагинский, И.С.* Из истории персидской и таджикской литератур. Избранные работы / И.С. Брагинский. – М.: Наука, 1972. – 524 с.

*Брагинский, И.С.* Литература Ирана и Средней Азии / И.С. Брагинский // История всемирной литературы. В девяти томах. Т. 2. – М.: Наука, 1984. – С. 248–277.

*Будагов, Л.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий / Л. Будагов. – СПб.: Тип. Императорской Акад. наук, 1869. – 814 с.

*Валитова, А.* О версиях татарской прозаической сказки «Алпамша» / А. Валитова // Тезисы докладов и сообщений регионального совещания по эпосу «Алпамыш». – Ташкент: АН Узбекской ССР, 1956. – 60 с.

*Валитова, А.О.* Татарская версия эпического сказания «Алпамыш» / А.О. Валитова // Тюрко-монгольское языкознание и фольклористика. – М.: Изд-во вост. лит-ры, 1960. – 350 с.

*Валиханов, Ч.Ч.* Избраные произведения / Ч.Ч. Валиханов. – М.: Наука, 1986. – 414 с.

*Валиханов, Ч.Ч.* Собр. соч. в пяти томах / Ч.Ч. Валиханов. – Алма-Ата: Изд-во Акад. наук КазССР, 1961, 1972 һ.б.

*Веселовский, А.Н.* Историческая поэтика / А.Н. Веселовский. – Л.: Гослитиздат, 1940. – 648 с.

*Веселовский, А.Н.* Историческая поэтика / А.Н. Веселовский. – М.: Высшая школа, 1989. – 406 с.

Взаимосвязи литератур Востока и Запада / колл. авторов. – М.: Изд-во восточной лит-ры, 1961. – 250 с.

Возвращенный эпос VIII–XXI вв. / сост., лит., обр., вступит. ст., комм. А.В. Преловского. – М.: Новый ключ, 2004. – 656 с.

Вопросы изучения эпоса народов СССР. – М.: Изд-во АН СССР, 1958. – 292 с.

*Галиуллин, Т.Н.* К изучению связей татарской поэзии 30-х гг. с народным творчеством / Т.Н. Галиуллин // Башкорт филологиясе. – Пермь-Стерлитамак, 1975. – С. 63–65.

*Галиуллин, Т.Н.* Современная татарская поэзия и народное творчество: автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.01.02 / Т.Н. Галиуллин. – Казань, 1968. – 30 с.

*Ганиева, Р.К.* Восточный ренессанс и поэт Кул Гали / Р.К. Ганиева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 173 с.

*Ганиева, Р.К.* Традиция Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени. / Р.К. Ганиева. – Казань: Фэн АН РТ, 2014. – 272 с.

*Гацак, В.М.* Эпический певец и его текст / В.М. Гацак // Текстологическое изучение эпоса. – М.: Наука, 1971. – 230 б.

Генезис романа в литературах Азии и Африки. Национальные истоки жанра. – М.: Наука. Гл. редакция восточной лит-ры, 1980. – 288 с.

Гёр-оглы. Туркменский героический эпос. – М.: Наука. Гл. редакция восточной лит-ры, 1983. – 803.

*Гилазев, З.З.* Татарская литература начала XX века в книжных изданиях / З.З. Гилазев. – Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2005. – 160 с.

*Гилязутдинов, С.М.* Описание рукописей на персидском языке из хранилища Института языка, литературы и искусства / С.М. Гилязутдинов. – Казань, 2002. – 254 с.

*Гилязутдинов, С.М.* Персидско-татарские литературные связи (X – начало XX в.) / С.М. Гилязутдинов. – Казань, 2011. 212 с.

*Гринцер, П.А.* Древнеиндийский эпос. Генезис и типология / П.А. Гринцер. – М.: Гл. редакция восточной лит-ры, 1974. – 420 с.

*Давлетшин, Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура / Г.М. Давлетшин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 192 с.

*Далгат, У.Б.* Героический эпос чеченцев и ингушей. Исследование и тексты / У.Б. Далгат. – М.: Наука, 1972. – 462 с.

Дастаны. Ашик Махмуд / сказитель – Махмуджон Юсупов. – Ташкент: Фан, 1970. – 80 с.

*Джувейни, Ата-Мелик.* Чингизхан. История завоевателя мира, написанная Ала-ад-дином Ата-Мелик Джувейни / перевод с текста Мирзы Мухаммеда Казниви на английский язык Дж.Э. Бойла; с предисловием и биографией Дэвида О. Моргана; перев. с англ. Е.Е. Харитоновой. – М.: Магистр-Пресс, 2004. – 690 с.

*Жирмунский, В.М.* Эпическое творчество славянских народов и проблемы сравнительного изучения эпоса / В.М. Жирмунский. – М.: Изд-во Акад. наук СССР, 1958. 146 с.

*Жирмунский, В.М.* Народный героический эпос: Сравнительно-героические очерки / В.М. Жирмунский. – М. – Л.: Гослитиздат. Ленингр. отд-ние, 1962. – 435 с.

*Жирмунский, В.М.* Некоторые итоги изучения героического эпоса народов Средней Азии / В.М. Жирмунский // Вопросы изучения эпоса народов СССР. – М.: Изд-во АН СССР,1958. – С. 24–65.

*Жирмунский, В.М.* Ритмико-синтаксический параллелизм как основа древнетюркского народного эпического стиха / В.М. Жирмунский // Вопросы языкознания. – М., 1964. № 4. – С. 27–52.

*Жирмунский, В.М.* Сказание об Алпамыше и богатырская сказка / В.М. Жирмунский. – М.: Изд-во восточной лит-ры, 1960. – 335 с.

*Жирмунский, В.М.* Сравнительное литературоведение. Восток и Запад. Избранные труды / В.М. Жирмунский. – Л.: Наука, 1979. – 493 с.

*Жирмунский, В.М.* Тюркский героический эпос / В.М. Жирмунский. – Л.: Наука, 1974. – 728 с.

*Жирмунский, В.М.* Узбекский народный героический эпос / В.М. Жирмунский, Х.Т. Зарифов. – М.: Гос изд-во худож. лит-ры, 1947. – 520 с.

*Жирмунский, В.М.* Теория литературы. Поэтика. Стилистика. Избранные труды / В.М. Жирмунский. – Л.: Наука, 1977. – 404 с.

*Завгарова, Ф.Х.* Вопросы истории татарской фольклористики // Татар халык иҗаты (фәнни эзләнүләр һәм үрнәкләр) / Ф.Х. Завгарова. – Казан: Алма-Лит, 2009. – С. 5–10.

*Загидуллина, Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе 1920-х гг. / Д.Ф. Загидуллина // Филология и культура. – 2013. – № 1 (31). – С. 146–150.

*Закирова, И.Г.* Эпическое творчество периода Золотой Орды: мифологические и исторические основы / И.Г. Закирова. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2011. – 268 с.

Золотая Орда в источниках. Т. I. Арабские и персидские сочинения. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды, в переводах В.Г. Тизенгаузена. Ч. II. – М.: б.и., 2003. – 448 с.

*Ибрагимова, Л.Х.* Дастан «Чура батыр» в творчестве тюркских народов: автореф. дис. ... канд. филол. наук / Л.Х. Ибрагимова. – Казань, 2000. – 26 с.

*Ибрагимова, Л.Х.* Дастан «Чура батыр» в творчестве тюркских народов: дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2000. – 185 с.

*Иванов, М.* Татар хрестоматиясе / М. Иванов. – Казан, 1842.

*Иделбаев, М.Х.* Изустная литература в системе башкирской словестности: автореф. дис. … докт. филол. наук / М.Х. Иделбаев. – Уфа, 2001. – 82 с.

*Идиатуллин, М.И.* Арабские рукописи по астрономии и математике в фондах научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского / М.И. Идиатуллин. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1987.

*Имаева, Г.З.* Народная сказка и ее литературные переложения: проблема происхождения и модефикации текстов / Г.З. Имаева. – М.: ГРЦРТФ, 2008. – 224 с.

История всемирной литературы: в девяти томах. Т. 2. – М.: Наука, 1984. – 672 с.

История всемирной литературы: в девяти томах. Т. 5. – М.: Наука, 1988. – 784 с.

История Сибири. Т. 2: Сибирь в составе феодальной России. – Л.: Наука, 1968. – 538 с.

*Исхаков, Д.М.* Татары: популярный очерк этнической истории и демографии / Д.М. Исхаков. – Набережные Челны: КАМАЗ, 1993. – 63 с.

Исхаков, Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.) / Д.М. Исхаков. – Казань: Мастер-Лайн, 1998. – 276 с.

Казанская история / подгот. текста, всупит. ст. и прим. Г.Н. Моисеевой; под ред. чл.-корр. АН СССР В.П. Андрияновой-Перетц. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1954. – 195 с.

*Каримуллин, А.А.* Татарский фольклор. Аннотированный указатель литературы (1612–1981). В двух частях / А.А. Каримуллин. – Казань, 1993. – Ч. I. – 135 б.

*Каримуллин, А.Г.* У истоков татарской книги. От начала возникновения до 60-х годов XIX века (Издание 2-е, испр. и пер.) / А.Г. Каримуллин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – 208 с.

*Каррыев, Б.А.* Эпические сказания о Кер-углы у тюрко-язычных народов / Б.А. Каррыев. – М.: Наука, 1968. – 260 с.

*Катанов, Н.*Ф. Исторические песни казанских татар / Н.Ф. Катанов. – Казань: Тип. Имп. ун-та, 1899. – 36с.

*Катанов, Н.Ф.* Материалы и сообщения / Н.Ф. Катанов. – Абакан: Хакасское кн. изд-во, 1958. – 215 с.

Кедейкан. Эр табылды. Эпостар. – Фрунзе: «Кыргызстан» басмасы, 1970. – 460 с.

*Киреев, А.Н.* Башкирский народный героический эпос / А.Н. Киреев. – Уфа, 1970.

*Кляус, В.Л.* В поисках эпической основы «Слова о полку Игореве». Сюжет о соревновании Молодца с Солнцем / В.Л. Кляус // Историк в России: между прошлым и будущем. – М., 2012. С. 254–276.

*Кляшторный, С.Г.* Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках / С.Г. Кляшторный // Тюркологический сборник, 1977. – М.: Наука. Гл. редакция восточ. лит-ры, 1981. – С. 117–138.

Кобланды батыр: Казахский героический эпос / сост. тома, авторы исслед. и комм. Н.В. Кидайш-Покровская и О.А. Нурмагамбетова. – М.: Наука, 1975. – 446 с.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествиях на Волгу в 921–922 гг. / А.П. Ковалевский. – Харьков: Изд-во Харьковского ун-та, 1956. – 345 с.

*Короглы, Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана / Х.Г. Короглы. – М.: Наука, 1983. – 336 с.

*Короглы, Х.Г.* Древнетюркская письменность / Х.Г. Короглы // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: ФЭН, 1999. – С. 11–40.

*Короглы, Х.Г.* Огузский героический эпос / Х.Г. Короглы. – М.: Наука, 1976. – 239 с.

*Котляр, Е.С.* Миф и сказка Африки / Е.С. Котляр. – М.: Наука, 1975. 254 с.

Краткая литературная энциклопедия / гл. ред. А.А. Сурков. – М.: Советская энциклопедия, 1964. – 1056 с.

Краткая литературная энциклопедия. – М.: Советская энциклопедия, 1975. – 1056 с.

*Крачковский, И.Ю.* Избранные сочинения / И.Ю. Крачковский. Т. 2. – М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1956. – 702 с.

Кузьмина, Е.Н. О новых аспектах изучения произведений героического эпоса народов Сибири: опыт систематизации «общих мест» / Е.Н. Кузьмина // Первый Всероссийский конгресс фольклористов. Сборник докладов. Т. 3. – М.: Государственный республиканский центр русского фольклора, 2006. – С. 55–69.

*Кукляшев, С.А.* Диване хикәяте татар / С.А. Кукляшев. – Казан: Ун-т тип., 1859. – 106 б.

*Курбатов, Х.* Ритмика татарского стиха / Х. Курбатов. – Казань: б.и., 2005. – 92 с.

*Лермонтов, М.Ю.* Ашик-Гериб // Лермонтов М.Ю. Проза / сост. В.А. Еремин. – М.: Московский рабочий, 1977. – С. 190–198.

Литературный энциклопедический словарь / под общей ред. М. Кожевникова и П.А. Николаева. – М.: Советская энциклопедия. 1987. – 753 с.

*Лоренц,* К. Агрессия (так называемое зло) / К. Лоренц. – СПб.: Амфора, 2001. – 349 с.

*Лосев, А.Ф.* Гомер / А.Ф. Лосев. – М.: Госпедиздат МП РСФСР, 1960. – 350 с.

*Малов, С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования / С.Е. Малов. – М. – Л. : Изд-во АН СССР, 1951. – 452 с.

*Маркс К., Энгельс Ф.* Сочинения. Изд. Второе. Т. 16 / К. Маркс, Ф. Энгельс. – М.: Гос. Изд-во политической литературы, 1960. – 839.

Масторава / на основе эрзянских и мокшанских мифов, эпических песен и сказаний написал А.М. Шаронов. – Саранск: Мордов. кн. изд-во, 2003. – 488 с.

*Мелетинский, Е.М.* «Эдда» и ранние формы эпоса / Е.М. Мелетинский. – М.: Наука, 1968. – 365 с.

*Мелетинский, Е.М.* Введение в историческую поэтику эпоса и романа / Е.М. Мелетинский. – М.: Наука, 1986. – 320 с.

*Мелетинский, Е.М.* Историческая поэтика новеллы / Е.М. Мелетинский. – М.: Наука, 1990. – 275 с.

*Мелетинский, Е.М*. Происхождение героического эпоса. Ранние формы и архаические памятники / Е.М. Мелетинский. – М.: Изд-во восточной лит-ры, 1963. – 463 с.

*Миннегулов, Х.Ю.* Татарская литература и восточная классика (Вопросы взаимосвязи и поэтики) / Х.Ю. Миннегулов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. – 384 с.

*Миннуллин, К.М.* Песня как искусство слова: автореф. дис. ... д-ра. филол. наук: 10.01.09 и 10.01.02 / К.М. Миннуллин. – Казань, 2001. – 70 с.

*Миннуллин, К.* Современые проблемы литературно-фольклорных взаимосвязей / К. Миннуллин, Ф. Урманчеев // Научный Татарстан. – 2008. – № 1. С. 3 – 17.

Мифы в искусстве старом и новом: историко-художественная монография (по Рене Менуару). – СПб.: Тип. А.С. Суворина, 1900. – 256 с.

Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. 2-е изд. – М.: Сов. Энцикл. Изд-во малого предприятия «Останкино», 1991. – 719 с.

*Молла-Непес*. Сказание о Зохре и Тахире / Молла-Непес. – М.: Гос. Изд-во худ. лит-ры, 1960. – 252 с.

*Мухамедова, Р.Г.* Татары-мишари: Историко-этнографическое исследование / Р.Г. Мухамедова. – Казань: Магариф, 2008. 295 с.

*Мухаметзянова, Л.Х.* Татарские книжные дастаны: история становления жанра и поэтика: автореф. дис. ... д-ра. филол. наук: 10.01.02 и 10.01.09 / Л.Х. Мухаметзянова. – Казань, 2015. – 45 с.

*Мухаметзянова, Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны / Л.Х. Мухаметзянова – Казань: ИЯЛИ, 2014. – 380 с.

Народный эпос «Кузы Курпес и Маян Хылу». – Уфа: ИИЯЛ, 1964. – 122 с.

*Навои, Алишер.* Лейла и Маджнун: соч. в 10 томах / Алишер Навои. – Ташкент: Изд-во Фан Узбек. ССР, 1968. – Т. 5. – 207 с.

*Неклюдов, С.Ю*. Героический эпос монгольских народов. Устные и литературные традиции / С.Ю. Неклюдов. – М.: Гл. ред. восточ. литературы, 1984. – 310 с.

*Неклюдов, С.Ю.* Эпические повествования в традиционной монгольской литерауре / С.Ю. Неклюдов // Специфика жанров в литературах Центральной и Восточной Азии. Современность и классические наследие. – М.: Наука, 1985. – 262 с.

*Неклюдов, С.Ю.* Монгольское сказание о Гесере. Новые записи / С.Ю. Неклюдов, Ж. Тумурцерен. – М.: Наука. Гл. ред. Восточной лит-ры, 1982. – 376 с.

*Низами Г.* Собрание сочинений: в пяти томах / пер. с фарси Т. Стрешневой. – М.: Худ. литер., 1986. – Т. 3. – 366 с.

Новый энциклопедический словарь. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2001. – 1416 с.

Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, собраны В.В. Радловым. Ч. IV. – СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1872. – 414 с.

*Окладников, А.П.* Якутский эпос (олонхо) и его связь с югом / А.П. Окладников. – Якутск: Сайдам, 2013. – 64 с.

Олонхосуты Якутии: справочник. – Якутск: Издательский дом СВФУ им. М.К. Аммосова, 2013. – 156 с.

*Орлов, А.С.* Казахский героический эпос / А.С. Орлов. – М.: Изд-во АН СССР, 1945. – 148 с.

Памятники книжного эпоса. Стиль и типологические особенности. – М.: Наука, 1978. – 272 с.

Памятники фольклора народов Сибири и Дальнего Востока. Якутский героический эпос. «Могучий Эр Соготох». – Новосибирск: Наука. Сибирская издательская фирма РАН, 1996. – 440 с.

Повесть Петеисе III. Древнеегипетская проза. – М.: Худ. литер., 1978. – 304 с.

*Пропп, В.Я*. Фольклор и действительность. Избранные статьи / В.Я. Пропп. – М.: Наука, 1976. – 325 с.

Путешествие Абу Хамида аль-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / под ред. О.Г. Большакова. – М.: Наука, 1971. – 137 с.

Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу / пер. и комм. под ред. акад. И.Ю. Крачковского. – М. – Л.: Изд-во Акад. наук СССР, 1939. – 212 с.

*Путилов, Б.Н.* Героический эпос и действительность / Б.Н. Путилов. – М.: Наука, 1988. – 224 с.

*Путилов, Б.Н.* Русский и южнославянский эпос: Сравнительно-типологическое исследование / Б.Н. Путилов. – М.: Наука, 1971. – 315 с.

*Пухов, И.В.* Олонхо – древний эпос якутов / И.В. Пухов. – Якутск: Сайдам, 2013. – 48 с.

*Рашид-эд-дин.* Сборник летописей / Рашид-эд-дин. Т. II. – М. – Л.: Изд-во Акад. наук СССР, 1960.

*Рифтин, Б.Л.* Историческая эпопея и фольклорная традиция в Китае (Устные и книжные версии «Троецарствия») / Б.Л. Рифтин. – М.: Наука, 1970. – 482 с.

*Рыбаков, С.Г.* Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта / С.Г. Рыбаков // Записки Имп. АН по историческому и филологическому отделению. – СПб.: Имп. Акад. наук, 1897. – Т. 2. – 330 с.

*Рычков, П.И*. Опыт Казанской истории древних и средних времен, сочинен Петром Рычковым / П.И. Рычков. – СПб., 1767. – 232 с.

*Садеков, М.Р.* Звучат лишь письмена... (Татарский фольклор периода Казанского ханства в русских исторических источниках) / М. Садеков. – Казань: Дом печати, 2005. – 128 с.

*Садекова, А.* Идеология ислама и татарское народное творчество / А. Садекова. – Казань: Иман, 2000. – 260 с.

*Самойлович, А.Н.* Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше, записанный Н. Хакимовым / А.Н. Самойлович // Тюркологический сборник. 1972. – М.: Наука. Главная ред. восточной лит-ры. – С. 186–211.

Сказания столетий. Эпос народов СССР / сост., авт., предисл. и коммент. Л.И. Климович, В.Н. Осокин. – М.: Молодая гвардия, 1981. – 431 с.

*Смирнов, Ю.И.* Славянские эпические традиции: Проблемы эволюции / Ю.И. Смирнов. – М.: Наука, 1974. – 264 с.

*Соколова, В.К.* Взаимодействие преданий с другими фольклорными жанрами / В.К. Соколова // Прозаические жанры фольклора народов СССР. – Минск, 1974. – С. 125–128.

Специфика жанров в литературах Центральной и Восточной Азии. Современность и классическое наследие. – М.: Наука. Гл. ред. восточ. литературы, 1985. – 262 с.

Специфика фольклорных жанров. – М.: Наука, 1973. – 304 с.

Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: ФЭН, 1999. – 240 с.

*Стеблева, И.В.* Поэзия тюрков VI–VIII веков / И.В. Стеблева. – М.: Наука, 1965. – 148 с.

*Стеблева, И.В.* Поэтика древнетюркской литературы и ее трансформация в ранне-классический период / И.В. Стеблева. – М.: Наука, 1976. – 215 с.

*Тагиров, И.Р.* Ступени независимости / И.Р. Тагиров. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1994. – 279 с.

Татарская книга: страницы истории. Татар китабы: тарихи сәхифәләр. – Казань, 2012. – 303 с.

Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. – Казань: Ихлас, 2010. – 384 с.

Татарская энциклопедия: в 6 т. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. – Т. 3: К–Л. – 664 с.

Татарская энциклопедия: в 6 т. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. – Т. 5: Р – Т. – 736 с.

Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. – 703 с.

Тезисы докладов и сообщений регионального совещания по эпосу «Алпамыш». – Ташкент: АН Узбекской ССР, 1956. – 60 с.

*Темкин, Э.Н.* Мифы Древней Индии / Э.Н. Темкин, В.Г. Эрман. – М.: Наука, 1982. – 272 с.

*Тиливалди, А. (Хамраев).* Древнетюркский книжный стих / А. Тиливалди. – Алматы: Алматинский Государственный Университет им. Абая, 2002. – 228 с.

Типология народного эпоса. – М.: Наука, 1975. – 326 с.

Труды общества изучения Киргизского края. Вып. III. – Оренбург: Караван-Сарай, 1922. – 215 с.

Тюрко-монгольское языкознание и фольклористика. – М.: Изд.вост. лит., 1960. – 350 с.

*Урманче, Ф.* Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: Основные проблемы изучения баитов / Ф. Урманче. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 256 с.

*Урманче, Ф.* Народный эпос «Идегей» / Ф. Урманче. – Казань: Фэн, 1999. – 200 с.

*Урманчеев, Ф.* Героический эпос татарского народа / Ф. Урманчеев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 312 с.

*Урманчеев, Ф.И.* Эпические сказания татарского народа. Сравнительно-исторические очерки / Ф.И. Урманчеев. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1980. – 120 с.

*Усманов, М.А.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. / М.А. Усманов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. – 223 с.

*Фахрутдинова, А.Р.* Дастан «Туляк и Сусылу»: тюрко-татарские варианты / А.Р. Фахрутдинова. – Казань: б.и., 2011. – 124 с.

Философский словарь / под ред. И.Т. Фролова. Изд. 4-е. – М.: Изд-во полит. лит-ры, 1980. – 445 с.

Фольклор. Издание эпоса. – М.: Наука, 1977. – 287 с.

*Хасавнех, А.А.* Этико-эстетические воззрения поэта-суфия XIX века Ахметзяна Тубыли: дис. …канд. филол. наук / А.А. Хасавнех. – Казань, 2002. – 215 с.

*Хасавнех, А.* Ахметзян Тубыли. Жизнь и творчество татарского поэта-суфия XIX века / А. Хасавнех. – Saarbrucken: Lap lambert Academic Publishing, 2012. – 206 с.

*Хисамов, Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али. Анализ источников сюжета и авторского творчества / Н.Ш. Хисамов. – М.: Наука, 1979. – 256 с.

*Хисамов, Н.Ш.* Сюжет Йусуфа и Зулейхи в средневековой тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв.: дис. в форме научного доклада … д-ра филол. наук / Н.Ш. Хисамов. – М., 1996.

*Хусаинова, Г.Р.* Башкирские волшебные сказки: поэтика и текстология / Г.Р. Хусаинова. – Уфа: Гилем, Башк. Энцикл., 2014. – 216 с.

*Чичеров, В.И.* Вопросы изучения эпоса народов СССР / В.И. Чичеров // Эпос народов СССР. – М., 1958. – С. 5–23.

*Шарипов, А.М.* Зарождение системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XIV вв.) / А.М. Шарипов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. – 364 с.

Эмрах и Сельви, необыкновенные приключения Караоглана и другие турецкие народные повести / составление, предисловие и примечания Х.Г. Короглы. – М.: Гл. ред. восточ. литературы, 1979. – 446 с.

Эпическое творчество народов Сибири (тезисы докладов научной конференции, Улан-Удэ, 17–20 июля 1973 г. – Улан-удэ, 1973. – 96 с.

*Ямалтдинов, И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века (Собирание, публикация и научное изучение фольклора): автореф. дис. ... канд. филол. наук: 10.01.09 / И.И. Ямалтдинов. – Казань, 2012. – 30 с.

*Ярмухаметов, Х.Х.* Сказание «Козе Корпеш и Баян Сылу» в устном творчестве сибирских татар / Х.Х. Ярмухаметов // Народный эпос «Кузы Курпес и Маян Хылу». – Уфа: ИИЯЛ, 1964. – Б. 79–89.

*Ярхо, В.Н.* Поэмы Гомера: фольклорная традиция и индивидуальное творчество // *Ярхо В.Н.* Собрание трудов. Древнегреческая литература. Эпос. Ранняя лирика. – М.: Лабиринт, 2001. – С. 55–127.

## Татар һәм башка төрки телләрдәге әдәбият

XVIII йөз татар әдәбияты: Проза. – Казан: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. 2012. – 444 б.

*Абилов, Ш.* Дастаннар / Ш. Абилов // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда, 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 568 б.

*Акчурина, М.* Иске әдәбиятымыз / М. Акчурина // Шура. – 1911. – 16 сан. – Б. 508–510.

Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 239 б.

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

*Әхмәтҗанов, М.И.* Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2005. – 224 б.

*Әхмәтҗанов, М.И.* Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 343 б.

*Әхмәтҗанов, М.И.* Шагыйрьләр төбәге / М.И. Әхмәтҗанов // Милли-мәдәни мирасыбыз. Мари Эл татарлары. Бәрәңге. – Казан, 2012. – Б. 70–80.

*Әхмәтҗанов, М.* Татар кулъязма китабы / М. Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 270 б.

*Әхмәтова, Ф.В.* Дастаннар / Ф.В. Әхмәтова // Татар фольклоры жанрлары. – Казан: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1978. – 139 б.

*Әхмәтова, Ф.В.* Дастаны Бабахан / Ф.В. Әхмәтова // Татар әдәбияты: 6 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Т. 1. Урта гасырлар дәвере. – Б. 312–321.

*Бакиров, М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек / М.Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2008. – 360 б.

*Бакиров, М.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары / М. Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2001. – 343 б.

Балалар күңеле. Бишенче төп. – Казан: Мaариф, 1921. – 15 б.

Башкорт халык ижады. VII том. Язма кисса һәм дастандар. – Өфө: Китап, 2004. – 624 б.

*Вәлиди, Ә.-З.* Кыскача төрек-татар тарихы / Ә.-З. Вәлиди; төзүчесе, төп текстның транскрипциясен әзерләүче, библиографик исемлек, искәрмәләр һәм ахыр сүз авторы Равил Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 181 б.

*Гайнетдин, М.* Хакыйкать юлыннан. Әдәби тәнкыйть / М. Гайнетдин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 319 б.

*Гали, К.* Йосыф кыйссасы / Кол Гали; төз. Н. Хисамов. – Казан: Дом печати, 2008. – 604 б.

*Галиуллин, Т.Н.* Утызынчы еллар татар совет поэзиясе һәм халык иҗаты / Т.Н. Галиуллин // Татар әдәбияты мәсьәләләре. Гыйльми язмалар. – Казан: КДПИ, 1974. – Б. 89–102.

*Галиуллин, Т.Н.* Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 319 б.

*Гобәйдуллин, Г.* Сәед Баттал Гази хикәясе турысында / Г. Гобәйдуллин // Шура. – 1911. – № 22. – Б. 682–685.

*Госманов, М.* Каурый каләм эзеннән / М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 463 б.

*Госман, Х.* Шигырь төзелеше / Х. Госман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 192 б.

*Дәүләтшин, Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы / Г. Дәүләтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 512 б.

*Диваев, А.А.* Батырлар. Т. 1–6 / А.А. Диваев. – Ташкент, 1922. (на казахском языке).

*Закирова, И.Г.* Болгар чоры халык иҗаты / И.Г. Закирова. – Казан: Фикер, 2003. – 144 б.

Заманалар узган – дастан туган: дастаннар. – Казан: Мәгариф, 2001. – 175 б.

*Ибраһимов, Г.* Әдәбият кануннары / Г. Ибраһимов. – Казан, 1918. – Б. 68–70.

*Ибраһимов, Г.* Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Т. 5. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – 616 б.

*Ибраһимова, Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны / Л.Х. Ибраһимова. – Казан: Фикер, 2002. – 192 б.

*Ибраһимова, Л.Х.* Дастаннар иленә сәяхәт / Л.Х. Ибраһимова // Мәдәни җомга. – 7 март, 14 март. – 11–12 саннар. – Б. 11.

*Исәнбәт, Н.* Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы / Н. Исәнбәт // Совет әдәбияты. – 1940. – № 11. – Б. 39–76; №12. № 12. – Б. 34–82.

*Исламов, Р.Ф.* Еще об одном варианте дастана «Тахир и Зухра» / Р.Ф.Исламов // Гасырлар авазы. Эхо веков. – 2005. – № 2. – С. 193–204.

*Исхакый, Г.* Әдәбият юллары / Г. Исхакый. – Казан, 1920. – Б. 3 –23.

*Корганбеков, Б.С.* «Шора батыр» эпосы: нүскалары, генезиси, тарихилыгы: монография / Б.С. Корганбеков. – Астана: Фолиант, 2014. – 304 б.

*Курманбек.* Җаныш. Байыш (эпос). – Фрунзе: Кыргызстан, 1970. – 383 с.

*Кыдырбаева, Р.Р.* Манас эпосунун варианттары / Р.Р. Кыдырбаева. – Фрунзе: Илим, 1988. – 160 с.

Лайли ва Мажнун (достон) / айтувчи – Фозил Йулдош угли. – Тошкент: «Фан» нашриёти, 1968. – 85 б.

Мәҗмугыл хикәят. Борынгы татар прозасы / Нәҗип Исмәгыйль күчермәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 446 б.

*Мәрҗани, Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) / Ш. Мәрҗани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 с.

*Мәхмүтов, Х.* Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкарьләрендә афоризмнар) / Х. Мәхмүтов. – Казан: Фикер, 2002. – 256 б.

*Миңнегулов, Х.Й.* Гасырлар өнен тыңлап... / Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Мәгариф, 2003. – 335 б.

*Миңнегулов, Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... / Х.Й. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 336 б.

*Миңнегулов, Х.Й*. Урта гасыр татар әдәбиятының фольклор белән охшашлыклары һәм уртак яклары / Х.Й. Миңнегулов // Татарская культура в контексте европейской цивилизации: материалы международной научной конференции. – Казань: Ихлас, 2010. – С. 284–285.

*Молла-Непес.* Сказание о Зохре и Тахире / Молла-Непес. – М.: Гос. изд-во худ. лит-ры, 1960.– 252 с.

*Мөхәммәтшин, З.* Фатих Халидинең иҗат мирасы / З. Мөхәммәтшин. – Казан: Таң-Заря, 2001. – 160 б.

*Навои, Алишер*. Лейла и Маджнун: соч.: в 10 томах / Алишер Нәвои. – Ташкент: Изд-во «Фан» Узбек. ССР, 1968. – Т. 5. – 207 б.

*Низами Г.* Ләйлә вә Мәҗнүн / Низами Г. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 182 б.

*Порядин, А.С.* Үрүн Үөдүйээн: саха олонхото / А.С. Порядин. – Дьокуускай: ХИФУ Издательский диэте, 2013. – 360 с.

*Равшан*. Кундуз билан Юлдуз. Икки жилдлик. Биринчи жилд / Равшан. – Тошкент: Гафур Гулом номидаги адабиет ва санъат нашриети, 1971. – 448 б.

*Рәхим, Г*. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. Икенче басма / Г. Рәхим, Г. Газиз. – Казан: Татиздат, 1925. – Б. 3–6.

*Садыйкова, А.Х.* XII–XX гасыр башы татар әдәбиятында дини фольклор / А.Х. Садыйкова. – Казан: ИЯЛИ, 2014. – 308 б.

*Саттар-Мулилле, Г* .Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге) / Г. Саттар-Мулилле. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 255 б.

*Сәгъди Г.* Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы? / Г. Сәгъди // Безнең юл. – 1923. – № 1. – Б. 31 – 47.

Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Т. 1. – 575 б.

Татар фольклоры жанрлары. – Казан: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФ АН СССР, 1978. – 139 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 408 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 3 нче китап. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 360 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 384 б.

Татар халык мәкальләре: 3 томда / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. – Казан: Татар кит. нәшр., 1959. – Т. 1. – 915 б.

Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: Татар энциклопедия институты, 2002. – 830 б.

Тохир ва Зухра: узбек халк достони (айтувчи – Зохир шоир Кучкор угли). – Тошкент: «Мухаррир» нашриёти, 2011. – 205 с.

*Тукай, Г.* Әсәрләр: 4 томда / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Т. 4. – 432 б.

*Тукай, Г.* Халык әдәбияты / Г. Тукай. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 100 б.

Узбек халк достонлари. Гулнор пари. – Тошкент: Узбекистон ССР «Фан» нашриети, 1965. – 309 б.

*Урманчеев, Ф.И.* Мәхәббәт дастаны / Ф.И. Урманчеев // Татар әдәбияты мәсьәләләре. Гыйльми язмалар. № 133. – Казан: Казан дәүләт педагогия институты, 1974. – Б. 115–135.

*Урманче, Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда / Ф. Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. – Т. 1. (А–Г). – 303 б.; 2009. – Т. 2. (Д–С). – 343 б.; 2011. – Т. 3. (С–Я). – 199 б.

*Урманче, Ф.* Татар халык иҗаты: югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек / Ф. Урманче. – Казан, 2002. – 335 б.

*Фәтхи, А.* Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә язмаларының тасвирламасы / А. Фәтхи. – Беренче бүлек. – Казан, 1960; Икенче бүлек. – Казан, 1962; Өченче бүлек. Казан, 1968.

*Фәтхи, А*. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. КДУ фәнни китапханәсенә 1959–1969 елларда кергән кулъязмаларның тасвирламасы / А. Фәтхи. – Казан, 1986. – 100 б.

*Хисамов, Н.* «Кыйссаи Йосыф» әсәренең халык версияләре / Н. Хисамов // Тезисы докладов III научной конференции молодых ученых. – Казань, 1974. – С. 12–18.

*Хисамов, Н.* «Кыйссаи Йосыф» поэмасының халык поэзиясенә тәэсире / Н. Хисамов // Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан. – Казан, 1981. – Б. 23–37.

*Хисамов, Н.* «Кыйссаи Йосыф» поэмасының халыкта яшәеше / Н. Хисамов // Казан утлары. – 1974. – № 9. – Б. 175–182.

*Хисамов, Н.* Бөек язмышлы әсәр / Н. Хисамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 336 б.

*Хисамов, Н.Ш.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» / Н.Ш. Хисамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 208 б.

*Хисмәтуллин, Х.* Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе (Дастан Бабахан» әсәренә 550 ел тулу уңае белән) / Х. Хисмәтуллин // Совет әдәбияты. – 1965. – № 7. – Б. 147–148.

Эраш Жуманбулбул угли. Узбек халк ижоди. Таржимаи хол. Равшан. Кундуз билан Юлдуз. Икки жилдлик. Биринчи жилд. – Тошкент: Гафур Гулом номидаги адабиет ва санъат нашриети, 1971. – 448 б.

*Ярми, Х.* Татар халкының поэтик иҗаты / Х. Ярми. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967.– 308 б.

*Яхин, Ф.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология / Ф. Яхин. – Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты, 2000. – 286 б.

«Koroglu» dastani (Əli Kamali arxivindəki variantlar). – Bakı: Nurlan, 2009. – 396 səh.

Resimli merakle halk hikayeleri. Tahir ile Zuhre. Yazan Selami Munir Yurdatap. – Istanbul: Bozkurt Kitabevi. Ercan matbaasi. 1960. – 48 b.

Tatar destanlari / hazilayan Prof. Dr. Fatih Urmanci. – T. 1. – Ankara: Turk Dil Kurumu. 399 s.

Tatar destanlari / hazilayan Prof. Dr. Fatih Urmanci. – T. 2. – Ankara: Turk Dil Kurumu. 447 s.

Halk kulturu ve Koroglu bilgi soleni bildirileri (2–4 Kasim 2006, Bolu). – Bolu, 2009. – 271 s.

21 Yuzyilda Koroglu ve Bolu Arastirmalari. Uluslararasi Koroglu, Bolu tarihi ve kulturu sempoziumu bildileri. 17–18 Ekim 2009. Bolu, Dortdivan / Turkiye. – Bolu. 2011. – 782 s.

## Электрон ресурслар

Азербайджанцы: историко-этнографический очерк. / URL: http://www.myazerbaijan.org/index.php?p=history/27 (дата обращени – 6. 07. 2012 г.)

*Аникеева Т.А.* Устные и книжные элементы в тюркской традиционной словесности: турецкая городская повесть: дис. ... канд. филол. наук: М., 2007. 139 с. URL: http://www.dissercat.kom/content/ustnye-i-knizhnye-elementy-v-tyrkskoi-traditsionn...(дата обращения: 04.02.2011.)

*Ахунов А.* Исламизация Волжско-Камского региона (VII–X вв.) // Татарская электронная библиотека: URL: http://kitap.net.ru/ahunov4.php?lang=tat (дата обращения – 26. 01. 2012).

*Емельянов В.* Народный ислам. URL: ethno. ru / cntnt / narodnij_i. html. (дата обращения – 4. 04. 2012)

*Гурьянов И.А.* Культурно-историческая основа эпоса о Тюште: фольклорно-литературные версии. URL: http://www.dissert.com/content/.kulturno-istorieheskaya-osnova-eposa-o tyushte-folklorno-literaturnye-versiu/...(дата обращения: 08.05.2011.)

Культура и искусство. URL: http://www.solvex.ru/article/?slug=kultura_i_iskusstvo (дата обращения: 11. 11. 2010.)

Фольклор и постфольклор: структура, типология, семиотика. URL: http://www.ruthenia. ru/folklore/program_aspir_gyalif.htm (дата обращения: 08. 06. 2011).

Эрзянь ки. Культурно-образовательный портал. URL: http://www.erzan.ru. (дата обращения: 10. 11. 2010).

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
**I бүлек. Татар халкында героик дастаннар** . . . . . . . . . . . . . . . . 34
§ 1. «Каһарман Катил» дастанында тарихи-мәдәни катламнар гармониясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
§ 2. Чура батырга багышланган эпик иҗат . . . . . . . . . . . . . . . 89
§ 3. «Күр углы» дастаны версиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
**II бүлек. Мәхәббәт дастаннары** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
§ 1. Татарларда Ләйлә белән Мәҗнүн тарихы . . . . . . . . . . . . 169
§ 2. «Таһир – Зөһрә» сюжетлы дастаннар . . . . . . . . . . . . . . . 222
**Йомгак** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Библиография . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258

Научное издание

**Мухаметзянова Лилия Хатиповна**

**ТАТАРСКИЕ ДАСТАНЫ В МИРОВОЙ ЦИВИЛИЗАЦИИ**

(на татарском языке)

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Печать офсетная. Гарнитура «Cambria».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 16,3 Уч.-изд. л. 14,8. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12